ФДББСна
туры килә

# ТУГАННАН АЛЫП МӘКТӘПКӘЧӘ





мәктәпкәчә
төп
белем бирү
программасы

ТУГАННАН АЛЫП
МӘКТӘПКӘЧӘ
ПРОГРАММАСЫ
КИТАПХАНӘСЕ

**ФДББСна**
**ТУРЫ КИЛӘ**

МӘКТӘПКӘЧӘ
ТӨП
БЕЛЕМ БИРҮ
ПРОГРАММАСЫ

# ТУГАННАН АЛЫП МӘКТӘПКӘЧӘ

Н.Е.Веракса,
Т.С.Комарова,
М.А.Васильева
**редакциясендә**

Педагогик кадрлар әзерләү өлкәсендә
белем бирү буенча УМБ тарафыннан мәктәпкәчә
төп белем бирү программасы үрнәге сыйфатында
тәкъдим ителә

МОЗАИКА-СИНТЕЗ
Москва, 2015

ХӘТЕР
Казан, 2016

ББК 74.100
УДК 373.2

*Авторлар коллективы җитәкчеләре* — психология фәннәре докторы, профессор *Н.Е. Веракса*; педагогика фәннәре докторы, профессор, РФнең атказанган фән эшлеклесе, Педагогик белем бирү халыкара академиясе академигы — *Т.С. Комарова*; Россиянең атказанган укытучысы, СССРның Мәгариф отличнигы, РСФСРның Мәгариф отличнигы — *М.А. Васильева*.

*Авторлар — Н.А. Арапова-Пискарева; К.Ю. Белая* — педагогика фәннәре кандидаты; *М.М. Борисова* — педагогика фәннәре кандидаты; *А.Н. Веракса* — психология фәннәре докторы; *Н.Е. Веракса* — психология фәннәре докторы; *Т.В. Волосовец* — педагогика фәннәре кандидаты; *В.В. Гербова* — педагогика фәннәре кандидаты; *Н.Ф. Губанова* — педагогика фәннәре кандидаты; *Н.С. Денисенкова* — психология фәннәре кандидаты; *Э.М. Дорофеева* — «Мозаика-Синтез» нәшрияты генераль директоры; *О.В. Дыбина* — педагогика фәннәре докторы; *Е.С. Евдокимова* — педагогика фәннәре кандидаты; *М.В. Жигорева* — педагогика фәннәре докторы; *М.Б. Зацепина* — педагогика фәннәре докторы; *И.Л. Кириллов* — психология фәннәре кандидаты; *Т.С. Комарова* — педагогика фәннәре докторы; *Е.Н. Кутепова* — педагогика фәннәре кандидаты; *Л.В. Куцакова* — педагог-методист; *Г.М. Лямина* — педагогика фәннәре кандидаты; *В.И. Петрова* — педагогика фәннәре докторы; *Л.Ф. Самборенко* — педагогика фәннәре кандидаты; *С.С. Славин* — Мәгарифне үстерү федераль институты өлкән фәнни хезмәткәре; *О.А. Соломенникова* — педагогика фәннәре кандидаты; *Э.Я. Степаненкова* — педагогика фәннәре кандидаты; *Т.Д. Стульник* — педагогика фәннәре кандидаты; *С.Н. Теплюк* — педагогика фәннәре кандидаты; *О.А. Шиян* — педагогика фәннәре кандидаты.

**ОТ РОЖДЕНИЯ ДО ШКОЛЫ. Основная образовательная программа дошкольного образования** / Под ред. Н.Е. Вераксы, Т.С. Комаровой, М.А. Васильевой. — 3-е изд., испр. и доп. — М.: МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2016. — 368 с.

**Рецензентлары:**

***С.М. Гаффарова*** — «Казан педагогика көллияте» Дәүләт автономияле һөнәри белем бирү оешмасы директоры урынбасары, РФнең урта һөнәри белем бирү Мактаулы хезмәткәре, ТРның атказанган укытучысы;

***Л.Ф. Җамалиева*** — филология фәннәре кандидаты, КФУның Л.Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты.

**ТУГАННАН АЛЫП МӘКТӘПКӘЧӘ. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы** / Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясендә. — Русчадан Р.И. Хәлиуллина тәрҗ. — Казан: Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшр., 2016. — 357 б.

Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясендәге «ТУГАННАН АЛЫП МӘКТӘПКӘЧӘ» мәктәпкәчә төп белем бирү программасы мәктәпкәчә учреждениеләр өчен инновацияле белем бирү программа документы булып тора, ул ватаныбызда һәм чит илләрдә мәктәпкәчә белем бирүдәге иң яңа фәнни һәм гамәли казанышларны исәпкә алып әзерләнгән.

«ТУГАННАН АЛЫП МӘКТӘПКӘЧӘ» программасы МББ ФДББС нигезендә эшләнгән (1155 нче номерлы 2013 ел 17 октябрь приказы) һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында төп белем бирү программаларын формалаштыруда куллану өчен тәкъдим ителә.

© Н.Е. Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева һ.б., 2015
ISBN 978-5-4315-0679-6
© «МОЗАИКА-СИНТЕЗ», 2015

ISBN 978-5-94113-482-3
© Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2016

# «МОЗАИКА-СИНТЕЗ» НӘШРИЯТЫ ИСЕМЕННӘН КЕРЕШ СҮЗ

2013 елның көзендә, Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты (алга таба — МББ ФДББС яисә Стандарт)[1] басылганнан соң, белгечләр арасында мәктәпкәчә мәгарифнең үрнәк программалары хакындагы мәсьәлә иң күп бәхәсләр уяткандыр, мөгаен. Аларны исәпкә алып, һәрбер мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (алга таба — МББО) үзенең белем бирү программасын эшләргә һәм язарга тиеш (алга таба — Программа).

Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт стандартында:

«1.7. Стандарт түбәндәгеләр өчен нигез булып тора:

1) Программаны эшләү;

2) мәктәпкәчә белем бирүнең **үрнәк программалары вариантларын** эшләү (алга таба — үрнәк программалар)...

2.5. Программа Оешма тарафыннан **мөстәкыйль** рәвештә шушы Стандартка яраклаштырып һәм **Үрнәк программаларны исәпкә алып** эшләнә һәм раслана...» — дип язылган.

Стандартның 2.2 пунктында исә:

«2.2. Бер Оешмага караган структур берәмлекләр (алга таба — Төркемнәр) **төрле Программаларны** гамәлгә ашыра ала», — дип укыйбыз.

Стандартта **үрнәк программаларның вариантлары** хакында сүз барса да һәм бу очракта «Үрнәк программалар» сүзтезмәсе күплек санда кулланылса да, профессиональ бергәлектә үрнәк программаларның вариативлыгын ничек гамәлгә ашыру турында даими бәхәсләр барды. Үрнәк программа берәү генә булырга тиешлеге мәсьәләсе һәрдаим куелды. Һәммәсе дә экспертлар советы төзелүне һәм үрнәк программаларның реестрын булдыруны көтте.

Бу вакыт эчендә «Туганнан алып мәктәпкәчә» мәктәпкәчә мәгарифнең белем бирү программасы МББ ФДББСна яраклы рәвештә яңадан эшләнде һәм РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының педагогик кадрлар әзерләү өлкәсендә белем бирү буенча УМБ карамагына экспертизага җибәрелде. Программага **«Мәктәпкәчә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен педагогик кадрлар әзерләү өлкәсендә белем бирү буенча УМБ тарафыннан мәктәпкәчә төп белем бирү программасы үрнәге сыйфатында тәкъдим ителә»** дигән УМБ грифы бирелде (2 нче номерлы 2014 ел 2 декабрь беркетмәсе). Шулай итеп,

[1] Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында»гы 1155 нче номерлы 2013 ел 17 октябрь приказы.

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы МББ ФДББСна туры килгәнлеген һәм үрнәк программа буларак кулланыла алуын раслады.

Шулай да, реестрга кертелгәнче, бер генә проект та Мәктәпкәчә белем бирүнең үрнәк программасы рәсми статусына ия түгел иде әле.

Ниһаять, 2015 елның 20 маенда (МББ ФДББС басылып, ел ярымнан артык вакыт узганнан соң) Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми Үрнәк төп гомуми белем бирү программалары реестрында Мәктәпкәчә белем бирүнең үрнәк төп белем бирү программасы (алга таба — ҮТББП) басылып чыкты. Әлеге Программа Россия мәгариф академиясендә гомуми белем буенча УМБнең Федераль укыту-методик берләшмәсе утырышында каралды һәм хупланды, шуннан соң Реестрда басылып чыкты. Башка бер генә мәктәпкәчә белем бирү программасы да анда каралмады һәм каралуга алынмады.

Урынлы сораулар туа: Реестрга кертелгән Үрнәк программа башка программалар белән ничек яраша, һәм МББО җитәкчеләренә мондый очракта нишләргә? Якын арада Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы әлеге мәсьәләгә рәсми ачыклык кертер дип өметләнәбез. Әмма Үрнәк программа текстына һәм МББ ФДББСна таянып, рәсми аңлатмаларга кадәр дә кайбер нәтиҗәләр ясарга мөмкин.

Беренчедән, игътибар итсәк, ҮТББП, аңа кереш өлештә язылганча, «кысалы» булып тора, анда Оешмага үзенең төп гомуми белем бирү программасын мөстәкыйль рәвештә эшләү һәм раслау өчен кирәк булган күп кенә сорауларны детальләп төшендерү юк. Шуңа күрә ҮТББПн эшләүчеләр мәктәпкәчә оешмаларга үз Программаларын төзегәндә гамәлдәге программаларның киң челтәреннән файдаланырга тәкъдим итәләр. Үрнәк программага керештә түбәндәгеләрне укыйбыз:

«**Программа** мәктәпкәчә белем бирү баскычында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар (алга таба — Оешмалар) өчен **документ булып тора, алар шуны нигез итеп алып, мөстәкыйль рәвештә** мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын **эшлиләр һәм раслыйлар.**

Үзенең оештыру-идарәчелек статусы буенча Стандарт принципларын гамәлгә ашыручы әлеге Программа модульле структурага ия.

**Үрнәк программаның кысалы характеры** мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында белем бирү процессының гомуми моделен тәкъдим итү, үсешнең яшькә бәйле нормативларын күрсәтү, белем бирү эшчәнлегенең структурасын билгеләү һәм эчтәлеген баланың биш төрле белем бирү өлкәсендә үсеш юнәлешләренә туры килә торган итеп тулыландыру аша ачыла. Белем бирү өлкәләре, белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге, белем бирү мохитен оештыру кебек үк, шул исәптән предмет тирәнлек һәм үсешкә китерүче белем бирү мохите дә Оешманың төп гомуми белем бирү программасын тәшкил итүче модульләр сыйфатында катнашалар. **Программа эчтәлеген күрсәтүнең модульле характеры мәктәпкәчә белем бирү оешмасының төп белем бирү программасын мәктәпкәчә белем**

**бирүнең гамәлдәге белем бирү программаларының киң челтәре материалларын файдаланып төзергә мөмкинлек бирә».**

Алга таба, ҮТББПна Аңлатма язуында «Программаның максатлары һәм бурычлары» дигән 1.1.1 бүлектә укыйбыз:

«Үзләренең төп белем бирү программасын эшләү буенча мөһим мәсьәләләрнең берсен хәл иткәндә, Оешмалар белем бирү программаларын сайлый һәм үз эшләрендә куллана алалар («Әдәби чыганаклар исемлеге»нең 24 нче пунктын кара), шулай ук аны төзү һәм гамәлгә кую өчен Стандартка туры килә торган кирәкле методик һәм фәнни-гамәли материалларны сайлап ала алалар».

Безнең карашка, бу бер ҮТББП шартларында мәктәпкәчә белем бирүнең вариативлыгын саклауда яхшы алым. Мәсьәләгә болай якын килгәндә, мәктәпкәчә белем бирүнең күпсанлы үрнәк программаларын реестрга кертү кирәклеге дә юкка чыга, чөнки педагоглар МББ ФДББСна туры килгән үз программалары буенча эшләүләрен дәвам итә алалар.

Шулай итеп, Реестрда басылып чыккан мәктәпкәчә белем бирүнең Үрнәк программасы кысалы булып исәпләнә һәм вариативлык принцибын хуплый. Бу мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә мәктәпкәчә төп белем бирү программасын МББ ФДББСна туры китереп, ҮТББПн исәпкә алып һәм мәктәпкәчә белем бирүнең гамәлдәге комплекслы һәм парциаль программалары нигезендә мөстәкыйль рәвештә эшләргә мөмкинлек бирә. Гамәлдәге мәктәпкәчә белем бирү программалары исемлеге белән, шул исәптән «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы белән дә, ФИРО сайтында, http://Navigator.firo.ru («Мәктәпкәчә белем бирү программалары навигаторы») электрон ресурсында танышырга мөмкин, ҮТББП шуңа таяна.

МББ ФДББС кабул ителгәннән соң, «Современное дошкольное образование» журналы сайтында (www.sdo-journal.ru) «Туганнан алып мәктәпкәчә» мәктәпкәчә белем бирү программасына карата җәмәгать тикшерүе оештырылды. «МОЗАИКА-СИНТЕЗ» һәм авторлар коллективы «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы эчтәлеге буенча барлык теләк һәм тәкъдимнәр өчен чиксез рәхмәтле. Үзегезнең фикерләрегезне һәм тәкъдимнәрегезне «МОЗАИКА-СИНТЕЗ» нәшриятына redactor@msbook.ru адресына җибәрүегезне дәвам итүегезне үтенәбез.

# ПРОГРАММАНЫҢ АВТОРЛАР КОЛЛЕКТИВЫ

## Авторлар коллективы җитәкчеләре

**Веракса Николай Евгеньевич** — психология фәннәре докторы, профессор, РДГУ ның Л.С.Выготский исем. Психология институты белем бирү психологиясе факультеты деканы, Мәскәү мәктәпкәчә белем бирү педагогия академиясе Югары һөнәри белем бирү автономияле коммерциячел булмаган оешмасы ректоры, «Современное дошкольное образование» журналының баш мөхәррире.

**Комарова Тамара Семеновна** — педагогика фәннәре докторы, профессор, РФнең атказанган фән эшлеклесе, Педагогик белем бирү Халыкара академиясе академигы, М.А.Шолохов исем. МДГУ ның башлангыч белем һәм педагогик технологияләр кафедрасы мөдире, М.А.Шолохов исем. МДГУның педагогика факультеты каршындагы «Яңа мәгариф технологияләре һәм шәхесне иҗади үстерү» фәнни-мәгариф үзәге директоры.

**Васильева Маргарита Александровна** — Россиянең атказанган укытучысы, СССРның Мәгариф отличнигы, РСФСРның Мәгариф отличнигы, «Балалар бакчасында тәрбия һәм укыту программалары»ның беренче басмасының җаваплы мөхәррире (М., 1985).

## Авторлар коллективы

**Арапова-Пискарева Наталья Александровна** («Элементар математик күзаллаулар формалаштыру»).

**Белая Ксения Юрьевна** — педагогика фәннәре кандидаты, профессор («Иминлек нигезләрен формалаштыру»).

**Борисова Марина Михайловна** — педагогика фәннәре кандидаты, доцент («Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру»).

**Веракса Александр Николаевич** — психология фәннәре докторы, доцент («Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре», «Проектлау эшчәнлеге»).

**Веракса Николай Евгеньевич** — психология фәннәре докторы, профессор («Аңлатма язуы», «Балаларның яшь үзенчәлекләре», «Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре», «Проектлау эшчәнлеге»).

**Волосовец Татьяна Владимировна** — педагогика фәннәре кандидаты, профессор («Катнаш юнәлештәге төркемнәрдә инклюзив практика оештыру һәм аның эчтәлеге»).

**Гербова Валентина Викторовна** — педагогика фәннәре кандидаты, («Сөйләм үстерү», «Матур әдәбиятка тарту», «Балаларга уку өчен якынча әдәбият исемлеге»).

**Губанова Наталья Федоровна** — педагогика фәннәре кандидаты, доцент («Уен эшчәнлеген үстерү», «Предметлы тирәлек мохитен оештыру үзенчәлекләре»).

**Денисенкова Наталья Сергеевна** — психология фәннәре кандидаты, доцент («Бала гаиләдә һәм бергәлектә», «Социаль дөнья белән таныштыру»).

**Дорофеева Әлфия Миңнемулла кызы** — «Мозаика-Синтез» нәшрияты генераль директоры (программаның структурасын төзү, «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасының аерымлык үзенчәлекләре», «Предметлы тирәлек мохитен оештыру үзенчәлекләре»).

**Дыбина Ольга Витальевна** — педагогика фәннәре докторы, профессор («Бала гаиләдә һәм бергәлектә», «Предметлы тирәлек белән таныштыру», «Социаль дөнья белән таныштыру»).

**Евдокимова Елена Сергеевна** — педагогика фәннәре кандидаты, доцент («Балалар бакчасының гаилә белән үзара багланышы»).

**Жигорева Марина Васильевна** — педагогика фәннәре докторы, профессор («ММОнда коррекцион эш (белем бирү өлкәләре буенча)»).

**Зацепина Мария Борисовна** — педагогика фәннәре докторы, профессор («Музыкаль эшчәнлек», «Мәдәни-ял эшчәнлеге», «Күңел ачулар һәм бәйрәмнәрнең якынча исемлеге»).

**Кириллов Иван Львович** — педагогика (психология) фәннәре кандидаты, доцент («Төп программаны язу буенча тәкъдимнәр»).

**Комарова Тамара Семеновна** — педагогика фәннәре докторы, профессор («Аңлатма язуы», «Сәнгатькә тарту», «Сурәтләү эшчәнлеге», «Сиземләүне үстерү», «Хезмәт тәрбиясе»).

**Кутепова Елена Николаевна** — педагогика фәннәре кандидаты («Катнаш юнәлештәге төркемнәрдә инклюзив практика оештыру һәм аның эчтәлеге»).

**Куцакова Людмила Викторовна** — педагог-методист («Конструкцияләү-модельләү эшчәнлеге»).

**Лямина Галина Михайловна** — педагогика фәннәре кандидаты («2 айдан алып 1 яшькә кадәрге балалар белән (сабыйлар төркеме) психологик-педагогик эшнең эчтәлеге», «1–2 яшьлек балалар белән (беренче кече яшьтәгеләр төркеме) психологик-педагогик эш эчтәлеге».

**Петрова Вера Ивановна** — педагогика фәннәре докторы («Социальләштерү, аралашуны үстерү, әхлакый тәрбия»).

**Самборенко Людмила Филипповна** — педагогика фәннәре кандидаты, доцент («Программаны гамәлгә ашыруның кадрлар шартлары»).

**Славин Семен Сергеевич** — («Программаны гамәлгә ашыруның финанс шартлары», «Программаны гамәлгә ашыруда финанс ягыннан тәэмин итүнең нормативлар билгеләре»).

**Соломенникова Ольга Анатольевна** — педагогика фәннәре кандидаты, доцент («Табигать дөньясы белән таныштыру»).

**Степаненкова Эмма Яковлевна** — педагогика фәннәре кандидаты («Физик культура», «Төп хәрәкәтләр, хәрәкәтле уеннар һәм күнегүләрнең якынча исемлеге»).

**Стульник Татьяна Дмитриевна** — педагогика фәннәре кандидаты, доцент («Социальләштерү, аралашуны үстерү, әхлакый тәрбия»).

**Теплюк Светлана Николаевна** — педагогика фәннәре кандидаты («2 айдан алып 1 яшькә кадәрге балалар белән (сабыйлар төркеме) психологик-педагогик эшнең эчтәлеге», «1–2 яшьлек балалар белән (беренче кече яшьтәгеләр төркеме) психологик-педагогик эш эчтәлеге»).

**Шиян Ольга Александровна** — педагогика фәннәре кандидаты («Программаны гамәлгә ашыруның психологик-педагогик шартлары»).

## Кулланылган кыскартулар исемлеге

**МББ (ДО)** — мәктәпкәчә белем бирү.

**МББО (ДОО)** — мәктәпкәчә белем бирү оешмасы.

**МКТ (ИКТ)** — мәгълүмати-коммуникацион технологияләр.

**СМЧ (ОВЗ)** — сәламәтлек мөмкинлекләре чикле.

**ТББП (ООП)** — Төп белем бирү программасы.

**Оешма** — Программа буенча мәгариф эшчәнлеген алып баручы оешма, индивидуаль эшмәкәр.

**УМК** — укыту-методик комплект.

**МББ ФДББС** — мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты (1155 нче номерлы 2013 ел 17 октябрь приказы).

# МАКСАТЛАР БҮЛЕГЕ

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

## Программаны гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы (алга таба — Программа) Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты (МББ ФДББС) нигезендә эшләнгән һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында төп белем бирү программаларын (ТББП) формалаштыруда куллану өчен тәгаенләнгән.

Программа авторлары алдындагы төп бурыч булып педагогларга укыту-тәрбия процессын ФДББС таләпләренә туры китереп оештырырга ярдәм итә һәм Үрнәк программа базасында үзләренең ТББПсын язарга мөмкинлек бирә торган программа документы эшләү тора.

Программаның төп максатлары — баланың мәктәпкәчә балачагын тулы канлы уздыру өчен уңай шартлар тудыру, шәхеснең база культурасы нигезләрен формалаштыру, яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, психик һәм физик сыйфатларны һәрьяклап үстерү, хәзерге җәмгыятьтәге тормышка әзерләү, уку эшчәнлегенә алшартлар формалаштыру, мәктәпкәчә яшьтәге баланың тормыш иминлеген тәэмин итү.

Программада баланың шәхесен үстерүгә, балаларның сәламәтлеген ныгытуга һәм саклауга, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларда патриотизм, актив тормыш позициясе, тормышта килеп туган төрле хәлләрдән чыгу юлларын таба белү, традицион кыйммәтләргә карата хөрмәт кебек сыйфатлар тәрбияләүгә аеруча игътибар бирелә.

Әлеге максатлар балалар эшчәнлегенең төрле төрләре: уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив (рәсем ясау, конструктив һ.б.), музыка белән шөгыльләнү, уку процессларында гамәлгә ашырыла.

Программаның максатларына ирешүдә түбәндәгеләр беренче дәрәҗә мөһим:

• һәрбер баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яктан үсеше турында кайгырту;

• төркемнәрдә барлык тәрбияләнүчеләргә карата аларны аралашучан, яхшы күңелле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерергә ярдәм итәрлек кешелекле һәм яхшы мөнәсәбәт булдыру;

• балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен максималь файдалану, тәрбия-белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында аларны интеграцияләү;

• тәрбия-белем бирү процессын иҗади оештыру;

• белем бирү материалын куллануның вариативлыгы, һәрбер баланың кызыксынулары һәм сәләтләренә туры китереп иҗат эшен үстерергә мөмкинлек бирү;

• балалар иҗаты нәтиҗәләренә хөрмәт белән карау;

• мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм гаилә шартларында балалар тәрбияләүгә бердәм якын килү;

• балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү эчтәлегендә акыл һәм физик яктан көч килүләрне булдырмаучы, предметлы укыту басымы ясамауны тәэмин итүче дәвамчанлыкны үтәү.

Программада билгеләнгән тәрбия максатларын һәм бурычларын хәл итү бары педагог тарафыннан баланың мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендәге беренче көннәреннән үк балалар активлыгының төрле формаларын һәм инициативаларын системалы һәм максатчан яклавы нәтиҗәсендә генә мөмкин. Бала ирешәчәк гомуми үсеш дәрәҗәсе, аңа салынган әхлакый сыйфатларның тотрыклылыгы һәрбер тәрбияченең педагогик осталыгына, аның культура дәрәҗәсенә, балаларга карата мәхәббәтенә бәйле. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре педагоглары гаилә белән берлектә, баланың сәламәтлеге һәм һәрьяклы тәрбиясе хакында кайгыртып, һәрбер баланың бәхетле балачагына омтылырга тиешләр.

## Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары

Программада белем бирүнең бала шәхесен формалаштыруны тәэмин итүче һәм педагогны аның индивидуаль үзенчәлекләренә юнәлтүче үстерү функциясе беренче планга чыга, бу балачакның мәктәпкәчә чорының үзкыйммәтен тану турындагы хәзерге фәнни «Мәктәпкәчә тәрбия концепциясе»нә (авторлары В.В. Давыдов, В.А. Петровский һ.б.) туры килә.

Программа балага карата гуманлылык һәм шәхес итеп карау мөнәсәбәтләрендә төзелгән һәм аның һәрьяклы үсешенә, рухи һәм гомумкешелек кыйммәтләрен, шулай ук сәләтләрен һәм интегратив сыйфатларын формалаштыруга юнәлтелгән.

Программада балаларның белемен катгый регламентацияләү һәм укытуда предметлы үзәкләштерү юк.

Программаны эшләгән вакытта авторлар мәктәпкәчә белем бирүнең илкүләм иң яхшы традицияләренә, аның фундаментальлегенә: балаларның тормышын саклау һәм сәламәтлеген ныгыту буенча бурычларны комплекслы хәл итүгә; һәрьяклы тәрбиягә; балалар иҗат эшчәнлегенең төрле төрләрен оештыру нигезендә үсешне баетуга (амплификацияләү) таяндылар.

Программада мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен төп әһәмияткә ия уен эшчәнлегенә аерым урын бирелә (А.Н. Леонтьев, А.В. Запорожец, Д.Б. Эльконин һ.б.).

Программа авторлары аеруча мөһим дидактик принципны — үсешкә китерүче укытуны һәм Л.С. Выготскийның дөрес оештырылган укыту үз артыннан үсешне «ияртә» дигән фәнни нигезләмәсен исәпкә алып эш иттеләр. Тәрбия һәм психик үсеш икесе аерым, бер-берсе белән бәйләнмәгән процесс буларак карала алмыйлар, әмма бу очракта «тәрбия бала үсешенең кирәкле һәм гомумкүләм формасы сыйфатында хезмәт итә» (В.В.Давыдов). Шулай итеп, Программа кысаларында үсеш балаларга тәрбия һәм белем бирүдә уңышлылыкның иң мөһим нәтиҗәсе булып тора.

Программада баланы туганнан алып мәктәпкәчә тәрбияләүнең һәм аңа белем бирүнең барлык төп эчтәлек юнәлешләре комплекслы күрсәтелә.

Программа мәдәни ярашканлык принцибына корылган. Әлеге принципны гамәлгә ашыру белем бирүдә милли кыйммәтләрне һәм традицияләрне исәпкә алуны тәэмин итә, рухи-әхлакый һәм эмоциональ тәрбия бирүдәге җитешсезлекләрдән арынырга булыша. Белем бирү баланы кешелек мәдәниятенең төп компонентларына (белем, әхлак, сәнгать, хезмәт) якынайту процессы буларак карала.

Программа материалын сайлауның төп критерие — аның тәрбияви кыйммәте, кулланылган мәдәният әсәрләренең (илебез, шулай ук чит илләр классикасы һәм халык иҗаты) югары сәнгатьлелек дәрәҗәсе, мәктәпкәчә балачакның һәрбер этабында баланың һәрьяклы сәләтләрен үстерү мөмкинлеге (Е.А. Флерина, Н.П. Сакулина, Н.А. Ветлугина, Н.С. Карпинская).

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы:

• баланың үсешенә ирешүне максат итеп куйган үсешкә китерүче белем бирү принцибына туры килә;

• фәнни нигезләнгәнлек һәм гамәлдә кулланучанлык принципларын исәпкә ала (Программаның эчтәлеге яшь чорлары психологиясе һәм мәктәпкәчә педагогиканың төп нигезләмәләренә туры килә һәм, тәҗрибәләр күрсәткәнчә, массакүләм мәктәпкәчә белем бирү практикасында уңышлы гамәлгә ашырыла ала);

• тулылык, зарурлык һәм җитешлелек критерийларына туры килә (җитәрлек күләмдә «минимум» материал кулланганда, куйган максатлар һәм бурычларны хәл итәргә мөмкинлек биреп);

• мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү процессының тәрбияви, үсеш һәм укыту максатлары һәм бурычлары бергәлеген тәэмин итә, аларны гамәлгә ашыру барышында мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсешенең нигезен тәшкил итүче сыйфатлар формалаша;

• балаларның яшь мөмкинлекләренә һәм үзенчәлекләренә, белем бирү өлкәләренең үзенчәлегенә һәм мөмкинлекләренә туры китереп, белем бирү өлкәләренең интеграциясе принцибын исәпкә алып төзелә;

• белем бирү процессын коруның комплекслы-тематик принцибына нигезләнә;

• программалы белем бирү бурычларын өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә хәл итүне турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, мәктәпкәчә белем бирүнең үзенчәлегенә туры китереп, режим моментларын уздырган вакытта да күздә тота;

• белем бирү процессын балалар белән эшләүнең яшь үзенчәлекләренә туры килгән формаларын куллану аша оештыруны күздә тота. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүнең төп формасы һәм алар эшчәнлегенең әйдәп баручы төре булып уен исәпләнә;

• төбәк үзенчәлекләренә бәйле рәвештә белем бирү процессын төрләндерүгә юл куя;

• мәктәпкәчә яшьтәге барлык төркемнәр арасында һәм балалар бакчасы белән мәктәп арасында дәвамчанлыкны саклауны исәпкә алып төзелә.

## Программага хас үзенчәлекләр

### Бала шәхесен үстерүгә юнәлгәнлек

Программаның өстенлеге — ирекле, үз-үзенә ышанган, актив тормыш позициясенә ия, тормыштагы төрле хәлләрдән чыгу юлларын табуга иҗади килергә омтылган, үз фикере булган һәм аны яклый белә торган кеше тәрбияләү.

### Программаның патриотик юнәлгәнлеге

Программада балаларда Туган илгә карата мәхәббәт, патриотик хисләр, Ватанның казанышлары белән горурлану, Россиянең героик үткәне һәм бәхетле киләчәге булган күпмилләтле бөек ил икәнлегенә ышаныч тәрбияләүгә зур игътибар бирелә.

### Әхлакый тәрбиягә, традицион кыйммәтләрне яклауга юнәлгәнлек

Ата-анага мәхәббәт, өлкәннәргә ихтирам, кечкенәләргә, олы яшьтәге кешеләргә карата кайгыртучан мөнәсәбәт кебек традицион кыйммәтләргә хөрмәт тәрбияләү; традицион гендер күзаллаулары булдыру; балаларның үз гамәлләрендә уңай үрнәккә иярү омтылышын тәрбияләү.

### Алга таба укуны дәвам итү максатын кую

Программа балаларда танып белү кызыксынучанлыгын үстерүгә, белем алу омтылышына, алга таба бөтен тормышы буена укуга (мәктәптә, институтта һ.б.) карата уңай мотивациягә; барлык кешеләргә дә белем алырга

кирәклекне аңлауга юнәлтелгән. Белем алуга карата аны иң мөһим тормыш кыйммәтләренең берсе итеп карауны формалаштыру.

### Балаларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга юнәлгәнлек

Программа тәрбиячеләр алдына куя торган төп бурычларның берсе — балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларда сәламәт яшәү рәвеше турында элементар күзаллаулар булдыру, уңай гадәтләр, шул исәптән дөрес туклану гадәте, хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ тәрбияләү.

### Баланың индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алуга юнәлгәнлек

Программа һәрбер баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән, аңа исә тормыш эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрендә дә (көндәлек режимны баланың индивидуаль үзенчәлекләренә якынайту һ.б.), бала белән үзара аралашу формаларында һәм ысулларында да (аның индивидуальлегенә карата хөрмәт, эмоциональ халәтләренә игътибарлылык, үз-үзенә ихтирамлылык хисләрен яклау һ.б. ш.) балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу хисабына ирешелә.

### Программаның структурасы үзенчәлекләре

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы структурасында иң әһәмиятлесе — материалны бирү принцибы: Программада психологик-педагогик эшнең эчтәлеге һәркайсында психологик-педагогик эшнең төп максатлары һәм бурычлары, шулай ук эчтәлеге билгеләнгән белем бирү өлкәләре буенча бәян ителә. Белем бирү өлкәләрендә психологик-педагогик эшнең эчтәлеге тематик блоклар буенча бирелә, аларда материал яшь төркемнәренә карап урнаштырылган. Программаның мондый структурасы бала сыйфатлары үсешенең вакыт арасындагы перспективасын күрергә, программа эчтәлеген сайлауга сыгылмалы якын килергә мөмкинлек бирә, вариатив өлешне кертүне гадиләштерә.

### Баланың үсеш дәрәҗәсен исәпкә алып Программа эчтәлеген сыгылмалы сайлау

Һәр тематик блокта материал яшь төркемнәре буенча тәкъдим ителә. Мәсәлән, «Социаль-коммуникатив үсеш» белем бирү өлкәсенең «Социальләштерү, аралашуны үстерү, әхлакый тәрбия» тематик блогы аерып күрсәтелә, анда психологик-педагогик эшнең эчтәлеге яшь төркемнәре буенча бүлеп бирелә. Бу мәктәпкәчә яшьтәге баланың әхлакый сыйфатларының вакыт арасындагы үсеш перспективасын күрергә мөмкинлек бирә, ул исә педагогка үз эшендә балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен тулырак исәпкә алырга, баланың яшенә бәйле тәкъдимнәргә караганда, аның индивидуаль үсеш дәрәҗәсенә таянып бурычлар билгеләргә ярдәм итә.

### Барлык яшь чорларын колачлау (туганнан алып мәктәпкәчә)

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасының өстенлекләренә, һичшиксез, аның балаларның физик һәм психик үсешенең барлык яшь чорларын колачлавын кертергә кирәк: сабыйлык яшендәгеләр (2 айдан 1 яшькә кадәр: сабыйлар төркеме); кече яшьтәгеләр (1 яшьтән 3 яшькә кадәр: беренче һәм икенче кече яшьтәгеләр төркеме); мәктәпкәчә яшьтәгеләр (3 яшьтән алып, мәктәпкәчә яшьтәгеләр: кечкенәләр, уртанчылар, зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемнәре).

Биредә туганнан алып 2 яшькә кадәрге балаларның яшь үзгәлегенә һәм үсеш үзенчәлекләренә карап сабыйлар һәм беренче кече яшьтәгеләр төркеме бүлекләре структур яктан башка бүлекләрдән (2 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар өчен) аерылып тора. Әлеге аерма бу яшь категориясендәге балаларны карау, тәрбияләү һәм өйрәтү процессларын аерып карау авырлыгыннан килеп туа.

### Вариатив өлешне кертүнең гадилеге

Программаның эчтәлеген тематик блоклар буенча бәян итү ТББПн язганда вариатив өлешне (белем бирү процессында катнашучылар формалаштыра торган өлеш) җиңел формалаштырырга мөмкинлек бирә — белем бирү оешмасының төрләре төрлелеген, өстенлекле юнәлешләрне исәпкә алырга, төбәк компонентын кертергә һ.б. Аерым алганда, мәгариф оешмасы бер яки берничә мәгънәви блокны парциаль һәм авторлык программалары белән алыштырырга яисә бу бүлекләрнең эчтәлеген мөстәкыйль рәвештә яңадан язарга мөмкин. Бердәнбер таләп — вариатив өлеш ФДББСна туры килергә һәм «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы максатларына һәм бурычларына каршы килмәскә тиеш.

### Уен эшчәнлеген үстерү буенча аерым бүлек булу

Гамәлдәге МББ ФДББСнда уен эшчәнлеге бер генә белем бирү өлкәсенә дә кертелмәгән иде. Бу мәктәпкәчә яшьтә уенның әйдәп баручы эшчәнлек булуы һәм аерым бер өлкәдә генә түгел, ә тулаем психологик-педагогик эштә катнашырга тиешлеге белән аңлатыла. Мәктәпкәчә яшьтәге баланың уен эшчәнлеген үстерүнең аеруча мөһимлеген таныган хәлдә, авторлар Программаны уенга багышланган кушымта белән тулыландырдылар. Кушымтада һәрбер яшькә туры килгән уен эшчәнлеген үстерү буенча психологик-педагогик эшнең эчтәлеге ачыклана, бу педагогка уен эшчәнлегенең барлык аспектларын алгарышлы үсештә комплекслы күрергә мөмкинлек бирә.

### Тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән үзара багланыш

Программа гаиләнең уникаль тәрбия институты буларак кыйммәтен һәм тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән җаваплы һәм тыгыз мөнәсәбәтләр булдыру кирәклеген ассызыклый. «Балалар бакчасының гаилә белән багланышы» бүлегендә тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары белән төп эшләү формалары тасвирлана, аларны куллану педагогларга мәктәпкәчә белем бирүнең гомуми мәгариф программасын уңышлы гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә.

Бала белән өйдә шөгыльләнү өчен кулланмалар — «Җиде Гном мәктәбе» сериясеннән китаплар белән тәэмин ителү Программаның мөһим өстенлеге булып тора.

### Программаның технологиялелеге

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасының зур өстенлеге — аның технологиялелеге һәм массакүләм практикада уңышлы кулланылуы. Программаны гамәлгә ашыру өчен нинди дә булса аерым шартлар, стандарт булмаган матди-техник яктан тәэмин ителеш яки махсус әзерлекле педагогик кадрлар таләп ителми. Программа мәктәпкәчә оешманың, ул гамәлдәге дәүләт стандартларына һәм таләпләренә җавап биргән шартта, яшәп килгән матди-техник базасында, тиешле дәүләт таләпләренә туры килгән квалификациягә ия педагоглар тарафыннан гамәлгә ашырыла ала.

### Киңәйтелгән исемлекле кушымта булу

Программаның хәзерге басмасында барлык үрнәк исемлекләр Кушымтага кертелгән. Бу Программаның эчтәлек өлешен сизелерлек кыскарта һәм аны кабул итүне җиңеләйтә. Моннан тыш Программаны шул рәвешчә кору үрнәк исемлекләрнең эчтәлеге балаларның яшенә карап ничек үзгәргәнен күрергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, хәзер балаларның һәр яшь төркемендә нәрсә укырга тәкъдим ителүне күрү һәм анализлау җиңеләя.

## Программаның эчтәлеген камилләштерү һәм үстерү буенча эш перспективалары

«МОЗАИКА-СИНТЕЗ» нәшриятында Программа авторлары һәм МББ ФДББСн эшләүчеләр катнашында МББ ФДББСн кабул итүгә бәйле рәвештә «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасына һәм аның мисалында МББ ФДББСн кертүгә карата тулы УМКн әзерләү буенча проектлау-тикшеренү төркеме оештырылды.

Проектлау-тикшеренү төркеменең бурычларына «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы базасында МББ ФДББСн кертүне методик һәм оештыру ягыннан, кадрлар белән һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү буенча эш алып бару керә.

## МББ ФДББСн кертүне методик һәм оештыру ягыннан тәэмин итү

1. МББ ФДББСн кертү процессын «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы мисалында мәгълүмати, фәнни-методик рәвештә, экспертлар катнашында алып бару.

2. «Туганнан алып мәктәпкәчә» мәктәпкәчә белем бирү программасына тулы УМКн МББ ФДББСна туры китереп эшләү.

3. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы мисалында МББ ФДББСн кертү өчен РФ субъектларында «Пилот мәйданчыклары»н билгеләү.

4. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы мисалында МББ ФДББСн кертү буенча төбәк эш төркемнәрен булдыру.

5. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы мисалында МББ ФДББС нигезендә Мәктәпкәчә белем бирүнең Төп гомуми белем бирү программасын язу буенча методик тәкъдимнәр эшләү.

6. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы мисалында МББ ФДББСн гамәлгә ашыру шартлары мониторингын оештыру.

7. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы мисалында МББ ФДББСн гамәлгә ашыру шартларында гражданнарның бердәй мөмкин һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алу хокукларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү мониторингын оештыру.

8. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы нигезендә ТББП гамәлгә ашыручы белем бирү оешмалары учредительләре өчен, МББ ФДББС таләпләренә туры китереп предмет-тирәлек мохитен оештырырга кирәкле җиһазлар исемлеге турында методик тәкъдимнәр эшләү.

## МББ ФДББСн кертүне кадрлар белән тәэмин итү

1. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы буенча эшләүче мәктәпкәчә оешмалар җитәкчеләре һәм педагогик хезмәткәрләре өчен квалификация күтәрү программалары эшләү һәм этаплы рәвештә квалификация күтәрүне тәэмин итү.

2. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы белән эшләүче мәктәпкәчә оешмалар педагогик хезмәткәрләренә аттестация үткәрү буенча методик тәкъдимнәр эшләү.

3. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы базасында МББ ФДББСн гамәлгә ашыруны бергә алып бару буенча тьюторлар әзерләү өчен стажировка мәйданчыклары эшен оештыру.

4. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы базасында МББ ФДББСн кертү буенча ресурс үзәкләрен һәм стажировка мәйданчыкларын методик яктан тәэмин итү.

5. Гаиләне психологик-педагогик яклауны тәэмин итү һәм ата-аналарның үсеш һәм белем бирү, балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту мәсьәләләрендә компетентлыгын арттыру өчен чаралар системасын эшләү, шул исәптән ата-аналар өчен һәм өй шартларында мәктәпкәчә белем бирү-

не оештыру өчен китаплар һәм кулланмалар әзерләү; педагогик хезмәткәрләргә тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән нәтиҗәле үзара багланышлар буенча методик тәкъдимнәр эшләү; ата-аналар өчен белем бирү курслары һәм консультацияләре оештыру.

### МББ ФДББСн кертүне мәгълүмати яктан тәэмин итү

1. Россия Федерациясе субъектларында МББ ФДББСн гамәлгә ашыру буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыру.

2. МББ ФДББСн гамәлгә ашыру барышы турында массакүләм мәгълүмат чараларында язмалар бастыру.

3. МББ ФДББСн апробацияләү буенча мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең үзара бәйләнешләр челтәрен булдыру.

# ПРОГРАММАНЫ ҮЗЛӘШТЕРҮНЕҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ

## Максат ориентирлары

Мәктәпкәчә балачакның үзгәлеге (бала үсешенең сыгылмалылыгы, аның үсеш вариантларының төрлелеге, аның табигыйлеге һәм нәрсәгә дә булса бәйле булуы) мәктәпкәчә яшьтәге баладан конкрет белем бирү нәтиҗәләренә ирешүне таләп итәргә мөмкинлек бирми һәм мәгариф программасын үзләштерү нәтиҗәләрен максат ориентирлары рәвешендә билгеләү зарурлыгын шарт итеп куя.

Мәктәпкәчә белем бирүнең ФДББСнда күрсәтелгән максат ориентирларын баланың ирешергә мөмкин булган казанышларының социаль-норматив сыйфатламалары буларак карарга кирәк. Бу — педагоглар һәм ата-аналар өчен өлкәннәрнең тәрбия эшчәнлегенең юнәлешен билгеләүче ориентир.

МББ ФДББСнда билгеләнгән максат ориентирлары Россия Федерациясенең бөтен мәгариф пространствосы өчен уртак булып тора.

Шулай итеп, «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы ориентирлары МББ ФДББСна һәм «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасына аңлатма язуында билгеләнгән максатларга һәм бурычларга нигезләнә, аларның Стандартлар белән туры килгән өлеше МББ ФДББС текстлары буенча бирелә. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасында, Стандарттагы кебек үк, максат ориентирлары кече яшьтәге балалар өчен (мәктәпкәчә яшькә күчү этабында) һәм мәктәпкәчә яшьтәге зурлар төркемендәге балалар өчен (мәктәпкәчә белем бирүне төгәлләү этабында) тәгаенләнә.

### Сабыйлык чорында һәм кече яшьтә белем бирүнең максат ориентирлары

• Бала әйләнә-тирә предметлар белән кызыксына һәм алар белән актив эшли; уенчыклар һәм башка предметлар белән эмоциональ эш итүгә тартыла, үз хәрәкәтләре нәтиҗәсендә нәрсәгәдер ирешүдә үзсүзлелек күрсәтергә омтыла.

• Предметларга карата махсус үзләштерелгән гамәлләр куллана, көнкүреш предметларының (кашык, тарак, карандаш һ.б.) кулланылышын белә һәм алардан файдалана ала. Үз-үзенә хезмәт күрсәтүнең иң гади күнекмәләренә ия; көнкүрештә һәм уенда мөстәкыйль булырга омтыла; пөхтәлек күнекмәләрен күрсәтә.

• Дорфалыкка, саранлыкка карата тискәре мөнәсәбәт белдерә.

• Элементар әдәплелек кагыйдәләрен үти (мөстәкыйль яисә искә төшереп, «рәхмәт», «исәнмесез», «хушыгыз», «хәерле төн» (гаиләдә, төркемдә) дип әйтә; бакчада, өйдә, урамда элементар үз-үзен тоту кагыйдәләре турында беренчел күзаллауларга ия һәм аларны үтәргә тырыша.

• Аралашуда актив сөйләмгә ия; сораулар һәм үтенечләр белән мөрәҗәгать итә ала, зурлар сөйләмен аңлый; әйләнә-тирәдәге предметлар һәм уенчыкларның исемнәрен белә. Сөйләм башка балалар белән аралашуда тулы канлы чарага әверелә.

• Зурлар белән аралашырга омтыла, һәм хәрәкәтләрдә, һәм гамәлләрдә актив рәвештә аларга охшарга тырыша; бала зурлар гамәлләрен кабатлап күрсәтә торган уеннар барлыкка килә. Зурлар тәкъдим иткән уенга эмоциональ тартыла, уен кагыйдәләрен кабул итә.

• Яшьтәшләре белән кызыксына; аларның эш-гамәлләрен күзәтә һәм аларга охшарга тырыша. Яшьтәшләре белән аларга комачауламый гына янәшә уйный белә. Зур булмаган төркемнәр белән уртак уеннарга карата кызыксыну күрсәтә.

• Әйләнә-тирә табигать дөньясы белән кызыксына, ел фасылларына кагылышлы күзәтүләрдә кызыксынып катнаша.

• Шигырьләргә, җырларга һәм әкиятләргә, рәсемнәр карауга кызыксыну белдерә, музыка тавышына хәрәкәтләр ясарга омтыла; төрле мәдәният һәм сәнгать әсәрләренә эмоциональ мөнәсәбәтен белдерә.

• Курчак театры геройлары гамәлләрен аңлап күзәтә; театральләштерелгән һәм сюжетлы-рольле уеннарда катнашырга теләк белдерә.

• Продуктив эшчәнлек белән (рәсем ясау, әвәләү, конструкцияләү, аппликация) кызыксына.

• Балага эре моторика хас, ул төрле төрдәге хәрәкәтләрне үзләштерергә омтыла (йөгерү, үрмәләү, атлап чыгу һ.б.). Гади эчтәлекле, катлаулы булмаган хәрәкәтле уеннарда кызыксынып катнаша.

## Мәктәпкәчә белем бирүне тәгәлләү этабында максат ориентирлары

• Бала төп мәдәни чараларны, эшчәнлек ысулларын үзләштерә, эшчәнлекнең төрле төрләрендә — уенда, аралашуда, танып белү-тикшеренү эшчәнлегендә, конструкцияләүдә һ.б да инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәтә; үзенә шөгыль төрен, уртак эшчәнлек буенча катнашучыларны сайлап алырга сәләтле.

• Бала дөньяга, хезмәтнең төрле төрләренә, башка кешеләргә һәм үз-үзенә карата уңай мөнәсәбәткә ия, аңа үзенең урынын белү хас; яшьтәшләре һәм зурлар белән актив аралаша, уртак уеннарда катнаша.

• Килешүләргә, башкаларның ихтыяҗлары һәм хисләре белән исәпләшергә, аларның уңышсызлыкларын бүлешергә һәм уңышларына сөенергә сәләтле, үз хисләрен, шул исәптән үзенә ышаныч хисен дөрес белдерә, каршылыкларны чишәргә тырыша. Төрле мәсьәләләр буенча үз позициясен аңлатырга һәм якларга сәләтле.

• Уртак эшчәнлектә хезмәттәшлеккә һәм лидерлык, һәм башкару функцияләрен дә үтәргә сәләтле.

• Барлык кешеләрнең дә, социаль чыгышлары, нинди этник төркемгә керүләренә, дини һәм башка инануларына, физик һәм психик үзенчәлекләренә карамастан, тигез икәнен аңлый.

• Башка кешеләргә карата эмпатиягә ия, мохтаҗларга ярдәмгә килергә әзер тора.

• Башкаларны тыңлый белә һәм башкаларның да үзен аңлауларына омтыла.

• Баланың хыялга бирелүе үсешкә ирешкән, ул эшчәнлекнең төрле төрләрендә, һәм барыннан да элек уенда, гамәлгә ашырыла; уенның төрле формаларын һәм төрләрен уйный белә, шартлы һәм чынбарлыктагы хәлләрне аера ала; төрле кагыйдәләрне һәм социаль нормаларны үтәргә сәләтле. Килеп туган төрле хәлләрне тотып ала һәм аларны дөрес бәяли белә.

• Бала сөйләм теленә шактый оста, үзенең уйларын һәм теләкләрен белдерә, сөйләмне үзенең уйларын, хисләрен һәм теләкләрен аңлату өчен, аралашу вакытында сөйләм тезмәләре төзү, сүзләрдә авазларны аерып карау өчен куллана ала, балада грамоталылыкның алшартлары формалаша.

• Балада эре һәм вак моторика үскән; ул хәрәкәтчән, түзем, төп хәрәкәтләрне ясый белә, үз хәрәкәтләрен тикшерә һәм алар белән идарә итә ала.

• Бала ихтыяр көчен җыярга сәләтле, эшчәнлекнең төрле төрләре вакытында социаль тәртип нормаларын һәм кагыйдәләрен үти ала, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләрдә иминлекне саклау тәртибе кагыйдәләрен һәм шәхси гигиена күнекмәләрен үти ала.

• Башланган эш өчен җаваплылык сизә.

• Кызыксынучанлык күрсәтә, өлкәннәргә һәм яшьтәшләренә сораулар бирә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре белән кызыксына, табигать күренешләренә һәм кешеләр кылган гамәлләргә карата мөстәкыйль рәвештә аңлатмалар табарга тырыша; күзәтергә, экспериментлар ясарга һәвәс. Үзе турында, табигый һәм үзе яшәгән социаль дөнья турында башлангыч белемнәргә ия, балалар әдәбияты әсәрләре белән таныш, тере табигать, табигать белеме, математика, тарих һ.б. өлкәләр буенча элементар күзаллаулары бар; эшчәнлекнең төрле төрләре буенча, үзенең белем һәм күнекмәләренә таянып, карарлар кабул итүгә сәләтле.

• Яңалыкны кабул итәргә әзер, ягъни белем алуга, алга таба мәктәптә, институтта укуга карата уңай мотивациягә омтылыш күрсәтә.

• Тормышка (аның төрле формаларында) хөрмәт белән карый һәм әйләнә-тирә мохит турында кайгырта.

• Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгына, халык сәнгате һәм профессиональ сәнгать әсәрләренә (музыкага, биюгә, театраль эшчәнлеккә, рәссамлык эшчәнлегенә һ.б.ш.) эмоциональ бәя бирә.

• Патриотик хисләр кичерә, үз иле, аның казанышлары белән горурлана, аның географик төрлелеге, күпмилләтлелеге, иң мөһим тарихи вакыйгалары хакында күзаллаулары бар.

• Үзе, гаилә, традицион гендер юнәлешләрен дә эченә алган традицион гаилә кыйммәтләре хакында беренчел күзаллауларга ия, үз җенесенә һәм капма-каршы җенескә карата ихтирамлы.

• Гомуми кабул ителгән элементар нормаларны үти, «нәрсә яхшы, нәрсә начар» булуы турында беренчел күзаллауларга ия, яхшы гамәлләр кылырга омтыла; өлкәннәрне хөрмәт итә һәм кечкенәләр турында кайгырта.

• Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллауларга ия. Сәламәт яшәү рәвешен кыйммәт буларак кабул итә.

## Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләрен бәяләү системасы

МББ ФДББС белән ярашлы рәвештә максат ориентирлары турыдан-туры, шул исәптән педагогик диагностика (мониторинг) рәвешендә дә, бәяләүгә алынмый һәм аларны балаларның реаль казанышлары белән формаль чагыштыру өчен нигез була алмый. Алар балаларның әзерлегенә һәм белем бирү эшчәнлегенә карата кабул ителгән таләпләргә туры килә торган объектив бәяләмәнең асылы булып тормый. Программаны үзләштерү арадаш аттестацияләр һәм тәрбияләнүчеләрнең йомгаклау аттестациясен уздыру белән кушылып китми.

МББнең ФДББСннан күренгәнчә, максат ориентирлары идарә итү бурычларын хәл иткәндә турыдан-туры нигез була алмыйлар. Әлеге бурычларга түбәндәгеләр кирә:

• педагогик кадрларны аттестацияләү;

• белем бирүнең сыйфатын бәяләү;

• балаларның соңгы, шулай ук арадаш үсеш дәрәҗәсен, шул исәптән мониторинг кысаларында бәяләү (шул исәптән күзәтүгә яисә балаларның нәтиҗәгә ирешүен тикшерүнең башка ысулларына нигезләнгән методлар кулланып тестлар уздыру формасында);

• максат ориентирларын биремне үтәүнең сыйфат күрсәткечен кертү ярдәмендә муниципаль (дәүләт) биремнәренең башкарылуын бәяләү;

• оешма хезмәткәрләре хезмәтенә түләүнең стимуллаштыручы фондын билгеләү.

Әмма педагог үз эше барышында һәрбер баланың индивидуаль үсеш траекториясен булдырырга тиеш. Моның өчен педагогка үз эшен бәяләүнең балалар белән иң уңайлы рәвештә үзара бәйләнеш булдырырга ярдәм итүче инструментарие кирәк.

Тәкъдим ителгән Программаны үзләштерү нәтиҗәләрен бәяләү системасында мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфатын бәяләүне аңлауның үзгәрүе белән бәйле заманча тенденцияләр чагылыш таба.

Беренче чиратта, игътибарны әкренләп объектив (тестлар уздыру) якын килүдән аутентик бәяләү ягына күчерү турында сүз бара. Тамырлары белән стандартлаштырылган тест традицияләренә китеп, объектив якын килү кысаларында тикшеренүләр махсус бурычларны хәл итү барышында балалар-

дагы аерымлыкларны (еш кына җитешсезлекләрне) билгеләүгә юнәлтелгән иде. Әлеге тестлар килеп чыккан нәтиҗәләрне норма белән чагыштырырга мөмкинлек тудыра, шуның белән һәрбер баланың үз яшьтәшләре белән чагыштырганда үсеше турында мәгълүмат бирә. Шунлыктан мондый тестлар педагогик хәвефлелек төркеменә керергә тиешле балаларны ачыклауда киң кулланыла.

Әлеге ысулның төп җитешсезлеге шунда: ясалма биремнәр еш кына балаларның көндәлек тормышыннан шактый ерак, шуңа күрә алар мәктәпкәчә яшьтәге балаларның реаль мөмкинлекләрен тулысынча чагылдыра алмыйлар. Тест ысулы балаларның социаль даирәсе үзенчәлекләрен исәпкә алмый, һәм аның нәтиҗәләренә корылган фаразлар да шактый шартлы.

Аутентик бәяләүнең нигезендә түбәндәге принциплар ята.

Беренчедән, асылда ул махсус биремнәрне үтәү нәтиҗәсенә түгел, баланың реаль тәртибен анализлауга карап корыла. Мәгълүмат турыдан-туры баланың тәртибен күзәтү ярдәмендә туплана. Күзәтү нәтиҗәләрен педагог гадәти тестларда куллана торган, мәктәпкәчә яшьтәге баланың реаль тормышына кагылышы аз булган уйлап чыгарылган ситуацияләрдә түгел, табигый мохиттә (уеннар вакытында, режим моментлары барышында, дәресләрдә) таба.

Икенчедән, әгәр тестларны махсус өйрәтелгән профессиональ белгечләр (психологлар, медицина хезмәткәрләре һ.б.) уздырса, аутентик бәяне исә бала белән озак вакыт булган, аның тәртибен яхшы белгән өлкәннәр куя ала. Бу очракта педагог тәҗрибәсе бәяләп бетергесез.

Өченчедән, аутентик бәя югары дәрәҗәдә структурлашкан.

Ниһаять, әгәр тестлар ярдәмендә бәя кую очрагында ата-аналар алынган мәгълүматларның мәгънәсен һәрвакытта да аңлап бетермәсәләр һәм шуңа да еш кына балаларга тест уздыруга тискәре мөнәсәбәт күрсәтсәләр, аутентик бәяләү вакытында җаваплар аларга аңлаешлы. Ата-аналар теге яисә бу сорауга җавап эзләгәндә педагогның партнерлары булып китәргә мөмкин.

## Педагогик диагностика

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасын гамәлгә ашыру балаларның индивидуаль үсешен бәяләүне күздә тота. Мондый бәяләү педагогик хезмәткәр тарафыннан педагогик диагностика (мәктәпкәчә яшьтәге балаларның индивидуаль үсешенә педагогик гамәлләрнең нәтиҗәлелеген бәяләү белән бәйле һәм аларны алга таба планлаштыруның нигезендә ятучы бәя бирү) кысаларында уздырыла.

Педагогик диагностика балаларның гадәти һәм махсус оештырылган эшчәнлектә активлыгын күзәтү барышында үткәрелә. Педагогик диагностика өчен инструментарий — балалар үсешен күзәтү карталары, алар һәрбер баланың индивидуаль динамикасын һәм үсеш перспективаларын түбәндәгеләр барышында билгеләргә мөмкинлек бирә:

• яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашулар (контакт урнаштыру һәм аны дәвам итү, уртак карарлар кабул итү, каршылыкларны хәл итү, лидерлык һ.б. ысуллары ничек үзгәрә);

• уен эшчәнлеге;

• танып белү эшчәнлеге (балаларның сәләтләре, танып белү активлыгы үсеше ничек бара);

• проект эшчәнлеге (балаларның инициативалылыгы, җаваплылыгы һәм автономиясе үсеше ничек бара, үз эшчәнлеген планлаштыру һәм оештыру күнекмәсе ничек үсә);

• сәнгати эшчәнлек;

• физик эшчәнлек.

Педагогик диагностика нәтиҗәләре фәкать түбәндәге белем бирү бурычларын хәл итү өчен кулланыла ала:

1) белем бирүне индивидуальләштерү (шул исәптән балага булышлык күрсәтү, аның белем бирү траекториясен булдыру яисә аның үсеш үзенчәлекләренә профессиональ төзәтмә кертү);

2) балалар төркеме белән эшне оптимальләштерү.

Белем бирү эшчәнлеге барышында балаларның индивидуаль динамикасын бәяләү һәм үз гамәлләренә төзәтмә кертү өчен педагоглар диагностик ситуацияләр булдырырга тиеш.

Һәрбер баланың индивидуаль үсеш траекториясен булдыру тәкъдимнәре белән барлык яшь төркемнәре буенча балалар үсешен күзәтү карталары «МОЗАИКА-СИНТЕЗ» нәшриятында басмага әзерләнә.

# ЭЧТӘЛЕК БҮЛЕГЕ

# 2 АЙДАН 1 ЯШЬКӘ КАДӘРГЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ПСИХОЛОГИК-ПЕДАГОГИК ЭШ ЭЧТӘЛЕГЕ

(сабыйлар төркеме)

Россия Федерациясенең «Мәгариф турында» Законы буенча мәктәпкәчә учреждениеләргә балалар 2 айдан башлап кабул ителә. Шулай да авторлар Программада материалны бала туганнан башлап урнаштыруны зарури дип саныйлар. Бу сабыйлык яше үзгәлеген тулырак ачу мөмкинлеген бирә.

Туганнан 2 яшькә кадәрге сабыйларның яшь үзгәлеге һәм үсеш үзенчәлекләре булу сәбәпле, сабыйлар төркеме һәм кече яшьтәгеләрнең беренче төркеме бүлекләре структур яктан мәктәпкәчә төркемнәр бүлекләреннән аерылып тора. Бу аерымлык әлеге яшь категориясенә кергән балаларны карау, тәрбияләү һәм өйрәтү процессларын бүлү кыенлыгы белән бәйле. Шуңа күрә Программаның кече яшьтәгеләр буенча барлык материалы аерым бүлеккә аерып бирелә.

## Тәрбия һәм өйрәтү бурычлары

Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларның сыйфатлы физик үсешен тәэмин итү.

Һәр баланың эмоциональ уңай халәтен саклауга булышу.

Үз вакытында гомуми хәрәкәтләр һәм кул хәрәкәтләре формалашуга, шуышырга һәм йөрергә өйрәнүгә ярдәм итү. Баланың талчыгуын булдырмау.

Күрү һәм ишетү юнәлешләрен формалаштыру. Сиземләү тәҗрибәсен баету.

Өлкән кешенең сүзләрен аңлау сәләтен үстерү һәм актив сөйләмгә ирешүгә әзерләү.

Балаларның үз-үзләренә хезмәт күрсәтү процессына керешү омтылышларын хуплау.

Балаларның үзара татулыгына, якын кешеләренә карата аерым дустанә мөнәсәбәтенә булышлык итү.

Уенчыкларга, рәсемнәргә, музыкага, җырлауга карата кызыксыну уяту; баланың гади бию хәрәкәтләре башкарудагы активлыгына булышлык итү.

Һәр баланың үз яшенә туры килгән сәләтләрне үзләштерүенә актив ярдәм итү, алынган нәтиҗәләрне системалы рәвештә һәм дөрес анализлау.

## Режим процесслары барышында тәрбия

Режим процессларына карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру, режимны бозмау, гаиләдә һәм Программа буенча белем бирү эшчәнлеге белән шөгыльләнүче оешмада шартлар даимилеген һәм балаларга карата таләпләр берлеген саклау.

Бер режим буенча яшәүче балаларны йокыдан уянуга карап ашату.

Балаларда киендерүгә, ашатуга, яткыруга карата уңай мөнәсәбәт булдыру. Сабыйларны бу процессларда хәлләреннән килгәнчә катнашуга җәлеп итү.

**Йокы.** Тирән һәм дәвамлы йокы өчен шартлар булдыру.

Балалар верандада яки ачык тәрәзәле йокы бүлмәсендә, башка яшьтәгеләр төркеме бу вакытта уяу булган бүлмәдән аерым урында йокларга тиеш.

Авырудан соң җайлашу чорында балаларны саф һавада йоклауга акрынлап күнектерергә кирәк.

**Уяулык халәте.** Һәр бала өчен: 2 айлык вакыттан — манежда, 7–8 айлык вакыттан идәндә барьер артында актив уяулык өчен шартлар булдыру.

Уен-шөгыльләр процессында максатчан өйрәтү.

Баланың актив рәвештә өлкән кешегә мөрәҗәгать итүенә, шулай ук мөстәкыйль рәвештә мәшгуль булуына омтылу.

Балаларның эмоциональ уңай халәтен саклауга булышу, тискәре гадәтләрне (бармак суыру, чайкалу һ.б.) булдырмау.

Кирәкле күнекмәләрне үзләштерү өчен һәр балага төрле уенчыклар тәкъдим итү. Балаларның яшь һәм индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, үз вакытында уен материалын яңарту һәм катлауландыру.

Балаларны мөстәкыйль гамәлләргә һәм хәрәкәтләргә, актив тел-аваз эшчәнлегенә җәлеп итү.

Балаларның активлыгына булышлык итү өчен эшчәнлек төрләрен үзгәртү. Балалар озак вакыт хәрәкәтсез тормасын, бер-берсенә комачауламасыннар өчен күз-колак булу.

Балалар өстенлек биргән уенчыклар белән уйнау урыннары оештыру.

Һәр бала өлкәннәр, үз сүзләрен ишетсен, башка балаларның тавышларына (гүләүгә, бытылдауга) колак салсын, актив сөйләшсен өчен төркемдә тыныч халәт булдыру.

Төркемдәге тәртипкә күз-колак булу, системалы рәвештә уенчыкларны эшкәртү.

Массаж һәм гимнастика белгеч тарафыннан башкарылырга тиеш.

**Ашату.** Тиешле өлешне ашау гадәтен формалаштыру. Балаларның ризыкка сайланулы мөнәсәбәтен исәпкә алу.

Мөстәкыйль гамәлләргә: 2,2–3 айлык вакыттан — ашау вакытында шешәне тотып торырга, аны алырга һәм авыз янына китерергә; 4–5 айлык вакыттан — кашыктан ярым сыек ризык ашарга; 5–6 айлык вакыттан — өлкән кеше кулындагы чынаяктан эчәргә; 7 айдан — ипи ашарга, аны кулда тотарга өйрәтү.

12 айга җиткәндә өстәлдән чынаякны алу, аны тотып мөстәкыйль эчү күнекмәсе формалаштыру.

7–8 айга кадәр баланы, ул кулларда яртылаш яткан хәлдә, 8 айдан (бала мөстәкыйль утырырга өйрәнгәч) — биек өстәл артына утыртып ашату. 11–12 айга җиткәндә баланы мөстәкыйль рәвештә тәбәнәк өстәл янына килергә, кәнәфигә утырырга өйрәтү.

Балаларда өлкән кешенең «Хәзер ашыйбыз» дигән сүзләренә карата уңай мөнәсәбәт булдыру. Өстәлгә куелган кайбер предметларның исемнәре (чынаяк, тәлинкә, кашык) белән таныштыру, гамәлләрне (утыр, эч, ипи аша һ.б.) аңлау сәләте формалаштыру.

Баланың сөйләмен активлаштыру (әм-әм, бир, мә һ.б.).

8 айдан, чиратлап, 2–3 кашык ризык биреп, берьюлы өстәл артында утыручы ике баланы ашату, янәшә утырган балага дустанә мөнәсәбәттә булырга, аңа комачауламаска өйрәтү. 8–9 айдан кул тастымалыннан (салфеткадан) файдаланырга өйрәтү.

Ашаганнан соң өлкән кешегә ияк кагу рәвешендә яки гади генә сүз (аваз) белән рәхмәт әйтү гадәтен тәрбияләү.

**Йокыга әзерләү, яткыру, торгызу.** Балаларны йокларга яткырганда аларда бу процесска карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру. Йокыга теләк булдыру, әкрен генә бишек җыры җырлау һ.б.

Һәр баланың индивидуаль үзенчәлекләрен (озаграк йокларга тиешле балаларны иң элек яткыру һәм соңрак торгызу, талчыккан сабыйны иртәрәк яткыру) исәпкә алу. Яңарак кына төркемгә кабул ителгән балаларга аерым игътибар бирү.

Тормышның беренче атналарыннан ук өстәмә тәэсирләрдән (тибрәтү, имезлек бирү һ.б.) башка йоклап китәргә гадәтләндерү.

Балаларны уянуларына карап торгызу. Аларның эмоциональ уңай халәтен тәэмин итү (өлкәннәрнең салмак гамәлләре, сәламләү).

Киенү эзлеклелеген үтәү.

Актив рәвештә тавыш белән җавап бирүгә (бытылдау, җиңелчә авазлар) теләк уяту.

Өлкәннәр аяк, өс киемнәре предметларын атаганда аларның сүзләрен аңлау сәләтен үстерү; балаларны кайбер гамәлләрне башкаруга (кул күтәрергә, колготканы бирергә) һәм өлкәннәр артыннан аерым сүзләрне кабатлауга җәлеп итү.

**Гигиена процедураларын уздыру.** Су процедураларына карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру. Баланың игътибарын куллар чисталыгына юнәлтү; битне һәм кулларны — пычрангач, ашау алдыннан юу.

Баланы көн саен яки көнаралаш (6 айдан соң) коендыру (төнге йокы алдыннан).

Су процедураларын башкарган вакытта өлкән кешенең сүзләрен аңлауны формалаштыру.

Су процедуралары (юыну, коену һ.б.) процессында баланың сүзләрен һәм хәрәкәтләрен хуплау.

**Чүлмәккә утырту.** 7–8 айлык балаларда чүлмәккә утыру теләген формалаштыру. Әгәр дә асты коры хәлдә уянса, баланы уянуга ук, шулай ук ашаганнан соң 10–15 минут узгач утыртырга.

Баланың физиологик хаҗәт үтәү теләге турында белдерергә теләү омтылышларын — авазларын, бытылдавын, үз-үзен тотышын хуплау, уңай нәтиҗә булганда мактау.

Билгеле бер урында һәм индивидуаль чүлмәккә утырту.

Чисталыкның иң гади күнекмәләренә өйрәтү. Чиста киемдә йөрү ихтыяҗын тәрбияләү.

## Уен-дәресләрдә тәрбияләү

Балада махсус өйрәтүдән башка барлыкка килмәүче сәләтләр формалаштыру (предметлар белән гамәлләр үстерү, кабул итү сәләтен камилләштерү һ.б.).

Мөстәкыйль рәвештә уйнаучы башка сабыйлар тыныч һәм мәшгуль булган шартларда уяулык халәте вакытында индивидуаль уен-дәресләр үткәрү.

2 айдан 8–9 айга кадәрге балалар белән уен-дәресләр — манежда яки барьер артында идәндә, 8–9 айдан өстәл артында яки төркем бүлмәсендә үткәрелә.

Индивидуаль уен-дәресләрнең дәвамлылыгы — 2–3 минут, төркем (төркемчә) уен-дәресләренеке — 5–7 минут. Берничә бала (5–7 кеше) белән берьюлы аларның тирәлектә беренчел элементар юнәлешләр запасы, шулай ук тою-сизү сәләтләре тупланганнан соң (якынча 5–6 айдан) гына шөгыльләнергә ярый. Төркемнәрне балаларның үсеш дәрәҗәсен, аларның индивидуаль аерымлыкларын исәпкә алып формалаштыру.

Яшьтәшләренә карата дустанә мөнәсәбәт, үзара татулык, өлкән кеше хәрәкәт итәргә тәкъдим иткәнче бераз сабыр итү гадәте тәрбияләү.

Өлкән кешенең турыдан-туры балага һәм барлык балаларга карата әйтелгән сүзләрен тыңлау һәм аңлау сәләте үстерү.

Кушылган эшне үтәргә тырышу, ирешелгән нәтиҗәләргә шатлану омтылышларын мактап җибәрү.

## Аңга кабул итүне үстерү

**Туганнан алып 2–3 айга кадәр**

Әкрен генә хәрәкәтләнүче уенчык артыннан туктап-туктап күзли алуына ирешү (10–15 көн).

Баланың карашын элеп куелган уенчыкка, аның белән ягымлы сөйләшүче өлкән кеше йөзенә төби белүен формалаштыру (20 көн тулганда).

Балада беренче елмаю уяту (1 ай тулганда).

Әкрен генә хәрәкәтләнүче уенчык артыннан эзлекле күзли белүен үстерүгә булышлык итү (1 ай).

Баланың карашын өлкән кеше йөзенә төбәү сәләтен формалаштыру (баланы вертикаль хәлдә тоткан килеш (1 ай тулганда)).

Сөйләшүче һәм салмак кына манеж тирәли хәрәкәтләнүче өлкән кеше артыннан күзләү (2 ай тулганда), аның тавышына, әкрен генә җырлавына, якындагы даирәдәге төрле авазларга колак салу сәләтен уяту. Балада «җанлану комплексы» (ачык итеп елмаю, гүләү һ.б.) тудыру.

Баланың аңга кабул итү үсешен мобиль чаралар ярдәмендә стимуллаштыру.

**2–3 айдан 5–6 айга кадәр**

Балаларның күрү һәм ишетү реакцияләрен ныгыту һәм баету.

Аваз чыганагын (сөйләшүче өлкән кеше, тавыш чыгаручы уенчык һ.б.) караш белән, башны борып эзләп табу омтылышларын хуплау.

Төрле халәттә (җилкәдә, корсакта ятканда; өлкән кешенең кулларында булган килеш) хәрәкәтләнүче объектлар артыннан күзләү һәм карашны хәрәкәтсез предметларда туплый белү сәләтен камилләштерү.

Әнисен, тәрбиячене күргәндә эмоциональ җавап бирә, шатлана белү сәләтен формалаштыру (4 ай тулганда).

Таныш өлкән кеше сөйләшенең төрле (ягымлы, шат, кырыс) интонацияләренә карата эмоциональ җавап бирә белү сәләтен үстерү.

Күрү, ишетү, ориентлашу реакцияләре тәэсирендә балада яңа сәләтләр: түбән эленгән уенчыкка таба өтелү, аны эләктереп алу, капшау омтылышлары формалашуга булышлык итү (3 ай тулганда).

Бала максатчан рәвештә уенчыкка үрелгән, аны эләктереп алган һәм тотып торган, аның белән уйнаган вакытта күрү-куллар моторикасы координациясен үстерү (4 ай тулганда).

**5–6 айдан 9–10 айга кадәр**

Баланың аңга кабул итүен күрү, ишетү, сиземләү аша баету. Аның игътибарына төрле формадагы (түгәрәк, овал, турыпочмаклык), төрле материалдан эшләнгән (йомшак, каты һ.б.) предметлар тәкъдим итү.

Төсле буяулар белән бизәлгән уенчыкларны, матур савыт-сабаны, чәчәк атучы үсемлекләрне һ.б. эстетик яктан аңга кабул итүенә булышлык итү.

Куллар координациясен үстерү. Теләсә нинди халәттән (яннан, баш өстеннән) уенчыкны алу һәм тотып тору, уенчыкка, предметка кадәр үрелү

(шуышырга, йөрергә әзерләнү) сәләтен формалаштыруга булышлык итү. Уен-күңел ачулар оештыру.

**9–10 айдан 12 айга кадәр**

Сиземләү тәҗрибәсен баетуны дәвам итү. Күрү, ишетү һәм тою, сиземләүне камилләштерү.

Барабан, сыбызгы тавышын тыңларга, төрле материаллардан эшләнгән предметларны сыйпарга, кыскаларга тәкъдим итү.

Балада шарның тәгәрәвен, аның түгәрәк чокырга төшеп китүен, шакмак өстенә башка шакмакны куеп булуны һ.б. аңлау сәләте формалаштыру.

Балалар төркеме белән уен-дәресләр. Өлкән кеше «сөйләштергән» яки «сөйләшүче» уенчыклар («Гаҗәеп капчык») тәкъдим итү, уен-күңел ачулар («Кулларны чәбәкләү», «Качышлы» һ.б.) уздыру.

## Сөйләм үстерү

**Туганнан алып 2–3 айга кадәр**

Өлкән кешенең бала белән эмоциональ аралашуын хуплау.

Өлкән кешенең ягымлы эндәшүенә колак сала белүне үстерү; беренче бугаз авазлары чыгартуга ирешү.

**2–3 айдан 5–6 айга кадәр**

Сөйләмне аңлау нигезе буларак, ишетү һәм күрү элемтәләре формалашуга булышлык итү.

Балада аның белән сөйләшүче өлкән кешенең төрле интонацияләренә колак салырга теләк уяту.

Актив сөйләмнең алшартларын формалаштыру. Аралашу процессында балада тавыш реакцияләре: 4–5 айлык вакытта — аһәңле сузыклар (гуләү), 5–6 айлык вакытта аерым иҗекләр (бә, мә, пә) булдыру һәм үстерү. Балага ияреп авазларны, аерым иҗекләрне әйтү, балада аларны кабатларга теләк уяту. Артикуляция аппаратын камилләштерүгә булышлык итү.

**5–6 айдан 9–10 айга кадәр**

Өлкән кешенең сөйләвен аңлау, ул әйткән авазларны, сүзләрне игътибар белән тыңлый белү сәләтен үстерү. Предмет һәм аны белдерүче сүз арасындагы элемтәне билгеләргә ярдәм итү. Өлкән кеше сүзе буенча баланың карашы белән якын кешесен («Әни кайда?»), һәрвакыт бер урында булган предметларны («Сәгать кайда?») эзләп табу омтылышларын хуплау, мактау. 8–9 айдан балаларда бүлмәнең төрле урыннарында булган предметларны эзләү теләге уяту.

Актив сөйләм алшартларын үстерүне дәвам итү.

Өлкән кешегә ияреп таныш иҗекләрне әйтү (9 ай тулганда), өлкән кешенең төрле интонацияләренә охшату сәләтен формалаштыру.

Балаларның үз инициативасы буенча өлкәннәр белән бергә «Кәҗәкәҗә», «Саескан», «Качышлы» һ.б. уен-күңел ачуларда катнашу омты-

лышларын үстерү һәм аларга булышлык итү; һәр баланың эмоциональ уңай халәтен саклауга булышу.

Балалар төркеме белән уен-дәресләр. Балаларда таныш уенчыклар белән хәрәкәтләр башкару теләге уяту: курчак килә — *туп-туп-туп,* бии — *әллә-лә-лиллә-лә*, китеп бара — *сау бул, исән бул*. Сюжетлы таныш уенчык белән хәрәкәтләр ясап күрсәтеп, балаларның аерым авазлар тезмәсенә охшату теләген хуплау: *һау-һау* — эт өрә, *әм-әм* — эт ашый.

Борып хәрәкәтләндерә торган уенчык күрсәтеп, уен-күңел ачулар вакытында («Киттек-киттек» һ.б.) балаларның сөйләм күренешләрен (авазлар, аваз тезмәләре, бытылдау) активлаштыру.

Балаларның кәефе яхшы булуга, аларның яшьтәшләренә карата дустанә мөнәсәбәтенә булышлык итү.

**9–10 айдан 12 айга кадәр**

Тирәлектә ориентлашуны киңәйтү. Өлкән кешенең сөйләвен аңлау, үз исемен белү, исеме белән эндәшүгә җавап бирү сәләтен формалаштыру (9 ай). Предметны бүлмәнең төрле урыннарыннан эзләп табу; билгеле бер уенчыкны башка уенчыклардан аерып алу (9 айдан); гади биремнәрне («Курчакны тап», «Этне ашат») үтәү; бер үк сүзнең төрле билгеләр буенча бер-берсеннән аерылып торган предметларны (төрле күлмәкләр кигән курчаклар, төрле зурлыктагы этләр һ.б.) аңлатуына төшенү сәләтен ныгыту (11–12 ай тулганда).

Бер үк шөгыльне төрле уенчыклар белән башкару (курчакны, аю баласын, куянны йокларга яткыру һ.б.).

Рәсемдәге таныш предметны танып алу, аны җиңелчә сүз белән атау сәләтен формалаштыру.

«Ярый» — «ярамый», «яхшы» — «начар» сүзләренең мәгънәләрен аңлау, үз гәүдәсенең төп өлешләрен һәм курчак гәүдәсенең өлешләрен күрсәтә белү сәләтен формалаштыру.

Актив сөйләм үстерүне дәвам итү. Яңа сүзләргә охшатып әйтергә (10 ай), таныш предметларның һәм гамәлләрнең аталышын аңлатучы җиңелчә сүзләрне (эт — *һау-һау,* йоклый — *бәү-бәү*) һәм беренче тулы сүзләрне *(әни, әти, абый, әби* һ.б.*)* кулланырга өйрәтү.

**Балалар төркеме белән уен-дәресләр.** Сюжетлы уенчыклар күрсәтүне, тере объектларны (песи баласы, чеби) күзәтүне оештыру. Балаларда әйткәнне үтәү теләген уяту («Тупларны алыгыз!» һ.б.).

Өлкәннәргә һәм балаларга карата дустанә мөнәсәбәт ныгуга булышлык итү, тере объектны кабул итүдән шатлык кичерүгә ирешү.

Уенчыкларга һәм предметларга карата эстетик мөнәсәбәт алшартлары формалаштыру.

## Хәрәкәтләрне үстерү

**Туганнан алып 2–3 айга кадәр**

Корсакка яткырганда һәм өлкән кеше кулларында вертикаль хәлдә булганда башны тотарга өйрәтү (3 көннән).

Аяк терәген ныгыту өчен, башын тоткан баланың каты өслектән аяклары белән этелүенә ирешү (сабыйны вертикаль хәлдә култык асларыннан тоткан килеш).

**2–3 айдан 5–6 айга кадәр**

Шартларга карап, өлкән кешенең бала белән эшлекле аралашуын формалаштыру.

Кул чугы үсешен, уенчыкларны эләктереп алу (4 ай), уенчыкны төрле торышта килеш алу һәм озак вакыт аның белән уйнау сәләтен стимуллаштыру.

Баланың үз гәүдәсе торышын үзгәртү: ян-якка (4 ай), аркадан корсакка (5 ай), корсактан аркага (6 ай) борыла белүен формалаштыру.

Турайтылган кулларның учларына таянып озак вакыт корсакта яту сәләтен ныгыту.

Үрмәләргә әзерләүче хәрәкәтләрне үстерү.

Аяклар терәген үстерү (баланы вертикаль хәлдә култык асларыннан тоткан килеш). Аяклар белән каты өслеккә терәлү сәләтен формалаштыру (5 ай).

Тигезлек саклауга күнектерү (сабыйны горизонталь һәм вертикаль хәлдә салмак кына тирбәтү рәвешендә).

**5–6 айдан 9–10 айга кадәр**

Куллар хәрәкәтенең алга таба үсешен, предметлар белән эш итүне, мөстәкыйль үрмәләүне стимуллаштыру (7 ай тулганда).

Үрмәләргә өйрәтү (баланы үз янына чакырып һәм уенчык белән җәлеп итеп, 6 айдан). Сабыйның 7 ай тулганда актив һәм озаклап үрмәли алуына омтылу.

Баланың куллары белән берәр терәккә тотынып мөстәкыйль рәвештә яткан хәлдән чүгәләргә, аннан соң утырырга, торырга, иелергә омтылышына булышу (8 ай тулганда).

Киртәгә (барьерга) куллар белән тотынып, аны атлап чыгу, бер предметтан икенчесенә күчү омтылышы үстерүгә ярдәм итү (9 ай).

Баланың таучыкка үрмәләп менү һәм аннан төшү (8 ай), баскыч култыксасына тотынып баскычтан таучыкка күтәрелү (10 ай), үрмәләп менеп бүрәнә аша чыгу, дидактик тартмалар эченә керү омтылышларына булышу (8–9 айдан).

Тигезлек саклауга күнектерү (утырганда, баскан хәлдә, атлап чыкканда).

**Балалар төркеме белән уен-дәресләр.** Күнегүләр ясау (үрмәләү, атлап чыгу) өчен балаларны бергә туплау. Төрле зурлыктагы туплар, зур күләмле сюжетлы һәм музыкаль уенчыклар куллану.

**9–10 айдан 12 айга кадәр**

Элек үзләштергән кул хәрәкәтләрен һәм гомуми хәрәкәтләрне камилләштерү.

Предметларга тотынып йөрү, бер предметтан икенчесенә күчү; ике кулга тотынып йөрү, баскычтан тыныч кына таучыкка менү һәм аннан төшү, чүгәләү, биек булмаган предметлар өстенә менү, иркенләп торып басу һәм иелү күнекмәләрен формалаштыру (10–11 ай тулганда).

**Балалар төркеме белән уен-дәресләр.** Балаларның йөрү, тирәлектә ориентлашу сәләтен ныгыту («Тавышы буенча тап (песине)», «Таучыктан уенчыкны үрелеп ал», «Тәгәрәгән шарларны җый», «Этне куып җит» һ.б. уеннар).

Уртак хәрәкәтләрдән канәгать булу, иптәшләре өчен шатлану хисен хуплау һәм ныгыту.

## Предметлар белән гамәлләр башкаруны үстерү

**Туганнан алып 2–3 айга кадәр**

Баланың куллары белән түбән эленгән уенчыкларга кагылып алу һәм аларны тоту омтылышларына булышлык итү (2 айдан).

Түбән эленгән уенчыкны ике кул белән эләктереп алу һәм капшау сәләтен үстерү (4 ай тулганда).

**2–3 айдан 5–6 айга кадәр**

Балага аның күкрәге турысына эленгән уенчыкны эләктереп алырга, капшарга, уенчык белән хәрәкәтләр ясарга булышу (4 айдан).

Төрле торышта (аркада, корсакта яткан, өлкән кешенең кулларында булган хәлдә) өлкән кеше кулыннан уенчык алу, уенчыкны бер кулдан икенчесенә күчерү сәләтен формалаштыру (6 ай).

**5–6 айдан 9–10 айга кадәр**

Башта өлкән кешенең күрсәтүе һәм әйтүе, соңыннан аның әйтүе буенча гына балада төрле гамәлләр башкару: шалтыравык шакылдату, туп тәгәрәтү, тартмадан предметлар алу һәм аларны тартмага салу (6–7 айдан), уенчыкны бер кулдан икенчесенә күчерү сәләтен формалаштыру (6 ай).

Предметларның үзлекләренә карап алар белән гамәлләр башкару: резина уенчыкларның тавышына колак салып, аларны кысу, туплар тәгәрәтү, вак предметларны савыттан, кечкенә чиләктән алу һәм аларны кире тутыру күнекмәләрен үстерү өчен шартлар тудыру (9–10 ай тулганда).

Кулларның вак хәрәкәтләрен (моторикасын) үстерү. Балаларда каптырмаларны ычкындыру, чөйдән боҗраларны алу, тартмаларны ачу күнекмәләрен формалаштыру (өлкән кеше гамәлләре мисалында).

Кечкенә тупларны кулга алырга, кармак җебенә тезелгән эре муенсаны, зур төймәләрне бөртекләп барлап чыгарга тәкъдим итеп, бармакларның хәрәкәтен үстерү. «Саескан», «Бармак-малай» һ.б. уеннар оештыру.

**Балалар төркемчәсе белән уен-дәресләр.** Туплар (төрле якка һәм өлкән кешегә таба), улак буенча шарлар тәгәрәтү һ.б. оештыру.

**9–10 айдан 12 айга кадәр**

Предметлар белән гамәлләр башкарганда мөстәкыйль рәвештә билгеле бер нәтиҗәгә ирешүгә булышлык итү: эче куыш бер предметны икенчесе эченә урнаштыру, тартмаларны ачу һәм ябу, чөйгә боҗралар тезү һәм боҗраларны аннан алу, шакмак өстенә шакмак кую, гөмбәчекләрне махсус өстәлдәге тишекләргә урнаштыру.

Дидактик тартма белән уеннар оештыру.

Сюжетлы уенчыклар белән охшатып кабатлауга корылган беренче уен гамәлләрен: «Тирбәт, ашат, бие» хәрәкәтләрен башкару күнекмәләрен формалаштыру.

Вак хәрәкәтләрне үстерү: баланы вертикаль һәм горизонталь хәлгә куелган чөйләргә кертеп тезелгән шарчыкларны тәгәрәтергә һәм күчерергә өйрәтү һ.б.

**Балалар төркемчәсе белән уен-дәресләр.** Шушы ук биремнәр балалар төркемчәсе белән уен-дәресләр өчен тәкъдим ителә.

## Музыкаль тәрбия[1]

Балаларның музыкаль сәләтләрен үстерү.

Музыканы кабул итүне үстерүгә булышлык итү.

Ишетү игътибарлылыгын үстерү; өлкән кешеләрнең җырлавын һәм инструменталь музыка яңгыравын эмоциональ кабул итүгә ирешү.

Өлкәннәрнең җырлавына, бию хәрәкәтләренә карата кызыксыну формалаштыру, шулай ук аерым иҗекләр белән кушылып җырлау һәм музыка астында хәрәкәтләр ясау вакытында кулларны чәбәкләү, биештергәләү, шалтыравык, яулык, шар болгау аша балаларның активлыгы ачылуга булышлык итү.

**Туганнан алып 2–3 айга кадәр**

Балада ишетү сәләтен туплауга ирешү, тавыш чыганагын (шалтыравык, кыңгырау, тавыш тартмачыгы, җырлаучы өлкән кеше) эзләп табу теләген уяту.

Тавышка колак салу, аңа уңай һәм эмоциональ җавап кайтара белү сыйфаты (елмаю, гүләү һ.б.) формалашуга булышлык итү.

**2–3 айдан 5–6 айга кадәр**

Музыканы кабул итүне үстерү, олы кешеләрнең җырлавына һәм музыкаль инструментлар яңгырашына карата игътибар туплау күнекмәсе формалаштыру.

[1] Музыкаль репертуар үрнәге Кушымтада тәкъдим ителә.

Күңелле һәм тыныч көйләрне эмоциональ кабул итүгә ирешү. Өлкәннәр җырлавында «катнашуны» (кул һәм аяк хәрәкәтләре, аерым авазларны әйтү һ.б.) хуплау. Бию көе яңгыраганда шатлыклы җанлану уяту.

Өлкән кеше булышлыгында кулларны бераз күтәрү һәм төшерү, чүгәләү; мөстәкыйль рәвештә шалтыравык, кыңгырау, шөлдер чыңлату, барабан кагу сәләтен формалаштыру.

**5–6 айдан 9–10 айга кадәр**

Вокаль һәм инструменталь музыканы тыңлауга тарту. Төрле музыка коралларында (курай, авыз гармуны, металлофон һ.б.) уйналган күңелле, тиз, моңсу, тыныч, талгын көйләрне эмоциональ уңай җавап бирүгә булышлык итү.

Өлкән кешенең җырлавына, музыка яңгыравына уңай реакция формалаштыру. Авазларны сузып әйтүне һәм иҗекләр белән кушылып җырлауны стимуллаштыру. Бию көйләрен кабул итүдә активлык күрсәтүгә булышлык итү.

Өлкәннәр ярдәмендә түбәндәге гамәлләрне башкару сәләтен үстерү: кулларны чәбәкләү, тыпырдау һәм җиңелчә чүгәләү, аякларны бөгү һәм турайту, тавышлы инструментлардан авазлар чыгару.

**9–10 айдан 12 айга кадәр**

Вокаль һәм инструменталь музыканы кабул итүдән канәгатьлек хисе туугa булышлык итү. Контраст характердагы (күңелле — тыныч, тиз — талгын) музыкага эмоциональ җавап кайтару формалаштыру. Металлофон, флейта, балалар пианиносы һ.б. яңгырауга кызыксыну уяту.

Өлкән кешенең аерым җыр интонацияләренә (а-а-а...) охшату, өлкәннәрнең җырлау-уен гамәлләренә («Курчак бии», «Саескан», «Качышлы») җавап кайтару, ике контраст (талгын һәм тиз) өлештән торган бию характерындагы музыканы төрлечә кабул итү теләге уяту. Балаларда актив һәм мөстәкыйль рәвештә кулларны чәбәкләүгә, кулларны болгауга, тыпырдауга, биештергәләүгә, шөлдергә сугуга, уенчык рояль белән уйнауга теләк булдыру.

## Уен-дәресләр

Балага мәхәббәт һәм игътибар күрсәтү. Аның белән аралашу; уйнау, күңелен ачу, әйләнә-тирәне танып белүгә өйрәтү. Өлкән кеше тавышының интонацияләренә, музыка авазларына игътибарын җәлеп итү.

Баланың аның өчен аңлаешлы классик һәм халык музыкасын ешрак тыңлавына омтылу.

Балаларда шатлык, җанлану уянуга булышлык итүче халык уеннары, уенчыклар белән уеннар («Качышлы», «Кәҗә-кәҗә», «Саескан», «Аю баласы бии», «Кош сайрый», «Куян йоклый» һ.б.) оештыру. Яраткан уенчыкларны кулланып

күңел ачу, такмак-такмаза, җырлар җырлау тамашалары оештыру, А. Барто шигырьләрен («Уенчыклар» циклыннан) сәхнәләштерү.

Музыкаль уенчыклар — өчпочмак, сыбызгылар, музыкаль чүкеч, шарманка һ.б. белән уеннарга җәлеп итү. Халык уенчыкларына, механик һәм борып хәрәкәтләндерелә торган уенчыкларга карата кызыксыну формалаштыру, алар белән уйнаудан күңелдә шатлык уяту.

# 1–2 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАР БЕЛӘН ПСИХОЛОГИК-ПЕДАГОГИК ЭШ ЭЧТӘЛЕГЕ
(Беренче кече яшьтәгеләр төркеме)

## Тәрбия һәм өйрәтү бурычлары

Балаларның сәламәтлеген ныгытуны, аларны чыныктыруны, хәрәкәтләрнең төп төрләрен үстерүне дәвам итү. Хәрәкәт активлыгы үсешенә ярдәм итүче шартлар тудыру. Балаларның талчыгуын булдырмау.

Режим процессларында мөстәкыйльлекнең, пөхтәлекнең, җыйнаклыкның иң гади күнекмәләрен формалаштыру.

Балаларның якын тирәлектә ориентлашуын киңәйтү, аңлашыла торган сүзләр запасын һәм актив сүзлекне тулыландыру, сүзләр белән аралашу ихтыяҗын үстерү. Предметларның, гамәлләрнең аталышын белдерүче сүзләрне аңлау сәләтен формалаштыру.

Гади җөмләләрне, кечерәк хикәяләрне аңлау сәләтен формалаштыру. Үз ихтыяҗларын һәм теләкләрен сүзләр, соңрак кыска җөмләләр белән аңлату, өлкән кешеләрнең сорауларына җавап бирү сәләте формалашуга булышлык итү.

Тирәлектәге мохитне һәм бала белән аралашуны аның аңга кабул итү сәләтен, фикерләвен, игътибарын, хәтерен үстерү өчен файдалану.

Уенчыкларның, якын-тирәдәге предметларның үзенчәлекләренә һәм кулланылышларына карап алар белән гамәлләр башкару; өлкән кешенең уен гамәлләренә охшату, ияргү уенында таныш тормыш халәтләрен чагылдыру.

Уеннарның барлык төрләрендә балаларның танып белү һәм хәрәкәт активлыгын үстерү.

Үз-үзеңне тоту культурасының исәнләшү, саубуллашу, рәхмәт белдерү күнекмәләрен формалаштыру. Баланың яшьтәшләренә карата дустанә мөнәсәбәтен хуплау, аларда бер-берсенең исемнәрен хәтердә калдыру теләген уяту. Ярдәмчеллек һәм теләктәшлек хисе тудыру.

Үсемлекләргә һәм хайваннарга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

Эстетик кабул итү сәләтен үстерү.

Балаларның игътибарын кискен контраст предметларның исләренә, авазларына, формасына, төсенә җәлеп итү.

Рәсемнәр, иллюстрацияләр карау сәләте формалаштыру.

Музыкага карата кызыксыну үстерү, әсәрне тыңлаганда шатлыклы халәт булуны саклау. Баланың музыкаль тәэсирләрен киңәйтү, музыкаль тоем тәҗрибәсен баету. Музыка һәм хәрәкәтләрнең үзара бәйлелеген аңлауны үстерү. Өлкән кешенең җырлау интонациясенә охшату омтылышы тудыру, музыка астында иң гади ритмик хәрәкәтләр ясау теләге уяту.

Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеген хуплау. Предметлы-уен эшчәнлегендә балаларга гамәлләрнең дөрес ысулларын күрсәтү, танып белү активлыгына булышлык итү, мөстәкыйльлеккә һәм төрле дидактик материаллар белән тәҗрибә үткәрүгә теләк уяту.

Төрле сюжетлы уенчыклар белән уйнау гамәлләре, алмаш предметларны файдалану сәләте формалаштыру.

Яшьтәшләренә комачауламыйча уйнарга өйрәтү.

Бергә уйнау, үз теләкләреңне тыеп кала белү сыйфаты формалаштыру. Сорап алу, көтеп тора белү сыйфатлары формалаштыру.

## Режим процесслары барышында тәрбия

Режим процесслары (ашату, йокларга яткыру, йокыдан торгызу, йөреп керергә әзерләнү һәм кайту, гигиена процедуралары уздыру) уяулык халәтенең шактый өлешен били. Балалар сабыр гына өйрәтүгә һәм өлкән кешенең турыдан-туры ярдәменә мохтаҗ.

**Культура-гигиена күнекмәләре һәм үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләре тәрбияләү.** Балаларның мөстәкыйльлеккә омтылышына булышлык итү. Һәр баланы режим процессына кертүнең эзлеклелек принцибын үтәү. (Өстәл янына мөстәкыйль ашый белмәгән 2–3 баланы гына утырту. Башкалар бу вакытта уйный бирәләр. Һәм алга таба шулай дәвам итәлә.)

Беренче төркемчәдәге балаларны ашау алдыннан һәм пычрануга карап аларның, һичшиксез, кулларын юуларына гадәтләндерү. Сабыйларны кашык белән куе ризык ашарга, 1 яшь 6 ай тулганда аш ашарга да өйрәтү. Төрле ризык ашарга, тастымалдан (салфеткадан) файдаланырга (өлкән кеше ярдәме белән), ашаганнан соң өлкәннәргә рәхмәт белдерергә (булдыра алганча) өйрәтү.

Икенче төркемчәдәге балаларны ашау алдыннан һәм пычрануга карап кулларын юарга, шәхси сөлгедән файдаланырга, өлкән кешенең өлешчә ярдәме белән тиешле өлешне ашарга өйрәтүне дәвам итү. Тастымалдан (салфеткадан) файдалану, ашаганнан соң өлкәннәргә рәхмәт белдерү, урындыкны кире урынына этеп куя белү күнекмәләрен ныгыту.

Балаларның һавада йөрү һәм йокы белән бәйле процессларда актив катнашуына булышлык итү. 1 яшь 7 ай тулганда өлкән кешенең беркадәр ярдәме белән чишенергә (баш киемен, киез итекләрне, рейтузны, чишелгән туфлиләрне, шортыны һәм колготкины салу) гадәтләндерү. 2 яшь тулганда

өлкән кеше контролендә аерым гамәлләр башкару: билгеле бер тәртиптә саналган өс һәм аяк киемнәрен салу һәм кию.

**Балаларны пөхтәлеккә һәм җыйнаклыкка өйрәтү.** 2 яшь тулганда өлкән кеше ярдәме белән кулъяулыктан файдаланырга, өс киемен, кыяфәтен-чәчләрен тәртипкә китерергә, җыйнак итеп һәм билгеле бер тәртиптә өс киемен төреп куярга, аяк киемен урынына куярга өйрәтү. Әйберләргә карата сакчыл мөнәсәбәттә булырга өйрәтү. Балаларның игътибарын төркемдәге тәртипкә юнәлтү.

Баланың үзенең физиологик хаҗәтләрен үтәүне тәртипкә салу күнекмәсен булдыруга ярдәм итү (2 яшь тулганда).

Үз-үзен тоту культурасының элементар күнекмәләрен тәрбияләү. Үз-үзен тотуның нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килгән күнекмәләрен ныгыту: өстәл янында үз-үзен тиешенчә тоту; төркемдә тыныч кына сөйләшү, йокы бүлмәсендә шауламау; өлкән кешенең сүзен тыңлау, аның күрсәтмәләрен үтәү, аның сорау-мөрәҗәгатьләренә җавап бирү. Төркемдә һәм участокта — тәрбиячегә, өй шартларында гаилә әгъзаларына, күршеләргә хәлдән килгәнчә ярдәм итү теләге формалаштыру.

Балаларны «яхшы», «начар», «ярамый», «ярый», «кирәк» сүзләрен аңларга һәм шул сүзләрнең мәгънәсенә ярашлы хәлдә гамәлләр кылырга өйрәтүне дәвам итү; сәламләргә, саубуллашырга, рәхмәт белдерергә өйрәтү.

Янәшәдә уйнаучы иптәшенә игътибар итү, аның хәлен аңлау, елаучыны кызгану сәләтен формалаштыру. Яшьтәшенә комачауламаска, уенчыкларны тартып алмаска, алар белән уртаклашырга, көтеп тора белергә өйрәтү.

Барлык тереклеккә карата сакчыл мөнәсәбәт: чәчәкләрне һәм яфракларны өзмәү, газоннарны таптап йөрмәү, хайваннарны кыерсытмау, аларга мәрхәмәтле булу, аларны яклау кебек сыйфатлар формалаштыру. Әйләнә-тирәгә карата уңай мөнәсәбәт гамәли рәвештә булырга тиеш: балаларны үсемлекләргә су сибәргә, хайваннарны һәм кошларны ашатырга өйрәтергә кирәк.

**Әйләнә-тирә мохиттә ориентлашуны киңәйтү.** Төркемдә (алгы бүлмәдә, йокы бүлмәсендә) иркен ориентлашу сәләте формалаштыру. Төркем бүлмәләренең урнашуы, шәхси әйберләрне саклау урыннары, баланың өстәл янындагы урыны белән таныштыру. Өйдән балалар мәйданчыгына илтүче юл белән таныштыру.

**Сөйләмне аңлауны үстерү.** Беренче төркемчәдәге балаларда аңлаешлы сүзләр: еш кулланылучы предметларның (сабын, кулъяулык, тарак һ.б.), көнкүрештәге иң гади гамәлләр (чишенү, юыну һ.б.), гәүдә өлешләренең аталышлары запасын киңәйтү.

Икенче төркемчәдәге балаларда кулланыштагы предметларны, аларның кирәклеген, төсен, зурлыгын, урынын (биек, түбән, тәбәнәк) белдерүче сүзләрне аңлау сәләтен ныгыту. Балаларга олы кеше әйтүе буенча башкарылучы гамәлләрнең эзлеклелеген (сабын алу, кулларны сабынлап юу, кулларны сөртү һ.б.) хәтердә калдырырга булышу.

**Актив сөйләмне үстерү.** Беренче төркемчәдәге балаларда аваз составы буенча гади сүзләрне, ике сүздән торучы гыйбарәләрне («миңа бир», «мә» һ.б.) әйтү сәләте үстерү.

Икенче төркемчәдәге балаларда җиңелләштерелгән сүзләрне тулы сүзләр белән алыштыру; өс һәм аяк киемнәре, йорт җиһазлары, алар белән бәйле аерым гамәлләр аталышын хәтердә калдыру теләге уяту. Үтенечләрне, теләкләрне, тәэсирләрне өч һәм күбрәк сүздән торган кыска җөмләләр белән белдерү сәләте формалашуга булышлык итү.

## Уен-дәресләр белән тәрбияләү

Балаларның үсешенә планлы рәвештә йогынты ясау өчен махсус уен-дәресләр уздыру.

Балаларны өлкән кешене тыңларга, ул эшләгәнне һәм күрсәткәнне күзәтергә, аның сүзләренә һәм гамәлләренә охшатырга, биремнәрне үтәргә өйрәтү.

Икенче яшькә чыккан балалар белән көнгә 2 шәр дәрес — һәр төркемчә белән атнага 10 ар дәрес уздырырга тәкъдим ителә. Беренче төркемчәдәге балалар белән уен-дәресләр — уяулык халәтенең икенче чорында, икенче төркемчәдәге балалар белән уяулык халәтенең иртәнге һәм кичке чорларында уздырыла.

1 яшьлек — 1 яшь 6 айлык балалар белән уен-дәресләр төркемчәләр буенча (2–4 кеше) уздырыла. Уен-дәреснең дәвамлылыгы — 3–6 минут. Уен-дәреснең төренә карап, 1 яшь 6 айлык — 2 яшьлек балаларны 4–6 кешелек төркемгә берләштерергә мөмкин. Уен-дәреснең дәвамлылыгы — 6–10 минут.

**Биш көнлек атнага исәпләнгән**
**төп уен-дәресләр исемлеге**

| Уен-дәресләрнең төрләре | Саны |
|---|---|
| Әйләнә-тирәдә ориентлашуны киңәйтү һәм сөйләм телен үстерү | 3 |
| Хәрәкәтләрне үстерү | 2 |
| Төзелеш материалы белән | 1 |
| Дидактик материал белән | 2 |
| Музыкаль | 2 |
| Уен-дәресләрнең гомуми саны | 10 |

## Сөйләм үстерү

**1 яшьтән 1 яшь 6 айга кадәр**

**Сөйләмне аңлау.** Аңлаешлы сүзләр запасын киңәйтү. Өлкән кешенең әйтүе буенча рәсемнәрдәге уенчыкларны, өс киеме предметларын, савыт-са-

баны, үз гәүдәсенең һәм сюжетлы уенчыкларның төп өлешләрен эзләп табу һәм күрсәтү, аларны өлешчә атау сәләтен үстерү.

Кеше гәүдәсе өлешләрен (куллар, аяклар, баш), йөз өлешләрен (авыз, күзләр, колаклар); көнкүреш һәм уен гамәлләрен(юыну, урамда йөрү); предмет төсләрен (кызыл, зәңгәр), контраст зурлыкларны (зур, кечкенә), формаларны (шакмак, кечкенә кирпеч, шар, призма) белдерүче сүзләрне аңлау сәләтен үстерү.

Балаларны өлкән кеше уенчыклар күрсәткәндә, үз гамәлләре вакытында әйтеп торган, төзелешләре һәм эчтәлекләре буенча гади гыйбарәләрне аңларга өйрәтү.

**Актив сөйләм.** Балаларның авазлар тезмәсенә һәм сүзләргә охшату сәләтен камилләштерү. Актив сүзлекне таныш гамәлләрнең аталышлары (*йокла, бар, егылды* һ.б. ) белән тулыландыру.

Рәсемдә хәрәкәтсез сурәтләнгән предметларны (1 яшь 3 ай тулганда) һәм аларны хәрәкәттә сурәтләнгән хәлдә (1 яшь 6 ай тулганда) күрсәтеп һәм әйтеп бирә белү сәләтен үстерү.

«Бу кем?», «Нәрсә эшли?» сорауларына җавап бирә белүне формалаштыру.

Ишарәләр һәм мимика ярдәмендә аралашудан мөмкин булган сөйләү чаралары аша аралашуга күчү теләге уяту. Ике сүздән торган җөмләне охшатып әйтә белү күнекмәләрен үстерү.

**1 яшь 6 айдан 2 яшькә кадәр**

**Сөйләмне аңлау**. Баланың гәүдә һәм йөз өлешләрен белдерүче аңлаешлы сүзләр запасын киңәйтү.

Балаларга предметларның төсләрен (кызыл, зәңгәр, сары, яшел), предметның зурлыгын (зур, кечкенә), формасын (шакмак, кечкенә кирпеч, түбә-призма), халәтен (чиста, пычрак), шулай ук аның урынын (монда, тегендә); вакыт (хәзер) һәм микъдар (бер һәм күп) чагыштырмаларын әйтеп аңлату.

Балаларда өлкән кеше ярдәме белән таныш предметларны төсләре буенча сайлый белү күнекмәләрен ныгыту.

Хайваннарның хәрәкәт итү (оча, йөгерә һ.б.), туклану (чукый, ялый һ.б.), тавыш бирү (мияулый, өрә һ.б.) ысулларын аңлатучы; кешенең хәрәкәт итү ысулларын (бара, йөгерә һ.б.) белдерүче сүзләрне аңлау сәләтен үстерү.

Зурлыкларына һәм төсләренә бәйсез рәвештә таныш предметларны (зур һәм кечкенә, кызыл һәм зәңгәр туп һ.б.) танып алу һәм күрсәтү; бер үк гамәлне берничә предмет белән бәйләү (курчакны, аю баласын, кечкенә филне ашатырга мөмкин һ.б.) сәләтен үстерү.

Курчаклар катнашындагы кечкенә инсценировкалар, курчак театрының балаларга үз тәҗрибәләре буенча таныш вакыйгалар турындагы спектакльләренең сюжетларын аңларга булышлык итү.

**Актив сөйләм.** Авазга охшатулы сүзләрне гомуми кулланыштагы сүзләр белән алыштыруны (*ау-ау* урынына — «эт» сүзен куллану һ.б.) хуплау.

Сүзләрне дөрес әйтү үрнәкләрен тәкъдим итү, балаларда охшатып әйтү теләге уяту.

Сүзләр запасын киңәйтүне һәм баетуны дәвам итү:

• уенчыклар, өс киемнәре, аяк киемнәре, савыт-саба, транспорт чаралары атамаларын белдерүче исемнәр белән;

• көнкүреш (*ашау, юыну* һ.б.), уен (*тәгәрәтү, төзү* һ.б.) гамәлләрен, мәгънәләре буенча капма-каршы гамәлләрне (*ачу — ябу, салдыру — кидерү* һ.б.) белдерүче фигыльләр белән;

• предметларның төсләрен, зурлыкларын белдергән сыйфатлар белән;

• рәвешләр белән *(биек, түбән, әкрен)*.

Балаларның өч һәм күбрәк сүздән гыйбарәләр төзү, грамматик формаларны дөрес куллану; исемнәр һәм алмашлыкларны фигыльләр белән яраклаштыру; фигыльләрне хәзерге һәм үткән заманнарда куллану; кушымчалардан *(эчендә, өстеннән)* файдалана белүне формалаштыру. Сорау сүзләрен *(кем, нәрсә, кая, кайда?)* куллану үрнәкләрен тәкъдим итү. Сөйләмнең интонацион сәнгатьлелеге формалашуга булышлык итү.

Балаларда сөйләм аша аралашу ихтыяҗын үстерүгә булышлык итү. Аларга өлкәннәр һәм яшьтәшләренә мөрәҗәгать итү очракларын күрсәтү *(сора; рәхмәт әйт; тәкъдим ит; кем килгән икән, кара да, безгә әйт һ.б.)*.

### Матур әдәбиятка тарту[1]

Эчтәлекләре буенча үзләштерерлек халык җырларын, такмазаларны, әкиятләрне, шулай ук автор әсәрләрен (проза, шигырьләр) тыңларга һәм аңларга өйрәтү. Укуны (сөйләүне) рәсемнәр, уенчыклар күрсәтү белән аралаштыру. Балаларны инде таныш әсәрләрне күрсәтүләрсез тыңларга өйрәтү.

### Хәрәкәтләрне үстерү

Балаларда хәрәкәт активлыгы уятучы шартлар тудыру; төп хәрәкәтләр үсешенә булышлык итү. Тигезлек саклап һәм акрынлап кул хәрәкәтләрен дә кушып туры юнәлештә йөрергә; җыелма баскычка менәргә һәм аннан төшәргә; үрмәләп керергә, аркылы шуышып чыгарга; ыргытканда һәм тәгәрәткәндә предметларны этеп җибәрергә; хәрәкәтләрне башка балалар белән бергәләп башкарырга өйрәтү.

**1 яшьтән 1 яшь тә 6 айга кадәр**

**Йөрү һәм тигезлек саклау күнекмәләре.** Идәндәге паласта туры юнәлештә төркемләп йөрү. Өлкән кеше ярдәмендә идәннән бер башы 10–15 см күтәрелгән такта (киңлеге 25 см, озынлыгы 1.5–2 м) буйлап өскә таба менү һәм тактаның очына кадәр түбән төшү. Түбә өскә каратып капланган тартма

[1] Балаларга уку өчен үрнәк әдәбият исемлеге Кушымтада тәкъдим ителә.

(50x50x10 см) өстенә менү һәм аннан төшү. Идәнгә сузылган бау яки идәннән 5–10 см га күтәртелгән таяк аша атлап чыгу.

**Шуышу, үрмәләү.** 2 м га кадәр арада шуышу, бау (50 см биеклектә) астына, кыршау (диаметры 50 см) эченә үрмәләп керү. Күчермә баскыч (биеклеге 1 м) буйлап өскә һәм аска үрмәләү.

**Тәгәрәтү, ыргыту.** Тупны (диаметры 25 см) алга таба тәгәрәтү (утырган, баскан хәлдә). Тупны (диаметры 6–8 см) аска, еракка ыргыту.

**1 яшь 6 айдан 2 яшькә кадәр**

**Йөрү һәм тигезлек саклау күнекмәләре.** Төркемләп йөрү, идәннән бер башы 15–20 см га күтәртелгән такта (киңлеге 20 см, озынлыгы 1,5–2 м) буйлап йөрү. Төбе өскә каратып капланган тартма (50x50x15 см) өстенә менү һәм аннан төшү. Идәннән 12–18 см га күтәртелгән бау яки таяк аша атлап чыгу.

**Шуышу, үрмәләү.** Бүрәнә (диаметры 15–20 см) аша үрмәләп чыгу, 35–40 см га күтәртелгән бау астына, кыршау (диаметры 45 см) эченә үрмәләп керү. Күчермә баскыч (биеклеге 1,5 м) баскыч буйлап өскә һәм аска үрмәләү.

**Тәгәрәтү, ыргыту.** Өлкән кеше белән парлашып туп (диаметры 20–25 см) тәгәрәтү, сөзәклек буенча тәгәрәтү һәм тупны сөзәклек янына күчерү. Тупны (диаметры 6–8 см) уң һәм сул кул белән 50–70 см ераклыкка ыргыту.

**Гомуми үсешне тәэмин итүче күнегүләр.** Эскәмиядә утырган хәлдә кулларны алга күтәрү һәм төшерү, аларны җилкә артына сузу.

Утырган хәлдә гәүдәне уңга һәм сулга борып предмет тапшыру.

Баскан хәлдә алга таба яртылаш иелүләр һәм тураю; өлкән кеше ярдәмендә таяк (идәннән 40–45 см биеклектә) аша бөгелеп алга таба яртылаш иелүләр.

Өлкән кеше ярдәмендә чүгәләүләр.

## Хәрәкәтле уеннар

Балаларда хәрәкәтле уеннарга карата тотрыклы уңай мөнәсәбәт формалаштыру. Көн саен уенчык кулланып һәм уенчыксыз хәрәкәтле уеннар уйнау.

1 яшьлек — 1 яшь 6 айлык балалар белән хәрәкәтле уеннар индивидуаль рәвештә уздырыла. 1 яшь 6 айлыктан зуррак балалар белән әлеге уеннар индивидуаль рәвештә һәм төркемчәләргә (2–3 кеше) берләштереп уздырыла.

Балаларның төп хәрәкәтләрен (йөрү, шуышу һәм үрмәләү, туп ыргыту) үстерү.

Бер юнәлештә төркемләп, бер-берсенә комачауламыйча хәрәкәт итә белү күнекмәләре формалаштыру. Өлкән кешене игътибар белән тыңлау, сигнал буенча эшләү сәләтен үстерү.

**Хәрәкәтле уеннарның якынча исемлеге**

«Тупны куып җит», «Тупны тапшыр», «Шалтыравыкка кадәр шуышып барып җит», «Этне куып җит», «Зурлар һәм кечкенәләр», «Күбәләкне тотып ал», «Тычкан баласы кайда чыелдый?» һ.б.

Балаларның аларда хәрәкәт активлыгын стимуллаштыручы уенчыклар — тәгәрәткечләр, арбалар, автомобильләр һ.б. белән мөстәкыйль уеннары.

## Дидактик материал белән уен-дәресләр

**1 яшьтән 1 яшь 6 айга кадәр**

Балаларның сиземләү тәҗрибәсен баетуны дәвам итү.

Балаларны предметлар белән гамәлләр башкарырга: кечкенә пирамиданың күчәренә бер зурлыктагы 2–3 боҗра тезәргә, өлкән кеше ярдәмендә билгеле бер эзлектә конус рәвешендәге, төрле зурлыктагы 2–3 капкачтан торган кечкенә пирамиданы җыярга; ике контраст зурлыктагы дүрт боҗрадан кечкенә пирамида җыярга; бер урынлы матрешканы ачарга һәм ябарга, кечерәк предметларны зурлары эченә куярга һәм аннан алырга өйрәтү.

Предметларның зурлыгына (зур, кечкенә), төсенә (кызыл, зәңгәр) карап алар белән төрле гамәлләр башкаруны (ачу-ябу, тезеп кую — тезмәдән алу, тәгәрәтү, тыгып кую, шнурлау, өстенә кую) камилләштерү. Төрле дидактик уенчыклар (шар аткычлар, дидактик тартмалар, гөмбәчекләр һәм чөйләр белән бергә өстәлчекләр һ.б.) белән эш итәргә өйрәтү.

**Төзелеш материалы (өстәл өстендә һәм идәндә кулланыла торган уенчыклар) белән уен-дәресләр.** Балаларны кайбер формалар (шакмак, кечкенә кирпеч, призма) белән «предметлаштырып» (призма — түбә) таныштыру.

Сюжетлы уенчыклар кулланып, өлкәннәр белән корылмалар төзеп уйнау.

**1 яшь 6 айдан 2 яшькә кадәр**

Балаларның сиземләү тәҗрибәсен баетуны дәвам итү. Предметларны зурлыклары буенча аеру сәләтен үстерү: өлкән кеше ярдәмендә 4–5 боҗрадан (зурысыннан кечкенәсенә таба), 4–5 капкачтан кечкенә пирамида җыю.

Тиешле формалары буенча тартмачыклар һәм шкатулкалар өчен капкачлар сайлау; ике урынлы дидактик уенчыклар (матрешкалар, кечкенә мичкәләр) җыю, ике кисәктән бүленә торган рәсемнәр (кечкенә пирамида, алма һ.б.) төзү.

Яссы фигураларны (түгәрәк, квадрат, өчпочмак, турыпочмаклык) дидактик тартма тишекләренә туры китерү буенча күнегүләр үткәрү.

Ишетү игътибарлылыгын үстерү буенча дидактик уеннар («Өйдә кем яши?», «Безне кем чакырды?» һ.б.) уздыру.

Дүрт төрле төсне (кызыл, зәңгәр, сары, яшел) аеру сәләтен үстерү; өлкән кеше тәкъдиме буенча билгеле бер төстәге предметларны аерып алу.

Махсус дидактик әсбаплар куллану: балаларга гөмбәчекләрнең һәм чөйләрнең төсләрен, формасын — төсле кыр, яссы һәм күләмле предметларны тартмачыклардагы һәм кечкенә өстәлләрдәге фигуралы тишекләр белән тиңләштерергә булышу. Дидактик уенчыклар, вак һәм эре төзелеш материалы белән мөстәкыйль уйнау мөмкинлеге тудыру.

**Төзелеш материалы (өстәл өстендә һәм идәндә кулланыла торган уенчыклар).** Балаларны кайбер формалар (шакмак, кечкенә кирпеч, призма, цилиндр) белән «предметлаштырып» (цилиндр — багана, торба) таныштыруны дәвам итү.

Төзү ысуллары — яннан кую, өскә кую белән таныштыру. Өлкәннәр белән бергә корылмалар төзеп уйнау теләге уяту, уеннар өчен сюжетлы уенчыклар куллану.

Үзләренең төрле корылмаларын төзегәндә төзелеш материалының таныш формаларын һәм пластмасса конструкторларның элементларын файдалана белүне формалаштыру.

Җәйге чорда тышта табигый материаллар белән уеннар оештыру. Ком белән уйнауларны — төзелеш материалы, су катнашындагы уеннарны сюжетлы уеннар белән аралаштыру. Өлкән кеше комда сызгалап ясаган таныш фигураларны вак ташлар, кабырчыклар, күркәләр белән бизәү — тулыландыру сәләтен үстерү. Балаларның сюжетлы уеннарда алмаш материаллар сыйфатында махсус рәвештә табигый материал куллануын хуплау (яфрак — тәлинкә).

## Музыкаль тәрбия[1]

Балаларда җырлаганда, музыкага ияреп хәрәкәтләр ясаганда һәм уен гамәлләре вакытында күңел күтәренкелеге тудыру.

Төрле алымнар (ишарә, мимика, кушылып җырлау, хәрәкәтләр) ярдәмендә музыкага карата эмоциональ тәэсир, музыкаль әсәрләр тыңлау теләге уяту.

Балалар белән бергә элек аларны таныштырган әсәрләрне күп тапкырлар кабатлау (туганнан алып беренче яшь дәвамында).

### 1 яшьтән 1 яшь 6 айга кадәр

Күңелле һәм тыныч музыкага тарту, ишетү буенча төрле тембрлы музыка коралларының (барабан, флейта яки сыбызгы) яңгырашын аера белүне формалаштыру.

Балаларга аларга ошаган җырның эчтәлеген аңларга, кушылып җырларга (булдыра алганча) ярдәм итү. Эзлекле рәвештә җырлауны өлкәннәр белән бергә тәмамлый белүне формалаштыру.

Музыка астында йөрү, иң гади бию хәрәкәтләре («пружинка», тыпырдау, аякларны алмаш-тилмәш басу, кулларны чәбәкләү, шалтыравык селкетү, яулык болгау; бөтерелү, кулларны әйләндерү — «фонарьлар») башкара белүне үстерү.

Уен хәрәкәтләре процессында образ (кошчык, аю баласы, куян) белән бәйле хәрәкәтләрне башкару теләге уяту.

### 1 яшь 6 айдан 2 яшькә кадәр

Балаларда музыкаль хәтер үстерә башлау.

[1] Якынча музыкаль репертуар Кушымтада тәкъдим ителә.

Таныш музыка әсәрләрен тыңлаудан шатлык, аны ахыргача тыңлап бетерү теләге уяту. Музыка коралларының (сыбызгы, барабан, гармун, флейта) тембр яңгырашын аерырга, өлкән кеше көйне башкарган уен коралын (икедән яки өчтән берне) күрсәтергә ярдәм итү.

Җырлаганда балаларның мөстәкыйль активлыгын (авазларга охшату, сүзләрне, гыйбарәләрне, катлаулы булмаган кушымталарны һәм җырларны кушылып җырлау) стимуллаштыру.

Музыка астында хәрәкәтләрне камилләштерүне дәвам итү, аларны мөстәкыйль башкарырга өйрәтү.

Балаларның музыканы бирелеп тыңлау, аның яңгырау рәвеше үзгәргәндә хәрәкәтләрне үзгәртә (йөрүдән тыпырдауга, бөтерелүгә күчү) белүен үстерү. Музыка характерын тоемларга һәм аны уен гамәлләре (аю баласы килә, куян сикерә, кошчык чукый) аша чагылдырырга ярдәм итү.

### Бәйрәмнәр, музыкаль уеннар, күңел ачулар[1]

Балаларны сюжетлы музыкаль уеннарга тарту. Уен вакытында яңгыраган музыканы кабул иткәндә үзгәреш кичерә белүен формалаштыру. Уен гамәлләре нәтиҗәсендә шатлык, канәгатьләнү хисе уяту.

Балаларга иң гади эчтәлекле спектакльләр күрсәтү.

[1] Күңел ачуларның һәм бәйрәмнәрнең үрнәк исемлеге Кушымтада тәкъдим ителә.

# 2 ЯШЬТӘН АЛЫП МӘКТӘП ЯШЕНӘ КАДӘРГЕ БАЛАЛАРНЫҢ ҮСЕШ ЮНӘЛЕШЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛГӘН БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

2–7 яшьлек балалар белән психологик-педагогик эш эчтәлеге «Социаль-коммуникатив үсеш», «Танып белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Сәнгати-эстетик үсеш», «Физик үсеш» белем бирү өлкәләре буенча бирелә. Эшнең эчтәлеге мәктәпкәчә яшьтәге балаларның, аларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен искә алып, төрле яклап үсешенә юнәлтелгән. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси сыйфатларын формалаштыру буенча психологик-педагогик эш бурычлары белем бирүнең һәрбер өлкәсенең үзгәлеген чагылдыра торган бурычлар белән, мәҗбүри психологик тәэмин итү белән берләттән, барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү барышында интеграцияле хәл ителә.

Бу очракта программаның мәгариф бурычларын хәл итү турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, режимлы моментлар барышында да — өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә дә, мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең мөстәкыйль эшчәнлегендә дә карала.

## «СОЦИАЛЬ-КОММУНИКАТИВ ҮСЕШ» белем бирү өлкәсе

«Социаль-коммуникатив үсеш, әхлакый һәм рухи кыйммәтләрне кертеп, җәмгыятьтә кабул ителгән нормаларны һәм кыйммәтләрне үзләштерүгә; баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуын һәм үзара бәйләнешен үстерүгә; мөстәкыйльлеген, максатчанлыгын һәм үз гамәлләрен үзе җайга салуын булдыруга; социаль һәм эмоциональ интеллектны, киң күңеллелекне, хәлгә керә белүне үстерүгә, яшьтәшләре белән уртак эшчәнлеккә әзерлек формалаштыруга, Оешмадагы балалар һәм өлкәннәр бергәлеге һәм үз гаиләләренеке булу хисен һәм аларга ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләүгә; хезмәтнең һәм иҗатның төрле төрләренә уңай караш формалаштыруга;

көнкүрештә, социумда, табигатьтә үз-үзеңне имин тоту нигезләрен булдыруга юнәлтелгән»[1].

## Төп максатлар һәм бурычлар

**Социальләштерү, аралаша белү сыйфатларын үстерү, әхлак тәрбиясе.** Җәмгыятьтә кабул ителгән нормалар һәм кыйммәтләрне үзләштерү, балада рухи һәм әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, аны үз гамәлләрен һәм яшьтәшләре гамәлләрен дөрес бәяли белергә өйрәтү.

Баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуын һәм үзара бәйләнешләрен үстерү, социаль һәм эмоциональ интеллектны, киң күңеллелекне, хәлгә керә белүне, әйләнә-тирәдәгеләргә ихтирамлы һәм дустанә мөнәсәбәтне үстерү.

Балаларда уртак эшчәнлеккә әзер булучанлык тәрбияләү, уртак фикергә килү, яшьтәшләре белән конфликтларны мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә өйрәтү.

**Бала гаиләдә һәм берләшмәдә.** «Мин» образын, үз гаиләсенеке һәм оешмадагы балалар һәм өлкәннәр бергәлегенеке булу хисе һәм аларга ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү; үзенең аерым җенескә каравын (гендер аерымлыгы), аерым гаиләнеке булуын аңлау формалаштыру.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйльлек, хезмәт тәрбиясе.** Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләрен үстерү; мөстәкыйльлек, максатка юнәлгәнлек һәм үз гамәлләрен үзе җайга сала белү сәләте тәрбияләү.

Культура-гигиена күнекмәләрен тәрбияләү.

Хезмәтнең һәм иҗатның төрле төрләренә уңай фикердә булуны формалаштыру, хезмәткә уңай мөнәсәбәт, хезмәт итүгә теләк тәрбияләү.

Үз хезмәтенә, башка кешеләр хезмәтенә һәм аның нәтиҗәсенә хөрмәт белән карау тәрбияләү. Йөкләнгән бурычны (эшне ахырына җиткерә белү сәләте һәм теләге, аны җиренә җиткереп башкару омтылышы) үтәүгә җаваплы карарга өйрәтү.

Өлкәннәр хезмәте, аның җәмгыятьтәге һәм һәр кешенең тормышындагы урыны хакында беренчел күзаллаулар булдыру.

**Куркынычсызлык нигезләрен формалаштыру.** Көнкүрештә, социумда, табигатьтә куркынычсызлык тәртибе турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүгә аңлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

Кешегә һәм әйләнә-тирә мохиткә куркыныч янау ихтималы булган хәлләргә карата сак мөнәсәбәт формалаштыру.

Кайбер типик хәвефле хәлләр һәм шул хәлләрдә үз-үзеңне тоту ысуллары турында күзаллаулар формалаштыру.

Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы кагыйдәләре турында элементар күзаллаулар формалаштыру; бу кагыйдәләрне үтәүнең зарурлыгына карата аңлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

---

[1] МББ ФДББСының 2.6. пунктын кара.

# Психологик-педагогик эш эчтәлеге

## Социальләштерү, аралашуны үстерү, әхлакый тәрбия

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Балаларда яшьтәшләре даирәсендә үз-үзләрен тоту тәҗрибәсе формалаштыру, аларда яшьтәшләренә карата ярату (симпатия) хисләре тәрбияләү. Яшьтәшләр белән дустанә мөнәсәбәтләр тәҗрибәсе тупланууга булышу, киң күңеллелек тәрбияләү (балаларның игътибарын иптәшенә карата кайгыртучанлык күрсәткән балага юнәлтү, кызгану, хәлгә керә белүне хуплау).

Дорфалыкка, комсызлыкка карата тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү; ызгышмыйча уйнау, бер-береңә ярдәм итү һәм уңышлар, матур уенчыклар булуга бергәләп шатлана белү сыйфатын үстерү.

Әдәпле мөгаләмәнең элементар күнекмәләрен тәрбияләү: сәламләү, саубуллашу, үтенеч белән тыныч кына, «рәхмәт» һәм «рәхим итегез» сүзләрен кулланып мөрәҗәгать итү. Бүлмәдә һәм урамда үз-үзеңне тыныч тоту сәләтен формалаштыру: шауламау, йөгереп йөрмәү, өлкән кеше кушканны үтәү.

Ата-анага һәм якын кешеләргә карата игътибарлы мөнәсәбәт һәм мәхәббәт тәрбияләү. Балаларны өлкән кешенең сүзен бүлдермәскә өйрәтү, өлкән кеше мәшгуль булганда көтеп тора белү сыйфатын формалаштыру.

### Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

Балалар бакчасында, өйдә, урамда үз-үзеңне тәртипле тоту күнекмәләрен ныгыту. Нәрсәнең яхшы һәм нәрсәнең начар булуы турында элементар карашлар формалаштыруны дәвам итү.

Балаларны әхлакый тәрбияләү өчен шартлар тәэмин итү. Яшьтәшен кызгану, аны кочаклау, аңа ярдәм итү омтылышларын хуплау. Әйләнә-тирәдәгеләргә карата игътибарлы, кайгыртучан мөнәсәбәт формалаштыруга ярдәм итүче уен ситуацияләре булдыру. Балаларны тыныч, кычкырмыйча аралашырга өйрәтү.

Бер-береңә карата дустанә мөнәсәбәт, иптәшең белән бүлешә белү, яхшы һәм начар гамәлләрне дөрес бәяләү тәҗрибәсе формалаштыру.

Тату яшәргә, уенчыклардан һәм китаплардан бергә файдаланырга, бер-береңә ярдәм итәргә өйрәтү.

Балаларны әдәплелеккә гадәтләндерү (сәламләргә, саубуллашырга, ярдәм өчен рәхмәт белдерергә өйрәтү).

### Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

Баланың әхлак нормаларын үтәүгә: үзара ярдәмләшүгә, кыерсытылган кешенең хәленә керүгә һәм кыерсытучының гамәлләре белән ризалашмауга карата шәхси мөнәсәбәте; гадел булган, яшьтәшенең үтенеченә юл куйган (шакмакларны тигез бүлгән) кешенең гамәлләрен хуплау формалашуга булышлык итү.

Балалар арасында дустанә мөнәсәбәтләр формалаштыру буенча эшне дәвам итү; балаларның игътибарын бер-берсенең яхшы гамәлләренә юнәлтү.

Коллектив уеннарга, үзара яхшы мөнәсәбәтләр кагыйдәләренә өйрәтү.

Тыйнаклык, ярдәмчеллек, гадел, көчле һәм кыю булу теләге тәрбияләү; ямьсез гамәл өчен оят хисе кичерергә өйрәтү.

Сәламләү, саубуллашу, мәктәпкәчә учреждение хезмәткәрләрен исемнәре һәм әтиләренең исемнәре белән атау, өлкәннәр сөйләшүенә катышмау, үз үтенечеңне әдәпле итеп җиткерү, күрсәтелгән хезмәт өчен рәхмәт белдерү зарурлыгы турында балаларның исләренә төшереп тору.

### Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Балалар арасында дусларча мөнәсәбәтләр; бергәләп уйнау, эшләү, шөгыльләнү гадәте; өлкәннәрне яхшы гамәлләр белән сөендерү омтылышы; мөстәкыйль рәвештә уртак кызыклы шөгыльләр таба белү сәләте тәрбияләү.

Әйләнә-тирәдәгеләргә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

Кечкенәләр турында кайгыртырга, аларга булышырга, көчсезрәкләрне якларга өйрәтү. Хәлгә керү, ярдәмчеллек кебек сыйфатлар формалаштыру.

Тыйнаклык, әйләнә-тирәдәгеләр турында кайгырту, ярдәмгә һәм игътибар билгеләренә карата рәхмәтле була белү сыйфатлары тәрбияләү.

Үз гамәлләреңне һәм яшьтәшләрнең гамәлләрен бәяли белү сәләте формалаштыру. Балаларның әйләнә-тирәгә карата үз мөнәсәбәтләрен белдерү, моның өчен мөстәкыйль рәвештә төрле сөйләм чаралары табу омтылышын үстерү.

Җәмәгать урыннарында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре; балалар бакчасындагы, өйдәге бурычлар турындагы карашларны киңәйтү.

Балалар телен әдәпле сүзләр (исәнмесез, сау булыгыз, рәхим итегез, гафу итегез, рәхмәт һ.б.) белән баету. Сөйләмдә фольклор (мәкальләр, әйтемнәр, такмазалар һ.б.) куллануга теләк уяту. Әхлаклылык нигезләре формалашуда туган телнең әһәмиятен күрсәтү.

### Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Балалар арасында дустанә мөнәсәбәтләр тәрбияләү; бергәләп уйнау һәм эшләү өчен мөстәкыйль рәвештә берләшү, сайлап алынган эш белән

мөстәкыйль шөгыльләнү, уртак фикергә килү, бер-береңә ярдәм итә белү сыйфатларын үстерү.

Оешканлык, дисциплиналылык, коллективизм, өлкәннәргә карата ихтирам тәрбияләү.

Кечкенәләргә, өлкән яшьтәге кешеләргә карата кайгыртучан мөнәсәбәт тәрбияләү, аларга ярдәм итәргә өйрәтү.

Хәлгә керү, ярдәмчеллек, гаделлек, тыйнаклык кебек сыйфатлар формалаштыру.

Ихтыяр сыйфатларын: үз теләгеңне чикләү, үз-үзеңне тотуның билгеләнгән нормаларын үтәү, үз гамәлләреңдә уңай мисалга таяну сыйфатларын үстерү.

Әйләнә-тирәдәгеләргә карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү. Әңгәмәдәшне тыңлый белү, ихтыяҗ булмаганда аны белдермәү сыйфатын формалаштыру. Үз фикереңне тыныч кына яклый белүне формалаштыру.

Сүзлекне телдәге әдәплелек формулалары белән баету (сәламләү, саубуллашу, үтенечләр, гафу үтенүләр).

Балаларның үз бурычлары турындагы карашларын барыннан да элек мәктәпкә әзерләнү белән бәйле рәвештә киңәйтү.

## Бала гаиләдә һәм берләшмәдә

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

**«Мин» образы.** Балаларда үзләре балалар бакчасына йөри башлауга бәйле рәвештә аларның социаль статусы үзгәрү (яше үсү) турында элементар карашлар формалаштыру; үз исемен әйтә белүне ныгыту.

Һәр балада, барлык балаларны яраткан кебек үк, аны яратулары, аның турында кайгыртулары хакында инанганлык формалаштыру; баланың мәнфәгатьләренә, аның ихтыяҗларына, теләкләренә, мөмкинлекләренә карата ихтирамлы мөнәсәбәт белдерү.

**Гаилә.** Ата-анага, якын кешеләргә карата игътибарлы мөнәсәбәт тәрбияләү. Үз гаиләсе әгъзаларының исемнәрен әйтә белүен хуплау.

**Балалар бакчасы.** Балалар бакчасының уңай яклары, аның өй белән уртаклыклары (җылы, уңайлыклар, ярату һ.б.) һәм өйдәге халәттән аерымлыклары (дуслар, уенчыклар, мөстәкыйльлек күбрәк һ.б.) турындагы карашларны үстерү.

Балаларның игътибарын аларның нинди чиста, якты бүлмәдә уйнауларына, ул бүлмәдә матур уенчыкларның күп булуына, караватлардагы урын-җирнең җыйнак итеп җыештырылуына юнәлтү. Һавага чыккач, балаларның игътибарын матур үсемлекләргә, участокның уйнау һәм ял итү өчен уңайлы итеп җиһазландырылуына юнәлтү.

Төркем бүлмәсендә, участокта ориентлаша белүне үстерү.

## Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

**«Мин» образы.** Эзлекле рәвештә «Мин» образын формалаштыру. Балаларга төрле, турыдан-туры аларга кагылышлы мәгълүматлар (син — малай, синең күзләрең соры, син уйнарга яратасың һ.б.), шул исәптән үткәннәре турындагы (йөри, сөйләшә белми идең; шешәдән ашадың) һәм алардагы үзгәрешләр (хәзер үзеңне өстәл янында дөрес тота, рәсем ясый, бии беләсең; «әдәпле» сүзләр беләсең) турындагы мәгълүматларны җиткерү.

**Гаилә.** Бала белән аның гаилә әгъзалары турында әңгәмә кору (исемнәре ничек, нәрсә эшлиләр, бала белән ничек уйныйлар һ.б.).

**Балалар бакчасы.** Балаларда балалар бакчасына карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру. Аларның игътибарын төркем бүлмәсенең, чишенү бүлмәсенең матур бизәлешенә һәм уңайлы җиһазландырылуына юнәлтү (якты төстәге стеналар, матур пәрдәләр, уңайлы йорт җиһазлары, яңа уенчыклар, китаплар почмагында матур рәсемле китаплар җыйнак итеп тезеп куелган).

Балаларны уеннар һәм дәресләр уздырыла торган участокның җиһазландырылуы һәм бизәлеше белән таныштыру, аның матурлыгына, уңайлыкларына, корылмаларның якты төсмерләрдә төрле төсләргә буялуына басым ясау.

Балаларның игътибарын төрле үсемлекләргә, аларның төрле-төрле булуына һәм матурлыгына юнәлтү.

Балаларны төркем тормышына җәлеп итү, төркемдә чисталык һәм тәртип саклау омтылышы тәрбияләү, уенчыкларга, китапларга, шәхси әйберләргә һ.б. карата сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру. Бергәлек, балалар бакчасы өчен һәр баланың мөһимлеге хисен формалаштыру.

Балалар бакчасының бүлмәләрендә һәм участогында иркен ориентлаша белү сәләтен камилләштерү.

Балалар бакчасы хезмәткәрләренә (музыка җитәкчесе, шәфкать туташы, мөдир, өлкән тәрбияче һ.б.), аларның хезмәтенә карата ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру; аларның исемнәрен һәм әтиләренең исемнәрен исләренә төшереп тору.

## Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

**«Мин» образы.** Баланың үсүе һәм үсеше, аның үткәне, хәзергесе һәм киләчәге турында күзаллаулар («мин кечкенә идем, мин үсәм, мин зур булачакмын») формалаштыру. Балаларда аларның хокуклары (уйнарга, дустанә мөнәсәбәткә, яңа белемнәргә һ.б.) һәм балалар бакчасындагы төркемдәге, өйдәге, урамдагы бурычлары (мөстәкыйль ашау, киенү, уенчыкларны җыеп кую һ.б.) турындагы беренчел күзаллауларны формалаштыру. Һәр балада аның яхшы булуы, аны яратулары турында инанганлык формалаштыру.

Беренче гендер күзаллауларын формалаштыру (малайлар көчле, кыю; кызлар мөлаем, нәфис).

**Гаилә.** Балаларның гаилә, аның әгъзалары турындагы күзаллауларын тирәнәйтү. Туганлык мөнәсәбәтләре турында беренчел күзаллаулар булдыру (улы, әнисе, әтисе, кызы һ.б.).

Баланың өйдәге тормышта нинди бурычлары (уенчыкларны җыеп кую, табын әзерләүдә булышу һ.б.) булуы турында кызыксыну.

**Балалар бакчасы.** Балаларны балалар бакчасы һәм аның хезмәткәрләре белән таныштыруны дәвам итү. Балалар бакчасы бүлмәләрендә ориентлаша белү сәләтен камилләштерү. Балаларда әйберләргә карата сакчыл мөнәсәбәтне ныгыту, әйберләрне тиешенчә файдаланырга, аларны урыннарына куярга өйрәтү.

Балалар бакчасы традицияләре белән таныштыру. Баланың үзе турында коллектив әгъзасы сыйфатында күзаллауларын ныгыту, башка балалар белән бергәлек хисен үстерү. Балалар бакчасында төркемне һәм залны, участокны бизәүдәге үзгәрешләрне (затлы, матур уенчыкларның, балалар рәсемнәренең күркәмлеге һ.б.) күрә белү сәләтен формалаштыру. Фикер алышуга һәм мөмкин кадәр төркемне бизәүдә катнашуга, төркемнең символикасын һәм традицияләрен булдыруга җәлеп итү.

## Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

**«Мин» образы.** Баланың үсү белән бәйле позициясе үзгәрү (кечкенәләр өчен җаваплылык, зурларга, шул исәптән өлкән яшьтәгеләргә карата ихтирам һәм аларга ярдәм итү һ.б.) турындагы күзаллауларын киңәйтү. Символик һәм образлы чаралар аша баланың үзе турында үткән, хәзерге һәм киләчәк чорларга карата күзаллауларын тирәнәйтү.

Традицион гендер күзаллауларын киңәйтү. Үз җенесеннән һәм капма-каршы җенестән булган яшьтәшләренә карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Гаилә.** Баланың гаилә һәм аның тарихы турындагы күзаллауларын тирәнәйтү. Гаилә тарихына таянып иң гади шәҗәрә төзергә өйрәтү.

Әти-әнисенең кайда эшләүләре, алар хезмәтенең җәмгыять өчен мөһим булуы турындагы күзаллауларны тирәнәйтү. Балаларның төрле гаилә бәйрәмнәрен әзерләүдә булдыра алган кадәр катнашуын хуплау. Өйдәге көндәлек даими бурычларны башкарырга өйрәтү.

**Балалар бакчасы.** Якын тирәлеккә: балалар бакчасына, балалар яшәгән өйгә, балалар бакчасы участогына һәм башкаларга карата кызыксыну формалаштыруны дәвам итү. Төрле бүлмәләрнең үзенчәлекле бизәлешенә игътибарны юнәлтү.

Бүлмәләр бизәлешендәге үзгәрешләрне күрә белү сәләтен үстерү, шул үзгәрешләрнең сәбәпләрен аңлатырга һәм күреп алынган үзгәрешләр буенча бизәлешнең мөмкин булган вариантлары хакында үз тәкъдимнәрен кертү турындагы фикер белдерергә өйрәтү. Балаларны әйләнә-тирәне бәяләүгә этәрү.

Төркемдә чисталык һәм тәртип саклау, төркем бүлмәсен сәнгать әсәрләре, рәсемнәр белән бизәү омтылышы уяту. Төркем бүлмәсен, залны бәйрәмнәр уздыру өчен бизәүгә җәлеп итү. Балалар тарафыннан ясалган эшләнмәләрне, рәсемнәрне, аппликацияләрне (кошлар, күбәләкләр, кар бөртекләре, яфраклы ботаклар һ.б.) куллану теләге уяту.

Баланың үзе турында коллектив әгъзасы сыйфатында күзаллауларын киңәйтү, уртак проект эшчәнлегендә катнашу, башка яшь төркемнәрендәге балалар белән бергә эш итү, булдыра алганча мәктәпкәчә учреждение тормышында катнашу аша аның актив тормыш позициясен формалаштыру. Балалар бакчасында уздырылучы чараларга (спектакльләр, спорт бәйрәмнәре һәм күңел ачулар, балалар эшләре күргәзмәләрен әзерләү һ.б.), шул исәптән, әти-әниләре белән бергә, тарту.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

**«Мин» образы.** Шәхеснең вакытка бәйле перспективасы, яшь үзгәрү белән кешенең позициясе үзгәрү (бала балалар бакчасына йөри, укучы бала укый, өлкән кеше эшли, олы яшьтәге кеше үз тәҗрибәсен башка буыннарга тапшыра) турындагы күзаллауны үстерү. Баланың үзе турында үткән, хәзерге һәм киләчәк чорларга карата күзаллауларын тирәнәйтү.

Традицион гендер күзаллауларын ныгыту, малайларда һәм кызларда аларның җенесләренә хас сыйфатларны үстерүне дәвам итү.

**Гаилә.** Туган ил тарихы контекстында балаларның гаилә тарихы турындагы күзаллауларын киңәйтү (ил тарихының төрле чорларында һәр буынның роле). Балаларга бабаларының, әбиләренең, әти-әниләренең сугышчан бүләкләре турында сөйләү.

Өй адресын һәм телефонын, әти-әниләренең үз исемнәре һәм әтиләренең исемнәрен, аларның һөнәрләрен белүне ныгыту.

**Балалар бакчасы.** Якын тирәлек турындагы күзаллауларны киңәйтүне дәвам итү (балалар бакчасы бүлмәләренең, участогының, паркның, скверның бизәлеше). Балаларны әйләнә-тирәнең таң калдырырлык компонентларын (стеналарның матур төскә буялуы, йорт җиһазлары, участокның бизәлеше һ.б.) аерып күрсәтергә өйрәтү.

Балаларны мәктәпкәчә учреждениенең үсешне тәэмин итүче тирәлеген (мини-музейлар, күргәзмәләр, китапханәләр, конструкторлык остаханәләре һ.б.) булдыруга җәлеп итү; әйләнә-тирәне эстетик бәяләү, бәяләмә бирү, үз фикереңне нигезли белү сәләте формалаштыру.

Кечерәк яшьтәгеләр төркемнәрен һәм әти-әниләрне колачлаган проект эшчәнлегендә, булдыра алганча мәктәпкәчә оешма тормышында катнашу (кечерәк мәктәпкәчә яшьтәге балаларны адаптацияләү, балалар бакчасындагы һәм аннан читтәге бәйрәмнәргә, чыгышларга, ярышларга әзерләнү һ.б.) аша балаларда үзләре турында коллективның актив әгъзасы сыйфатында күзаллаулар формалаштыру.

## Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйльлек, хезмәт тәрбиясе

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

**Культура-гигиена күнекмәләре тәрбияләү.** Пычрануга карап һәм ашау алдыннан (башта өлкән кеше контролендә, соңрак мөстәкыйль рәвештә) кулларны юу, битне һәм кулларны шәхси сөлге белән корытып сөртү гадәте формалаштыру.

Өлкән кеше ярдәмендә үз-үзен тәртипкә китерергә, индивидуаль предметлардан (кулъяулык, салфетка, сөлге, тарак, чүлмәк) файдаланырга өйрәтү.

Ашаганда кашыкны дөрес тотарга өйрәтү.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү.** Балаларны билгеле бер тәртиптә киенергә һәм чишенергә; өлкән кешенең беркадәр ярдәме белән өс, аяк киемнәрен салырга (алдагы төймәләрне чишү, ябышучан каптырмаларны ычкындыру); өстән салган киемнәрне билгеле бер тәртиптә төреп куярга өйрәтү. Пөхтәлеккә өйрәтү.

**Иҗтимагый-файдалы хезмәт.** Балаларны иң гади хезмәт гамәлләре башкаруга җәлеп итү: өлкән кеше белән бергә һәм аның контролендә ипи савытларын (иписез килеш), салфетка савытларын урнаштыру, кашыклар кую һ.б.

Уен бүлмәсендә тәртип сакларга, уеннар төгәлләнгәч уен материалын урыннарына куярга өйрәтү.

**Өлкәннәр хезмәтенә ихтирам.** Балаларның өлкәннәр эшчәнлегенә карата кызыксынуын хуплау. Өлкән кешенең нәрсә һәм ничек эшләвенә (ничек итеп үсемлекләрне (су сибә) һәм хайваннарны (ашата) карый; урам себерүче ничек итеп ишегалдын себерә, кар көри; балта остасы ничек итеп беседка ясый һ.б.), аның ни өчен теге яки бу гамәлләр башкаруына игътибар юнәлтү. Кайбер хезмәт гамәлләрен танырга һәм атарга өйрәтү (тәрбияче ярдәмчесе савыт-саба юа, ашарга китерә, сөлгеләрне алыштыра).

### Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

**Культура-гигиена күнекмәләре.** Культура-гигиена күнекмәләрен камилләштерү, ашау, юыну вакытында үз-үзеңне тотуның иң гади күнекмәләрен формалаштыру.

Балаларны үзләренең тышкы кыяфәтләрен карарга, сабыннан дөрес файдаланырга, кулларны, битне, колакларны пөхтә итеп юарга; юынганнан соң корытып сөртенергә, сөлгене урынына эләргә, тарактан һәм кулъяулыктан файдаланырга өйрәтү.

Табын артында үз-үзеңне тотуның элементар күнекмәләрен формалаштыру: аш һәм чәй кашыкларыннан, чәнечкедән, салфеткадан дөрес файдалану, ипине вакламау, ризыкны авызны ябып чәйнәү, авыз тулы булганда сөйләшмәү.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү.** Балаларны мөстәкыйль рәвештә билгеле бер тәртиптә киенергә һәм чишенергә өйрәтү (киемне кию һәм салу, төймәләрне чишү һәм төймәләү, кием предметларын төреп, элеп кую һ.б.). Пөхтәлек саклау, киемдәге тәртипсезлекне күреп алу һәм өлкәннәрнең аз гына ярдәме белән аны тәртипкә китерә белү күнекмәләре тәрбияләү.

**Иҗтимагый-файдалы хезмәт.** Булдыра алганча хезмәттә катнашу теләге, зур булмаган кыенлыкларны җиңәргә өйрәтү тәрбияләү. Балаларда өлкәннәр кушканны мөстәкыйль рәвештә үтәү теләге уяту: дәрес уздыру өчен материаллар (кечкенә пумалалар, әвәләү өчен такталар һ.б.) әзерләү, уеннан соң уенчыкларны, төзелеш материалларын урыннарына кую.

Балалар бакчасы бүлмәсендә һәм участогында тәртип һәм чисталык саклауга өйрәтү.

Елның икенче яртысында балаларда ашханәдә дежур тору өчен кирәкле күнекмәләр (төшке ашка табын әзерләү; кашыклар кую, ипи савытлары (ипи-сез килеш), тәлинкәләр, чынаяклар урнаштыру һ.б.) формалаштыра башлау.

**Табигатьтәге хезмәт.** Табигать почмагында һәм участокта үсемлекләрне һәм хайваннарны карау-тәрбияләүдә катнашу теләге тәрбияләү: өлкән кеше ярдәмендә балыклар, кошлар ашату, бүлмәдәге һәм түтәлләрдәге үсемлекләргә су сибү, суган утырту, яшелчәләр җыю, сукмакларда кар көрәү, эскәмияләрне кардан чистарту.

**Өлкәннәр хезмәтенә ихтирам.** Өлкәннәр хезмәтенә карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру. Балаларга аларга аңлаешлы һөнәрләр (тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, музыка җитәкчесе, табиб, сатучы, пешекче, шофер, төзүче) турында сөйләү, хезмәт гамәлләре, хезмәт нәтиҗәләре турындагы күзаллауларны киңәйтү һәм баету.

Таныш һөнәр ияләренә карата ихтирам тәрбияләү. Өлкәннәргә ярдәм итү теләге уяту, аларның хезмәте нәтиҗәләренә карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

## Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

**Культура-гигиена күнекмәләре.** Балаларда пөхтәлек, үзләренең тышкы кыяфәтләрен кайгырту гадәте тәрбияләүне дәвам итү.

Мөстәкыйль рәвештә юыну, пычрануга карап, ашау алдыннан, бәдрәфтән чыккач кулларны сабынлап юу гадәте тәрбияләү.

Тарак, кульяулыктан файдалану, йөткергәндә һәм төчкергәндә читкә борылу, авызны һәм борынны кульяулык белән каплау гадәтен ныгыту.

Пөхтә ашау: ризыкны азлап алу, яхшылап чәйнәү, тавыш-тын чыгармыйча ашау, өстәл приборларыннан (кашык, чәнечке), салфеткадан дөрес файдалану, ашаганнан соң авызны чайкау күнекмәләрен камилләштерү.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү.** Үзлектән киенү, чишенә белү күнекмәләрен камилләштерү. Өс киемен җыйнак итеп төрергә һәм эләргә, өлкән кеше ярдәмендә аны тәртипкә китерергә (чистарту, киптерү) өйрәтү. Җыйнак һәм пөхтә булу теләге тәрбияләү.

Үз эш урынын мөстәкыйль рәвештә әзерләргә, рәсем, әвәләү, аппликация дәресләре төгәлләнгәч аны җыештырырга (кечкенә банкаларны, пумалаларны юу, өстәлне сөртү һ.б.) өйрәтү.

**Иҗтимагый-файдалы хезмәт.** Балаларда хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт, хезмәт теләге тәрбияләү. Кушылган биремгә карата җаваплылык мөнәсәбәте (эшне ахыргача җиткерә белү һәм җиткерү теләге, аны яхшы башкару омтылышы) формалаштыру.

Индивидуаль һәм коллектив йөкләмәләрне башкару, үз хезмәтенең башкалар өчен әһәмиятен аңлау тәрбияләү; тәрбияче ярдәмендә коллектив эшне бүлешү турында килешенү, уртак биремне вакытында башкарып чыгу турында кайгырту формалаштыру. Иптәшләренә, өлкән кешеләргә ярдәм итү инициативасын хуплау.

Балаларны мөстәкыйль рәвештә балалар бакчасының төркем бүлмәсендә һәм участогында тәртип сакларга өйрәтү: төзелеш материалын, уенчыкларны урыннарына җыеп кую; тәрбиячегә китапларны, тартмаларны ябыштырырга булышу.

Балаларны ашханәдә мөстәкыйль рәвештә дежурлык вазифаларын башкарырга өйрәтү: җыйнак итеп ипи савытларын, тәлинкәләре белән чынаякларны, тирән тәлинкәләрне урнаштыру, салфетка савытларын, өстәл приборларын (кашыклар, чәнечкеләр, пычаклар) кую.

**Табигатьтәге хезмәт.** Балаларның үсемлекләрне һәм хайваннарны карау-тәрбияләү теләген хуплау; үсемлекләргә су сибү, балыкларны ашату, суэчергечләрне юу, аларга су салу, улакка азык салу (тәрбияче катнашында).

Балаларны язгы, җәйге һәм көзге чорларда булдыра алганча яшелчә бакчасында һәм чәчәклектә эшләүгә (орлыклар чәчү, су сибү, уңышны җыю), кышкы чорда кар көрәүгә җәлеп итү.

Балаларны кошларга кышкы чорда ашату өчен үлән үстерүгә; кышлаучы кошларны ашатуга җәлеп итү.

Тәрбиячегә хезмәт эшчәнлегендә кулланылучы җиһазларны тәртипкә китерүдә (чистарту, киптерү, тиешле урынга илтү) булышу омтылышын формалаштыру.

**Өлкәннәр хезмәтенә ихтирам.** Балаларны, игътибарларын якын кешеләре хезмәтенең әһәмиятенә юнәлтеп, аларның һөнәрләре белән таныштыру. Әти-әниләренең һөнәрләренә карата кызыксыну формалаштыру.

## Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

**Культура-гигиена күнекмәләре.** Балаларда тәннең чисталыгын, киемнең, чәчнең пөхтәлеген карау; мөстәкыйль рәвештә тешләрне чистарту, юыну, кирәклектән чыгып кулларны юу, тырнакларның чисталыгын карау; йөткергәндә һәм төчкергәндә авызны һәм борынны кульъяулык белән каплау гадәтен формалаштыру.

Үзенең тышкы кыяфәтендәге җитешсезлекне күреп ала белергә өйрәтү һәм мөстәкыйль рәвештә тәртипкә китерү күнекмәләрен ныгыту.

Ашау культурасын: өстәл приборларыннан (чәнечке, пычак) дөрес файдалану; өстәл янында дөрес утырып, пөхтә, тавышланмыйча ашау; үтенеч белән мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү күнекмәләрен камилләштерү.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү.** Тиз, җыйнак киенү һәм чишенү, үз шкафында тәртип саклау (өс киемен билгеле урынга төреп кую), урын-җирне пөхтә итеп җыештыру күнекмәләрен ныгыту.

Материалларны һәм әсбапларны дәрескә мөстәкыйль рәвештә һәм үз вакытында әзерли белергә, тәрбияче тарафыннан дәрес уздыру өчен әзерләнгән материалларны мөстәкыйль рәвештә урнаштырырга, аларны җыеп куярга, пумалаларны һәм буяу савытларын, палитраны юарга, өстәлләрне сөртергә өйрәтү.

**Иҗтимагый-файдалы хезмәт.** Балаларда хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт, хәлдән килерлек хезмәт йөкләмәләрен башкару теләге тәрбияләү. Балаларга аларның хезмәтенең мөһимлеген аңлату.

Уртак хезмәт эшчәнлегендә катнашу теләге тәрбияләү. Хезмәтнең төрле төрләрендә кирәкле сәләтләр һәм күнекмәләр формалаштыру. Мөстәкыйльлек һәм җаваплылык, башланган эшне ахырына җиткерә белү тәрбияләү. Хезмәтнең төрле төрләрен башкарганда иҗадилык һәм инициативалылыкны үстерү.

Балаларны эшнең аеруча бәрәкәтле алымнары белән таныштыру. Хезмәт эшчәнлеге культурасы, материалларга һәм инструментларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

Үз эшенең нәтиҗәсен бәяләргә өйрәтү (өлкән кеше ярдәмендә).

Балалар арасында дустанә мөнәсәбәтләр; бергәләп уйнау, эшләү, шөгыльләнү гадәте тәрбияләү. Бер-береңә ярдәм итү теләген үстерү.

Балаларда уку-өйрәнү эшчәнлеге алшартлары (элементлары) формалаштыру. Игътибарны, куелган бурычны (нәрсә эшләргә), аны башкару ысулларын (ничек эшләргә) аңлауны үстерүне дәвам итү; түземлелек тәрбияләү; ахыргы нәтиҗәгә ирешү өчен үҗәтлек, максатка омтылучанлык күрсәтергә өйрәнү.

Балаларны төркемдә зурларга тәртип саклауда булышырга: уенчыкларны, төзелеш материалын һ.б. сөртеп куярга өйрәтүне дәвам итү.

Балалар бакчасы участогында тәртип урнаштыру (сукмакларны себерү һәм чүптән, кышкы чорда кардан чистару, комлыкта комга су сибү һ.б.) күнекмәләрен формалаштыру.

Ашханәдә дежурлык вазифаларын: табын әзерләү, ашаганнан соң өстәлне җыештыруны намуслы башкарырга өйрәтү.

**Табигатьтәге хезмәт.** Табигать почмагында хайваннарны һәм үсемлекләрне карау-тәрбияләү белән бәйле төрле йөкләмәләрне; табигать почмагында дежурлык вазифаларын (бүлмә үсемлекләренә су сибү, туфракны йомшарту һ.б.) башкару теләген хуплау.

Балаларны табигатьтә өлкәннәргә ярдәм итүгә һәм хәлдән килерлек эшкә: көзен — яшелчә бакчасында уңышны җыеп алуга, орлык җыюга, чәчәкле үсемлекләрне грунттан табигать почмагына күчереп утыртуга; кышын —

агач кәүсәләренә һәм куаклыкларга таба кар көрәүгә, кошлар һәм җәнлекләр (табигать почмагында яшәүчеләр) өчен үлән үстерүгә, тамыразыклар утыртуга, кардан сыннар һәм корылмалар төзүгә; язда туфрак йомшартуга, түтәлләргә һәм клумбаларга су сибүгә җәлеп итү.

**Өлкәннәр хезмәтенә ихтирам.** Балаларның өлкәннәр хезмәте, хезмәтнең нәтиҗәләре, иҗтимагый әһәмияте турындагы күзаллауларын киңәйтү. Кеше куллары белән эшләнгән әйберләргә карата сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру. Балаларда кешеләргә карата хезмәтләре өчен рәхмәтле булу хисе тәрбияләү.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

**Культура-гигиена күнекмәләре.** Тиз һәм дөрес юыну, шәхси сөлге белән корытып сөртенү, тешләрне дөрес чистарту, ашаганнан соң авызны чайкау, кулъяулыктан һәм тарактан файдалану гадәте тәрбияләү.

Балаларның өстәл приборларыннан пөхтә файдалану; табын артында үз-үзләрен дөрес тоту; үтенеч белән мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү күнекмәләрен ныгыту.

Өс һәм аяк киемнәренең чисталыгын карап тору, тышкы кыяфәттәге тәртипсезлекне күреп алу һәм тәртипкә китерү, иптәшенә әдәпле генә итеп киеменә, чәченә төзәтенү кирәклеген җиткерү күнекмәләрен ныгыту.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү.** Үзлектән һәм тиз генә киенү һәм чишенү, киемнәрне шкафка төреп кую, аяк киемен урынына кую, кирәк булганда юеш әйберләрне киптерү, аяк киемен карап тоту (юу, сөртү, чистарту) күнекмәләрен ныгыту.

Йокыдан торгач, урын-җирне мөстәкыйль рәвештә, тиз һәм пөхтә итеп җыештыру күнекмәләрен ныгыту.

Мөстәкыйль рәвештә һәм үз вакытында дәрес уздыру өчен материаллар һәм әсбаплар әзерләү, әйткәнне көтмичә, үзенең эш урынын җыештыру.

**Иҗтимагый-файдалы хезмәт.** Хезмәт сәләтләре һәм күнекмәләре формалаштыруны, хезмәт сөючәнлек тәрбияләүне дәвам итү. Балаларны кушылганны тырышып, пөхтә итеп үтәргә, материалларны һәм предметларны сакларга, эштән соң аларны урыннарына алып куярга өйрәтү.

Башкалар белән тигез дәрәҗәдә уртак хезмәт эшчәнлегендә катнашу теләге, әйләнә-тирәдәгеләр өчен файдалы булу омтылышы, коллектив хезмәт нәтиҗәләренә сөенү тәрбияләү. Мөстәкыйль рәвештә бергәләп уйнау һәм эшләү өчен берләшү, бер-береңә ярдәм итү сыйфатын үстерү.

Хезмәт эшчәнлеген планлаштыру, кирәкле материалларны сайлап алу, катлаулы булмаган эшләнмәләр ясау күнекмәләрен ныгыту. Балаларны төркемдә һәм участокта тәртип сакларга; уенчыкларны, төзелеш материалын сөртергә һәм юарга, тәрбияче белән бергә китапларны һәм уенчыкларны (шул исәптән балалар бакчасында кечерәк яшьтәгеләр төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр китапларын һәм уенчыкларын) төзәтергә өйрәтүне дәвам итү.

Балалар бакчасы участогында мөстәкыйль рәвештә тәртип урнаштырырга: сукмаларны себерергә һәм чүптән, кышын кардан чистартырга, комлык-

тагы комга су сибәргә; бәйрәмнәр алдыннан участокны бизәргә өйрәтүне дәвам итү.

Балаларны ашханәдә дежурлык вазифаларын намуслы башкарырга: тулысынча табын әзерләргә һәм ашаганнан соң өстәлләрне сөртергә, идәнне себерергә өйрәтү.

Уку эшчәнлегенә карата кызыксыну һәм мәктәптә уку теләге тәрбияләү.

Уку эшчәнлеге күнекмәләре (тәрбиячене игътибар белән тыңлау, ул тәкъдим иткән план буенча эшләү, шулай ук үз гамәлләреңне планлаштыру, куелган бурычны башкару, үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәләрен дөрес бәяләү) формалаштыру.

**Табигатьтәге хезмәт.** Табигать почмагында мөстәкыйль рәвештә һәм җаваплылык тоеп дежурлык вазифаларын башкару күнекмәләрен ныгыту: бүлмә үсемлекләренә су сибү, туфракны йомшарту, улакларны юу, балыклар, кошлар өчен азык әзерләү һ.б.

Балаларда табигатьтәге хезмәткә карата кызыксыну тәрбияләү, аларны хәлдән килерлек эшкә: көзен — яшелчә бакчасында уңышны җыеп алуга, орлыклар җыюга, чәчәкләрнең суганчаларын, бүлбеләрен казып алуга, түтәлләр казуга, чәчәкле үсемлекләрне грунттан табигать почмагына күчереп утыртуга; кышын — агач кәүсәләренә һәм куаклыкларга таба кар көрәүгә, кошлар һәм хайваннар (табигать почмагында яшәүчеләр) өчен үлән үстерүгә, тамыразыклар утыртуга, тәрбияче ярдәмендә бәйрәмнәр уздыру өчен чәчәкләр үстерүгә; язын — яшелчә бакчасында һәм чәчәклектә җир казуга, орлыклар (яшелчәләр, чәчәкләр орлыклары) чәчүгә, үсентеләрне туфракка утыртуга; җәен туфрак йомшартуга, чүп утауга һәм үсемлекләрнең төпләрен өюгә, түтәлләргә һәм клумбаларга су сибүгә җәлеп итү.

**Өлкәннәр хезмәтенә ихтирам.** Өлкәннәр хезмәте, алар хезмәтенең җәмгыять өчен әһәмияте турындагы күзаллауларны киңәйтү. Хезмәт кешеләренә хөрмәт тәрбияләү. Балаларны туган авыл, шәһәр (поселок) белән бәйле һөнәрләр белән таныштыруны дәвам итү.

Төрле һөнәрләргә, аерым алганда әти-әниләрнең һөнәрләренә һәм эш урыннарына карата кызыксынуны үстерү.

## Куркынычсызлык нигезләрен формалаштыру

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

**Табигатьтә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.** Табигатьтә үз-үзеңне тотуның элементар кагыйдәләре белән таныштыру (белмәгән хайваннарга якын килмәү, аларны сыйпамау, котыртмау; үсемлекләрне өзмәү һәм аларны авызга капмау һ.б.).

**Юлларда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.** Машиналар, урам, юл турында беренчел күзаллаулар формалаштыру.

Транспорт чараларының кайбер төрләре белән таныштыру.

**Үз тормыш эшчәнлегеңнең куркынычсызлыгы.** Предметлар дөньясы һәм предметлар белән хәвефсез эш итү кагыйдәләре белән таныштыру.

«Ярый-ярамый», «куркыныч» төшенчәләре белән таныштыру.

Ком һәм су белән уйнаганда куркынычсызлык кагыйдәләре турында күзаллаулар формалаштыру (суны эчмәскә, ком ыргытмаска һ.б.).

## Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

**Табигатьтә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.** Терек һәм терек булмаган табигатьтәге иң гади үзара бәйләнешләр турында күзаллаулар формалаштыру. Табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру (үсемлекләрне тиктомалдан өзмәү, агач ботакларын сындырмау, хайваннарга тимәү һ.б.).

**Юлларда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.** Әйләнә-тирәдә ориентлашу күнекмәләрен киңәйтү. Балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләре белән таныштыру.

Юлның йөри торган өлешен, тротуарны аера белергә, светофорның яшел, сары һәм кызыл сигналларының мәгънәсен аңларга өйрәтү.

Юлларда куркынычсызлык турында беренчел күзаллаулар формалаштыру (юл аркылы өлкән кешенең кулына тотынып чыгу).

Машина йөртүченең эше белән таныштыру.

**Үз тормыш эшчәнлегеңнең куркынычсызлыгы.** Өйдәге куркыныч чыганаклар (кайнар плитә, үтүк һ.б.) белән таныштыру.

Бина эчендә имин хәрәкәт итү күнекмәләре формалаштыру (баскычтан саклык белән, култыксаларга тотынып төшү һәм менү; ишекләрне ишек тоткасыннан тотып ачу һәм ябу).

Вак предметлар белән уйнаганда кагыйдәләрне үти белүне формалаштыру (предметларны колакка, борынга тыкмау; аларны авызга капмау).

Ярдәм сорап өлкәннәргә мөрәҗәгать итә белүне ныгыту.

Ком, су, кар белән уйнаганда куркынычсызлык күнекмәләре формалаштыру.

## Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

**Табигатьтә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.** Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының күптөрлелеге, терек булмаган табигать күренешләре белән таныштыруны дәвам итү.

Хайваннар һәм үсемлекләр белән үзара тәэсир итешү ысуллары, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында элементар күзаллаулар формалаштыру.

«Ашарга яраклы», «ашарга яраксыз», «дару үләннәре» төшенчәләрен аңлауны формалаштыру.

Куркыныч бөҗәкләр һәм агулы үсемлекләр белән таныштыру.

**Юлларда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.** Күзәтүчәнлек, балалар бакчасында бина эчендә һәм участокта, якын-тирәдә ориентлаша белү сәләтен үстерү.

«Урам», «юл», «урам чаты», «юл чаты», «җәмәгать транспорты тукталышы» төшенчәләре һәм урамда үз-үзеңне тотуның элементар кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү. Балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәүнең зарур булуын аңлауга китерү.

Балаларның светофорның кирәклеге һәм полицейскийның эше турындагы белемнәрен ачыклау.

Балаларны шәһәр транспортының төрләре, аларның тышкы күренешләренең һәм кулланылышының үзенчәлекләре белән таныштыру («Ашыгыч ярдәм», янгын сүндерү машинасы, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (МЧС) машинасы, «Полиция», трамвай, троллейбус, автобус).

Юл хәрәкәте билгеләре: «Җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу урыны», «Җәмәгать транспорты тукталышы» белән таныштыру.

Җәмәгать транспортында үз-үзеңне культуралы тоту күнекмәләре формалаштыру.

**Үз тормыш эшчәнлегеңнең куркынычсызлыгы.** Уеннар вакытында үз-үзеңне хәвефсез тоту кагыйдәләре белән таныштыру. Тормышка һәм сәламәтлеккә куркыныч тудыручы хәлләр турында сөйләү.

Көнкүреш приборларының (тузан суырткыч, электр чәйнеге, үтүк һ.б.) кирәклеге, эше һәм алардан файдалану кагыйдәләре белән таныштыру.

Өстәл приборларыннан (чәнечке, пычак), кайчыдан файдалану күнекмәләрен ныгыту.

Велосипедта йөрү кагыйдәләре белән таныштыру.

Таныш булмаган кешеләр янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

Балаларга янгын сүндерүчеләр эше, янгыннарның килеп чыгу сәбәпләре һәм янгын вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында сөйләү.

## Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

**Табигатьтә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү**. Экологик культура һәм табигатьтә куркынычсызлык кагыйдәләре нигезләрен формалаштыру.

Табигатьтә бар нәрсәнең үзара бәйләнештә булуы, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясына зыян китермәү өчен кешенең бу үзара бәйләнешне бозарга тиеш түгеллеге турында төшенчәләр формалаштыру.

Терек булмаган табигать күренешләре (яшенле яңгыр, күк күкрәү, яшен, салават күпере), яшенле яңгыр вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

Балаларны бәрелгәндә һәм бөҗәкләр тешләгәндә беренче ярдәм күрсәтү кагыйдәләре белән таныштыру.

**Юлларда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.** Балаларның юл элементлары (машина юлы, җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу урыны, тротуар), транспорт хәрәкәте, светофор эше турындагы белемнәрен ачыклау.

Балалар бакчасына якын урнашкан урамнар һәм балалар яши торган урамнарның исемнәре белән таныштыру.

Юл хәрәкәте кагыйдәләре, җәяүлеләр һәм велосипедчылар хәрәкәте кагыйдәләре белән таныштыру.

«Балалар», «Трамвай тукталышы», «Автобус тукталышы», «Җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу урыны», «Беренче медицина ярдәме күрсәтү пункты», «Туклану пункты», «Машина кую урыны», «Керү тыела», «Юл эшләре», «Велосипед юлы» дигән юл билгеләре белән таныштыруны дәвам итү.

**Үз тормыш эшчәнлегеңнең куркынычсызлыгы.** Кешенең тереклек эшчәнлеге иминлеге нигезләрен ныгыту.

Елның төрле фасылларында уен вакытында (сулыкларда коену, велосипедта йөрү, чанада, тимераякта, чаңгыда шуу һ.б.) куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.

Көнкүрештәге хәвеф чыганаклары (электр приборлары, газ плитәсе, үтүк һ.б.) турындагы белемнәрне киңәйтү. Көнкүреш предметларыннан хәвефсез файдалану күнекмәләрен ныгыту.

Балаларның янгын сүндерүчеләр, янгыннарның сәбәпләре, янгын вакытында үз-үзеңне тотуның элементар кагыйдәләре турындагы белемнәрен ачыклау. Коткару хезмәте — МЧС эше белән таныштыру. Бик кирәк булган очракта өлкәннәрнең «01», «02», «03» телефоннары буенча шалтыратулары турындагы белемнәрне ныгыту.

Ярдәм сорап өлкәннәргә мөрәҗәгать итә белү күнекмәләре формалаштыру.

Баланы үз исемен, фамилиясен, яшен, өй адресын, телефонын атарга өйрәтү.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

**Табигатьтә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.** Экологик культура нигезләрен формалаштыру.

Табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.

Кызыл китап, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының аңа кертелгән аерым вәкилләре белән таныштыру.

Табигатьнең яшенле яңгыр, күк күкрәү, яшен, салават күпере, давыл кебек күренешләре турындагы күзаллауларны ачыклау һәм киңәйтү, кешенең шундый шартларда үз-үзен тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

**Юлларда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.** Балаларның юл төзелеше, юл хәрәкәте турындагы белемнәрен системалаштыру. «Мәйдан», «бульвар», «проспект» төшенчәләре белән таныштыру.

Юл йөрүнең кисәтүче, тыючы һәм мәгълүмат бирүче билгеләре белән таныштыруны дәвам итү.

Балаларны юл йөрү кагыйдәләрен үтәүнең зарурлыгын аңлауга китерү.

Балаларның ЮХИДИ эше турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Урамда һәм җәмәгать транспортында үз-үзеңне тоту культурасы тәрбияләү.

Балалар бакчасына якын булган җирлек чикләрендә ориентлашуны үстерү. Җирлек схемасында өйдән балалар бакчасына юлны таба белүне формалаштыру.

**Үз тормыш эшчәнлегеңнең куркынычсызлыгы.** Балаларда файдалы һәм кирәкле көнкүреш предметларының алардан белмичә файдаланганда зыян китерү һәм бәла-казага сәбәпче булуы ихтималы турында күзаллаулар формалаштыру (электр приборлары, газ плитәсе, инструментлар һәм көнкүреш предметлары). Көнкүреш предметлары белән куркынычсыз эш итү кагыйдәләрен ныгыту.

Елның төрле фасылларында уен вакытында (сулыкларда коену, велосипедта йөрү, чанада, тимераякта, чаңгыда шуу һ.б.) үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту.

Балаларны саклык чараларын үтәү зарурлыгын аңлауга китерү, куркынычны җиңү өчен үз мөмкинлекләрен бәяләргә өйрәтү.

Балаларда «Өйдә ялгыз калу», «Югалу», «Адашу» очракларында үз-үзләрен тоту күнекмәләре формалаштыру. Ярдәм сорап өлкәннәргә мөрәҗәгать итә белү сәләте формалаштыру.

Балаларның Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, янгын сүндерү хезмәте, ашыгыч ярдәм хезмәте эше турындагы белемнәрен киңәйтү. Янгын сүндерүчеләр эше, янгын вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турындагы белемнәрен ачыклау. Бик кирәк булган очракта өлкәннәрнең «01», «02», «03» телефоннары буенча шалтыратулары турындагы белемнәрне ныгыту.

Баланың үз исемен, фамилиясен, яшен, өй адресын, телефонын атый белүен ныгыту.

## «ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ» белем бирү өлкәсе

«Танып белү үсеше баланың мәнфәгатьләре, кызыксынучанлыгы һәм танып белү омтылышы үсешен; танып белү гамәлләре, аңы формалашуын; хыялы һәм иҗади активлыгы үсешен; үзе, башка кешеләр, әйләнә-тирәдәге объектлар, әйләнә-тирәдәге объектларның үзлекләре һәм үзара бәйләнешләре (форма, төс, үлчәм, материал, яңгыраш, ритм, темп, микъдар, сан, өлеш һәм бөтенлек, тирәлек һәм вакыт, хәрәкәт һәм тыныч халәт, сәбәпләр һәм нәтиҗәләр һ.б.), туган җир һәм Туган ил турындагы беренчел күзаллаулары, халкыбызның социомәдәни кыйммәтләре, Ватаныбызның традицияләре һәм бәйрәмнәре, кешеләрнең уртак һәм гомуми йорты буларак Җир планетасы, аның табигатенең үзенчәлекләре, дөньядагы илләрнең һәм халыкларның күптөрлелеге турындагы күзаллаулары формалашуын күз алдында тота»[1].

[1] МББ ФДББСның 2.6. пунктын кара.

## Төп максатлар һәм бурычлар

**Элементар математик күзаллаулар формалаштыру.** Элементар математик күзаллаулар, әйләнә-тирә объектларының төп сыйфатлары һәм бәйләнешләре: форма, төс, үлчәм, микъдар, сан, өлеш һәм бөтенлек, тирәлек һәм вакыт турындагы беренчел күзаллаулар формалаштыру.

**Танып белү-тикшеренү эшчәнлеген үстерү.** Балаларның танып белү омтылышын үстерү, тирәлектә ориентлашу тәҗрибәсен киңәйтү, сиземләү үсеше, кызыксынучанлык һәм танып белү нигезен үстерү; танып белү гамәлләрен, аңны формалаштыру; хыялны һәм иҗади активлыкны үстерү; әйләнә-тирә объектлары, әйләнә-тирә объектларының үзлекләре һәм үзара бәйләнешләре (форма, төс, үлчәм, материал, яңгыраш, ритм, темп, сәбәпләр һәм нәтиҗәләр һ.б.) турында беренчел күзаллаулар формалаштыру.

Аңга кабул итүне, игътибарны, хәтерне, күзәтүчәнлекне, әйләнә-тирә предметларының һәм күренешләренең үзенчәлекле, мөһим билгеләрен анализлау, чагыштыру, аерып күрсәтү, предметлар һәм күренешләр арасындагы иң гади бәйләнешләрне ачыклау, иң гади гомумиләштерүләр ясый белү сәләтен үстерү.

**Предметлы тирәлек белән таныштыру.** Предметлы тирәлек белән таныштыру (предметның аталышы, функциясе, кулланылышы, сыйфатлары); предметны кеше фикерләве һәм хезмәт нәтиҗәсе буларак кабул иттерү.

Предметлы тирәлекнең күптөрлелеге, кешенең, тормышны җайлырак һәм уңайлырак итеп, үзе һәм башка кешеләр өчен предметлы тирәлек тудыруы, аны үзгәртүе һәм камилләштерүе турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Предметлар дөньясы һәм табигый дөнья арасындагы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен ачыклый белү сәләтен үстерү.

**Социаль дөнья белән таныштыру.** Әйләнә-тирә социаль мохите белән таныштыру, балаларның белем дәрәҗәсен киңәйтү, дөньяның тулай картинасын формалаштыру. Туган җир һәм Туган ил турында беренчел күзаллаулар, халкыбызның социомәдәни кыйммәтләре, илебезнең традицияләре һәм бәйрәмнәре турында күзаллаулар формалаштыру. Гражданлык мөнәсәбәтен формалаштыру; Ватанга мәхәббәт, аның казанышлары белән горурлану, патриотик хисләр тәрбияләү. Кешеләрнең уртак һәм гомуми йорты буларак Җир планетасы, дөньядагы илләрнең һәм халыкларның күптөрлелеге турында элементар күзаллаулар формалаштыру.

**Табигать дөньясы белән таныштыру.** Табигать һәм табигать күренешләре белән таныштыру. Табигать күренешләре арасындагы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклый белү сәләтен үстерү. Җир планетасының табигый күптөрлелеге турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Элементар экологик күзаллаулар формалаштыру. Кешенең табигатьнең бер өлеше булуын, аның табигатьне сакларга һәм якларга тиешлеген, табигатьтә бар нәрсәнең дә үзара бәйле булуын, кешенең Җирдәге тормышының күп очракта әйләнә-тирә дөнья белән бәйлелеген аңлауны формалаштыру. Табигатьтә

үз-үзеңне дөрес тоту күнекмәләре формалаштыру. Табигатькә карата мәхәббәт, аны саклау теләге тәрбияләү.

## Психологик-педагогик эш эчтәлеге

## Элементар математик күзаллаулар формалаштыру

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

**Микъдар.** Балаларны бертөрле предметлар төркеме формалаштыруга җәлеп итү. Предметлар микъдарын аерырга өйрәтү (бер — күп).

**Зурлык.** Балаларның игътибарын контраст зурлыктагы предметларга һәм аларны сөйләмдә билгеләүгә җәлеп итү (зур йорт — кечкенә йорт, зур курчак — кечкенә курчак, зур туплар — кечкенә туплар һ.б.).

**Форма.** Предметларны формасы буенча аерырга һәм аларны атарга өйрәтү (шакмак, кечкенә кирпеч, шар һ.б.).

**Тирәлектә ориентлашу.** Балаларда әйләнә-тирәне (балалар бакчасындагы төркем бүлмәләре һәм участок) практик үзләштерү тәҗрибәсе туплауны дәвам итү.

Үз гәүдәңнең өлешләрендә (баш, йөз, куллар, аяклар, җилкә) ориентлашу тәҗрибәсен киңәйтү.

Тәрбияче артыннан билгеле бер юнәлештә хәрәкәтләнергә өйрәтү.

### Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

**Микъдар.** Төркем предметларының гомуми билгесен күрә белүне үстерү (барлык туплар йомры, боларның барысы да кызыл, боларның барысы да зур һ.б.).

Бертөрле предметлар төркеме төзергә һәм алар арасыннан аерым предметларны аерып алырга; «күп», «бер», «берәрләп», «берәү дә юк» төшенчәләрен аерырга; тирәлектә бер һәм берничә бертөрле предметны табарга; «Ничә?» соравын аңларга; җавап биргәндә «күп», «бер», «берәү дә юк» сүзләрен кулланырга өйрәтү.

Элементларны (предметларны) капма-каршы кую нигезендә предметларның ике тигез (тигез булмаган) төркемен чагыштыру. Эзлекле рәвештә бер төркем предметларын икенче төркем предметлары өстенә һәм янына кую алымнары белән таныштыру; «Болар тигезме?», «Кайсы күбрәк (азрак)?» сорауларын аңларга; сорауларга «Мин һәр түгәрәккә гөмбә куйдым. Түгәрәкләр күбрәк, ә гөмбәләр азрак» яки «Түгәрәкләр гөмбәләр санынча» кебек җөмләләр кулланып җавап бирергә өйрәтү.

Бер яки берничә предметны азрак санлы предметлар төркеменә өстәү яки күбрәк санлы предметлар төркеменнән бер предметны алу юлы белән предметлары тигез булмаган төркемнәрне тигезләргә өйрәтү.

**Зурлык.** Контраст һәм бертөрле зурлыктагы предметларны чагыштыру; предметларны чагыштырганда өстенә һәм янына кую алымнарын кулланып, бирелгән зурлык билгесе (озынлык, киңлек, биеклек, гомуми зурлык) буенча бер предметны икенчесенә карата үлчәү, чагыштыру; чагыштыру нәтиҗәләрен сүзләр белән билгеләү (озын — кыска, озынлык буенча бертөрле (тигез), киң — тар, киңлек буенча бертөрле (тигез), биек — тәбәнәк, биеклек буенча бертөрле (тигез), зур — кечкенә, зурлык буенча бертөрле (тигез).

**Форма.** Балаларны геометрик фигуралар: түгәрәк, квадрат, өчпочмак белән таныштыру. Күрү һәм капшау нәтиҗәсендә әлеге фигураларның формасын тикшерергә өйрәтү.

**Тирәлектә ориентлашу.** Үз гәүдәсенең төрле өлешләре урнашуда ориентлашу һәм әгъзаларының үзенә карата юнәлешләрен аера белүне үстерү: өстә — аста, алда — артта, уңда — сулда. Уң һәм сул кулларны аера белү.

**Вакыт буенча ориентлашу.** Тәүлекнең контраст өлешләрендә ориентлашырга өйрәтү: көн — төн, иртә — кич.

## Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

**Микъдар һәм исәп.** Балаларга күплекнең («күп») төрле сыйфатлы элементлардан: төрле төстәге, зурлыктагы, формадагы предметлардан тору ихтималы турында күзаллау мөмкинлеге бирү; предметларны парлап урнаштыру нигезендә (санамыйча гына) күплекләрнең тигезлеген яки тигез булмавын ачыклау нәтиҗәсендә аларның өлешләрен чагыштырырга өйрәтү. Балаларның сөйләменә «Биредә түгәрәкләр күп, аларның бер өлеше — кызыл, икенчеләре зәңгәр төстә; кызыл түгәрәкләр зәңгәрләренә караганда күбрәк, зәңгәр түгәрәкләр кызылларына караганда азрак» яки «кызыл һәм зәңгәр түгәрәкләр саны бертигез» гыйбарәләрен кертү.

Исәпләү кагыйдәләрен кулланып, 5 кә кадәр санарга өйрәтү (күрсәтеп башкару нигезендә): саннарны тәртип буенча атау; һәр санны санала торган төркемдәге бер предмет белән бәйләү; соңгы санны саналган барлык предметларга карата куллану, мәсәлән: «Бер, ике, өч — барлыгы өч түгәрәк». Предметларның 1–2, 2–2, 2–3, 3–3, 3–4, 4–4, 4–5, 5–5 саннары белән аталган ике төркемен чагыштыру.

Тәртип буенча санау турында күзаллау формалаштыру, микъдар һәм тәртип саннарын дөрес кулланырга, «Ничә?», «Исәп буенча ничәнче?», «Ничәнче урында?»сорауларына җавап бирергә өйрәтү.

«Биредә бер, ике куян, ә монда бер, ике, өч чыршы. Чыршылар куяннарга караганда күбрәк; 2 гә караганда 3 күбрәк, 3 кә караганда 2 азрак» дип санау нигезендә төркемнәрнең тигез яки тигез булмавы турында күзаллау формалаштыру.

Кечерәк төркемгә бер (җитмәгән) предмет өстәп яки зуррак төркемнән бер (артык) предметны алып, ике ысул белән тигез булмаган төркемнәрне тигезләргә өйрәтү («2 куянга 1 куян өстәдек, 3 куян булды һәм чыршылар да өчәү. Чыршылар һәм куяннар саны бертигез — 3 һәм 3» яки: «Чыршылар күбрәк (3), ә куяннар азрак (2). 1 чыршыны алып куйдык, хәзер чыршылар да 2 булды. Чыршылар һәм куяннар саны тигезләште: 2 һәм 2».

Күпсанлы төркемнән предметларны санап чыгу; үрнәкләре яки кушылган (бирелгән) сан буенча 5 саны чикләрендә билгеле бер санда предметларны кую, китерү (4 әтәч санап ал, 3 куян алып кил).

Төркемдәге предметлар бер-берсеннән төрле ераклыкта урнашканда, алар зурлыклары, урнашу рәвеше буенча бер-берсеннән аерылып торган халәттә санау-исәпләү нигезендә предмет төркемнәренең тигезлеген (тигез булмавын) билгеләү.

**Зурлык.** Ике предметны зурлыклары (озынлык, киңлек, биеклек) буенча чагыштыра белүне камилләштерү, шулай ук ике предметны бер-берсе өстенә яки янына кую юлы белән аларны калынлыклары буенча чагыштырырга өйрәтү; сыйфатлар кулланып, чагыштыру нәтиҗәләрен сөйләмдә чагылдыру (озынрак — кыскарак, киңрәк — таррак, биегрәк — тәбәнәгрәк, калынрак — юкарак яки озынлык, киңлек, биеклек, калынлык буенча тигез (бертөрле)).

Предметларны зурлыкның ике билгесе буенча чагыштырырга өйрәтү (кызыл тасма яшеленнән озынрак һәм киңрәк, сары шарф зәңгәреннән кыскарак һәм таррак).

Төрле озынлыктагы (киңлектәге, биеклектәге), калынлыктагы 3–5 предмет арасындагы зурлык чагыштырмаларын билгеләү, бу предметларны билгеле бер эзлеклелектә — зурлык кими яки үсә бару тәртибендә урнаштыру. Балаларның актив сөйләменә предметларның зурлык чагыштырмаларын белдерүче төшенчәләр кертү («бу (кызыл) манара — арада иң биеге, бу (кызгылт-сары) манара тәбәнәгрәк, бу (алсу) манара тагын да тәбәнәгрәк, ә бу (сары) манара — арада иң тәбәнәге» һ.б).

**Форма.** Балаларның геометрик фигуралар — түгәрәк, квадрат, өчпочмак, шулай ук шар, куб турындагы күзаллавын үстерү. Күрү һәм тою-хәрәкәт анализаторлары ярдәмендә фигураларның үзенчәлекле билгеләрен (почмаклар булу һәм булмау, тотрыклылык, хәрәкәтчәнлек һ.б.) аерырга өйрәтү.

Түгәрәк, квадрат, өчпочмак белән чагыштырып, балаларны турыпочмаклык белән таныштыру. Балаларны турыпочмаклыкны, аның элементларын — почмакларын һәм якларын аерырга һәм атарга өйрәтү.

Фигураларның төрле зурлыкта була алулары турында күзаллау формалаштыру: зур — кечкенә куб (шар, түгәрәк, квадрат, өчпочмак, турыпочмаклык).

Предметларның формасын билгеле геометрик фигуралар белән тиңләштерергә өйрәтү: тәлинкә — түгәрәк, яулык — квадрат, туп — шар, тәрәзә, ишек — турыпочмаклык һ.б.

**Тирәлектә ориентлашу.** Үзеннән читкә таба тирәлек юнәлешләрен билгеләү, билгеләнгән юнәлештә (алга — артка, уңга — сулга, югарыга — түбәнгә) хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерү, предметларның үзеңә карата

урнашуын сүзләр белән билгеләү (каршымда — өстәл, уң ягымда — өстәл, сул ягымда — тәрәзә, артымдагы киштәләрдә — уенчыклар).

Тирәлек чагыштырмалары белән таныштыру: ерак — якын (йорт якында урнашкан, ә каен еракта үсә).

**Вакыт буенча ориентлашу.** Балаларның тәүлек өлешләре, аларның характерлы үзенчәлекләре, эзлеклелеге (иртә — көндез — кич — төн) турындагы күзаллауларын киңәйтү.

«Кичә», «бүген», «иртәгә» сүзләренең мәгънәләрен аңлату.

## Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

**Микъдар һәм исәп.** Төрле сыйфатлы элементлардан (төрле төстәге, зурлыктагы, формадагы, кулланылыштагы предметлардан; тавышлардан хәрәкәтләрдән) күплекләр (предмет төркемнәре) төзергә өйрәтү; күплекләрне өлешләргә таркату һәм шул өлешләрне яңадан кушу; тулай күплек һәм аның һәр өлеше арасындагы бәйләнешне ачыклау, күплекнең өлештән зуррак, ә өлешнең тулай күплектән азрак (кечерәк) булуын аңлау; санау-исәпләү һәм бер элементны (предметны) икенчесе белән тиңләштерү нигезендә күплекнең төрле өлешләрен чагыштыру; күплекнең зур (кечкенә) өлешен яки аларның тигезлеген ачыклау.

10 га кадәр санарга өйрәнү; эзлекле рәвештә 5 тән 10 га кадәр чикләрдә һәр санның ясалуы белән таныштыру (әсбап нигезендә).

10 га кадәрге чикләрдә конкрет күплекләрне чагыштыру нигезендә янәшә торучы саннарны чагыштыру; кечерәк күплеккә бер предмет өстәп яки зуррак күплектән бер предметны алып, тигезсезлектән тигезлек (тигезлектән тигезсезлек) булдыру («8 дән 7 кечерәк, әгәр 7 гә бер предмет өстәсәк, 8, тигез була»; «7 дән 8 зуррак, әгәр 8 предметтан бер предметны алсак, 7 шәр, тигез була»).

Янәшә торган саннарның чагыштырмаларын аңлау сәләте формалаштыру ($5<6$ дан 1 гә, $6>5$ тән 1 гә).

Зур күплектән предметларны үрнәкләре һәм билгеләнгән сан буенча санап аерып алу (10 чикләрендә).

Туры һәм кире тәртиптә санау тәртибен камилләштерү (10 чикләрендә).

Предметларны капшап санау, авазларны, хәрәкәтләрне үрнәкләре һәм билгеләнгән сан буенча санау һәм кабатлау (10 чикләрендә).

0 дән 9 га кадәр саннар белән таныштыру.

10 чикләрендә тәртип буенча санау белән таныштыру, «Ничә?», «Ничәнче?», «Нинди?» сорауларын аерырга һәм аларга дөрес җавап бирергә өйрәтү.

Тигезлек турында күзаллау формалаштыруны дәвам итү: төрле предметлардан торган төркемнәрдә тигез микъдар булуын ачыклау; төркемнәрне санау-исәпләү һәм чагыштыру нигезендә санлы мәгънәләрне дөрес гомумиләштерү (биредә 5 әтәч, 5 курчак, 5 машина — барлык уенчыклар да тигез санда — 5 әр).

Балаларны санның предметларның зурлыгына, предметлар арасындагы арага, формага, предметларның урнашуына, шулай ук санау-исәпләүнең юнәлешенә (уңнан сулга, сулдан уңга таба, теләсә кайсы предметтан башлап) бәйле булмавын аңларга өйрәтү.

Конкрет материал мисалында 5 чикләрендә санның берәмлекләрдән торган микъдар составы белән таныштыру: 5 — бер, тагын бер, тагын бер, тагын бер һәм тагын бер.

**Зурлык.** Төрле озынлыктагы (биеклектәге, киңлектәге) яки калынлыктагы 5–10 предмет арасындагы зурлык чагыштырмаларын ачыкларга өйрәтү: зурлыклары буенча үсә (кими) бару тәртибендә урнаштырып, предметларны системалаштыру; сөйләмдә предметларның урнашу тәртибен һәм алар арасындагы зурлык чагыштырмасын чагылдыру: «Алсу тасма — иң киңе, шәмәхә тасма — бераз таррак, кызыл тасма тагын да таррак, ләкин ул сары тасмадан киңрәк, ә яшел тасма сарысыннан һәм барлык башка тасмалардан да таррак» һ.б.

Зурлык (озынлык, киңлек, биеклек) буенча ике предметны өченчесе (шартлы үлчәү берәмлеге), чагыштырылучы предметларның берсенә тиң предмет ярдәмендә чагыштыру.

Күз үлчәмен, үрнәк итеп алынган предметтан озынрак (кыскарак), биегрәк (тәбәнәгрәк), киңрәк (таррак) һәм аңа тиң предметларны эзләп таба белү сәләтен үстерү.

Предметны (кәгазь бите, тасма, түгәрәк, квадрат һ.б.) берничә (ике, дүрт) тигез өлешкә бүлеп булуны аңлауны формалаштыру.

Бүлгәннән соң барлыкка килгән өлешләрне атарга, бербөтенне һәм өлешләрне чагыштырырга, бербөтен предметның аның барлык өлешләреннән зуррак, ә өлешнең бербөтеннән кечерәк булуын аңларга өйрәтү.

**Форма.** Түгәрәк һәм турыпочмаклык белән чагыштыру нигезендә балаларны овал белән таныштыру.

Дүртпочмаклык турында күзаллау булдыру: квадрат һәм турыпочмаклыкның дүртпочмаклык төрләре булуын аңлауга ирешү.

Балаларда геометрик күрү үткенлеге: предметларны формалары буенча анализлау һәм чагыштыру, якын-тирәдәге бертөрле һәм төрле формадагы предметларны: турыпочмаклык рәвешендәге китапларны, картинаны, одеялны, өстәл капкачларын, овал рәвешендәге поднос һәм зур тәлинкәне, түгәрәк әйберләрдән тәлинкәләрне һ.б. таба белүне үстерү.

**Тирәлектә ориентлашу.** Тирәлектә ориентлашуны камилләштерү; тирәлектәге чагыштырмалар мәгънәсен аңлау (өстә — аста; алда (алдында) — артта (артында), сулда — уңда, арасында, янәшәсендә, янында); сигналлар буенча үзгәртүләр белән, шулай ук билгеләр — хәрәкәт юнәлешләре күрсәткечләре (алга, артка, сулга, уңга һ.б.) буенча билгеләнгән юнәлештә хәрәкәт итү; тирәлектәге кешеләр һәм предметлар арасында үзеңнең урыныңны ачыклау: «Мин Алсу һәм Гөлназ арасында, Мансур артында, Гүзәлдән арттарак (аның артында), Наҗия алдында, Аяз янында басып торам», сөйләмдә предметларның үзара торышын күрсәтү: «Курчактан уңда куян утыра, ә курчактан сулда ат басып тора, артта — аю баласы, ә алда — машина».

Кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтү (уңда — сулда, өстә — аста, уртада, почмакта).

**Вакыт буенча ориентлашу.** Балаларда иртә, кич, көн һәм төннең тәүлек тәшкил итүе турында күзаллау булдыру.

Конкрет мисалларда төрле вакыйгаларның эзлеклелеген билгеләргә өйрәтү: элегрәк (башта) нәрсә булды, соңрак (аннары) нәрсә булды; бүген кайсы көн, кичә нинди көн булуын, иртәгә кайсы көн булачагын ачыклау.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

**Микъдар һәм исәп.** Күплек турында гомуми күзаллаулар: билгеләнгән нигезләр буенча күплекләр формалаштыру, күплекнең предметлары аерым билгеләре буенча аерылучы өлешләрен күреп ала белү сәләте формалаштыру.

Күплекләрне берләштерергә, тулыландырырга, күплектән аның бер өлешен яки аерым өлешләрен алырга өйрәтү. Предметларны санау-исәпләү, аларның парларын төзү яки предметларны уклар белән бәйләү нигезендә күплекнең аерым өлешләре, шулай ук тулай күплек һәм аның һәр өлеше арасындагы бәйләнешләрне ачыклау.

10 чикләрендә микъдар һәм тәртип буенча санау күнекмәләрен камилләштерү. Саннар белән гамәлләр башкармыйча гына 20 чикләрендә санау белән таныштыру.

Икенче дистә саннары белән таныштыру. Натураль рәт саннары арасындагы чагыштырманы аңлауны (6 дан 7 1гә зуррак, 7 дән 6 1 гә кечерәк), һәр санны 1 гә кечерәйтә һәм зурайта белүне ныгыту (10 чикләрендә).

Саннарны уңай һәм кире тәртиптә санарга (телдән), аталган яки цифра белән билгеләнгән санның алдындагы һәм артындагы саннарны, төшеп калган санны атарга өйрәтү.

10 чикләрендә саннар составы белән таныштыру.

Санны ике кечерәк санга бүләргә һәм ике кечерәк саннан зур сан төзергә өйрәтү (10 чикләрендә, күрсәтмә әсбап нигезендә).

1, 5, 10 тиенлек, 1, 2, 5, 10 сумлык акчалар белән таныштыру (акчаларны аеру, туплау һәм ваклау).

Күрсәтмә әсбаплар нигезендә кушу (зурга кечкенә кушыла) һәм алу (киметүче калдыктан кечерәк) гамәлләре буенча гади математик мәсьәләләр төзергә һәм чишәргә өйрәтү; мәсьәләләрне чишкәндә гамәл билгеләре: кушу/плюс (+), алу/ минус (–) һәм тигезлек (=) билгеләрен куллану.

**Зурлык.** Санау берәмлеге буларак бер генә түгел, берничә предмет яки предмет өлеше кабул ителгән зурлык буенча санарга өйрәтү.

Предметны (кәгазь, тукыма һ.б.) бөкләү юлы белән, шулай ук шартлы зурлыкны кулланып, предметны 2–8 һәм күбрәк тигез өлешләргә бүлү; бербөтеннең өлешләрен дөрес билгеләү (ярты, ике өлешнең берсе (икедән бер), дүрт өлешнең икесе (дүрттән ике) һ.б.); бербөтеннең һәм өлешнең, өлешләр зурлыгының чагыштырмасын ачыклау; бербөтеннең өлешләрен һәм билгеле өлешләр буенча бербөтенне таба белү.

Балаларда башлангыч үлчәү күнекмәләре формалаштыру. Шартлы үлчәү берәмлеге (шакмаклы кәгазь) ярдәмендә предметларның озынлыгын, киңлеген, биеклеген (туры сызык кисемтәләре) үлчәргә өйрәтү.

Шартлы үлчәү берәмлеге ярдәмендә балаларны сыек һәм бөртекле матдәләр күләмен үлчәргә өйрәтү.

Предметларның авырлыгы һәм аны үлчәү ысуллары турында күзаллаулар булдыру. Учка салып үлчәү юлы белән предметларның авырлыгын чагыштыру (авыррак — җиңелрәк). Үлчәү белән таныштыру.

Үлчәү нәтиҗәсенең (предметларның озынлыгы, авырлыгы, күләме) шартлы үлчәү берәмлеге зурлыгына бәйле булуы турындагы күзаллауны үстерү.

**Форма.** Билгеле геометрик фигураларны, аларның элементларын (түбәләр, почмаклар, яклар) һәм башка кайбер үзлекләрен белүне ачыклау.

Күппочмаклык (өчпочмак һәм дүртпочмаклык мисалында), туры сызык, туры сызык кисемтәсе турында күзаллау булдыру[1].

Тирәлектә урнашуларына бәйсез рәвештә фигураларны танырга, яссылыкта сурәтләргә, урнаштырырга, зурлыклары буенча тәртипкә салырга, классификацияләргә, төс, форма, зурлык буенча төркемләштерергә өйрәтү.

Геометрик фигураларны модельләштерү; берничә өчпочмактан — күппочмаклык, берничә кечкенә квадраттан — бер зур турыпочмаклык, түгәрәк өлешләреннән — түгәрәк, дүрт кисемтәдән — дүртпочмаклык, ике кыска кисемтәдән бер зур кисемтә һ.б. төзергә өйрәтү; телдән тасвирлау һәм характерлы үзлекләрен санап чыгудан фигуралар конструкцияләү; фигуралардан үзең уйлаганча тематик композицияләр төзү.

Предметларның гомуми формасын һәм аларның аерым өлешләрен анализлау; контурлы үрнәкләр, тасвирлаулар, күзаллаулар буенча аерым өлешләрдән катлаулы формалы предметларны яңадан ясау.

**Тирәлектә ориентлашу.** Чикләнгән территориядә (кәгазь бите, уку тактасы, дәфтәр, китап бите һ.б.) ориентлашуга өйрәтү; предметларны һәм аларның сурәтләрен билгеләнгән юнәлештә урнаштыру, сөйләмдә аларның тирәлектә урнашуын чагылдыру (өстә, аста, өстәрәк, астарак, сулда, уңда, сулдарак, уңдарак, сулдагы өске (уңдагы аскы) почмакта, алда, артта, арасында, янәшә, янәшәсендә һ.б.).

План, схема, маршрут, карта белән таныштыру.

Тирәлектә объектлары арасындагы бәйләнешләрне рәсем, план, схема рәвешендә модельләштерү сәләтен үстерү.

Объектларның тирәлектәге бәйләнешләрен һәм аларның тирәлектәге хәрәкәтен белдерүче иң гади график мәгълүматны «укырга» өйрәтү: сулдан уңга, уңнан сулга, астан өскә, өстән аска; шартлы билгеләргә (тамгалар һәм символлар) ориентлашып, тирәлектә мөстәкыйль хәрәкәт итү.

**Вакыт буенча ориентлашу.** Балаларда вакыт турында элементар күзаллаулар: аның узучанлыгы, периодиклыгы, кире кайтмаслыгы, атнаның барлык көннәренең, айларның, ел фасылларының эзлеклелеге турында күзаллаулар булдыру.

---

[1] Билгеләмәләр бирелми.

Сөйләмдә «башта», «аннары», «кадәр», «соң», «элегрәк», «соңрак», «шул ук вакытта» төшенчәләрен кулланырга өйрәтү.

«Вакытны тою», вакытны саклау, үз эшчәнлегеңне вакытка туры китереп көйли белү сәләтен үстерү; аерым вакыт интерваллары дәвамлылыгын (1 минут, 10 минут, 1 сәгать) аеру.

Сәгатькә карап, вакытны 1 сәгатькә кадәр төгәллек белән билгеләргә өйрәтү.

## Танып белү-тикшеренү эшчәнлеген үстерү

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

**Танып белү-тикшеренү эшчәнлеге.** Балаларны әйләнә-тирә тормышның төрле объектларын өйрәнүнең гомумиләштерелгән ысуллары белән таныштыру. Кызыксынучанлыкны стимуллаштыру. Балаларны өлкәннәр белән бергә башкарыла торган эксперименталь характердагы практик танып белү гамәлләренә тартып кертү.

**Сиземләүне үстерү.** Аңга кабул итүнең барлык төрләренә эзлекле рәвештә кушылу барышында эшчәнлекнең төрле төрләрендә балаларның турыдан-туры сиземләү тәҗрибәсен баету эшен дәвам итү. Предметларның төсен, зурлыгын, формасын аерып күрсәтеп, аларны тикшерергә булышу; предмет белән танышу процессында аның буенча кулларны хәрәкәтләндерү теләге уяту (предметның өлешләре буйлап кулларны йөртү, аларны сыпыру һ.б.).

**Дидактик уеннар.** Дидактик материал белән уеннар вакытында балаларның сиземләү тәҗрибәсен баету ( төрле зурлыктагы 5–8 боҗрадан торган кечкенә пирамидалар (манаралар); «Геометрик мозаика» (түгәрәк, өчпочмак, квадрат, турыпочмаклык); киселә торган рәсемнәр (2–4 өлешле), җыела торган шакмаклар (4–6 данә) һ.б); аналитик сәләтләрне (бертөрле предметларны берәр билгеләре — төс, форма, зурлык буенча чагыштыра, бәйли, төркемләштерә, тәңгәлләштерә һәм аера белүне) үстерү.

Игътибар һәм хәтерне («Нәрсә юкка чыкты?» һ.б.), ишетеп аера белүне («Бу нәрсә тавышы?» һ.б.); тотып сиземләүләрне, температура аерымлыкларын («Хикмәтле капчык», «Җылы–салкын», «Җиңел–авыр» һ.б), кулларның вак хәрәкәтләрен (төймәле, ыргаклы, молнияле, шнурлы уенчыклар һ.б.) үстерүгә юнәлтелгән дидактик уеннар оештыру.

### Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

**Танып белү-тикшеренү эшчәнлеге.** Балаларны махсус эшләнгән эталоннар системасы, аңга кабул итү гамәлләре ярдәмендә әйләнә-тирә дөньяның төрле объектларын тикшерүнең гомумиләштерелгән ысулларына өйрәтү. Тикшеренү гамәлләрен файдалануны стимуллаштыру.

Балаларны өлкәннәр белән бергә башкарылучы, өйрәнелүче объектның элек яшерен булган үзлекләре ачыла торган, эксперименталь характердагы практик танып белү гамәлләренә тарту.

Эшчәнлекнең бурычына һәм алгоритмы эчтәлегенә тәңгәл гамәлләр башкарырга тәкъдим итү. Өлкән кеше ярдәмендә модельләштерү характерындагы гамәлләр куллану.

**Сиземләү үсеше.** Балаларның сиземләү тәҗрибәсен баету, бу тәҗрибәне сөйләмдә беркетү сәләтен үстерү. Аңга кабул итүне камилләштерү (барлык сизү-тою органнарын актив рәвештә эшкә җигеп). Образлы күзаллауларны үстерү (предметларны сыйфатлаганда эпитетлар һәм чагыштырулар кулланып).

Балаларны предметларның төсе, формасы, зурлыгы, тоемланучы үзлекләре (җылы, салкын, каты, йомшак, йомшак йонлы һ.б.) белән таныштыру өчен шартлар тудыру; төрле музыка кораллары, туган телдәге сөйләм яңгырашын кабул итү сәләтен үстерү.

Төс, форма, зурлыкны предметларның үзләренә бер төрле үзлекләре буларак аерып ала белү сәләтен ныгыту; охшаш предметларны тоемланучы берничә билге: зурлык, форма, төс буенча төркемләштерү.

Балаларга формалар аталышын әйтеп бирү (түгәрәк, өч почмаклы, туры почмаклы һәм квадрат).

**Дидактик уеннар.** Предметларны төсләре һәм зурлыклары буенча сайлап алу (зур, уртача һәм кечкенә; 2–3 төс); билгеле бер эзлеклелектә 2–3 төсне чиратлаштырып, зурлыклары буенча кечерәя барган боҗралардан кечкенә пирамида җыю; 4–6 өлештән рәсем җыю.

Бергәләп уздырылучы дидактик уеннарда балаларны акрынлап катлаулана барган кагыйдәләрне үтәргә өйрәтү.

## Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

**Танып белү-тикшеренү эшчәнлеге.** Балаларны махсус эшләнгән сиземләү эталоннары системасы ярдәмендә төрле объектларны тикшерүнең гомумиләштерелгән ысуллары белән таныштыруны дәвам итү, аңга кабул итү гамәлләрен үзләштерүгә булышу. Яңа объектны гамәли тикшерү процессында аның турында мәгълүматлар ала белү сәләте формалаштыру.

Эшчәнлекнең бурычына һәм тәкъдим ителүче алгоритмына тәңгәл эзлекле гамәлләр башкаруны формалаштыру. Танып белү-тикшеренү эшчәнлегендә өлкән кеше тарафыннан тәкъдим ителгән модельләрне аңларга һәм файдаланырга өйрәтү.

**Сиземләүне үстерү.** Эшчәнлекнең төрле төрләрендә сиземләүне үстерү эшен дәвам итү. Балаларны предметларның һәм объектларның киң даирәсе, аларны тикшерүнең яңа ысуллары белән таныштырып, сиземләү тәҗрибәсен баету. Предметларны һәм объектларны тикшерүнең элгәрәк булдырылган күнекмәләрен ныгыту.

Барлык сиземләү органнарын (тоемлау, күрү, ишетү, тәм тою,ис сизү) актив файдалану юлы белән балаларның аңга кабул итүен камилләштерү. Сиземләү тәҗрибәсен һәм алынган тәэсирләрне сөйләмдә ныгытуны баету.

Геометрик фигуралар (түгәрәк, өчпочмак, квадрат, турыпочмаклык, овал), төсләр (кызыл, зәңгәр, яшел, сары, кызгылт-сары, шәмәхә, ак, соры) белән таныштыруны дәвам итү.

Тоюны үстерү. Капшау, кагылу, сыпыру нәтиҗәсендә төрле материаллар белән таныштыру, тоюларны сыйфатлап (шома, салкын, йомшак йонлы, каты, чәнечкеле һ.б.) башкарыла.

Эшчәнлекнең төрле төрләре процессында образлы рәвештә аңга кабул итү нигезендә образлы күзаллаулар формалаштыру.

Предметлар сыйфатының гомум кабул ителгән үзлекләре (төс, форма, зурлык, авырлык һ.б.) буларак эталоннардан файдалануны үстерү; предметларны 1–2 сыйфатлары (төс, зурлык, материал һ.б.) буенча сайлап алу.

**Проектлау эшчәнлеге.** Проектлау-тикшеренү эшчәнлегендә беренчел күнекмәләрне үстерү, бу эшчәнлекнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерүдә һәм аларны яшьтәшләргә тәкъдир итү өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтү. Ата-аналарны балаларның тикшеренү эшчәнлегендә катнашуга җәлеп итү.

**Дидактик уеннар.** Предметларның тышкы билгеләрен чагыштыру, аларны төркемләштерү күнекмәләрен камилләштереп, балаларны предметларның үзлекләре турындагы күзаллауларны ныгытуга юнәлтелгән уеннарга өйрәтү; өлешләрдәнербөтен төзү (шакмаклар, мозаика, пазллар).

Балаларның тою, ишетү, тәм тою сиземләүләрен камилләштерү («Капшап (тәм буенча, яңгыраш буенча) ачыкла»). Күзәтүчәнлекне һәм игътибарны үстерү («Нәрсә үзгәрде?», «Йөзек кемдә?»).

Балаларга иң гади өстәл уеннары («Домино», «Лото») кагыйдәләрен үзләштерергә булышу.

## Зурлар төркеме
## (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

**Танып белү-тикшеренү эшчәнлеге.** Махсус сиземләү эталоннары системасы ярдәмендә объектларны тикшерүнең гомумиләштерелгән ысулларыннан, аңга кабул итү гамәлләреннән файдалану күнекмәләрен ныгыту.

Танып белү гамәлләренең төрле чараларын кулланып, объектлар һәм күренешләр системалары арасындагы функциональ элемтәләрне һәм бәйләнешләрне ачыклау теләге уяту. Яшерен үзлекләрне ачу өчен мөстәкыйль рәвештә экспериментал характердагы гамәлләр куллануга булышлык итү. Яңа объектны тикшерү процессында аның турында мәгълүмат ала белү сәләте ныгыту.

Балаларның тәкъдим ителүче алгоритмга тәңгәл рәвештә эш итә белү сәләте үстерү. Үз эшчәнлегеңнең алгоритмын билгели белү сәләте; өлкән кеше ярдәмендә модельләр төзү һәм аларны танып белү-тикшеренү эшчәнлегендә файдалана белү формалаштыру.

**Сиземләүне үстерү.** Сиземләү: күрү, ишетү, тоемлау, ис сизү, тәм тою органнарын эшкә җигеп, аңга кабул итүне, предметларның үзлекләрен һәм бәйләнешләрен (төс, форма, зурлык, тирәлектә урнашу һ.б.) аера белү сәләте үстерү.

Спектр төсләре: кызыл, кызгылт-сары, сары, яшел, күк, зәңгәр, шәмәхә (хроматик төсләр) һәм ак, соры, кара (ахроматик төсләр) белән таныштыруны дәвам итү. Төсләрне ачыклык һәм куелык буенча аерырга, аларны дөрес атарга өйрәтү. Балаларга төс төсмерләренең спектрда урнашу үзенчәлекләрен күрсәтү.

Төрле геометрик фигуралар белән таныштыруны дәвам итү, эталоннар сыйфатында яссылыклы һәм күләмле формалар кулланырга өйрәтү.

Төрле формадагы предметларны тикшерә белү күнекмәләре формалаштыру; тикшерү вакытында кулларны предмет өслеге буйлап хәрәкәтләндерү. Предметларның фактурасы турындагы күзаллауларны киңәйтү (шома, йомшак йонлы, кытыршы һ.б.). Күз үлчәвен камилләштерү.

Кызыклы тәҗрибәләр, фокуслар күрсәтеп, иң гади экспериментларга җәлеп итеп, танып белү-тикшеренүгә карата кызыксыну үстерү.

**Проектлау эшчәнлеге.** Балалар тарафыннан өч типтагы — тикшеренү, иҗади һәм норматив проектлар гамәлгә ашырылсын өчен шартлар тудыру.

Тикшеренү тибындагы проектлау эшчәнлеген үстерү. Проектларны тәкъдир итүне оештыру. Балаларда проект авторлыгы турында күзаллаулар формалаштыру.

Иҗади типтагы проектлау эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру. (Бу яшьтә иҗади проектлар индивидуаль характерда була.)

Норматив типтагы проектлау эшчәнлеге үсешенә булышлык итү. (Норматив проектлау эшчәнлеге — балалар тарафыннан балалар коллективында үз-үзеңне тоту нормаларын һәм кагыйдәләрен эшләүгә юнәлтелгән проектлау эшчәнлеге.

**Дидактик уеннар.** Балаларны 2–4 кешелек төркемчәләргә берләштереп, дидактик уеннар оештыру; уен кагыйдәләрен үтәргә өйрәтү.

Уеннарда балаларның хәтерен, игътибарын, күзаллавын, фикерләвен сөйләмен, сиземләү сәләтен үстерү. Предметларны чагыштырырга, аларның билгеләрендәге мөһим булмаган аермаларны (төс, форма, зурлык, материал) күреп алырга, предметларны гомуми билгеләре буенча берләштерергә, өлешләрдән бербөтенне төзергә (җыела торган шакмаклар, мозаика, пазллар), предметларның урнашуындагы үзгәрешләрне (алда, артта, уңда, сулда, астында, өстендә, уртасында, янда) билгеләргә өйрәтү.

Төрле дидактик уеннар һәм уенчыклар (халык, электрон, компьютер уеннары һәм уенчыклары һ.б.) белән эш итү теләге формалаштыру.

Балаларда уен гамәленә карата эмоциональ-уңай тәэсир булдырып, аларда уенда мөстәкыйльлеккә омтылыш уяту.

Төркемле уеннарда кагыйдәләргә буйсынырга өйрәтү. Иҗади мөстәкыйльлек тәрбияләү. Дуслык хисе, дисциплиналылык кебек сыйфатлар формалаштыру. Уен-ярышларда намуслы көндәшлек культурасы тәрбияләү.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

**Танып белү-тикшеренү эшчәнлеге.** Махсус эшләнгән сиземләү эталоннары системасы һәм аңга кабул итү гамәлләре ярдәмендә объектларны тикшерүнең гомумиләштерелгән ысуллары характерын һәм эчтәлеген камилләштерү, танып белү бурычына тәңгәл рәвештә аларны оптималь сайлап алу.

Объектлар һәм күренешләр системалары арасындагы элемтәләрне һәм бәйләнешләрне, төрле чаралар кулланып, мөстәкыйль рәвештә ачыклау өчен шартлар тудыру. Объектларның яшерен үзлекләрен ачуга юнәлтелгән эксперименталь характердагы гамәлләрнең асылын камилләштерү.

Эшчәнлекнең шартларына һәм максатларына тәңгәл рәвештә кирәкле мәгълүматны алу ысулын ачыклый белү сәләте камилләштерү.

Тәкъдим ителүче алгоритмга тәңгәл рәвештә мөстәкыйль эш итү сәләтен үстерү; максат кую, үзеңә тиешле алгоритмны төзү; нәтиҗәнең һәм максатның бер-берсенә туры килмәвен табу; үз эшчәнлегеңә төгәллек кертү. Балаларны мөстәкыйль рәвештә модельләр төзергә һәм аларны танып белү-тикшеренү эшчәнлегендә файдаланырга өйрәтү.

**Сиземләүне үстерү.** Күрү, ишетү, ис сизү, тоемлау, тәм тою, сиземләү-моториканы үстерү.

Кул һәм күз координациясен камилләштерү; эшчәнлекнең төрле төрләрендә кулларның вак хәрәкәтләрен үстерү.

Игътибарны предметларның һәм күренешләрнең сыйфатларын иң нечкә дәрәҗәдә аеруга юнәлтеп, аларны күзәтә белүне үстерү (текәлеп карау, колак салып тыңлау).

Аңга кабул итү процессында предметларның берничә сыйфатын аерып алырга өйрәтү; предметларны форма, зурлык, төзелеш, тирәлектә урнашу, төс буенча чагыштыру; үзенчәлекле детальләрне, төсләрнең һәм төсмерләрнең үзара матур ярашуын, төрле авазларны (музыкаль, табигатьтәге авазлар һ.б.) аерып алу.

Предметларны гомуми сыйфатлары (форма, зурлык, төзелеш, төс) буенча классификацияләү күнекмәләрен камилләштерү.

Балаларның хроматик һәм ахроматик төсләр турындагы белемнәрен ныгыту.

**Проектлау эшчәнлеге.** Проектлау эшчәнлегенең барлык (тикшеренү, иҗади, норматив) типларын үстерү.

Тикшеренү проектлау эшчәнлегендә игътибарны мәгълүмат чыганакларының нәтиҗәлелеген анализлауга юнәлтә белү сәләте формалаштыру. Проектны яшьтәшләр даирәсендә тикшерүне хуплау.

Индивидуаль һәм төркем белән башкарыла торган иҗади проектлау эшчәнлегенә булышлык итү.

Норматив проектлар өстендә эшләгәндә әлеге проектларга охшаш ситуацияләрдә гамәлдәге нормалар бозылган очракта барлыкка килүләре ихтимал булган хәлләрне һәм тискәре нәтиҗәләрне балалар белән тикшерүне хуплау.

Балаларга хәлне, аның төп мәгънәләрен символик һәм образлы рәвештә чагылдыруда ярдәм итү.

**Дидактик уеннар.** Балаларны төрле дидактик уеннар (лото, мозаика, шырпы тартыш (бирюлки) һ.б.) уйнарга өйрәтүне дәвам итү. Уеннар оештыру, алып баручы ролен башкару сәләтен үстерү.

Үз гамәлләреңне алып баручының һәм уенда катнашучыларның гамәлләре белән килештерергә өйрәтү.

Уенда тапкырлык күрсәтә, куелган бурычны мөстәкыйль рәвештә хәл итә белү сыйфатларын үстерү.

Балаларны кайбер дидактик уеннарны («Шаулавычлар», «Кыштырдагычлар» һ.б.) иҗат итүгә тарту. Сиземләү сәләтен үстерү һәм ныгыту.

Уенда мәктәпкә әзерләү өчен кирәкле сыйфатлар — үз-үзеңне ирекле тоту, ассоциатив-образлы һәм логик фикерләү, күзаллау, танып белү активлыгы чагылышына һәм үсешенә булышлык итү.

## Предметлы тирәлек белән таныштыру

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Балаларда якын тирәлек предметларына карата кызыксыну тудыру: уенчыклар, савыт-саба, өс киеме, аяк киеме, йорт җиһазы, транспорт чаралары.

Балаларда предметларның төсен, зурлыгын, нинди материалдан (кәгазь, агач, тукыма, балчык) эшләнүен атау теләге уяту; таныш предметларны (төрле баш киемнәре, бияләйләр, аяк киемнәре һ.б.) чагыштыру, тәңгәл предметларны сайлап алу (шундыйны ук тап, парлап сайла), аларны куллану ысулы буенча төркемләштерү (чынаяктан эчәләр һ.б.). Предметларны төрлечә куллану ысулларын ачу.

Баланың предметлар белән эш итү ихтыяҗын гамәлгә ашыруына булышлык итү. Бер үк төрле аталучы предметлар арасындагы охшашлыкларны һәм аерымлыкларны ачыкларга өйрәтү (бертөрле көрәкләр; кызыл туп — зәңгәр туп; зур шакмак — кечкенә шакмак). Балаларда предметларның үзлекләрен атау теләге уяту: зур, кечкенә, йомшак, йомшак йонлы һ.б.

Балалар сүзлегендә гомумиләштерүче төшенчәләр барлыкка килүгә булышлык итү (уенчыклар, савыт-саба, өс киеме, аяк киеме, йорт җиһазы һ.б.).

### Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

Балаларны якын тирәлек предметлары (уенчыклар, йорт кирәк-яраклары, транспорт төрләре), аларның функцияләре һәм кулланылышлары белән таныштыруны дәвам итү.

Йорт кирәк-яракларының кайбер үзенчәлекләрен (өлешләр, зурлыклар, форма, төс) аерып алу, төзелеш һәм функция арасындагы бәйләнешләрне ачыклау теләге уяту. Ниндидер өлешнең булмавының предметны, аны файдалану мөмкинлеген бозуын аңлау.

Балаларның материал (агач, кәгазь, тукыма, балчык) үзлекләре (ныклык, катылык, йомшаклык) турындагы күзаллауларын киңәйтү. Иң гади тәҗрибәләрне кертеп (бата — батмый, ертыла — ертылмый), предметларны тикшерү ысулларына ия булуга булышлык итү. Яхшы таныш предметларны төркемләштерергә (чәй, өстәл (ашханә), кухня савыт-сабасы) һәм классификацияләргә (савыт-саба — өс киеме) тәкъдим итү.

Балаларга бер төрле предметларның кеше кулы белән эшләнүе (савыт-саба, йорт җиһазы һ.б.), башкаларының табигать тарафыннан булдырылуы (таш, күркәләр) турында сөйләү. Кешенең үзенең һәм башкаларның тормышы өчен кирәкле предметлар (йорт җиһазы, өс киеме, аяк киеме, савыт-саба, уенчыклар һ.б.) ясавын, эшләвен аңлауны формалаштыру.

### Уртанчылар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Балаларның әйләнә-тирә дөнья объектлары турындагы күзаллауларын киңәйтү өчен шартлар тудыру. Балаларга эшчәнлекнең төрле төрләрендә (уенда, хезмәттә, рәсем ясаганда, аппликация эшләгәндә һ.б.) кирәк булган предметлар турында сөйләү. Балаларның җәмәгать транспорты (автобус, поезд, самолет, теплоход) турындагы белемнәрен киңәйтү.

Балаларны предметларның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү, аларда предметларның төсен, формасын, зурлыгын, авырлыгын ачыклау теләге уяту. Предметларның нинди материаллардан (пыяла, металл, резина, күн, пластмасса) эшләнүе, аларның үзлекләре һәм сыйфатлары турында сөйләү. Предметны билгеле бер материалдан (машиналар корпусын — металлдан, шинны — резинадан һ.б.) эшләүнең максатка ярашлы булуын аңлату.

Уенчык һәм көнкүреш кирәк-яраклары тарихы мисалында кеше хезмәте төрләренең һәм көнкүрешнең үзгәрүе турында элементар күзаллаулар формалаштыру.

### Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Балаларның предметлар дөньясы турындагы күзаллауларын баетуны дәвам итү. Таныш булмаган предметларның кирәклеген аңлату. Көнкүрештә кеше хезмәтен җиңеләйтүче (кофетарткыч, миксер, иттарткыч һ.б.), комфорт тудыручы (бра, картиналар, келәм һ.б.) предметлар турында күзаллау формалаштыру. Предметның ныклыгы һәм чыдамлылыгы ул ясалган предметның үзлекләреннән һәм сыйфатларыннан бәйле булуын аңлату. Предметлар ясалган материалларны мөстәкыйль рәвештә ачыклау, предметларның үзлекләрен һәм сыйфатларын — өслекнең структурасын һәм температурасын, катылык — йомшаклыкны, уалучанлык — ныклыкны, ялтырауны, яңгыравыклыкны характерлау сәләтен үстерү.

Предметларны чагыштыру (кулланылыш, төс, форма, материал буенча), аларны классификацияләү (савыт-саба — фарфор, пыяла, керамика, пластмасса) теләге тудыру.

Теләсә кайсы әйбернең күп кешеләр хезмәте белән эшләнүен сөйләү («Өстәл каян килгән?», «Китап ничек барлыкка килгән?» һ.б.). Предметларның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге бар.

### Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Балаларның предметлар дөньясы турындагы күзаллауларын киңәйтүне һәм аларга төгәллек кертүне дәвам итү. Транспорт төрләре (җир өсте, җир асты, һава, су транспорты) турындагы күзаллауларны баету. Производствода кеше хезмәтен җиңеләйтүче предметлар (компьютер, роботлар, станоклар һ.б.); бинада һәм урамда комфорт һәм уңайлык тудыручы объектлар турында күзаллаулар формалаштыру. Балаларда кешенең үзе һәм башкалар өчен предметларны үзгәртүен, камилләштерүен, шул рәвешчә тормышны уңайлырак һәм комфортлырак итүен аңлау теләге тудыру. Балаларның предметларны эшләү, булдыру турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Кулдан эшләнгән предметларга һәм табигать объектларына соклану хисе тудыру.

Табигать бирмәгәнне кешенең үзе булдыруын, ясавын аңлауны формалаштыру (кешенең канатлары юк, ул самолет булдырды; буе озын булмаганга кран, баскыч ясады һ.б.). Предметлы тирәлекне кеше аңы иҗаты буларак кабул итүгә булышу.

Предметларның мөһим сыйфатламалары, төрле материалларның үзлекләре һәм сыйфатлары турындагы күзаллауларны тирәнәйтү. Кешеләрнең материалларны табулары-чыгарулары һәм җитештерүләре (агач, металл, тукыма) турында сөйләү, өлкән кешенең ролен аңлауга китерү. Предметларны тикшерүнең төрле ысулларын (өстәп кую, кушып кую, микъдар буенча чагыштыру һ.б.) куллану теләген тудыру.

## Социаль дөнья белән таныштыру

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Үзләре яшәгән шәһәрнең (поселокның) исемен балаларның исләренә төшереп тору.

Өлкән якын кешеләре хезмәтенә карата кызыксыну уяту. Кайбер хезмәт гамәлләрен белү һәм атап әйтү теләге тудыру (тәрбияче ярдәмчесе савыт-саба юа, бүлмәне җыештыра, ашарга китерә, сөлгеләрне алыштыра һ.б.). Өлкәннәрнең хезмәт сөючән булулары, хезмәт сөючәнлекнең аларга хезмәт гамәлләрен уңышлы башкарырга ярдәм итүе турында сөйләү.

## Кечкенәләр төркеме
## (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

Мини-спектакльләр һәм тамашалар, шулай ук балалар әдәбияты әсәрләрен сәхнәләштереп уйналган уеннар аша театр белән таныштыру.

Якын тирәлек (шәһәр / поселок инфраструктурасының төп объектлары): йорт, кибет, поликлиника, парикмахерская белән таныштыру.

Балаларга аларга аңлаешлы һөнәрләр (тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, музыка җитәкчесе, табиб, сатучы, пешекче, шофер, төзүче) турында сөйләү, хезмәт гамәлләре, хезмәт нәтиҗәләре турындагы күзаллауларны киңәйтү һәм баету. Балаларның игътибарын кешенең аңа хезмәттә ярдәм итә торган шәхси (яхшылык теләүче, игътибарлы) һәм эшлекле (хезмәт сөючән, җыйнак) сыйфатларына юнәлтү.

Туган җиргә карата кызыксыну һәм аның турында беренчел күзаллаулар формалаштыру: үзләре яшәгән шәһәрнең (поселокның) исемен балаларның исләренә төшерү; ял көннәрендә кайда булулары (паркта, скверда, балалар шәһәрчегендә) турында сөйләү теләге тудыру һ.б.

## Уртанчылар төркеме
## (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

Җәмәгать урыннарында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Балаларны җәмәгать транспорты (автобус, поезд, самолет, теплоход) турындагы белемнәрен киңәйтү.

Мәктәп турында беренчел күзаллаулар формалаштыру.

Мәдәни күренешләр (театр, цирк, зоопарк, вернисаж), аларның атрибутлары, аларда эшләүче кешеләр, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.

Шәһәрдәге һәм авыл җирендәге тормыш һәм хезмәт үзенчәлекләре турында элементар күзаллаулар булдыру (балаларның үз тәҗрибәсенә таянып). Төрле һөнәрләр (шофер, почта таратучы, сатучы, табиб һ.б.) белән таныштыруны дәвам итү; хезмәт гамәлләре, хезмәт кораллары, хезмәт нәтиҗәләре турындагы күзаллауларны киңәйтү һәм баету.

Балаларны акча, аннан файдалану мөмкинлекләре белән таныштыру.

Туган якка мәхәббәт хисе тәрбияләүне дәвам итү; балаларга туган шәһәрләренең (поселокның) иң матур, истәлекле урыннары турында сөйләү.

Балаларда дәүләт бәйрәмнәре турында аларга аңлаешлы күзаллаулар булдыру.

Россия армиясе, Ватаныбызны саклаучы сугышчылар (чик сакчылары, диңгезчеләр, очучылар) турында сөйләү.

### Зурлар төркеме
### (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Балаларның һөнәрләр турындагы күзаллауларын баету.

Уку-укыту оешмалары (балалар бакчасы, мәктәп, колледж, югары уку йорты), кеше эшчәнлеге өлкәләре (фән, сәнгать, җитештерү, авыл хуҗалыгы) турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Мәдәни күренешләр (цирк, китапханә, музей һ.б.), аларның атрибутлары, җәмгыять тормышындагы әһәмияте, алар белән бәйле һөнәрләр, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.

Акча, аның функцияләре (хезмәт өчен түләү, сатып алуларда исәп-хисап чарасы), гаилә бюджеты һәм мөмкинлекләре белән таныштыруны дәвам итү.

Сәнгать әсәрләре (сынлы сәнгать, дөнья халыкларының мифлары һәм легендалары) белән таныштыру, кешеләрнең төрле заманнардагы тормыш рәвешен (өс киемнәре, кирәк-яраклар, традицияләр һ.б.) реконструкцияләү аша кешелек тарихы (Борынгы заман, Урта гасырлар, хәзерге җәмгыять) турында элементар күзаллаулар формалаштыру.

Балаларга тәрбияче, укытучы, табиб, төзүче, авыл хуҗалыгы, транспорт, сәүдә, элемтә хезмәткәрләре һ.б. һөнәрләр; алар хезмәтенең мөһимлеге; хезмәтне җиңеләйтү өчен төрле техникадан файдалану турында сөйләү. Хезмәт кешесенең шәхси һәм эшлекле сыйфатлары турында сөйләү.

Иҗади һөнәр кешеләренең: рәссамнарның, язучыларның, композиторларның, халык декоратив-гамәли сәнгате осталарының хезмәте; алар хезмәтенең нәтиҗәләре (картиналар, китаплар, ноталар, гамәли сәнгать предметлары) белән таныштыру.

Хезмәте өчен кешегә карата рәхмәт хисләре тәрбияләү.

Туган җир турындагы күзаллауларны киңәйтү. Балаларга туган якның истәлекле урыннары, мәдәнияте, традицияләре; үз төбәген данлаган кешеләр турында сөйләү.

Балаларның Туган ил, дәүләт бәйрәмнәре (8 Март, Ватанны саклаучылар көне, Җиңү көне, Яңа ел һ.б.) турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Россия Федерациясенең (Россиянең) зур, күпмилләтле ил булуы турында күзаллаулар формалаштыру. Балаларга Мәскәүнең Ватаныбызның төп шәһәре, башкаласы булуы турында сөйләү. Россиянең флагы һәм гербы, гимнының көе белән таныштыру.

Балаларның Россия армиясе турындагы күзаллауларын киңәйтү. Ватанны саклаучыларга карата мәхәббәт хисе тәрбияләү. Ватанны, аның тынычлыгын һәм иминлеген саклауның авыр, әмма мактаулы бурыч булуы, сугыш елларында ерак бабаларыбызның, бабайларның һәм әтиләребезнең ничек итеп батырларча сугышулары һәм илебезне дошманнан саклаулары турында сөйләү. Балалар бакчасына хәрбиләрне, балаларның якын туганнары арасыннан ветераннарны чакыру. Балалар белән бергә сугыш тематикасы яктыртылган картиналар, репродукцияләр, альбомнар карау.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме
## (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Китапханәләр, музейлар белән таныштыруны дәвам итү.

Балаларның алга таба уку турындагы күзаллауларын тирәнәйтү, мәктәп, колледж, югары уку йортының үзенчәлеге турында элементар белемнәр формалаштыру (мөмкин булганда мәктәпкә бару, укытучылар һәм укучылар белән танышу һ.б.).

Балаларның кеше эшчәнлеге өлкәләре (фән, сәнгать, җитештерү һәм хезмәт күрсәтү өлкәсе, авыл хуҗалыгы) турында хәбәрдарлыгын, бала, аның гаиләсе, балалар бакчасы һәм, гомумән алганда, җәмгыять тормышы өчен бу өлкәләрнең мөһимлеге турындагы күзаллауны киңәйтү.

Эксперимент һәм гамәли эшчәнлек аша балалар өчен югарыда саналган өлкәләрнең һәрберсендәге һөнәри эшчәнлек элементлары белән танышу мөмкинлеге тудыру (су, һава, магнит белән иң гади экспериментлар уздыру һәм бу экспериментларны аңлату; коллектив панно яки рәсем иҗат итү, нәрсә булса да әзерләү; кечкенәләр төркемен һавада йөреп керергә әзерләргә булышу; ашарга яраклы үсемлек үстерү, йорт хайваннарын карау).

Төрле һөнәр ияләре турындагы күзаллауларны киңәйтүне дәвам итү. Балаларга хезмәт кешесенә карата тулаем караш тәкъдим итү: җаваплылык, пөхтәлек, кул хезмәте белән төрле матди һәм рухи кыйммәтләр тудыра белү.

Икътисад элементлары турындагы күзаллауларны киңәйтү (акча, аның тарихы, җәмгыять өчен әһәмияте, гаилә бюджеты, кешеләрнең тәэмин ителү дәрәҗәсе төрле булу, азрак тәэмин ителгән кешеләргә ярдәм итү зарурлыгы, хәйриячелек).

Җирнең эволюциясе (Җирнең барлыкка килүе, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы эволюциясе), кешенең табигать дөньясындагы һәм социаль дөньядагы урыны, төрле расаларның килеп чыгышы һәм биологик яктан нигезле булуы турында элементар күзаллаулар формалаштыру.

Сәнгать әсәрләре (сынлы сәнгать, скульптура, дөнья халыкларының мифлары һәм легендалары) белән танышу, уен һәм эшчәнлекнең нәтиҗәле төрләре аша кешелек тарихы турында элементар күзаллаулар формалаштыру.

Балаларга Җирнең уртак йортыбыз булуы, Җирдә күп кенә төрле илләр барлыгы; дөньяда барлык халыклар белән тату яшәүнең, аларның мәдәниятен, йолаларын һәм традицияләрен хөрмәт итүнең мөһим булуы турында сөйләү.

Үзеңнең кешелек бергәлегеңдә булуың, башка илләрдәге балаларның балачагы, дөньяда балаларның хокуклары (Бала хокуклары Декларациясе), бала хокукларын саклау белән шөгыльләнүче илебез оешмалары һәм халыкара оешмалар (опека органнары, ЮНЕСКО) турындагы күзаллауларны киңәйтү. Кешелек казанышы буларак шәхес иреге турында элементар карашлар формалаштыру.

Туган як турындагы күзаллауларны киңәйтү. Балалар яшәгән төбәктәге истәлекле урыннар белән таныштыруны дәвам итү.

Тирәлек турындагы белемнәрне киңәйтү нигезендә патриотик һәм интернациональ хисләр, Ватанга карата мәхәббәт хисе тәрбияләү. Ватаныбыз — Россия турындагы күзаллауларны тирәнәйтү һәм аларга төгәллек кертү. Балаларның илдә барган вакыйгаларга карата кызыксынуын хуплау, ил казанышлары белән горурлану хисе тәрбияләү.

Россия флагы, гербы һәм гимны турындагы белемнәрне ныгыту (гимн бәйрәм яки башка тантаналы вакыйгалар вакытында башкарыла; гимн яңгыраганда барысы да торып баса, ирләр һәм малайлар баш киемнәрен салалар).

Россия Федерациясенең (Россиянең) зур, күпмилләтле ил булуы турындагы күзаллауларны үстерү. Төрле милләт кешеләренә һәм аларның йолаларына карата хөрмәт тәрбияләү.

Россиянең төп шәһәре, башкаласы Мәскәү турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Дәүләт бәйрәмнәре турындагы белемнәрне киңәйтү. Балаларга Ю.А.Гагарин һәм космосның башка геройлары турында сөйләү.

Россия армиясе турындагы белемнәрне тирәнәйтү. Ватанны саклаучыларга, һәлак булган сугышчылар истәлегенә карата хөрмәт тәрбияләү (балалар белән бергә обелискларга, һәйкәлләргә чәчәкләр салу һ.б.).

## Табигать дөньясы белән таныштыру

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Балаларны табигатьнең аңлаешлы күренешләре белән таныштыру.

Натурада, рәсемнәрдә, уенчыкларда йорт хайваннарын (мәчене, этне, сыерны, тавыкны һ.б.) һәм аларның балаларын танырга, аларны атап әйтергә өйрәтү. Рәсемдә кайбер кыргый хайваннарны (аюны, куянны, төлкене һ.б.) тану һәм аларны атау.

Балалар белән бергә участокта кошларны һәм бөҗәкләрне, аквариумдагы балыкларны күзәтү; кошларны ашату.

Тышкы күренешләреннән яшелчәләрне (помидор, кыяр, кишер һ.б.) һәм җиләк-җимешләрне (алма, груша һ.б.) аерырга өйрәтү.

Балаларга елның төрле фасылында табигатьнең матурлыгын күрергә булышу.

Хайваннарга карата мәрхәмәтле мөнәсәбәт тәрбияләү. Табигать белән үзара тәэсир итешү нигезләренә өйрәтү (үсемлекләрне һәм хайваннарны аларга зыян китермичә карау; һава торышы шартларына карап киенү).

Сезонлы күзәтүләр

**Көз.** Балаларның игътибарын табигатьтәге көзге үзгәрешләргә юнәлтү: суытты, агачлардагы яфраклар саргайдылар һәм коелалар. Көз көне күп кенә яшелчәләрнең һәм җиләк-җимешләрнең өлгерүе турында күзаллаулар формалаштыру.

**Кыш.** Табигатьтәге кышкы күренешләр турында күзаллаулар формалаштыру: салкынайтты, кар ява. Кышкы күңел ачуларга җәлеп итү (таудан чана шуу, кар атышып уйнау, кар бабай әвәләү һ.б.).

**Яз.** Табигатьтәге язгы үзгәрешләр турында күзаллаулар формалаштыру: җылытты, кар эри; гөрләвекләр барлыкка килде, үләннәр, бөҗәкләр; бөреләр бүртте.

**Җәй.** Табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтү: якты кояш, эссе, күбәләкләр оча.

## Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

Балаларның үсемлекләр һәм хайваннар турындагы күзаллауларын киңәйтү. Балаларны йорт хайваннары һәм аларның балалары, үз-үзен тотышларының һәм туклануларының үзенчәлекләре белән танышуны дәвам итү.

Балаларны аквариум балыклары һәм декоратив кошлар (дулкынлы попугайлар, кенәриләр һ.б.) белән таныштыру.

Кыргый хайваннар (аю, төлке, тиен, керпе һ.б.), җир-су хайваннары (бака мисалында) турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Участокта очрый торган кошларны (ала карга, күгәрчен, песнәк, чыпчык, кызылтүш һ.б.) күзәтергә, аларны кышын ашатырга өйрәтү.

Балаларның бөҗәкләр (күбәләк, май коңгызы, камка, энә карагы һ.б.) турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Тышкы күренешләре буенча яшелчәләрне (кыяр, помидор, кишер, шалкан һ.б.), җимешләрне (алма, груша, персик һ.б.), җиләкләрне (кура җиләге, карлыган һ.б.) аерырга һәм атап әйтергә өйрәтү.

Әлеге җирлектәге үсемлекләр — агачлар, чәчәк атучы үләнчел үсемлекләр (тузганак, үги ана яфрагы һ.б.) турында элементар күзаллаулар булдыру.

Бүлмә гөлләренең (фикус, яран һ.б.) ничек үсүен күрсәтү. Үсемлекләр үссен өчен җир, су һәм һава кирәклеге турында күзаллаулар булдыру.

Бер-бер артлы килүче ел фасылларының характерлы үзенчәлекләре, өлкәннәрнең һәм балаларның тормышында һәм эшчәнлегендә бу үзенчәлекләргә бәйле үзгәрешләр белән таныштыру.

Суның (ага, түгелә, җылына, суына), комның (коры — коела, юеш — ябыша), карның (салкын, ак, җылыда эри) үзлекләре турында күзаллаулар булдыру.

Алынган тәэсирләрне сөйләмдә һәм эшчәнлекнең нәтиҗәле төрләрендә чагылдырырга өйрәтү.

Табигатьтәге иң гади үзара бәйләнешләрне аңлый белү сәләте формалаштыру (үсемлек үссен өчен аңа су сибәргә кирәк һ.б.).

Табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру (кирәкмәскә үсемлекләрне өзмәү, агачларның ботакларын сындырмау, хайваннарга тимәү һ.б.).

Сезонлы күзәтүләр

**Көз.** Табигатьтәге үзгәрешләрне күрергә өйрәтү: салкынрак була башлады, яңгырлар ява, кешеләр җылы киемнәрен кияләр, яфраклар төсләрен үзгәртә һәм коела башлыйлар, кошлар җылы якларга очып китәләр.

Көз көне яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр уңышын җыю турындагы күзаллауларны киңәйтү. Иң күп таралган яшелчәләрне һәм җиләк-җимешне тышкы күренешләре, тәмнәре, формалары буенча аерырга һәм атап әйтергә өйрәтү.

**Кыш.** Кышкы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре турындагы күзаллауларны киңәйтү (салкын, кар ява; кешеләр кышкы киемнәрен кияләр).

Участокка очып килүче кошларны күзәтүне оештыру, аларны ашату. Кышкы табигатьнең матурлыгын күрергә өйрәтү: агачлар карлы киемдә, мамыктай йомшак кар, үтә күренмәле боз кисәкләре һ.б.; таудан чана шууда, кардан әйберләр әвәләүдә, кар корылмаларны бизәүдә катнашу.

**Яз.** Язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү: кояш яктырак яктырта, кар эри башлый, көпшәкләнә, үлән үсте, агачлар яфрак ярды, күбәләкләр һәм май коңгызлары күренә.

Балаларның табигатьтәге иң гади бәйләнешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү: кояш җылыта башлады — җылыта төште — үлән пәйда булды, кошлар сайрый башлады, кешеләр җылы киемнәрен җиңелчә киемнәргә алыштырдылар.

Чәчәкле үсемлекләрнең һәм яшелчәләрнең эре орлыкларын ничек итеп түтәлләргә утыртуларын күрсәтү.

**Җәй.** Табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларны киңәйтү: эссе, якты кояш, үсемлекләр чәчәк ата, кешеләр су коена, күбәләкләр оча, ояларда кошчыклар пәйда була.

Җимеш бакчасы һәм яшелчә бакчасы үсемлекләре турында элементар белемнәр бирү. Җәй көне күп кенә җимешләрнең, яшелчәләрнең һәм җиләкләрнең өлгерүе турындагы белемнәрне ныгыту.

## Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

Балаларның табигать турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Йорт хайваннары, декоратив балыклар (вуалькойрык һәм телескоптан тыш, алтын балыклар, кәрәкә һ.б.), кошлар (попугайлар, кенәриләр һ.б.) белән таныштыру.

Балаларны сөйрәлүчеләр классы вәкилләре (кәлтә, ташбака), аларның тышкы кыяфәтләре һәм хәрәкәтләнү ысуллары (кәлтә озынча буйлы, аның озын койрыгы бар, ул койрыгын өзеп калдырырга мөмкин; кәлтә бик тиз йөгерә) белән таныштыру.

Балаларның кайбер бөҗәкләр (кырмыска, күбәләк, коңгыз, камка) турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Җимешләр (алма, груша, слива, персик һ.б.), яшелчәләр (помидор, кыяр, кишер, чөгендер, суган һ.б.) һәм җиләкләр (кура җиләге, карлыган, крыжовник һ.б.), гөмбәләр (майлы гөмбәләр, баллы гөмбәләр, ал гөмбәләр һ.б.) турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Балаларның үләннәр һәм бүлмә гөлләре (кына гөле, фикус, хлорофитум, яран, бегония, примула һ.б.) турындагы белемнәрен ныгыту; аларны карау ысуллары белән таныштыру.

Агачларның 3–4 төрен (чыршы, нарат, каен, усак һ.б.) танырга һәм атап әйтергә өйрәтү.

Тәҗрибә эшчәнлеге процессында балаларның ком, балчык һәм ташның үзлекләре турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Участокка очып килүче кошларны (ала карга, күгәрчен, песнәк, чыпчык, кызылтүш һ.б.) күзәтүне оештыру, кышын аларны ашату.

Балаларның кешеләр, хайваннар, үсемлекләр яшәеше өчен иң кирәкле шартлар (һава, су, туклану һ.б.) турындагы күзаллауларын ныгыту.

Балаларны табигатьтәге үзгәрешләрне күрергә өйрәтү.

Үсемлекләрне һәм хайваннарны саклау турында сөйләү.

## Сезонлы күзәтүләр

**Көз.** Балаларны табигатьтәге үзгәрешләрне күрергә һәм атап әйтеп бирергә өйрәтү: салкынайтты, явым-төшемнәр, җил, яфраклар коелу, җимешләр һәм тамыразыклар өлгерә, кошлар көньякка очып китәләр.

Терек һәм терек булмаган табигать күренешләре арасындагы иң гади бәйләнешләрне ачыклау (салкынайтты — күбәләкләр, коңгызлар юкка чыкты; чәчәкләр сулды һ.б.).

Үсемлек орлыкларын җыюда катнашуга җәлеп итү.

**Кыш.** Балаларны табигатьтәге үзгәрешләрне күрергә өйрәтү, көзге һәм кышкы пейзажларны чагыштыру.

Кошларның урамда һәм табигать почмагында үз-үзләрен тотышын күзәтү.

Кошларның кардагы эзләрен карау һәм чагыштыру. Кышлаучы кошларга ярдәм итү, аларны атап әйтү.

Балаларның салкында суның бозга, боз сөңгеләренә әверелүе, бозның һәм карның җылы бүлмәдә эрүе турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Кышкы күңел ачуларда катнашуга җәлеп итү: таудан чанада шуу, чаңгыда йөрү, кардан әйберләр әвәләп ясау.

**Яз.** Балаларны ел фасылын танырга һәм атап әйтергә өйрәтү; яз билгеләрен аерып күрсәтү: кояш җылырак яктырта башлады, агачларда бөреләр бүртте, үлән пәйда булды, умырзаялар чәчәк атты, бөҗәкләр пәйда булды.

Балаларга яз көне күп кенә бүлмә гөлләренең чәчәк атуы турында сөйләү.

Балаларда язгы чорда җимеш һәм яшелчә бакчаларында башкарыла торган эшләр турында күзаллаулар формалаштыру. Орлыклар чәчүне һәм аларның шытуын күзәтергә өйрәтү.

Балаларны яшелчә бакчасындагы һәм чәчәклектәге эшләргә җәлеп итү.

**Җәй.** Балаларның табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү: чиста зәңгәр күк йөзе, кояш якты яктырта, эсселек, кешеләр җиңелчә киенгән, кызыналар, су коеналар.

Эшчәнлекнең төрле төрләре процессында балаларның ком, су, ташлар һәм балчыкның үзлекләре турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Җәй көне күп кенә җимешләрнең, гөмбәләрнең өлгерүе; хайваннарның балалары үсә төшү турындагы белемнәрне ныгыту.

## Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Балаларның табигать турындагы күзаллауларын киңәйтү һәм аларга төгәллек кертү. Күзәтергә өйрәтү, кызыксынучанлык үстерү.

Якын-тирәлектәге үсемлекләр: агачлар, куаклыклар һәм үләнчел үсемлекләр турындагы күзаллауларны ныгыту. «Урман», «болын» һәм «бакча» төшенчәләре белән таныштыру.

Бүлмә гөлләре белән таныштыруны дәвам итү.

Үсемлекләрне карарга-үстерергә өйрәтү. Үсемлекләрнең вегетатив үрчү ысуллары турында сөйләү.

Йорт хайваннары, аларның гадәтләре, кешедән бәйле булулары турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Балаларны табигать почмагында яшәүчеләрне карарга-тәрбияләргә өйрәтү.

Балаларның кыргый хайваннар турындагы күзаллауларын киңәйтү: кайда яшиләр, ничек азык табалар һәм кышкы йокыга әзерләнәләр (керпе көзге яфраклар эченә күмелә, аюлар өндә кышлыйлар). Кошлар турындагы күзаллауларны киңәйтү (карлыгач, сыерчык һ.б. мисалында).

Балаларда сөйрәлүчеләр (кәлтә, ташбака һ.б.) һәм бөҗәкләр (бал корты, озынборын, чебен һ.б.) турында күзаллаулар булдыру.

Ел фасылларының, тәүлек өлешләренең чиратлашуы һәм аларның кайбер сыйфатлары турында күзаллаулар формалаштыру.

Балаларны туган як табигатенең күптөрлелеге; төрле климатик зоналардагы үсемлекләр һәм хайваннар белән таныштыру.

Кешенең үз тормышында судан, комнан, балчыктан һәм ташлардан ничек файдалануын күрсәтү.

Табигать белән таныштыру процессында матур әдәбият, музыка әсәрләрен, халык сынамышларын файдалану.

Кешенең табигатьнең бер өлеше булуы, аның табигатьне сакларга һәм якларга тиешлеге турында күзаллаулар формалаштыру.

Табигать белән аралашу процессында үз сәламәтлегеңне ныгытырга өйрәтү.

Табигать күренешләре арасындагы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыкларга өйрәтү (сезон — үсемлекләр — кешеләр хезмәте).

Терек һәм терек булмаган табигатьнең үзара тәэсир итешүен күрсәтү.

Кояшның һәм һаваның кеше, хайваннар һәм үсемлекләр яшәешендә әһәмияте турында сөйләү.

### Сезонлы күзәтүләр

**Көз.** Көннең салкынаюы һәм кыскаруының ничек итеп үсемлекләр, хайваннар, кешеләр тормышын үзгәртүе турындагы күзаллауларны ныгыту.

Балаларны кайбер хайваннарның ничек итеп кышка әзерләнүләре (бакалар, кәлтәләр, ташбакалар, керпеләр, аюлар йокыга талалар, куяннар төс алыштыралар, кайбер кошлар (казлар, үрдәкләр, торналар) җылы якларга очып китәләр).

**Кыш.** Балаларның кышкы табигатьнең үзенчәлекләре (салкыннар, туңдырулар, кар явулар, көчле җилләр), шәһәрдә, авылда кешеләр эшчәнлегенең үзенчәлекләре турындагы белемнәрен киңәйтү һәм баету. Табигать күренеше — томан белән таныштыру.

**Яз.** Балаларның табигатьтәге язгы үзгәрешләр турындагы белемнәрен киңәйтү һәм баету: кар эри, елгалар җәелә, кошлар киләләр (кайталар), үлән һәм чәчәкләр, күләгәле урынга караганда, кояшлы якта тизрәк үсеп чыгалар.

Кошларның (ала каргаларның һ.б.) оялавын күзәтү.

**Җәй.** Җылылыкның, кояш яктысының кешеләр, хайваннар һәм үсемлекләр яшәешенә йогынтысы турындагы күзаллауларны киңәйтү һәм баету (табигать «чәчәк ата», җиләкләр, җимешләр, яшелчәләр күп; җәнлекләр, кошлар һәм аларның балалары өчен азык күп).

Ашарга яраклы һәм ашарга яраксыз гөмбәләр турында күзаллаулар булдыру (ашарга яраклылар — майлы гөмбәләр, баллы гөмбәләр, әтәч гөмбәләре һ.б.; ашарга яраксызлар — чебен гөмбәсе, ялган баллы гөмбә һ.б.).

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Балаларның агачлар, куаклыклар, үләнчел үсемлекләр; болын, бакча, урман үсемлекләре турындагы белемнәрен киңәйтү һәм аларга төгәллек кертү.

Балаларның бүлмә гөлләренең яшәү шартлары турындагы күзаллауларын конкретлаштыру. Аларның вегетатив (чыбыкчадан, яфрактан, мыекчадан) үрчү ысуллары белән таныштыру. Балаларны үсемлекнең торышы һәм әйләнә-тирәлек шартлары арасындагы бәйләнешләрне ачыкларга өйрәтүне дәвам итү. Дару үләннәре (бака яфрагы, кычыткан һ.б.) турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Йорт кошлары, кышлаучы һәм күчмә кошлар; йорт хайваннары һәм табигать почмагында яшәүчеләр турындагы белемнәрне киңәйтү һәм системалаштыру.

Балаларда кыргый хайваннар һәм аларның әйләнә-тирә мохиткә яраклашу үзенчәлекләре турында тулырак күзаллаулар булдыру.

Балаларның имезүчеләр, җир-су хайваннары һәм сөйрәлүчеләр турындагы белемнәрен киңәйтү. Бөҗәкләр турындагы күзаллауларны киңәйтү. Алар тормышының үзенчәлекләре белән таныштыру (кырмыскалар, бал кортлары, шөпшәләр зур гаиләләр булып яшиләр; кырмыскалар — кырмыска ояларында, бал кортлары агач куышларында, умарталарда яшиләр. Җир-су хайваннарының һәм сөйрәлүчеләрнең үз дошманнарыннан саклануларының кайбер формалары белән таныштыру (мәсәлән, тузбаш дошманнарын ысылдап куркыта һ.б.).

Күбәләкләрне (кәбестә күбәләге, кычыткан күбәләге, тавис күзе һ.б.) һәм коңгызларны (камка, бызылдавык һ.б.) тышкы кыяфәтләреннән аерырга һәм дөрес итеп атап әйтергә өйрәтү. Бөҗәкләрне хәрәкәтләнү ысулы буенча чагыштырырга өйрәтү (очалар, сикерәләр, шуышалар).

Туган як белән кызыксынуны үстерү. Авылда яшәүчеләр (игенчеләр, механизаторлар, урманчылар һ.б.) хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.

Табигать фасыллары турындагы күзаллауларны гомумиләштерергә һәм системалаштыруга өйрәтү.

Матдәләрнең каты хәлдән сыек хәлгә һәм киресенчә күчеше турында күзаллаулар формалаштыру. Табигатьнең бәс, боз яву, томан, яңгыр кебек күренешләрен күзәтү.

Үзеңнең табигатькә мөнәсәбәтеңне хикәяләү һәм эшчәнлекнең нәтиҗәле төрләре аша белдерә белүне ныгыту. Табигатьтә бар нәрсәнең үзара бәйләнештә икәнлеген аңлату.

Табигать күренешләре арасындагы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыкларга өйрәтү (әгәр бөҗәкләр — үсемлекләрне серкәләндерүчеләр юкка чыкса, үсемлекләрнең орлыклары булмый һ.б.).

Балаларны Җирдә кеше тормышының күп очракта әйләнә-тирә мохиткә бәйле булуын аңлауга китерү: чиста һава, су, урман, туфрак кеше тормышында һәм сәламәтлегендә уңай яктан чагыла.

Табигатьтә үз-үзеңне дөрес тота белүне ныгыту (табигать матурлыгына соклану, зыян китермичә генә үсемлекләрне һәм хайваннарны күзәтү).

Ел фасыллары турында альбом төзү: рәсемнәр, фотосурәтләр, балалар рәсемнәрен һәм хикәяләрен сайлап туплау.

### Сезонлы күзәтүләр

**Көз.** Балаларның сентябрьнең көзнең беренче ае булуы турындагы белемнәрен ныгыту. Көз билгеләрен күрергә өйрәтү (суытты; җир туңдырудан катыланды; күлләвекләр бозланды; яфраклар коела; туфракта сыкы).

Куакларны кисүне күрсәтү, ни өчен болай эшләү турында сөйләү. Бакча үсемлекләрен (настурция, кашкарыйлар) чүлмәкләргә күчереп утыртуга җәлеп итү.

Төрле әйберләр ясау өчен табигый материаллар (орлыклар, күркәләр, имән чикләвекләре, яфраклар) җыярга өйрәтү.

**Кыш.** Балаларның табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр (иң кыска көннәр һәм иң озын төннәр, суык, салкын, бозлавык һ.б.) турындагы күзаллауларын баету.

Балаларның игътибарын кайбер агачларда (миләштә, чыршыда һ.б.) җимешләрнең озак саклануына юнәлтү. Моның кошлар өчен азык булуын аңлату.

Карның үзлекләрен билгеләргә өйрәтү (салкын, мамыктай йомшак, тарала, ябышучан һ.б.; дымлы авыр кардан корылмалар яхшырак ясала).

Балаларны февральдә һава торышы үзгәрүен күрергә өйрәтү (әле кояш яктырта, әле җил исә, әле кар ява, йортларның түбәләре кырыенда боз сөңгеләре барлыкка килә).

22 декабрьнең ел эчендәге иң кыска көн булуы турында сөйләү. Кошлар өчен солы утыртуга җәлеп итү.

**Яз.** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның язгы үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү (кояш ешрак яктырта, умырзаялар чәчәк ата; агачлардагы һәм куаклардагы бөреләр бүртә, бозлар ага башлый; үлән бакалары, гөберле бакалар, кәлтәләр уяна; кошлар оялар кора; кычыткан күбәләкләре очып чыга; кырмыскалар пәйда була).

Термометр белән таныштыру (кайда — күләгәдә яки кояшка караган хәлдә булуга карап, терекөмеш баганасы тиз генә күтәрелергә һәм төшәргә мөмкин).

Ничек итеп агачлар һәм куаклар утыртуны, кисүне күзәтү.

Табигать почмагындагы үзгәрешләрне күрергә өйрәтү (бүлмә гөлләре яңа яфраклар чыгара башлыйлар, чәчәк аталар һ.б.); бүлмә гөлләрен күчереп, шулай ук чыбыкчадан үрчетү ысулы белән утырту. Балаларны Халыкара хатын-кызлар көненә багышлап чәчәкләр (лаләләр) үстерергә өйрәтү.

Балаларны халык сынамышлары белән таныштыру: «Озын боз сөңгеләре — озын язга», «Язда күп пәрәвез очса, җәй эссе булачак» һ.б.

**Җәй.** Балаларның табигатьтә бара торган үзгәрешләр турындагы күзаллауларын ачыклау (иң озын көннәр һәм иң кыска төннәр, җылы, эссе; коеп яуган яңгырлар, яшенле яңгырлар, салават күпере). Җәй көне үсемлекләргә үсү өчен иң уңай шартлар булуны аңлату, ягъни: үсәләр, чәчәк аталар һәм җимеш бирәләр.

Халык сынамышлары: «Яңгырдан соң чыккан салават күпере озак торса — һава бозылуга, тиз юкка чыкса — аяз көнгә», «Кичен озынборыннар куе күч булып очсалар — җылы булачак», «Баллы гөмбәләр чыкты — җәй бетте» белән таныштыру.

22 июньнең җәйге кояш торгынлыгы көне (елның иң озын көне: шул көннән башлап төннәр озая, ә көн кыскара бара) булуы турында сөйләү.

Кешеләрнең кырлардагы, җимеш һәм яшелчә бакчаларындагы хезмәте белән таныштыру. Өлкәннәргә булышу теләге тәрбияләү.

## «СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ» белем бирү өлкәсе

«Сөйләм үсеше аралашу һәм мәдәният чарасы буларак сөйләмгә ия булуны; актив сүзлекне баетуны; бәйләнешле, грамматик яктан дөрес диалогик һәм монологик сөйләмне; сөйләм иҗаты үсешен; сөйләмнең аваз һәм интонация культурасы, фонематик ишетү сәләте үсешен; китап культурасы, балалар әдәбияты белән танышуны, балалар әдәбиятының төрле жанрлары текстларын ишетеп аңлауны; укырга-язарга өйрәтүнең алшарты буларак авазлы аналитик-синтетик активлык формалашуны үз эченә ала»[1].

### Төп максатлар һәм бурычлар

**Сөйләм үстерү.** Өлкәннәр һәм балалар белән ирекле аралашуны үстерү, тирә-юньдәгеләр белән үзара тәэсир итешүнең конструктив ысулларына һәм чараларына ия булу.

Балаларда сөйләм теленең барлык компонентларын: сөйләмнең грамматик төзелешен, бәйләнешле сөйләмне — аның диалогик һәм монологик формаларын үстерү; сүзлек запасы формалаштыру, сөйләмнең аваз культурасын тәрбияләү.

Тәрбияләнүчеләрнең гамәли рәвештә сөйләм нормаларына ия булуы.

**Матур әдәбият**. Укуга карата кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү; әдәби сөйләмне үстерү.

Матур әдәбият әсәрләрен тыңлау теләге һәм тыңлый белү, вакыйгалар барышын күзәтә белү сәләте тәрбияләү.

## Психологик-педагогик эш эчтәлеге

### Сөйләм үстерү

#### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

**Үсешкә китерүче сөйләм мохите.** Аралашу чарасы буларак сөйләм үстерүгә булышлык итү. Балаларга аларга яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашу мөмкинлеге биргән төрле йомышлар кушу («Чишенү бүлмәсенә күз сал да, миңа кем килүен әйт», «Алия ападан сорашып бел дә, миңа сөйләрсең», «Мансурны кисәтеп куй... Мансурга син нәрсә әйттең? Ә ул сиңа нәрсә дип җавап бирде?»). Яшәешнең өченче елы ахырына сөйләмнең балаларның бер-берсе белән тулы сыйфатлы аралашу чарасына әверелүенә ирешү.

[1] МББ ФДББСның 2.6. пунктын кара.

Балаларның бер-берсе һәм тәрбияче белән аралашуында күрсәтмә материал сыйфатында, мөстәкыйль рәвештә карау өчен рәсемнәр, китаплар, уенчыклар тәкъдим итү. Балаларга шул предметлар, шулай ук кызыклы вакыйгалар (мәсәлән, йорт хайваннарының гадәтләре һәм хәйләкәрлеге) турында сөйләү; рәсемнәрдә кешеләрнең һәм хайваннарның халәтләрен күрсәтү (шатлана, күңелсезләнә һ.б.).

**Сүзлек формалаштыру.** Балаларның якын тирәлектә ориентлашуын киңәйтү нигезендә сөйләмне аңлау сәләтен үстерү һәм сүзлекне активлаштыру.

Өлкәннәрнең сөйләмен күрсәтмәләрдән башка гына аңларга өйрәтү. Педагогның телдән күрсәтмәсе буенча балаларның предметларны аталышлары, төсләре, зурлыклары буенча эзләп таба белү сәләтен («Мәрьямгә варенье вазасын алып килеп бир», «Кызыл карандашны ал», «Кечкенә аю баласына җыр җырла»); предметларның урыннарын атый белү («Гөмбә өске киштәдә, югарыда», «Янәшә торалар»; кешеләрнең гамәлләрен һәм хайваннарның хәрәкәтен имитацияләү («Сиптергечтән ничек су сибүләрен күрсәт», «Аю баласы кебек йөр») күнекмәләрен үстерү.

Балаларның сүз байлыгын үстерү:

• уенчыклар, шәхси гигиена предметлары (сөлге, теш щеткасы, тарак, кулъяулык), өс киемнәре, аяк киемнәре, савыт-саба, йорт җиһазлары, йокы кирәк-яраклары (юрган, мендәр, җәймә, пижама), транспорт чаралары (автомашина, автобус), яшелчәләр, җимешләр, йорт хайваннары һәм аларның балалары аталышларын белдерүче исемнәр белән;

• хезмәт гамәлләрен (кер юу, дәвалау, су сибү), мәгънәләре буенча капма-каршы гамәлләрне (ачу — ябу, салу — кию, алу — кую), кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен (булышу, кызгану, бүләк итү, кочаклау), кешеләрнең эмоциональ халәтен (елау, көлү, шатлану, үпкәләү) белдерүче фигыльләр белән;

• предметларның төсен, зурлыгын, тәмен, температурасын белдерүче сыйфатлар (кызыл, зәңгәр, татлы, ачы, зур, кечкенә, салкын, кайнар) белән;

• рәвешләр (якын, ерак, биек, тиз, караңгы, әкрен, салкын, эссе, тайгак) белән.

Үзләштерелгән сүзләрнең балаларның мөстәкыйль сөйләмендә кулланылуына булышлык итү.

**Сөйләмнең аваз культурасы**. Балаларны аерым торган сузык һәм тартык авазларны (сызгырулы, чыжылдаучы һәм сонор авазлардан тыш) ачык итеп әйтергә, аваз ияртемнәрен, сүзләрне һәм гади гыйбарәләрне (2–4 сүздән торган) дөрес итеп кабатларга өйрәтү.

Артикуляция һәм тавыш аппараты, сөйләм сулышы, тыңлау игътибары үсешенә булышлык итү.

Тавыш югарылыгы һәм көчен файдалана белү сәләтен формалаштыру («Пескәй, прес!», «Кем килде?», «Кем шакый?»).

**Сөйләмнең грамматик төзелеше**. Исемнәрне һәм алмашлыкларны фигыльләр белән яраштырырга, фигыльләрне киләчәк һәм үткән заманнарда кулланырга, аларны затлар буенча үзгәртергә, сөйләмдә бәйлекләр (эченә, эчендә, өстенә, өстендә, янында, артында, астында) кулланырга өйрәтү.

Кайбер сорау сүзләрен (кем, нәрсә, кайда) һәм 2–4 сүздән торган гыйбарәләрне («Песи-пескәй, кая киттең?») кулланырга өйрәтү.

**Бәйләнешле сөйләм**. Балаларга иң гади («Нәрсә?», «Кем?», «Нишли?») һәм катлаулырак («Өстенә нәрсә кигән?», «Нәрсә алып бара?», «Кемгә?», «Нинди?», «Кайда?», «Кайчан?», «Кая?») сорауларга җавап бирергә булышу.

2 яшь 6 айдан өлкәнрәк балаларның үз инициативалары яки тәрбияче соравы буенча рәсемдә сурәтләнгәннәр, яңа уенчык, үз тәҗрибәләренә таянып, берәр вакыйга турында сөйләргә омтылуларын хуплау.

Уен-инсценировкалар вакытында балаларны катлаулы булмаган гыйбарәләр кабатларга өйрәтү. 2 яшь 6 айдан өлкәнрәк балаларга яхшы таныш әкиятләрнең өзекләрен уйнап күрсәтергә ярдәм итү.

Зур булмаган хикәяләрне күрсәтмә әсбаплардан башка гына тыңларга өйрәтү.

## Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

**Үсешкә булышлык итүче сөйләм мохите**. Кушканны үтәү аша (сора, ачыкла, ярдәмеңне тәкъдим ит, рәхмәт әйт һ.б.) балаларга үзләренә таныш өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашырга булышуны дәвам итү.

Балаларга төркем бүлмәсенә кергән өлкән кешегә мөрәҗәгать итү үрнәкләрен әйтеп күрсәтү («Рәхим итеп узыгыз» дип әйтегез», «Карыйсыгыз киләме...» дип тәкъдим итегез», «Безнең рәсемнәребез ошадымы?» дип сорагыз»).

Көнкүрештә, мөстәкыйль уеннарда балаларга сөйләм аша бер-берсе белән бергәләп эш итәргә, элемтәләр урнаштырырга булышу («Мөниргә шакмакларны зур машинага төяп күчерергә киңәш ит», «Сашага капканы киңрәк ясарга тәкъдим ит», «Сугышу оят! Син зур бит инде» дип әйт»).

Инициативалы сөйләм үстерү, якын-тирәлектәге предметлар турындагы күзаллауларны баету һәм ачыклау максатында балаларга мөстәкыйль рәвештә карау өчен рәсемнәр, китаплар, предмет җыелмалары тәкъдим итү.

Балаларны тәрбиячеңең тормышта булган кызыклы хәлләр турындагы хикәяләрен тыңларга өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек формалаштыру.** Якын-тирәлек турындагы күзаллауларны баету нигезендә балаларның сүз запасын киңәйтүне һәм активлаштыруны дәвам итү. Өс киемнәре, аяк киемнәре, баш киемнәре, савыт-саба, йорт җиһазлары предметларының, транспорт төрләренең аталышларын һәм кулланылышын ачыклау.

Балаларны предметларның мөһим детальләрен һәм өлешләрен (күлмәктә — җиңнәр, яка, кесәләр, төймәләр), сыйфатларын (төс һәм аның төсмерләре, форма, зурлык), өслекнең үзенчәлекләрен (шома, йомшак, йонлы, кытыршы), кайбер материалларны һәм аларның үзлекләрен (кәгазь җиңел ертыла һәм җеби, пыяла предметлар ватыла, резина уенчыклар кысканнан соң элеккеге формага кайталар), урынны (тәрәзә артында, югарыда, еракта, шкаф астында) аера һәм әйтә белергә өйрәтү. Балаларның игътибарын охшаш максатларда файдаланылучы предметларга юнәлтү (тәлинкә — зур тәлинкә, урындык — утыргыч — эскәмия, тун — пальто — кайры тун). Го-

мумиләштерүче сүзләрне аңларга өйрәтү (өс киемнәре, савыт-саба, йорт җиһазы, яшелчәләр, җимешләр, кошлар һ.б.); тәүлек өлешләрен атау (иртә, көндез, кич, төн); йорт хайваннарын һәм аларның балаларын, яшелчәләрне һәм җимешләрне атау.

**Сөйләмнең аваз культурасы.** Балаларны сүзләрдәге сузык (а, ә, у, ү, и, о, ө, э) һәм кайбер тартык авазларны (п-б-т-д-к-г; ф-в; т-с-з-ц) ачык итеп әйтергә өйрәтүне дәвам итү.

Сөйләм-хәрәкәт аппаратының моторикасын, ишетеп кабул итүне, сөйләмне ишетүне һәм сөйләм сулышын үстерү, авазлар артикуляциясен ачыклау һәм ныгыту. Сөйләмнең дөрес темпын, интонация тәэсирен булдыру. Сүзләрне һәм кыска гыйбарәләрне ачык итеп әйтергә, табигый интонация белән тыныч сөйләргә өйрәтү.

**Сөйләмнең грамматик төзелеше.** Балаларны сыйфатларны исемнәр белән, сан, килеш буенча яраштырырга өйрәтүне дәвам итү; исемнәрне бәйлекләр (эченә, эчендә, өстенә, өстендә, астында, артында, янында) белән куллану. Балаларга сөйләмдә хайваннарны һәм аларның балаларын белдерүче исемнәрне берлек һәм күплек сан формаларында (үрдәк — үрдәк бәбкәсе — үрдәк бәбкәләре); исемнәрнең күплек сан формасын иялек килешендә (тасмаларның, матрешкаларның, китапларның, грушаларның, сливаларның) кулланырга булышу. Балаларның сүзләр иҗат итүенә грамматика белән актив эш итү этабы буларак карау, балаларга сүзнең дөрес формасын әйтеп бирү.

Җыйнак гади җөмләләргә (ия белән хәбәрдән генә торалар) аергычлар, тәмамлыклар, хәлләр кертү юлы белән җыйнак җөмләләрне җәенке җөмләләргә әверелдерергә ярдәм итү; тиңдәш кисәкләре булган җөмләләр төзү («Без зоопаркка барырбыз, анда фил, зебра һәм юлбарыс күрербез»).

**Бәйләнешле сөйләм.** Сөйләмнең диалогик төрен үстерү.

Балаларны предметлар, картиналар, иллюстрацияләр караганда; тере объектларны күзәткәндә; спектакльләр, мультфильмнар караганнан соң сөйләшүгә җәлеп итү.

Педагог белән диалог алып бару сәләтенә: бирелгән сорауны тыңларга һәм аңларга, аңа аңлаешлы итеп җавап бирергә, сөйләшүче өлкән кешене бүлдермичә нормаль темпта сөйләргә өйрәтү.

«Рәхмәт», «исәнмесез», «сау булыгыз», «хәерле төн» дип әйтү кирәклеге турында балаларның исләренә төшереп тору (гаиләдә, төркемдә).

Бер-берсе белән дустанә аралашырга булышу.

Үз тәэсирләреңне тәрбиячеләр һәм әти-әниләр белән бүлешү ихтыяҗы формалаштыру.

## Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

**Үсешкә булышлык итүче сөйләм мохите.** Балалар белән бергә алар өчен гадәти тирәлек чикләреннән читтәге предметлар, күренешләр, вакыйгалар турындагы сөйләшү.

Балалар сөйләгәнне тыңлау, аларның җавапларына төгәллек кертү, предмет, күренеш, торыш, гамәл үзенчәлеген төгәлрәк чагылдырган

сүзләрне әйтеп җибәрү; фикерне логик рәвештә һәм аңлаешлы итеп белдерергә ярдәм итү.

Кызыксындыруны үстерүгә булышлык итү.

Балаларга яшьтәшләре белән дустанә аралашырга ярдәм итү, дусны ничек итеп шатландырырга, котларга мөмкин булуын, аның гамәлләренә карата ризасызлыкны ничек итеп тыныч кына белдерергә, ничек гафу үтенергә икәнлеген әйтеп тору.

**Сүзлек формалаштыру.** Якын тирәлек турындагы белемнәрне тирәнәйтү нигезендә балаларның сүз запасын тулыландыру һәм активлаштыру. Үз тәҗрибәләре аша таныш булмаган предметлар, күренешләр, вакыйгалар турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Сөйләмдә предметлар, аларның өлешләре, алар эшләнгән материалларның атамаларын куллануны активлаштыру.

Сөйләмдә иң күп кулланылучы сыйфатларны, фигыльләрне, рәвешләрне, бәйлекләрне файдаланырга өйрәтү.

Балалар сүзлегенә һөнәрләрне белдерүче исемнәрне, хезмәт гамәлләрен сыйфатлаучы фигыльләрне кертү.

Балаларны предметның урынын (сулда, уңда, янәшә, янында, арасында), тәүлек вакытын ачыкларга һәм билгеләргә, аларны әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү. Балалар тарафыннан еш кулланылучы күрсәтү алмашлыкларын һәм рәвешләрне (тегендә, шунда, шундый, шушы, бу) төгәлрәк мәгънәле сүзләр белән алыштырырга булышу; антоним сүзләр куллану (чиста — пычрак, якты — караңгы).

Гомумиләштерүче мәгънәле исемнәр кулланырга өйрәтү (йорт җиһазлары, яшелчәләр, хайваннар һ.б.).

**Сөйләмнең аваз культурасы.** Сузык һәм тартык авазларны дөрес әйтүне ныгыту, сызгырулы, чыжылдаучы һәм сонор (р, л) авазларны әйтергә өйрәнү. Артикуляция аппаратын үстерү.

Дикция өстендә эшләүне дәвам итү: сүзләрне һәм сүзтезмәләрне ачык итеп әйтүне камилләштерү.

Фонематик ишетү сәләтен үстерү: билгеле бер авазга башланучы сүзләрне яңгырашлары буенча аерырга һәм әйтергә өйрәтү.

Сөйләмнең интонация тәэсирен камилләштерү.

**Сөйләмнең грамматик төзелеше.** Балаларда җөмләдә сүзләрне яраштыру, сөйләмдә бәйлекләрне дөрес куллана белү сәләте формалаштыруны дәвам итү, хайваннарның балаларын белдерүче исемнәрнең күплек сан формасын ясау (аналогия буенча), бу исемнәрне баш һәм төшем килешләрендә куллану (төлке балалары — төлке балаларын, аю балалары — аю балаларын); исемнәрнең иялек килешендәге күплек сан формасын дөрес куллану (чәнечкеләрнең, алмаларның, туфлиләрнең).

Татар телендә кайбер парлы әгъзалар (күзләр, куллар, аяклар) турында берлек сандагыча сөйләшү тәртибе белән таныштыру: «күзем йомыла», «кулым туңды», «аягым арыды» һ.б.

Яшәешнең бишенче елы өчен хас сүзләр иҗат итү күренешен хуплау, әдәпле генә итеп сүзнең гомуми кабул ителгән үрнәген әйтеп җибәрү.

Балаларда сөйләмдә тезмә кушма һәм иярченле кушма җөмләләрнең иң гади төрләрен актив куллану теләге тудыру.

**Бәйләнешле сөйләм**. Диалогик сөйләмне камилләштерү: әңгәмәдә катнашырга, тыңлаучылар өчен аңлаешлы итеп сорауларга җаваплар, сораулар бирергә өйрәтү.

Балаларны сөйли белергә өйрәтү: предметны, картинаны тасвирлау, таратылган дидактик материалны кулланып, бала үзе ясаган картина (күренеш) буенча хикәя төзергә өйрәтү.

Балалар белән әкиятләрдән иң тәэсирле һәм хәрәкәткә бай өзекләрне сөйләп күрсәтү буенча күнегүләр уздыру.

## Зурлар төркеме
## (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

**Үсешкә булышлык итүче сөйләм мохите.** Аралашу чарасы буларак сөйләмне үстерүне дәвам итү. Балаларның әйләнә-тирә дөньяның күптөрлелеге турындагы күзаллауларны үстерү. Карау өчен халык кәсепчелеге эшләнмәләрен, мини-коллекцияләр (открыткалар, маркалар, акчалар, билгеле бер материалдан эшләнгән уенчыклар җыелмалары), иллюстрацияле китаплар (шул исәптән төрле рәссамнарның рәсемнәре белән бизәлгән таныш әкиятләр), туган якның, Мәскәүнең истәлекле урыннары төшерелгән открыткалар, фотосурәтләр, картиналар (шул исәптән революциягә кадәрге Россия тормышы чагылдырылганнары) репродукцияләрен тәкъдим итү.

Баланың алган төрле тәэсирләрен педагог һәм башка балалар белән уртаклашу омтылышларын хуплау, алынган мәгълүмат чыганагын ачыклау (телетапшыру, якыннарының сөйләгәннәре, күргәзмәдә булу, балалар спектаклен карау һ.б.).

Көндәлек тормышта, уеннарда балаларга итагатьлелек белдерү формаларын (кичерүне үтенү, гафу үтенү, рәхмәт белдерү, комплимент әйтү) җиткерү.

Балаларны бәхәсле мәсьәләләрне һәм низагларны сөйләм ярдәмендә: ышандыру, дәлилләү, аңлату юлы белән хәл итәргә өйрәтү.

**Сүзлек формалаштыру.** Балаларның сөйләм телен көнкүреш тирәлеге предметларын белдерүче исемнәр; предметларның үзлекләрен тасвирлаучы сыйфатлар; кешеләрнең үзара, хезмәткә карата мөнәсәбәтләрен белдерүче рәвешләр белән баету.

Сыйфатка туры килгән исемнәр (ак — кар, шикәр, акбур), охшаш мәгънәле сүзләр (шаян — наян — шук), капма-каршы мәгънәле сүзләр (көчсез — көчле, болытлы — кояшлы) табарга өйрәтү.

Балаларда сөйләмдә сүзләрне мәгънәләренә төгәл туры китереп кулланырга ярдәм итү.

**Сөйләмнең аваз культурасы.** Авазларны дөрес, ачык итеп әйтүне ныгыту. Артикуляция һәм яңгыраш буенча охшаш с – з, с – ц, ш – ж, ч –ц, с – ш, ж – з, л – р авазларын ишетү буенча аерырга һәм ачык итеп әйтергә өйрәтү.

Фонематик ишетү сәләтен үстерүне дәвам итү. Сүздә авазның урынын (башта, уртада, ахырда) билгеләргә өйрәтү.

Сөйләмнең интонация тәэсирен үзләштерү.

**Сөйләмнең грамматик төзелеше.** Җөмләләрдә сүзләрне: исемнәрне — саннар (биш груша, өч бала) һәм сыйфатларны исемнәр (яшел бака) белән яраштыру сәләтен камилләштерү. Балаларга сүздә басымның дөрес куелмавын, тартыклар чиратлашуындагы хатаны күрергә ярдәм итү, аны мөстәкыйль рәвештә төзәтү мөмкинлеге бирү.

Сүзләр ясалуның төрле ысуллары белән таныштыру (шикәр савыты, аяк киеме; майлы; кульъяулык; тәрбияче, укытучы, төзүче).

Тамырдаш сүзләр ясалышы буенча күнекмәләр үткәрү (аш — ашамлык — ашлык — ашау; баш — башлык — башлангыч — башта; чәчү — чәчүлек — чәчкеч).

Балаларга күплек сандагы исемнәрне баш килештә һәм төшем килешендә; боерык фигыльләрне; сыйфатларны һәм рәвешләрне чагыштыру дәрәҗәсендә; төрләнмәүче исемнәрне дөрес кулланырга булышу.

Үрнәк буенча гади һәм кушма җөмләләр төзергә өйрәтү.

Туры һәм кыек сөйләмнәрне куллана белү күнекмәләрен камилләштерү.

**Бәйләнешле сөйләм.** Әңгәмәне дәвам иттерү сәләтен үстерү.

Сөйләмнең диалог формасын камилләштерү. Үз фикерен, иптәшенең җавабы белән килешү яки килешмәүне белдерү омтылышларын хуплау.

Сөйләмнең монолог формасын үстерү.

Зур булмаган әкиятләрне, хикәяләрне бәйләнешле, эзлекле һәм тәэсирле итеп кабат сөйләргә өйрәтү.

Предмет, сюжетлы картинаның эчтәлеге турында сөйләргә (план һәм үрнәк буенча), вакыйга эзлекле рәвештә үстерелгән рәсемнәр буенча хикәя төзергә өйрәтү.

Баланың үз тәҗрибәсендәге вакыйгаларга нигезләнеп хикәяләр төзү, әкиятләрнең ахырын үзенчә уйлап чыгару сәләтен үстерү.

Тәрбияче тәкъдим иткән темага иҗади характердагы кечерәк хикәяләр төзү сәләтен формалаштыру.

### Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

**Үсешкә булышлык итүче сөйләм мохите.** Балаларны — булачак укучыларны яңа белемнәр алу максатында инициатива күрсәтергә өйрәтү.

Аралашу чарасы буларак сөйләмне камилләштерү.

Балаларның үз күзләре белән нәрсә күрергә теләүләрен, нәрсә турында белергә теләүләрен, нинди өстәл уеннары һәм интеллектуаль уеннар уйнарга өйрәнергә теләүләрен, кайсы мультфильмнарны кабат һәм ни өчен карарга теләүләрен, нинди хикәяләрне (нәрсә турындагы) тыңлауга өстенлек бирүләрен һ.б. ачыклау.

Балаларның тәҗрибәсенә таянып һәм аларның теләкләрен исәпкә алып, мөстәкыйль рәвештә аңга кабул итү, алга таба тәрбияче һәм яшьтәшләре белән уртага салып тикшерү өчен күрсәтмә материаллар сайлап алу.

Балаларның әйткәннәренә төгәллек кертү, аларга объектны, хәлне төгәлрәк тасвирларга булышу; фаразлар әйтергә һәм фикерләрен тирәлектәгеләр өчен аңлаешлы бәян итәргә өйрәтү.

Үз фикереңне яклый белү сәләте формалаштыруны дәвам итү.

Сөйләм этикеты формаларын үзләштерергә ярдәм итү.

Кызыклы фактлар һәм вакыйгалар турында балаларга эчтәлекле, тәэсирле итеп сөйләүне дәвам итү.

Балаларны фикерләү мөстәкыйльлегенә өйрәтү.

**Сүзлек формалаштыру.** Балаларның көнкүреш, табигать һәм җәмгыятькә кагылышлы сүз запасын баету эшен дәвам итү.

Балаларда сүзнең мәгънәсе белән кызыксыну теләге уяту.

Төрле сүз төркемнәрен мәгънәләренә һәм фикерне җиткерү максатына төгәл туры китереп куллана белү сәләтен камилләштерү.

Балаларга телнең сәнгатьле чараларын үзләштерергә ярдәм итү.

**Сүзнең аваз культурасы.** Ишетү һәм әйтелеш буенча туган телнең барлык авазларын аера белүне камилләштерү. Дикцияне камилләштерү: балаларны сүзләрне һәм сүзтезмәләрне табигый интонацияләр белән аңлаешлы һәм ачык әйтергә өйрәтү.

Фонематик ишетү сәләтен камилләштерү: билгеле бер аваз кергән сүзне аерып әйтергә, җөмләдә бу аваз булган сүзне табарга, сүздә авазның урынын билгеләргә өйрәтү.

Сөйләмнең интонация тәэсирен камилләштерү.

**Сүзнең грамматик төзелеше.** Балаларны җөмләдә сүзләрне яраштыруга өйрәтүне дәвам итү.

Тамырдаш сүзләр (үрнәк буенча), исемнәр, фигыльләр, чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәләрендә сыйфатлар ясый белүне камилләштерү. Иярченле кушма җөмләләрне дөрес төзергә, аларның өлешләрен бәйләү өчен тел чаралары (өчен, дип, вакытта, чөнки, әгәр, әгәр дә һ.б.) кулланырга булышу.

**Бәйләнешле сөйләм.** Сөйләмнең диалог һәм монолог формаларын камилләштерүне дәвам итү.

Тәрбияче һәм бала, балалар арасында диалог алып бара белү сәләтен формалаштыру; дустанә һәм әдәпле әңгәмәдәшләр булырга өйрәтү, сөйләшеп аралашу культурасы тәрбияләү.

Әдәби текстларның эчтәлеген тулы һәм сәнгатьле итеп сөйләп бирергә, аларны уйнап күрсәтергә өйрәтүне дәвам итү.

Предметлар турында, картинаның эчтәлеге турында, вакыйга эзлекле рәвештә сурәтләнгән рәсемнәр буенча хикәяләр төзи белү сәләтен камилләштерү. Хикәянең планын төзергә һәм шул планнан чыкмаска ярдәм итү.

Үз тәҗрибәңә нигезләнеп хикәяләр төзи белү сәләте үстерү.

Бирелгән темага кыска әкиятләр иҗат итү сәләтен камилләштерүне дәвам итү.

**Укырга-язарга өйрәтүгә әзерләү.** Җөмлә турында күзаллаулар булдыру (грамматик билгеләмәдән башка).

Җөмләләр төзү, гади җөмләләрне (теркәгечләрдән һәм бәйлекләрдән башка), эзлеклелекне күрсәтеп, сүзләргә бүлү буенча күнекмәләр уздыру.

Балаларны ачык иҗекләрдән торган ике иҗекле һәм өч иҗекле сүзләрне (без-дә, ча-на, бә-рәң-ге, ма-ши-на) өлешләргә бүләргә өйрәтү.

Иҗекләрдән сүзләр төзергә өйрәтү (телдән).

Гади сүзләрдә авазлар чиратлашуын аерырга өйрәтү.

## Матур әдәбиятка тарту[1]

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Балаларга кече яшьтәгеләрнең икенче төркеме өчен программада каралган матур әдәбият әсәрләрен уку.

Балаларны халык җырлары, әкиятләр, автор әсәрләрен тыңларга өйрәтүне дәвам итү. Укуны уенчыклар, рәсемнәр, өстәл театры персонажлары һәм башка күрсәтмә чаралар белән чиратлаштыру, шулай ук матур әдәбият әсәрләрен күрсәтмә әсбаплардан башка тыңларга өйрәтү.

Зур булмаган шигъри әсәрләрне укуны уеннар белән чиратлаштыру.

Тәрбияче таныш шигырьләрне укыганда балаларга сүзләрне, гыйбарәләрне әйтеп бетерү мөмкинлеге бирү.

Өлкән кеше ярдәмендә шигырь текстын тулысынча укып чыгу омтылышларын хуплау.

2 яшь 6 айдан өлкәнрәк балаларга таныш әкиятне уйнарга булышу.

Балаларны китаплардагы рәсемнәрне карарга тартуны дәвам итү. Таныш предметларны атау, тәрбияче соравы буенча аларны күрсәтү теләге тудыру, «Бу кем (нәрсә)?», «Нәрсә эшли?» сорауларын бирергә өйрәтү.

### Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

Кечкенәләрнең беренче төркеме өчен программа тарафыннан тәкъдим ителгән таныш, балаларның яраткан әсәрләрен уку.

Яңа әкиятләр, хикәяләр, шигырьләр тыңлый, вакыйга үсешен күзәтә, әсәр геройларының кичерешләрен уртаклаша белү сәләте тәрбияләү. Балаларга персонажларның гамәлләрен һәм бу гамәлләрнең нәтиҗәләрен аңлату. Балаларга сүзләрне һәм әйтү өчен катлаулы булмаган гыйбарәләрне әйтеп бетерү мөмкинлеге биреп, укылган әсәрдән иң кызыклы, тәэсирле өзекләрне кабатлау.

Тәрбияче ярдәмендә халык әкиятләреннән кечерәк өзекләрне сәхнәләштерергә һәм уйнап күрсәтергә өйрәтү.

Балаларны яттан мәзәкләр һәм кечерәк шигырьләр сөйләргә өйрәтү.

Китапларга карата кызыксынучанлык формалашуга булышуны дәвам итү. Балалар белән даими рәвештә иллюстрацияләр карау.

---

[1] Балаларга уку өчен үрнәк әдәбият исемлеге Кушымтада тәкъдим ителә.

## Уртанчылар төркеме
## (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

Балаларны әкиятләр, хикәяләр, шигырьләр тыңларга өйрәтүне дәвам итү; кечерәк һәм гади эчтәлекле санамышларны истә калдыру. Төрле алымнардан һәм педагогик ситуацияләрдән файдаланып, аларга әсәрнең эчтәлеген дөрес кабул итәргә, геройларның кичерешләрен уртаклашырга булышу.

Әсәргә карата шәхси мөнәсәбәт булдыруга булышлык итеп, бала соравы буенча әкияттән, хикәядән, шигырьдән аңа ошаган өзекне уку.

Әдәби әсәрдә сүзгә карата игътибар һәм кызыксыну саклау.

Китапка карата кызыксыну формалаштыру эшен дәвам итү. Балалар игътибарына таныш әсәрләрнең иллюстрацияле басмаларын тәкъдим итү. Китаптагы рәсемнәрнең мөһим булуын аңлату; китаптагы иллюстрацияләрне игътибар белән карап күп кенә кызыклы нәрсәләр турында белергә мөмкин булуын күрсәтү. Ю. Васнецов, Е. Рачев, Е. Чарушин тарафыннан бизәлгән китаплар белән таныштыру.

## Зурлар төркеме
## (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Балаларның матур әдәбиятка карата кызыксынуын үстерүне дәвам итү. Әкиятләрне, хикәяләрне, шигырьләрне игътибар һәм кызыксыну белән тыңларга; санамышларны, тизәйткечләрне, табышмакларны истә калдырырга өйрәтү. Зур күләмле әсәрләрне укуга (бүлекләп) карата кызыксыну тәрбияләү.

Әдәби әсәрләргә карата эмоциональ мөнәсәбәт формалаштыруга булышлык итү.

Балада әдәби персонажның конкрет гамәлен ничек кабул итүе турында сөйләү теләге тудыру. Балаларга әсәр геройларының үз-үзләрен тотышының яшерен мотивларын аңларга ярдәм итү.

Әкиятләрнең, хикәяләрнең, шигырьләрнең балаларга аңлаешлы жанр үзенчәлекләрен аңлатуны дәвам итү (укылган әсәргә таянып).

Нәфис сүзгә карата игътибарлылык тәрбияләү; аеруча ачык, истә калырлык тасвирлаулар, чагыштырулар, эпитетлар булган өзекләрне уку. Балаларны шигъри текстның ритмын һәм аһәңлелеген күңел биреп тыңларга өйрәтү.

Шигырьләрне сәнгатьле итеп, табигый интонацияләр белән укырга, текстны рольләргә бүлеп укуда, сәхнәләштерүләрдә катнашырга булышлык итү.

Китаплар белән таныштыруны дәвам итү. Балаларның игътибарын китапның бизәлешенә, иллюстрацияләргә юнәлтү. Төрле рәссамнарның бер үк әсәргә ясалган иллюстрацияләрен чагыштыру. Балаларның кайсыларына өстенлек бирүләрен ачыклау.

### Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Балаларның матур әдәбиятка карата кызыксынуын үстерүне дәвам итү. Әдәби багажны әкиятләр, хикәяләр, шигырьләр, табышмаклар, санамышлар, тизәйткечләр белән тулыландыру.

Китап геройларының хәленә керергә, аларның кичерешләрен уртаклашырга, үзен яраткан персонажы белән тәңгәлләштерергә сәләтле укучы тәрбияләү. Балаларда юмор хисе үстерү.

Балаларның игътибарын тәэсир итү чараларына (образлы сүзләр һәм гыйбарәләр, эпитетлар, чагыштырулар); әсәр теленең матурлыгын һәм сәнгатьлелеген тоярга булышу; шигъри сүзгә карата игътибарлылык тәрбияләү.

Шигырь сөйләгәндә, тамашада катнашканда балаларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү (башкаруның эмоциональлеге, үз-үзеңне тотуның табигыйлеге, интонация, ишарә, мимика белән әдәби гыйбарә эчтәлегенә карата үз мөнәсәбәтеңне белдерә белү сәләте).

Балаларга төрле әдәби жанрлар — әкият, хикәя, шигырь арасындагы төп аермаларны аңлатырга ярдәм итү.

Балаларны танылган рәссамнарның иллюстрацияләре белән таныштыруны дәвам итү.

## «СӘНГАТИ-ЭСТЕТИК ҮСЕШ» белем бирү өлкәсе

«Сәнгати-эстетик үсеш сәнгать (сүз-тел сәнгате, музыкаль, сынлы сәнгать) әсәрләрен, табигать дөньясын кыйммәт-мәгънә ягыннан кабул итү һәм аңлау алшартлары үсешен; әйләнә-тирә дөньяга карата эстетик мөнәсәбәт барлыкка килүне; сәнгать төрләре турында элементар күзаллаулар формалашуны; музыканы, матур әдәбиятны, фольклорны аңга кабул итүне; әдәби әсәрләр персонажларының кичерешләрен уртаклашуны стимуллаштыруны; балаларның мөстәкыйль иҗади (сурәтләү, конструкцияләү-модельләү, музыкаль һ.б.) эшчәнлеген гамәлгә ашыруны күздә тота»[1].

### Төп максатлар һәм бурычлар

Әйләнә-тирә чынбарлыкның эстетик ягына карата кызыксынучанлык, әйләнә-тирә дөнья предметларына һәм күренешләренә, сәнгать әсәрләренә карата эстетик мөнәсәбәт формалаштыру; нәфис-иҗади эшчәнлеккә карата кызыксынучанлык тәрбияләү.

Балаларның эстетик хисләрен, сәнгати кабул итүен, образлы күзаллауларын, хыялларын, иҗади сәләтләрен үстерү.

[1] МББ ФДББСның 2.6. пунктын кара.

Балалар иҗатын, мөстәкыйль иҗади (сурәтләү, конструкцияләү-модельләү, музыкаль һ.б.) эшчәнлеккә карата кызыксынуны үстерү; балаларның үз-үзләрен күрсәтү ихтыяҗын канәгатьләндерү.

**Сәнгатькә тарту.** Әдәби һәм музыкаль әсәрләрне, әйләнә-тирә дөньяның, сәнгать әсәренең матурлыгын эмоциональ бәяләүне үстерү.

Илебез һәм чит илләр сәнгатенең иң яхшы үрнәкләре белән таныштыру аша балаларны халык сәнгатенә һәм профессиональ сәнгатькә (сүз-тел, музыкаль, сынлы сәнгать, театр сәнгатенә, архитектурага) тарту; сәнгать әсәрләренең эчтәлеген аңлый белү сәләте тәрбияләү.

Сәнгатьнең төрләре һәм жанрлары, сәнгатьнең төрле төрләрендәге тәэсир итү чаралары турында элементар күзаллаулар формалаштыру.

**Сурәтләү эшчәнлеге.** Сурәтләү эшчәнлегенең төрле төрләренә карата кызыксынуны үстерү; рәсем ясау, әвәләү, аппликация, гамәли иҗат күнекмәләрен камилләштерү.

Сынлы сәнгать әсәрләре белән танышканда эмоциональ тоемлый белү сыйфатын тәрбияләү.

Коллектив эшләр башкарганда яшьтәшләре белән бергәләп эшләү теләге һәм эшли белү сыйфаты тәрбияләү.

**Конструкцияләү-модельләү эшчәнлеге.** Конструкцияләүгә тарту; конструкцияләү эшчәнлегенә карата кызыксынуны үстерү, конструкторларның төрле төрләре белән таныштыру.

Коллектив эшләү, үз эшләнмәләреңне гомуми ният кысаларында берләштерү, эшнең кайсы өлешен кем башкарачагы турында сүз куеша белү сыйфаты тәрбияләү.

**Музыкаль эшчәнлек.** Музыкаль сәнгатькә тарту; музыка сәнгатен кыйммәт-мәгънә ягыннан кабул итү һәм аңлау алшартларын үстерү; музыкаль культура нигезләрен формалаштыру, элементар музыкаль төшенчәләр, жанрлар белән таныштыру; музыка әсәрләре белән танышканда эмоциональ тоемлый белү сыйфатын тәрбияләү.

Музыкаль эшчәнлек өчен зарур сыйфатлар: шигъри һәм музыкаль тоем, ритм хисен, музыкаль хәтерне үстерү; җыр зәвыгы, музыкаль зәвык формалаштыру.

Музыкаль-сәнгати эшчәнлеккә карата кызыксыну тәрбияләү, эшчәнлекнең бу төрендәге күнекмәләрне камилләштерү.

Балалар музыкаль-нәфис иҗатын үстерү, балаларның мөстәкыйль иҗади эшчәнлеген гамәлгә ашыру; үз-үзләрен күрсәтү ихтыяҗын канәгатьләндерү.

## Психологик-педагогик эш эчтәлеге

### Сәнгатькә тарту

#### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Сәнгати кабул итүне үстерү, музыкага һәм җырлауга, балаларга аңлаешлы сәнгать, әдәбият әсәрләрен тоемлый белү сыйфаты тәрбияләү.

Балалар белән бергә балалар әдәбияты әсәрләренә карата ясалган иллюстрацияләр карау. Рәсемнәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белү күнекмәләрен үстерү.

Балаларның яшенә туры килгән халык уенчыклары белән таныштыру.

Балаларның игътибарын уенчыкларның характерына (күңелле, кызык һ.б.), формасына, төсләр белән бизәлешенә юнәлтү.

#### Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

Балаларның эстетик хисләрен, сәнгати кабул итүен үстерү, әдәби һәм музыкаль әсәрләргә, әйләнә-тирә дөньяның матурлыгына, халык сәнгате һәм профессиональ сәнгать әсәрләренә (китап иллюстрацияләре, халык кәсепчелеге эшләнмәләре, көнкүреш предметлары, өс киеме) карата уңай эмоциональ тоемлау барлыкка килүгә булышлык итү.

Балаларда сәнгать әсәрләренә тартылу уяту. Сәнгатьнең төрле төрләрендәге элементар тәэсир итү чаралары (төс, аваз, форма, хәрәкәт, ишарәләр) белән таныштыру, сәнгати образ аша сәнгать төрләрен аера белүгә китерү.

Балаларны курчак театрына, балалар эшләре күргәзмәсенә барырга әзерләү һ.б.

#### Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

Балаларда сәнгатькә тартылуны, сәнгатькә карата кызыксынуны үстерү. Халык сәнгате һәм декоратив-гамәли сәнгать әсәрләрен караганда, музыкаль фольклор әсәрләрен тыңлаганда эстетик хисләр, эмоцияләр чагылышын хуплау.

Балаларны артист, рәссам, композитор һөнәрләре белән таныштыру.

Табигатьтәге, әйләнә-тирәдәге предметларны һәм күренешләрне тану һәм әдәбият, музыка, сынлы сәнгатьтәге сәнгати образлар белән атау теләге тудыру.

Сәнгать жанрларын һәм төрләрен аерырга өйрәтү: шигырьләр, проза, табышмаклар (әдәбият), җырлар, биюләр, музыка, картина (репродукция), скульптура (сынлы сәнгать), бина һәм корылма (архитектура).

Төп тәэсир итү чараларын (төс, форма, зурлык, ритм, хәрәкәт, ишарә, аваз (тавыш)) аерырга һәм әйтә белергә, шулай ук сурәтләү, музыкаль, конструкцияләү эшчәнлегендә үз нәфис образларын тудырырга өйрәтү.

Балаларны архитектура белән таныштыру. Алар яшәгән йортларның (балалар бакчасы, мәктәп, башка биналар) архитектура корылмалары икәнлеге; йортларның форма, биеклек, озынлык, катлар һәм подъездлары исәбе, тәрәзә рәвешләре һ.б. буенча төрле булуы турында карашлар формалаштыру.

Балалар бакчасы тирәсендә урнашкан төрле корылмаларга (бала һәм аның дуслары яшәгән йортлар, мәктәп, кинотеатр) карата кызыксыну уяту.

Балаларның игътибарын төрле биналарның охшашлыгына һәм аерымлыкларына җәлеп итү, мөстәкыйль рәвештә бинаның өлешләрен, аның үзенчәлекләрен аера белүне хуплау. Форма һәм төзелеш буенча охшаш биналарда аерымлыклар (ишекләр, тәрәзәләр һәм башка өлешләрнең формасы һәм зурлыгы) күрә белүне ныгыту.

Балаларның рәсемнәрдә, аппликацияләрдә чынбарлыктагы һәм әкияти корылмаларны сурәтләү омтылышын хуплау.

Музейга баруны оештыру (әти-әниләр белән бергә), музейның төре, вазифасы турында сөйләү.

Курчак театрына, күргәзмәләргә йөрүгә карата кызыксынуны үстерү.

Балаларның китап, китап иллюстрациясе турындагы белемнәрен ныгыту. Язучылар һәм шагыйрьләр тарафыннан иҗат ителгән китапларны саклау үзәге буларак, китапханә белән таныштыру.

Халык иҗаты әсәрләре (мәзәкләр, әкиятләр, табышмаклар, җырлар, әйлән-бәйлән, мөрәҗәгать-такмаклар, халык гамәли-бизәлеш сәнгате эшләнмәләре) белән таныштыру.

Сәнгать әсәрләренә карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

### Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Музыкага, сынлы сәнгатькә, әдәбиятка, халык сәнгатенә карата кызыксыну формалаштыруны дәвам итү.

Эстетик хисләр, эмоцияләр, эстетик зәвык, сәнгать әсәрләрен эстетик кабул итүне үстерү, сәнгать әсәрләренең тәэсир итү чараларын аера белүне формалаштыру. Сәнгати образны аны сәнгатьнең төрле төрләрендә характерлаучы тәэсир итү чаралары белән тиңләштерергә, мөстәкыйль сәнгать эшчәнлеге өчен материал һәм әсбаплар сайларга өйрәтү.

Сәнгать әсәрләрен сәнгать төрләре (әдәбият, музыка, сынлы сәнгать, архитектура, театр) буенча аерып исемләү, төркемләштерә белүне формалаштыру. Сынлы сәнгать һәм музыка сәнгате жанрлары белән таныштыруны дәвам итү. Үзеңнең сурәтләү, музыкаль, театральләштерелгән эшчәнлегеңдә сәнгатьнең төрле төрләренең тәэсир итү чараларын аера һәм куллана белүне формалаштыру, сәнгати эшчәнлекнең төрле төрләре өчен кирәкле материалларны атау.

Сынлы сәнгатьнең төрле әсәрләре (И. Шишкин, И. Левитан, В. Серов, И. Грабарь, П. Кончаловский һ.б.) һәм рәссамнарның туган як табигатен сурәтләгән картиналары белән таныштыру. Графика (аның тәэсир итү чаралары) турындагы күзаллауларны киңәйтү. Балалар китапларын иллюстрацияләгән рәссамнар (Ю. Васнецов, Е. Рачев, Е. Чарушин, И. Билибин һ.б.) иҗаты белән таныштыру.

Архитектура белән таныштыруны дәвам итү. Төрле максатлардагы биналар — торак йортлар, кибетләр, театрлар, кинотеатрлар һ.б. булу турындагы белемнәрне ныгыту. Балаларның игътибарын бер төрле максаттагы архитектура корылмаларының охшашлыкларына һәм аерымлыкларына юнәлтү: форма, пропорцияләр (биеклек, озынлык, бизәкләр — декор һ.б.). Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны бина конструкциясенең аның нинди максат белән төзелүенә: торак, йорт, театр, храм һ.б. төшендерү.

Күзәтүчәнлекне үстерү, биналарны игътибар белән карарга, аларга хас үзенчәлекләрне, пропорцияләренең, конструкцияләренең, бизәлеш детальләренең төрлелеген күрергә өйрәтү.

Әдәби әсәрләрне, әкиятләрне укыганда балаларның игътибарын әкияти өйләрнең (теремкәй, бияләй, тавык аякларындагы йорт), сарайларның тасвирлануына юнәлтү.

«Халык сәнгате», «халык сәнгате төрләре һәм жанрлары» төшенчәләре белән таныштыру. Балаларның халык сәнгате, фольклор, музыка һәм халык нәфис кәсепчелеге турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Балаларда сәнгать әсәрләренә карата ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру.

### Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Эстетик кабул итүне, ритмны тоемлауны, сәнгати зәвыкны, тирәлеккә, сәнгатькә һәм нәфис эшчәнлеккә карата эстетик мөнәсәбәтне үстерү.

Классик сәнгатькә һәм халык сәнгатенә (музыкага, сынлы сәнгатькә, әдәбиятка, архитектурага) карата кызыксыну формалаштыру.

Сәнгати культура нигезләрен формалаштыру. Сәнгатькә карата кызыксыну үстерү. Иҗади эшчәнлек төре буларак сәнгать, аның төрләре (гамәли-бизәлеш, сынлы сәнгать, әдәбият, музыка, архитектура, театр, бию, кино, цирк) турындагы белемнәрне ныгыту.

Балаларның сынлы сәнгать турындагы белемнәрен киңәйтү, сынлы сәнгать әсәрләрен сәнгати кабул итүне үстерү. Балаларны нәкыш сәнгате әсәрләре белән таныштыруны дәвам итү: И. Шишкин («Арыш кыры», «Нарат урманында иртә»), И. Левитан («Алтын көз», «Март», «Яз. Зур су»), А. Саврасов («Каргалар кайтты»), А. Пластов («Көн уртасы», «Җәй», «Печән өсте»), В. Васнецов («Аленушка», «Баһадирлар», «Патша улы Иван Соры бүре өстендә») һ.б.

Образлы тәэсир итү чараларын (форма, пропорцияләр, төс, характерлы детальләр, позалар, хәрәкәтләр һ.б.) аерып күрсәтеп, кече формалы скульптура турындагы күзаллауларны баету.

Балалар китапларын иллюстрацияләнгән рәссамнар (И. Билибин, Ю. Васнецов, В. Конашевич, В. Лебедев, Т. Маврина, Е. Чарушин) иҗаты белән таныштыруны дәвам итү.

Халык гамәли-бизәлеш сәнгате (Гжель, Хохлома, Жостово, Мезень бизәкләре), керамик эшләнмәләр, халык уенчыклары белән таныштыруны дәвам итү.

Балаларны архитектура белән таныштыруны дәвам итү, биналарның төрле максатларда (торак йортлар, кибетләр, кинотеатрлар, балалар бакчалары, мәктәпләр һ.б.) булуы турындагы белемнәрне баету.

Бер төрле максаттагы архитектура корылмаларының охшашлыкларын һәм аерымлыкларын аера белүне үстерү. Конструкциянең бер төрле өлешләрен һәм детальләрнең үзенчәлекләрен аера белүне формалаштыру.

Храм архитектурасы үзенчәлекләре белән таныштыру: гөмбәз, аркалар, бина әйләнәсе буенча арка поясы, барабан (гөмбәз астындагы түгәрәк өлеш) һ.б. Архитектура белән балалар яшәгән җирлекнең төбәк үзенчәлекләренә таянып таныштыру. Балаларга, сәнгатьнең һәр төрендәге кебек, архитектурада да бөтен дөньяга танылган ядкярләр: Россиядә — Кремль, Василий Блаженный соборы, Кышкы сарай, Исаакий соборы, Петергоф, Алтын боҗра ядкярләре һ.б. булуы — аларның һәр шәһәрдә дә барлыгы турында сөйләү.

Балаларның сәнгати эшчәнлектә архитектура корылмалары, әкияти корылма образларын чагылдыра белүен үстерү. Корылмаларның детальләрен (тәрәзә һәм ишек йөзлекләре, түбә контуры буенча челтәр кәрниз) сурәтләү омтылышын хуплау.

Балаларның иҗади эшчәнлек, аның үзенчәлекләре турындагы күзаллауларын киңәйтү; сәнгати эшчәнлек төрләрен, сәнгать эшлеклеләре һөнәрләрен (рәссам, композитор, артист, биюче, җырчы, пианинода уйнаучы, скрипкачы, режиссер, театр директоры, архитектор һ.б.) белүен формалаштыру.

Эстетик хисләрен, эмоцияләрен, кичерешләрен; эшчәнлекнең төрле төрләрендә мөстәкыйль рәвештә нәфис образлар тудыру күнекмәләрен үстерү.

Сәнгати эшчәнлек өчен кешенең сизү органнарының әһәмияте турында күзаллаулар формалаштыру, сизү органнарын сәнгать төрләре белән тиңләштерә белүне (музыканы тыңлыйлар, картиналарны карыйлар, шигырьләрне укыйлар һәм тыңлыйлар һ.б.) формалаштыру.

Сәнгать тарихы һәм сәнгать төрләре белән таныштыру; халык сәнгатен һәм профессиональ сәнгатьне аера белүне формалаштыру. Күргәзмәләргә, театрга, музейга, циркка баруны оештыру (әти-әниләр белән бергә).

Халык сәнгатенең, нәфис кәсепчелекнең төрлелеге турындагы күзаллауларны киңәйтү (материалларның төрле төрләре, илнең һәм дөньяның төрле төбәкләре).

Туган як сәнгатенә карата кызыксыну; сәнгать әсәрләренә карата мәхәббәт һәм сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

Балаларның үз теләкләре белән һәм өлкән кеше җитәкчелегендә сәнгати эшчәнлектә актив катнашуларын хуплау.

## Сурәтләү эшчәнлеге

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Балаларда карандаш, фломастер, пумала, буяулар, балчык белән эш итүгә карата кызыксыну тудыру.

**Рәсем ясау.** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның аңга кабул итүен үстерү, предметларның формаларын аерып күрсәтү, аларны контурлары буенча башта — бер, аннары икенче кул белән йөреп чыгу ярдәмендә сиземләү тәҗрибәсен баету.

Балаларга сайлау иреге биреп, үзләренә таныш предметларны сурәтләргә этәрү.

Балаларның игътибарын карандашның очланган башын (фломастерны, пумала кылын) кәгазьдә йөрткәндә аның эз калдыруына юнәлтү. Карандашның кәгазь өслегендәге хәрәкәтен күзәтергә өйрәтү.

Балаларның игътибарын алар кәгазьдә сурәтләгән төрле сызыкларга, конфигурацияләргә җәлеп итү. Аларны нәрсә ясаулары, ясаганнарының нәрсәгә охшаш булуы турында уйланырга этәрү. Балаларда үзләре ясаган штрихларга һәм сызыкларга карап шатлану хисе тудыру. Балаларда ясалган сурәтне өстәмә детальләр белән тулыландыру; элегрәк ясалган штрихларны, сызыкларны, тапларны, формаларны аңлы рәвештә кабатлау теләге уяту.

Тирәлектәге предметларны эстетик кабул итүне үстерү. Балаларны карандашларның, фломастерларның төсләрен аерырга, аларның исемен дөрес итеп әйтергә; төрле (озын, кыска, вертикаль, горизонталь, авыш) сызыклар сызгаларга, алар аркылы предметларга — кечкенә тасмаларга, яулыкларга, юлларга, инешләргә, боз сөңгеләренә, коймага һ.б. га охшатып сызыклар сызарга өйрәтү. Балаларны түгәрәк предметларны ясарга этәрү.

Рәсем ясаганда дөрес поза формалаштыру (җайлы утыру, кәгазь бите өстенә бик түбән иелмәү), буш кул сабый рәсем ясаган кәгазь битне тотып тора.

Материалларга сакчыл карарга, аларны дөрес кулланырга: рәсем ясап бетергәч урыннарына куярга, аңа кадәр пумаланы яхшылап юарга өйрәтү.

Карандаш һәм пумаланы җайлы итеп: өч бармак белән, карандашны очланган башыннан өстәрәк, пумаланы тимер очлыгыннан чак кына өстәрәк тотарга; пумаланың кылын манып буяу алырга, банка авызы кырыена кагылып артык буяудан арынырга өйрәтү.

**Әвәләп ясау.** Балаларда әвәләп ясауга карата кызыксыну тудыру. Пластик материаллар: балчык, пластилин, пластик масса белән таныштыру (балчыкка өстенлек биреп). Материаллар белән пөхтә эш итәргә өйрәтү.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны балчыктан кечкенә кисәкләр сындырып алырга; туры хәрәкәтләр ясап, балчык кисәген учлар арасында әвәләп таякчыклар әвәләргә; таякчыкның очларын тоташтырырга (балдак, клиндер, тәгәрмәч һ.б.) өйрәтү.

Түгәрәк формалы предметлар (шар, алма, җиләк һ.б.) ясау өчен балчык кисәген әйләнүле хәрәкәт белән әвәләргә, учлар арасында кысып янчергә (көлчәләр, печенье, прәннекләр); бармаклар белән янчелгән балчык кисәге уртасында чокыр ясарга (миски, тәлинкә) өйрәтү. Әвәләп ясалган ике предметны — таякчыкны һәм шарны (шалтыравык яки гөмбә), ике шарны (аумас курчак) һ.б. ны бер предметка берләштерергә өйрәтү.

Балаларны балчыкны һәм әвәләп ясалган предметларны такта кисәгенә яки алдан әзерләп җәелгән клеенкага куярга өйрәтү.

## Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

Эстетик кабул итүне үстерү; балаларның игътибарын тирәлектәге предметлар (уенчыклар), табигать объектлары (үсемлекләр, хайваннар) матурлыгына юнәлтү, шатлык хисе уяту.

Сурәтләү эшчәнлеге дәресләренә карата кызыксыну формалаштыру. Рәсем ясауда, әвәләп ясауда, аппликациядә, образ тәэсирлелеген чагылдырып, гади предметларны һәм күренешләрне сурәтләргә өйрәтү.

Предметны тикшерү процессына ике кулның да предмет өслегендәге хәрәкәтләрен кушу, предметны куллар белән тотуны кертү.

Табигать матурлыгын, сәнгать әсәрләрен (китап иллюстрацияләре, халык кәсепчелеге эшләнмәләре, көнкүреш предметлары, өс киеме) күзәтүдән уңай хисләр алырга өйрәтү.

Рәсемнәрдә, әвәләп ясауда аппликациядә индивидуаль һәм коллектив композицияләр тудырырга өйрәтү.

**Рәсем ясау.** Балаларга рәсемнәрендә әйләнә-тирәдәге предметларның һәм табигатьнең матурлыгын чагылдырырга тәкъдим итү (ак болытлар йөзгән зәңгәр күк йөзе, җилдә бөтерелеп җиргә коелучы төрле төстәге яфраклар; кар бөртекләре һ.б.).

Карандашны, пумаланы мускулларны киермичә һәм бармакларны ныгытып кысмыйча, дөрес тотарга өйрәтүне дәвам итү; кулның карандаш һәм пумала тотып иркен хәрәкәтләнүенә ирешү. Пумалага буяу алырга өйрәтү: аны пөхтә генә итеп кылы белән банкадагы буяуга тутырып ману, банка авызына җиңелчә генә кагылып, артык буяудан арыну, башка төстәге буяуга манганчы пумаланы яхшылап юу. Юылган пумаланы йомшак чүпрәк яки кәгазь салфетка белән корытырга өйрәтү.

Төсләрнең аталышын (кызыл, зәңгәр, яшел, сары, ак, кара) белүне ныгыту, төсмерләр (алсу, күксел, соры) белән таныштыру. Балаларның игътибарын сурәтләнүче предметка туры килгән төсне сайлауга юнәлтү.

Балаларны декоратив эшчәнлеккә тарту: тәрбияче кисеп биргән уенчыкларның (кошчык, кәҗә бәтие, ат һ.б.), һәм предметларның (тәлинкә, бияләйләр) силуэтларын Дымково бизәкләре белән бизәргә өйрәтү.

Сызыкларны, штрихларны, тапларны, буяуны ритмик рәвештә төшерергә өйрәтү (агачлардан яфраклар коела, яңгыр ява, «кар бөтерелә, бөтен урам ап-ак», «яңгыр, яңгыр, там, там, там...»).

Гади предметларны, туры сызыкларны (озын, кыска) төрле юнәлешләрдә сурәтләргә, аларны буярга (буйлар, тасмалар, юллар, койма, шакмаклы яулык һ.б.) өйрәтү. Балаларны төрле формадагы (түгәрәк, турыпочмаклык рәвешендәге) предметларны һәм төрле формалар һәм сызыклар катнашыннан торган предметларны (аумас курчак, кар бабай, чеби, арба, вагон һ.б.) сурәтләүгә җәлеп итү.

Бер предмет сурәтен кабатлап (безнең участоктагы чыршылар, аумас курчаклар саф һавада йөриләр) яки төрле предметларны, бөҗәкләрне һ.б. ны сурәтләп (үләндә коңгызлар һәм суалчаннар шуыша; колобок юлдан тәгәрәп бара һ.б.), катлаулы булмаган сюжетлы композицияләр төзи белү сәләте формалаштыру. Сурәтләрне битне тутырып урнаштырырга өйрәтү.

**Әвәләп ясау.** Әвәләп ясауга карата кызыксыну формалаштыру. Балаларның балчык, пластилин, пластик масса һәм әвәләп ясау ысуллары турындагы күзаллауларын ныгыту. Балчык кисәкләрен туры һәм әйләнүле хәрәкәт белән әвәләргә, әвәләүдән барлыкка килгән таякчык очларын тоташтырырга, шарны учлар белән янчергә өйрәтү. Балаларда очланган башлы таяк кулланып әвәләп ясалган предметларны бизәү теләге тудыру; бер-берсенә кысып беркетеп, 2–3 өлештән торган предметлар ясарга өйрәтү.

Балчыкны пөхтә куллану, балчык кисәкләрен һәм әвәләп ясалган предметларны такта кисәгенә кую тәртибен ныгыту.

Балаларны берничә өлештән торган предметларны (аумас курчак, чеби, пирамида һ.б.) әвәләп ясарга өйрәтү. Әвәләп ясалган фигураларны коллектив композициягә берләштерергә тәкъдим итү (аумас курчаклар әйлән-бәйлән әйләнәләр, алмалар тәлинкәдә ята һ.б.).

**Аппликация.** Балаларны аппликация сәнгатенә тарту, эшчәнлекнең бу төренә карата кызыксыну формалаштыру. Башта, сурәт (бала тарафыннан уйланыла яки тәрбияче тарафыннан тәкъдим ителә) хасил итеп, кәгазь битенә (билгеле бер тәртиптә) төрле формадагы, зурлыктагы, төстәге әзер детальләрне куеп чыгарга, аннары аларны ябыштырырга өйрәтү.

Җилемне пөхтә кулланырга өйрәтү, аны кечкенә пумала белән юка гына итеп ябыштырылачак фигураның арткы ягына сылау (махсус әзерләнгән клеенка өстендә); җилем сыланган ягы белән кәгазь битенә кую һәм ныгытып салфетка белән кысып тору.

Пөхтә эшләү күнекмәләре формалаштыру. Балаларның ясалган сурәткә карап шатлануына ирешү.

Төрле формадагы (квадрат, розетка һ.б.) кәгазь аппликациядә, геометрик формаларны һәм табигый материалларны формалары һәм төсләре буенча кабатлап һәм чиратлаштырып, предметлы һәм декоратив композицияләр төзергә өйрәтү. Предметларның формаларын һәм төсләрен белүне ныгыту. Ритм хисе үстерү.

## Уртанчылар төркеме
## (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

Балаларның сынлы сәнгатькә карата кызыксынуын үстерүне дәвам итү. Рәсем ясау, әвәләп ясау, кисеп алу һәм ябыштыру тәкъдимнәрен эмоциональ яктан уңай кабул итү булдыру.

Эстетик кабул итү, образлы күзаллаулар, хыял, эстетик хисләр, сәнгати иҗат сәләтләре үстерүне дәвам итү.

Предметларны җентекләп карый һәм өйрәнү (шул исәптән куллар ярдәмендә дә) күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү.

Иҗади үсеш нигезе буларак, балаларның сынлы сәнгать турындагы күзаллауларын баету (балалар әдәбияты әсәрләренә иллюстрацияләр, нәкыш сәнгате әсәрләре репродукцияләре, халык бизәлеш сәнгате, кече формалы скульптура һ.б.). Рәсем ясау, әвәләп ясау, аппликациягә хас тәэсир итү чараларын аерырга һәм кулланырга өйрәтү.

Рәсем ясауда, әвәләп ясауда, аппликациядә коллектив әсәрләр иҗат итү күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү.

Рәсем ясаганда дөрес утыру: бөкрәймәү, өстәл өстенә, мольбертка таба бик түбән иелмәү; үзеңне киеренке тотмыйча, иркен утыру күнекмәләрен ныгыту. Балаларны пөхтәлеккә: үз эш урынын тәртиптә тотуга, эш беткәч барысын да өстәлдән җыеп алуга өйрәтү.

Башка балаларның эшләрен бәяләгәндә дусларча киң күңеллелек күрсәтергә өйрәтү.

**Рәсем ясау.** Балаларда аерым предметларны ясау, бер үк предметларны кабатлап (аумас курчаклар саф һавада йөриләр, кышын безнең участоктагы агачлар, чебиләр үләндә йөриләр) һәм алар янына башкаларын өстәп (кояш, кар ява һ.б.) сюжетлы композицияләр төзи белү сәләте формалаштыруны дәвам итү.

Предметларның формасы (түгәрәк, овал, квадрат, турыпочмаклык рәвешендә, өч почмаклы), өлешләрнең зурлыгы, урыны турында күзаллаулар формалаштыру һәм ныгыту.

Сюжетны чагылдырганда, балаларга сурәтләрне кәгазь битенә вакыйга эчтәлегенә һәм вакыйгага кертелгән объектларга туры китереп урнаштырырга ярдәм итү. Балаларның игътибарын предметларның зурлык буенча чагыштырмаларына юнәлтү: агач биек, куак агачтан тәбәнәгрәк, чәчәкләр куактан тәбәнәгрәк.

Балаларның тирәлектәге предметларның һәм табигать объектларының төсләре һәм төсмерләре турындагы күзаллауларын ныгытуны һәм баетуны дәвам итү. Инде билгеле төсләргә һәм төсмерләргә яңаларын өстәү (коңгырт, кызгылт-сары, сыек яшел); бу төсләрне ничек табу мөмкинлеге турында күзаллау формалаштыру.

Тиешле төсләрне һәм төсмерләрне табу өчен буяуларны кушарга өйрәтү.

Рәсем ясауда, аппликациядә төрле төсләр куллану теләген үстерү, игътибарны әйләнә-тирә дөньяның күптөрле булуына юнәлтү.

Карандаш, пумала, фломастер, төсле акбурны дөрес тоту; сурәтләр ясаганда аларны куллана белү күнекмәләрен ныгыту.

Балаларны рәсемнәрне — пумала, карандаш белән, сызыкларны һәм штрихларны бер генә юнәлештә (өстән аска яки сулдан уңга таба) сызып буярга өйрәтү; буяуны, штрихларны ритмлы хәрәкәтләр белән бөтен форма буенча, контур чикләреннән чыкмыйча төшерү; калын сызыкларны пумаланың бар киңлеге белән, нәзек сызыкларны һәм нокталарны кыл очы белән генә төшерү. Башка төстәге буяу куллану алдыннан пумаланы чиста итеп юу тәртибен ныгыту. Ел ахырына балаларда, карандашка басымны үзгәртеп, төснең сыек һәм куе төсмерләрен таба белүне формалаштыру.

Катлаулы предметлар (курчак, куян һ.б.) рәсемнәрен ясаганда, аларның өлешләрен дөрес урнаштыра һәм бу өлешләрне үлчәм буенча ярраштыра белүне формалаштыру.

**Декоратив рәсем ясау.** Дымково, Филимоново бизәкләре мотивлары буенча декоратив композицияләр ясарга өйрәтүне формалаштыруны дәвам итү. Матурлыкны эстетик кабул итүне үстерү һәм Дымково, Филимоново бизәлешләре стилендәге бизәкләр иҗат итү өчен үрнәк сыйфатында шул бизәлешләрдәге эшләнмәләрне файдалану (бизәкләү өчен балалар әвәләп ясаган уенчыклар һәм кәгазьдән кисеп алынган уенчык силуэтлары кулланылырга мөмкин).

Балаларны Городец эшләнмәләре белән таныштыру. Городец бизәлеше элементларын (чәчәк бөреләре, роза чәчәкләре, яфраклар) аерырга өйрәтү; бизәлештә кулланылган төсләрне аерып ала һәм атап әйтә белергә өйрәтү.

**Әвәләп ясау.** Балаларның әвәләп ясауга карата кызыксынуын үстерүне дәвам итү; балчыктан (пластилиннан, пластик массадан) әвәләп ясау күнекмәләрен камилләштерү. Моннан алдагы төркемнәрдә үзләштерелгән әвәләп ясау алымнарын ныгыту; яньчелгән шарның барлык кырыйларын чеметкәләп, аз гына тышка сузып чыгарырга, балчык кисәгенең аерым өлешләрен сузып озынайтырга, вак детальләрне (мәче баласының колакларын, кошчыкның томшыгын) чеметкәләп ясарга өйрәтү. Әвәләп ясалган предметның, фигураның өслеген бармаклар белән шомартырга өйрәтү.

Куыш эчле форма булдыру өчен шарның, цилиндрның үзәген батырып эчкә кертү алымнарына өйрәтү. Стека (махсус таякчык) куллану алымнары белән таныштыру. Әвәләп ясалган эшләнмәләрне стека ярдәмендә бизәкләү омтылышын хуплау.

Пөхтә әвәләү алымнарын ныгыту.

**Аппликация.** Аппликациянең эчтәлеген катлауландырып һәм төрле сурәтләр иҗат итү мөмкинлекләрен киңәйтеп, аппликациягә карата кызыксыну тәрбияләү.

Балаларда кайчыны дөрес тоту һәм аны файдалана белү күнекмәләре формалаштыру. Туры сызык буенча иң элек кыска, аннары озын буйлар кисү күнекмәсен формалаштырудан башлап, фигуралар кисеп алырга өйрәтү. Буйлардан төрле предметлар (койма, эскәмия, баскыч, агач, куак һ.б.) сурәтләрен төзергә өйрәтү. Почмакларны түгәрәкләү юлы белән квадраттан түгәрәк формалар һәм турыпочмаклыктан овал формалар кисеп алырга өйрәтү; бу алымны аппликациядә яшелчәләр, җимешләр, җиләкләр, чәчәкләр һ.б. сурәтләрен ясау өчен куллану.

Аппликациядә әзер формалардан җыелучы предметларның (чын һәм хыялдагы кошлар, хайваннар, чәчәкләр, бөҗәкләр, йортлар) санын арттыра бару. Балаларны әлеге формаларны ике яки дүрт өлешкә (түгәрәкне — ярымтүгәрәкләргә, чирекләргә; квадратны өчпочмакларга һ.б.) кисеп, үзгәртергә өйрәтү.

Пөхтә итеп кисү һәм ябыштыру күнекмәләрен ныгыту.

Активлык һәм иҗадилык чагылышын хуплау.

### Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Балаларның сурәтләү эшчәнлегенә карата кызыксынуын үстерүне дәвам итү. Сизү органнарын — күрү, ишетү, ис сизү, тоемлау, тәм тоюны үстереп, сиземләү тәҗрибәсен баету; предметларның һәм табигать объектларының төп формалары турындагы белемнәрне ныгыту.

Эстетик кабул итүне үстерү, әйләнә-тирә дөньяның матурлыгын күзәтергә өйрәтү. Предметларны һәм күренешләрне аңга кабул итү процессында фикерләү операцияләрен — анализлауны, чагыштыра һәм охшата белүне (нәрсәгә охшаган) үстерү, предметларның һәм аларның өлешләренең охшашлыгын, аерымлыкларын ачыклау, гомуми һәм үзенчәлекле билгеләрне аеру, гомумиләштерү. Сурәттә предметларның төп үзлекләрен (форма, зурлык, төс) генә түгел, үзенчәлекле детальләрен, предметларның һәм аларның өлешләренең зурлык, биеклек, бер-берсенә карата урнашулары буенча чагыштырмаларын күрсәтергә өйрәтү.

Табигать күренешләрен һәм объектларын күзәтү, аларны җентекләп карау (бирелеп тыңлау), алардагы үзгәрешләрне (мәсәлән, акрын гына йөзүче болытларның формасы һәм төсе ничек үзгәрүен, чәчәкнең таҗының ничек итеп иртән ачылуын һәм кичен ябылуын, кояш астында һәм күләгәдә предметлар яктыртылышының ничек үзгәрүен) күрә белүне үстерү.

Сурәттә предметларның төп үзлекләрен (форма, зурлык, төс), үзенчәлекле детальләрен, предметларның һәм аларның өлешләренең зурлык, биеклек, бер-берсенә карата урнашулары буенча чагыштырмаларын чагылдырырга өйрәтү.

Табигать күренешләрен күзәтү, аларның динамикасын, акрын гына йөзүче болытларның формасын һәм төсен күзәтә белүне үстерү.

Сурәтләү күнекмәләрен һәм осталыгын камилләштерү, сәнгати иҗат сәләтләрен формалаштыру.

Форманы, төсне, пропорцияләрне тоюны үстерү.

Халык гамәли бизәлеш сәнгате (Городец, Полхов-Майдан, Гжель) белән таныштыруны дәвам итү, халык уенчыклары (Городец, Богородское матрешкалары) турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Балаларны милли гамәли бизәлеш сәнгате (төбәк үзенчәлекләре нигезендә); гамәли бизәлеш сәнгатенең башка төрләре (фарфор һәм керамик эшләнмәләр, кече формалы скульптура) белән таныштыру. Балаларның бизәү иҗатын (шул исәптән коллектив иҗатны) үстерү.

Үз эш урыныңны оештыру, дәресләр өчен кирәкле әйберләрне әзерли белү; пөхтә эшләү, материалларны бәрәкәтле куллану, эш урынын чисталыкта тоту, эш беткәч аны тәртипкә китерү күнекмәләре формалаштыру.

Балаларның эшләрне (рәсемнәр, әвәләп ясалган әйберләр, аппликацияләрне) карау, ирешелгән нәтиҗәгә шатлану, сурәтләрнең тәэсирле чагылышларын аерып күрсәтә белү сәләтен камилләштерү.

**Предметлы рәсем ясау.** Рәсемдә предметлар, объектлар, әкият һәм әдәби әсәр персонажлары образларын чагылдыру күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү. Балаларның игътибарын предметларның форма, зурлык, өлешләрнең пропорцияләре буенча аерымлыкларына юнәлтү; аларда бу аерымлыкларны рәсемнәрдә чагылдыру теләге тудыру.

Кәгазь битендә предметларның тирәлектә урнашуын чагылдырырга өйрәтү, балаларның игътибарын предметларның яссылыкта төрлечә урнаша алуларына (басып тору, яту, торышны үзгәртү: тере затлар хәрәкәтләнергә, позаларын үзгәртергә, агач җилле көндә бөгелергә мөмкин һ.б.) юнәлтү.

Композиция корырга булышлык итү: предметны кәгазь битендә аның пропорцияләрен исәпкә алып урнаштыру (әгәр предмет биеклеккә таба сузынкы булса, аны кәгазь битендә вертикаль хәлдә урнаштыру; әгәр ул киңлеккә сузылса, мәсәлән, бик үк биек булмаган, әмма озын йорт, горизонталь хәлдә урнаштыру). Төрле сурәтләү материаллары (төсле карандашлар, гуашь, акварель, төсле акбурлар, пастель, сангина, күмерле карандаш, фломастерлар, төрле пумалалар һ.б.) белән рәсем ясау ысулларын һәм алымнарын ныгыту.

Рәсемне буяганда аны пычратучы тупас сызыклар калмасын өчен, предмет контурларын гади карандаш белән, аңа җиңелчә генә басым биреп ясау күнекмәләрен булдыру.

Акварель белән аның үзенчәлекләренә (төснең үтә күренмәлеге һәм җиңеллеге, бер төстән икенчесенә салмак күчеш) туры китереп эш итәргә өйрәтү.

Пумала белән төрле ысуллар кулланып эш итәргә: калын сызыкларны пумаланың бар киңлеге белән, нәзек сызыкларны очы белән генә; төс салганда пумаланы кәгазьгә тулысынча орындырып, вак тапларны пумала очы белән ясарга өйрәтү.

Билгеле булган төсләр турындагы белемнәрне ныгыту, яңа төсләр (шәмәхә) һәм төсмерләр (күк, алсу, куе яшел, сирень төсе) белән таныштыру, төсне тоемлау сәләтен үстерү. Яңа төсләр һәм төсмерләр булдыру өчен буяуларны кушарга (гуашь кулланганда) һәм, буяуга су өстәп, төсне сыекландырырга (акварель кулланганда) өйрәтү. Карандаш белән рәсем ясаганда, карандашка басымны үзгәртеп, төснең төсмерләрен бирергә өйрәтү. Карандаш белән эш иткәндә, карандашка басымны төрлечә үзгәртеп, балалар төснең өч төсмерен бирә алалар.

**Сюжетлы рәсем ясау.** Балаларны әйләнә-тирә дөнья һәм әдәби әсәрләр темаларына («Колобок кемне очраткан?», «Ике саран аю баласы», «Чыпчык төшке ашны кайда ашаган?» һ.б.) сюжетлы композицияләр иҗат итәргә өйрәтү.

Композиция төзү күнекмәләрен үстерү, рәсемнәрне кәгазь битенең аскы өлеше буйлап, бөтен битне тутырып урнаштырырга өйрәтү.

Балаларның игътибарын сюжеттагы барлык предметларның зурлык чагыштырмасына юнәлтү (йортлар зур, агачлар биек һәм тәбәнәк; кешеләр йортлардан кечерәк, әмма болында үсүче чәчәкләрдән зуррак). Рәсемдә предметларны бер-берсен каплап тормаслык итеп урнаштырырга өйрәтү (йорт каршында үсүче һәм өлешчә аны каплап торучы агачлар һ.б.)

**Декоратив рәсем ясау.** Балаларны халык кәсепчелеге эшләнмәләре белән таныштыруны дәвам итү, Дымково һәм Филимоново уенчыклары һәм аларның бизәлешләре турындагы белемнәрне тирәнәйтү; халык декоратив бизәлеше мотивлары буенча сурәтләр ясарга тәкъдим итү, шул бизәлешнең төсләр җыелмасы һәм композиция элементлары белән таныштыру, кулланылучы элементларның тагын да күптөрлерәк булуына ирешү. Городец бизәлеше, аның төсләр бирелеше, декоратив төсләр (кагыйдә буларак, чиста тоннар түгел, бәлки төсмерләр) табу үзенчәлеге белән таныштыруны дәвам итү, бизәү өчен зиякләр (оживки) кулланырга өйрәтү.

Полхов-Майдан бизәлеше белән таныштыру. Городец һәм Полхов-Майдан бизәлешләрен балаларның иҗади эшенә кертү, бизәлешнең әлеге төрләре үзенчәлекләрен үзләштерергә ярдәм итү. Җирле бизәлеш сәнгате белән таныштыру. Гжель, Городец, Полхов-Майдан бизәлешләре мотивлары буенча бизәкләр төзергә өйрәтү: үзенчәлекле элементлар (чәчәк бөреләре, чәчәкләр, яфраклар, үләннәр, мыекчалар, бөтеркәләр, зиякләр) белән таныштыру.

Кәгазь битләрендә халык эшләнмәләре (поднос, тоз савыты, чынаяк, розетка һ.б.) рәвешендәге бизәкләр ясарга өйрәтү.

Бизәк төшерү эшчәнлегендә иҗатны үстерү өчен декоратив тукымалар куллану. Балаларга өс һәм баш киемнәре (калфак, яулык, свитер һ.б.), көнкүреш предметлары (тастымал, сөлге) рәвешендәге кәгазьләр бирү.

Бизәкләрне ритм белән урнаштырырга өйрәтү. Кәгазь силуэтларга һәм күләмле фигураларга бизәк төшерергә тәкъдим итү.

**Әвәләп ясау.** Балаларны балчыктан, пластилиннан һәм пластик массадан әвәләп ясау үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү.

Таныш предметларны (яшелчәләр, җимешләр, гөмбәләр, савыт-саба, уенчыклар) натурадан карап һәм күзаллау буенча әвәләп, аларга хас үзенчәлекләрне чагылдыра белүне үстерү. Балчык кисәгеннән һәм пластилиннан тасма ысулы белән савыт-саба әвәләп ясарга өйрәтүне дәвам итү.

Предметларны пластик, конструкцияләү һәм катнаш ысуллар белән әвәләп ясау күнекмәләрен ныгыту. Форма өслеген шомартырга, предметларны тотрыклы итәргә өйрәтү.

Әвәләп ясаган сында образ үзенчәлеген чагылдырырга, кеше һәм хайваннар сыннарын хәрәкәттә ясарга, предметларның кечерәк төркемнәрен катлаулы булмаган сюжетларга (коллектив композицияләрдә) берләштерергә өйрәтү: «Тавык һәм чебиләр», «Ике саран аю баласы сыр таптылар», «Балалар һавада йөриләр» һ.б.

Балаларда әдәби әсәр геройларын күзаллау буенча әвәләп ясый белү сәләте формалаштыру (Аю һәм Колобок, Төлке һәм Куян баласы, Машенька һәм Аю һ.б.). Иҗатны, инициативаны үстерү.

Вак детальләрне әвәләп ясау: стека кулланып, балыкка тәңкәләр төшерү, хайванның күзләрен, йонын, кошның каурыйларын, кешеләрнең киемнәрендәге бизәкне, җыерчыкларны һ.б. ны күрсәтү күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү.

Әвәләп ясау өчен төрле материаллар белән эшләүдә техник күнекмәләр формалаштыруны дәвам итү; өстәмә материаллар (җимеш төшләре, бөртекләр, сәйлән бөртекләре һ.б.) куллану теләге уяту.

Пөхтә әвәләү күнекмәләрен ныгыту.

Әвәләп ясау төгәлләнгәннән соң кулларны яхшылап юу күнекмәләрен ныгыту.

**Декоратив әвәләп ясау.** Балаларны декоратив әвәләп ясау үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Халык гамәли бизәлеш сәнгате предметларына карата кызыксыну һәм эстетик мөнәсәбәт формалаштыру.

Халык уенчыклары типлары (Дымково, Филимоново, Каргополь эшләнмәләре һ.б.) буенча кошларны, хайваннарны, кешеләрне әвәләп ясарга өйрәтү.

Бизәлеш сәнгате предметларын бизәкләр белән матурлау сәләте формалаштыру. Эшләнмәләргә гуашь кулланып бизәк төшерергә, аларны әвәләп ясалган детальләр һәм чокырайтылган рельеф белән бизәргә, стека кулланырга өйрәтү.

Образ тудыру өчен кирәк булганда, әвәләп ясалган сурәттәге тигез булмаган урыннарны шомарту өчен, бармакларны суга манып алырга өйрәтү.

**Аппликация.** Балаларның сурәтләр иҗат итә белүен ныгыту (кәгазьне кыска һәм озын буйларга бүлеп кисү; квадратлардан — түгәрәкләр, турыпочмаклыклардан оваллар кисеп алу, бертөрле геометрик фигураларны икенчеләренә үзгәртү: квадратны — ике-дүрт өчпочмакка, турыпочмаклыкны буйларга, квадратларга яки кечкенә турыпочмаклыкларга әверелдерү), шул фигуралардан төрле предметларның сурәтләрен яки декоратив композицияләр төзү.

Гармун рәвешендә бөкләнгән кәгазьдән — бертөрле фигуралар яки аларның детальләрен, урталай бөкләнгән кәгазьдән симметрияле сурәтләр (стакан, ваза, чәчәк һ.б.) кисеп алу. Тәэсирле образ тудыру максатында өзеп (ертып) алу алымына өйрәтү.

Предметлы һәм сюжетлы композицияләр иҗат итү, аларны сурәтләрне баетучы детальләр белән тулыландыру теләге тудыру.

Материалларга карата пөхтәлек һәм сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру.

**Гамәли иҗат.** Кәгазь белән эшли белүне камилләштерү: битне төрле юнәлештә дүрт өлешкә бүлү; әзер өлге буенча эшләү (башлык, кечкенә көймә, кечкенә өй, кесә).

Кәгазьдән күләмле фигуралар ясау күнекмәләрен ныгыту: квадрат рәвешендәге битне берничә тигез өлешкә бүлү, бөгелгән сызык урыннарны тигезләү, шул сызыклар буенча кисемнәр ясау (йорт, кәрзин, шакмак).

Балаларның табигый материаллардан (күркәләр, ботаклар, җиләкләр) һәм башка материалдан (кәтүкләр, тышы төсле тимерчыбык, буш тартмалар һ.б.) уенчыклар, сувенирлар ясау күнекмәләрен ныгыту.

Мөстәкыйль рәвештә сюжетлы-рольле уеннар өчен уенчыклар (кечкенә флаглар, сумкалар, башлыклар, салфеткалар һ.б.); әти-әниләр, балалар бакчасы хезмәткәрләре өчен сувенирлар, чыршы уенчыклары ясау күнекмәләре формалаштыру.

Балаларны дәресләр һәм мөстәкыйль эшчәнлек өчен әсбаплар (тартмалар, санау материалы) эшләүгә, китапларны, өстәл уеннарын ремонтлауга җәлеп итү.

Балаларның материалларны сакчыл һәм рациональ файдалана белүен ныгыту.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Балаларда сурәтләү эшчәнлегенә карата тотрыклы кызыксыну формалаштыру. Сиземләү тәҗрибәсен баету, предметлар белән танышу процессына кулларның предмет буйлап хәрәкәтен кертү.

Образлы эстетик кабул итүне, образлы күзаллауны үстерүне, эстетик фикерләү формалаштыруны дәвам итү; иптәшләрнең эшләренә карата дусларча һәм ихтирамлы мөнәсәбәтнең мәҗбүрилегенә игътибар юнәлтеп, бала үзе һәм аның яшьтәшләре тарафыннан иҗат ителгән сурәтләрне нигезле һәм тәфсилле бәяләргә өйрәтү.

Әйләнә-тирә предметларына һәм күренешләренә, сәнгать әсәрләренә, сәнгати иҗат эшчәнлегенә карата эстетик мөнәсәбәт формалаштыру.

Мөстәкыйльлек тәрбияләү; тәэсир итү чараларын кулланып, элегрәк рәсем ясауда, әвәләп ясауда, аппликациядә үзләштерелгән ысулларны актив һәм иҗади кулланырга өйрәтү.

Балаларны натурадан карап рәсем ясарга өйрәтүне дәвам итү; анализлау сәләтен, предметларны чагыштыра белүне, һәр предметның үзенчәлекләрен аера белүне үстерү; предметларны аларның формасын, зурлыгын, төзелешен, пропорцияләрен, төсен, композициясен чагылдырып сурәтләү күнекмәләрен камилләштерү.

Коллектив иҗатны үстерүне дәвам итү. Килешеп эш итү, эшнең кайсы өлешен кем башкарачагы, аерым сурәтләрнең ничек итеп гомуми картинага берләшәчәге турында сүз куешу омтылышы тәрбияләү.

Үз эшләреңнең кимчелекләрен күрә һәм аларны төзәтә белүне формалаштыру; иҗат ителә торган образның тагын да тәэсирлерәк булуына ирешү өчен өстәмәләр кертү.

**Предметлы рәсем ясау.** Предметларны хәтер буенча һәм натурадан карап сурәтләү күнекмәләрен камилләштерү; күзәтүчәнлек, предметларның характерлы үзенчәлекләрен күрү һәм аларны рәсем чаралары (форма, пропорцияләр, кәгазь битендә урнаштыру) белән чагылдыра белүне үстерү.

Сурәтләү техникасын камилләштерү. Күзәтү астында кулның ирекле, бер үк вакытта төгәл, салмак һәм ритмлы хәрәкәтләрен үстерү. Балалар рәсем ясаганда кулланырга мөмкин булган материаллар җыелмасын киңәйтү (гуашь, акварель, коры һәм майлы пастель, сангина, күмерле карандаш, гельле ручка һ.б.). Тәэсирле образ тудыру өчен бер үк рәсемдә төрле материалларны берләштерергә тәкъдим итү. Таныш материаллар белән эшләүнең яңа ысулларына (мәсәлән, юеш катлам өстендә акварель белән рәсем ясау); сурәтләнәчәк картина өчен фон әзерләүнең төрле ысулларына (акварель һәм гуашь белән рәсем ясаганда фон төп сурәт иҗат ителгәнче әзерләнә; пастель һәм төсле карандашлар белән рәсем ясаганда фон башта ук яки төп сурәт иҗат ителгәч булдырыла) өйрәтү.

Сызыклы рәсем ясаганда карандаш белән иркен эш итү күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү, түгәрәк сызыклар, бөтеркәләр ясаганда төрле юнәлешләрдә (ботактан һәм бөтеркәнең өчыннан ботакка таба, вертикаль һәм горизонталь рәвештә) кулның салмак борылышларын башкарырга өйрәтү, озын сызыкларны, зур формаларны ясаганда — бөтен кул белән, кечкенә формаларны һәм вак детальләрне, кыска сызыклар, штрихлар, үлән (Хохлома), зияк (Городец) һ.б. ясаганда, бармаклар белән генә эш итәргә өйрәтү.

Иҗат ителгән сурәтнең һәм форманы чагылдыруның, сызыкларның салмаклыгы һәм кушылуы яки аларның нечкәлеге, сызыклар һәм таплар урнашуының нәфислеге, ритмлылыгы, рәсемнең тигез буялышы матурлыгын күрергә; төснең тигез буяу һәм карандашка басымны көйләү нәтиҗәсендә барлыкка килгән салмак төсмерләр күчешләрен тоемларга өйрәтү.

Предметларның чынбарлыктагы төсләренә, декоратив бизәкләргә, әкият сюжетларына таянып, төсләрнең һәм төсмерләрнең төрлелеге турындагы күзаллауны үстерү; төсләр һәм төсмерләр табарга өйрәтү.

Балаларны эзлекле рәвештә ике төсмерне үз эченә алган (яшькелт-сары, зәңгәрсу-күк) яки табигый төсләргә тәңгәл (кура җиләге төсе, персик төсе һ.б.) төсләрне күрсәтә белүгә китерү. Аларның игътибарын предметларның төсе үзгәрүчәнлеккә (мәсәлән, үсү процессында помидорлар яшел булалар, өлгергәч кызаралар) юнәлтү. Һава торышы үзгәргәндә табигатьтә төс үзгәрүен күрергә өйрәтү (кояшлы көндә күк йөзе зәңгәр, болытлы көндә соры төстә). Рәсемнең төсләр җыелмасын баету максатында төсләр аша кабул итү сәләтен үстерү.

Балаларны төсләрнең төсмерләрен аерырга һәм аларны рәсемдә чагылдырырга өйрәтү, тирә-юньдәге предметларны һәм күренешләрне төс аша кабул итә, аларны күзәтә һәм чагылдыра белү сәләтен үстерү (яңа гына пәйда булган яфраклар сыек яшел төстә, тузганакларның сабаклары сыек яшел, яфраклары куе яшел һ.б.).

**Сюжетлы рәсем ясау.** Балаларны кәгазь битендә сурәтләрне аларның реаль урынына карап (рәсем ясаучыга якынрак яки аңардан ераграк; битнең астагы читенә якынрак — алгы план, аннан ераграк — арткы план) урнаштырырга; сурәтләнүче предметларның зурлыклары арасындагы аерымлыклар-

ны (агач биек, чәчәк агачтан тәбәнәгрәк; чыпчык баласы кечкенә, ала карга зур һ.б.) чагылдырырга өйрәтү. Рәсем композициясен төзү; кешеләрнең һәм хайваннарның хәрәкәт итүен, җилдән бөгелгән үсемлекләрнең торышын чагылдыра белү күнекмәләре формалаштыру. Рәсемнәрдә халык әкиятләренең, шулай ук автор әсәрләренең (шигырьләрнең, әкиятләрнең, хикәяләрнең) сюжетларын чагылдыра белү; тема, композиция һәм төсләр бирелешен сайлауда мөстәкыйльлек күрсәтү формалаштыруны дәвам итү.

**Декоратив рәсем ясау.** Балаларның декоратив иҗатын үстерүне; аларга инде таныш һәм әлегә яңалык булган халык бизәлеш сәнгате мотивлары буенча (Городец, Гжель, Хохлома, Жостово, Мезень) бизәкләр ясарга өйрәтүне дәвам итү. Балаларны билгеле бер халык бизәлеш сәнгате төренең төсләр җыелмасын аерырга һәм чагылдырырга өйрәтү. Төрле формадагы кәгазь битләрендә, предмет һәм уенчык силуэтларында композицияләр төзү күнекмәләрен ныгыту; балалар тарафыннан әвәләп ясалган уенчыкларга бизәк төшерү.

Халык сәнгатенең теге яки бу төре нигезендә декоратив композиция төзегәндә, шул төр өчен хас бизәк элементлары һәм төсләр җыелмасы куллану күнекмәләрен ныгыту.

**Әвәләп ясау.** Балалар иҗатын үстерү; предметлар, табигать объектлары, әкият персонажлары образларын иҗат итү өчен, элек үзләштерелгән төрле алымнарны иркен кулланырга өйрәтү; төп өлешнең һәм башка өлешләрнең формасын, шул өлешләрнең пропорцияләрен, сурәтләнүче объектларның позасын, аларга хас үзенчәлекләрне чагылдырырга өйрәтүне дәвам итү; форма өслеген бармаклар хәрәкәте һәм стека белән эшкәртү.

Кешегә һәм хайваннарга хас хәрәкәтләрне чагылдыру, тәэсирле образлар иҗат итү (кошчык канатларын күтәрде, очарга әзерләнде; кәҗә бәтие сикерә-сикерә бара, кыз бии; балалар гимнастика ясыйлар — коллектив композиция) күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү.

Балаларны ике-өч фигурадан скульптур төркемнәр төзергә өйрәтү, композицияне тоемлау, предметларның пропорцияләрен, аларның зурлыклары чагыштырмасын, позалар, хәрәкәтләр, детальләр төгәллеген күрсәтә белү осталыгын үстерү.

**Декоратив әвәләп ясау.** Декоратив әвәләп ясау күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү; әвәләп ясауның төрле ысулларын (өстәп әвәләү, чокырайтылган рельеф) файдаланырга, стека кулланырга өйрәтү. Балчыктан әвәләп ясаганда пластинага бизәк төшерергә, стека белән бизәк ясарга; балчыктан, төрле төстәге пластилиннан предметлы һәм сюжетлы, индивидуаль һәм коллектив композицияләр иҗат итәргә өйрәтү.

**Аппликация.** Натурадан карап һәм күзаллау буенча предметлы һәм сюжетлы сурәтләр ясарга өйрәтүне дәвам итү: композиция хисен үстерү (сурәтләнүче предметларның пропорцияләренә туры килгән форматтагы кәгазь битендә фигураларны матур итеп урнаштырырга өйрәтү).

Төрле формадагы кәгазь битләрендә геометрик һәм үсемлек элементларыннан бизәкләр һәм декоратив композицияләр төзү; балалар күзаллавын-

ча һәм халык сәнгате мотивлары буенча кошларны, хайваннарны сурәтләү күнекмәләрен үстерү.

Икегә бөкләнгән кәгазьдән симметрияле предметлар; гармун рәвешендә бөкләнгән кәгазьдән берничә предмет яки аларның өлешләрен кисеп алу алымнарын ныгыту.

Образлар иҗат иткәндә кәгазьдән кисеп алуның, өзеп (ертып) алуның, сурәтләрне ябыштыруның (тулысынча яки, күләм иллюзиясе тудырып, өлешчә җилем сылап) төрле алымнарын куллануны хуплау, башта рәсемнең өлешләре һәм детальләре формаларын карандаш белән җиңелчә билгеләп, сурәтләүнең мозаика ысулына өйрәтү. Төсне, колоритны, композицияне тоемлауны үстерүне дәвам итү. Иҗат чагылышларын хуплау.

**Гамәли иҗат: кәгазь һәм катыргы белән эшләү.** Турыпочмаклы, квадрат, түгәрәк формалы кәгазьне төрле юнәлешләрдә бөкли белү күнекмәсен ныгыту (пилотка); төрле фактуралы кәгазь куллану, өлге ярдәмендә билгеләп чыгу; кызыклы уенчыклар (физкультурачы аю баласы, чукучы әтәч һ.б.) ясау.

Төсле кәгазь буйларыннан предметлар (келәм, җәймә, китап тоткычы) ясый белүне; уенчыклар, сувенирлар, бәйрәмгә костюм детальләре һәм бизәмәләр эшләгәндә төсләрне һәм аларның төсмерләрен сайлый белүне формалаштыру. Үрнәктән файдалана белүне формалаштыру. Балаларның оригами техникасында күләмле уенчыклар иҗат итә белү күнекмәләрен формалаштыру.

**Гамәли иҗат: тукыма белән эшләү.** Энәгә җеп саплау, җепне төенли белүне; төймә, элгеч тегеп кую; энәне алга атлатып, иң гади әйберләрне (орлыклар өчен кечкенә капчык, курчаклар өчен алъяпкыч, энә мендәрчеге) тегә белүне формалаштыру. Төрле фактуралы тукыма кисәкләре (күбәләк өчен ефәк, куян өчен байка һ.б.) кулланып аппликация ясау, акбур белән контур сызу һәм уйланылган сюжет буенча кисеп алу күнекмәләрен ныгыту.

**Гамәли иҗат: табигый материал белән эшләү.** Имән чикләвекләреннән, күркәләрдән, җимеш төшләреннән, үләннән, ботаклардан, тамырлардан кеше, хайван, кош фигуралары иҗат итү; образның тәэсирлелеген чагылдыру, гомуми композицияләр төзү («Урман аланы», «Әкият геройлары») күнекмәләрен ныгыту. Фантазияне, хыялны үстерү.

Балаларның материаллардан пөхтә һәм сакчыл файдалана белү күнекмәләрен ныгыту.

## Конструкцияләү-модельләү эшчәнлеге

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Өстәл өстендә һәм идәндә төзелеш материалы белән уйнау процессында балаларны детальләр (шакмак, кечкенә кирпеч, өч кырлы призма, пластина,

призма), яссылыкта төзелеш формаларының урнашу вариантлары белән таныштыру.

Балаларны үрнәк буенча элементар корылмалар төзергә өйрәтүне дәвам итү, мөстәкыйль рәвештә нәрсәдер төзү теләген хуплау.

Тирәлек тирәнлеге чагыштырмаларын аңлауга булышлык итү.

Корылмаларның масштабларына туры килгән өстәмә сюжетлы уенчыкларны файдаланырга өйрәтү (кечкенә гаражлар өчен кечкенә машиналар һ.б.).

Уен төгәлләнгәннән соң барлык әйберләрне урыннарына алып куярга өйрәтү.

Балаларны иң гади пластмасса конструкторлар белән таныштыру.

Өлкәннәр белән бергә манаралар, йортлар, машиналар конструкцияләргә өйрәтү.

Балаларның мөстәкыйль рәвештә төзү теләген хуплау.

Җәйге чорда, табигый материаллар (ком, су, имән чикләвекләре, ташлар һ.б.) кулланып, төзелеш уеннары уйнауга булышлык итү.

## Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

Балаларны төзелгән корылмаларны иң гади анализлауга этәрү. Конструкцияләү күнекмәләрен камилләштерү, төп төзелеш детальләрен (шакмаклар, кечкенә кирпечләр, пластиналар, цилиндрлар, өч кырлы призмалар) аерырга, исемләп атарга һәм кулланырга, элегрәк белгәннәрне (өскә кую, янга бастырып кую, янга кую) файдаланып, яңа корылмалар төзергә, корылмаларда төрле төстәге детальләрне файдаланырга өйрәтү. Төзелеш нәтиҗәләренә карата шатлык хисе тудыру.

Кечкенә кирпечләрне, пластиналарны вертикаль хәлдә (рәткә тезеп, әйләнә буенча, дүртпочмаклык периметры буенча), бер-берсенә терәп, билгеле бер ара калдырып (койма, капка) куярга, урнаштырырга өйрәтү. Башка детальләр өстәп (капка баганалары өстенә — өч кырлы призмалар, баганалар янәшәсенә шакмаклар кую һ.б.), балаларда конструкция вариантларын иҗат итү теләге тудыру. Корылмаларны ике ысул — бертөрле детальләрне икенчеләре белән алыштыру яки аларны биеклеккә, озынлыкка өстәп төзү юлы белән үзгәртергә (тәбәнәк һәм биек манара, кыска һәм озын поезд) өйрәтү.

Баланың үзе уйлаганча корылмалар төзү теләген үстерү. Балаларны корылмалар төзеп уйнарга, аларны сюжет буенча берләштерергә өйрәтү: юл һәм йортлар — урам; өстәл, урындык, диван — курчаклар өчен йорт җиһазлары. Балаларны уйнаганнан соң детальләрне пөхтә-җыйнак итеп тартмаларга салып куярга өйрәтү.

## Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

Балаларның игътибарын үзләре яшәгән йортлар һәм балалар бакчасы тирәсендә урнашкан төрле биналарга һәм корылмаларга юнәлтү. Һавага чыккач уйналган уеннар процессында, балалар белән бергә машиналар, ав-

тобуслар һәм транспортның башка төрләрен күзәтү, аларның төрле өлешләрен аерып карау, формаларының иң зур өлешкә карата ничек урнашуларын ачыклау.

Балаларда төзелеш детальләрен (куб, пластина, кечкенә кирпеч, борыс) аера һәм атап әйтә белү сәләтен үстерүне дәвам итү; аларны конструкция үзлекләрен (тотрыклылык, форма, зурлык) исәпкә алып кулланырга өйрәтү. Балаларның нинди охшаш корылмалар күрүләрен исләренә төшерергә тәкъдим итеп, ассоциатив бәйләнешләрне ачыклый белүләрен үстерү.

Корылма үрнәген анализларга өйрәтү: төп өлешләрне аерып күрсәтү, аларны зурлык һәм форма буенча аеру һәм чагыштыру, бу өлешләрнең бер-берсенә карата пространствода урнашуларын билгеләү (йортларда — стеналар, өстә — түшәм, түбә; автомобильдә — кабина, кузов һ.б.).

Корылмаларны мөстәкыйль рәвештә үлчәргә (биеклек, озынлык һәм киңлек буенча), тәрбияче тарафыннан бирелгән конструкция принцибын сакларга («Шундый ук, әмма биек йорт төзе») өйрәтү.

Эре һәм вак төзелеш материалларыннан корылмалар төзергә, корылмаларны төзү һәм бизәү өчен төрле төстәге детальләр кулланырга өйрәтү.

Кәгазьдән конструкцияләүгә өйрәтү: якларын һәм почмакларын бер-берсенә тәңгәлләштереп, туры почмаклы кәгазь битен урталай бөкләү (альбом, участокны бизәү өчен флаглар, котлау открыткасы), төп формага детальләр (йортка — тәрәзәләр, ишекләр, морҗа; автобуска — көпчәкләр; урындыкка — җилкә терәге) ябыштыру.

Балаларны табигый материаллардан: кайрыдан, ботаклардан, яфраклардан, күркәләрдән, каштаннардан, чикләвек кабыгыннан, саламнан әйберләр (көймәләр, керпеләр һ.б.) ясарга тарту. Өлешләрне беркетү өчен җилем, пластилиннан файдаланырга, әйберләр ясаганда кәтүкләр, төрле зурлыктагы тартмалар һ.б. кулланырга өйрәтү.

### Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Балаларда үзләре төзи торган һәм әйләнә-тирәдә күргән корылмалар арасында бәйләнеш урнаштыра алу сәләтен; төрле корылмалар һәм конструкцияләр (йортлар, спорт һәм уен җиһазлары һ.б.) төзү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү.

Конструкцияләрнең төп өлешләрен һәм үзенчәлекле детальләрен аерырга өйрәтү.

Мөстәкыйльлекне, иҗатны, инициативаны, дустанә мөнәсәбәтне хуплау.

Тәрбияче тарафыннан эшләнгән әйберләрне һәм корылмаларны анализларга булышу; анализ нигезендә конструктив чишелеш табу һәм үз корылманы төзүне планлаштыру.

Яңа детальләр: формалары һәм зурлыклары буенча төрле пластиналар, борыслар, цилиндрлар, конуслар һ.б. белән таныштыру. Бер детальне икенчеләре белән алыштырырга өйрәтү.

Бер үк объектның төрле зурлыктагы һәм конструкцияле корылмаларын төзи белүне формалаштыру.

Рәсем буенча төзергә, мөстәкыйль рәвештә кирәкле төзелеш материалын сайлап алырга өйрәтү.

Коллектив эшләү, үз эшләнмәләреңне (эшләнгән әйберләреңне) уртак нияткә яраштырып берләштерү, эшнең кайсы өлешен кем башкарачагы турында сүз куеша белүне үстерүне дәвам итү.

### Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Төрле биналарга һәм корылмаларга (торак йортлар, театрлар һ.б.) карата кызыксыну формалаштыру. Аларның үзенчәлекләрен конструкцияләү эшчәнлегендә чагылдыру теләген хуплау.

Объект конструкциясен күрергә һәм аның төп өлешләрен, шул өлешләрнең функциональ кулланылышын анализларга өйрәтү.

Булган корылмаларны анализлау нигезендә балаларга мөстәкыйль рәвештә аерым конструктив чишелешләр табарга тәкъдим итү.

Коллектив эшләү күнекмәләрен — вазифаларны бүлешү, бер-береңә комачауламыйча, уртак ният буенча эшләү күнекмәләрен ныгыту.

**Төзелеш материалыннан конструкцияләү.** Балаларны, кулланылыш максатларына карап, бер үк объектның төрле конструкцияләрен (җәяүлеләр күпере, транспорт күпере) төзергә өйрәтү. Төзелеш өчен нинди детальләрнең күбрәк туры килүен, максатка яраршлырак рәвештә аларны ничек итеп берләштереп кулланырга кирәклеген ачыклау; корылманы төзү процессын планлаштыру сәләтен үстерүне дәвам итү.

Бер тема белән берләштерелгән корылмалар (урам, машиналар, йортлар) төзергә өйрәтүне дәвам итү.

**Конструктор детальләреннән конструкцияләү.** Төрле пластмасса конструкторлар белән таныштыру. Рәсемнәр, тәрбиячененң телдән бирелгән инструкциясе, үз теләге буенча төрле модельләр (биналар, самолетлар, поездлар һ.б.) төзергә өйрәтү.

Балаларны детальләре штифтлар (башсыз кадаклар) белән беркетелүче агач конструктор белән таныштыру.

Рәсем һәм тәрбиячененң телдән бирелгән инструкциясе буенча төрле конструкцияләр (йорт җиһазы, машиналар) төзергә өйрәтү.

Бер тема белән берләштерелгән конструкцияләр (балалар мәйданчыгы, машиналар кую урыны) төзергә өйрәтү.

Конструкцияләрне сүтәргә өйрәтү (пластмасса конструкторларда).

## Музыкаль эшчәнлек[1]

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Музыкага карата кызыксыну, музыканы тыңлау, кушылып җырлау, иң гади бию хәрәкәтләре башкару теләге тәрбияләү.

[1] Музыкаль репертуар үрнәге Кушымтада тәкъдим ителә.

**Тыңлау.** Балаларны тыныч һәм дәртле җырларны, төрле характердагы музыкаль пьесаларны игътибар белән тыңларга, нәрсә (кем) турында җырлауны аңларга һәм эшчәнлеккә карата эмоциональ мөнәсәбәт белдерергә өйрәтү.

Авазларны югарылык буенча (кыңгырауның, фортепианоның, металлофонның югары һәм түбән яңгырашы) аерырга өйрәтү.

**Җырлау.** Балаларда кушылып җырлаганда һәм җырлаганда активлык тудыру. Җырдагы фразаларны кушылып җырлау күнекмәләрен үстерү (тәрбияче белән бергә эшләнә). Акрынлап аерым җырларга өйрәтү.

**Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр.** Хәрәкәтләр аша музыканы кабул итүнең эмоциональлеген һәм образлылыгын үстерү. Өлкәннәр күрсәткән хәрәкәтләрне (чәбәкләү, тыпырдау, ярымчүгәләү, кул чукларын селкетү һ.б.) кабатлау күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү. Балаларны хәрәкәтне музыка башлангач башларга һәм тәмамлангач төгәлләргә; образлар тудырырга (кошчык оча, куян сикерә, камыт аяклы аю баласы бара) өйрәтү. Йөрү һәм йөгерүне (аяк очына басып, тын гына; аякларны биек һәм аз гына күтәреп; туры галоп белән), түгәрәктә һәм сибелеп бию хәрәкәтләре башкару, музыканың характеры яки җыр эчтәлеге үзгәрүгә карап, хәрәкәтләрне үзгәртү күнекмәләрен камилләштерү.

## Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

Балаларда музыканы эмоциональ кабул итү тәрбияләү.

Өч музыкаль жанр — җыр, бию, марш белән таныштыру. Музыкаль хәтерне үстерүгә булышлык итү. Таныш җырларны, пьесаларны танып алу сәләте, музыканың характерын (күңелле, дәртле, тыныч) тоемлау, аңа эмоциональ мөнәсәбәт белдерү формалаштыру.

**Тыңлау.** Музыкаль әсәрне ахырынача тыңлап бетерергә, музыка характерын аңларга, әсәрдә ничә өлеш булуын белергә һәм ачыкларга өйрәтү.

Октава — септима чикләре эчендә авазларны югарылык буенча аеру, көй яңгырашындагы үзгәрешләрне (көчле, акрын) тою сәләтен үстерү.

Төрле музыкаль уенчыклар, балалар музыка уен кораллары (музыкаль чүкеч, шарманка, шалтыравык, барабан, шөлдерле барабан, металлофон һ.б.) яңгырашын аеру сәләтен камилләштерү.

**Җырлау.** Җырлау күнекмәләрен үстерүгә: ре (ми) — ля (си) диапазонында булышлык итү, көчәнмичә, башкаларның барысы белән бер темпта җырлау, сүзләрне чиста һәм ачык итеп әйтү, җыр характерын (күңелле, озын, йомшак, аһәңле) чагылдыруга булышлык итү.

**Җыр иҗаты.** «Әлли-бәлли» иҗекле бишек җырларының, «лә-лә» иҗекле күңелле җыр көйләренең ахырын җырлап бетерергә өйрәтү. Үрнәк буенча күңелле һәм моңлы җырлар иҗат итү күнекмәләрен формалаштыру.

**Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр.** Музыканың ике өлешле формасына һәм аның яңгырау көченә (көчле, акрын) тәңгәл рәвештә хәрәкәт итәргә; музыка яңгырый башлауны һәм аның тәмамлануын тоюны белдерергә өйрәнү.

Төп хәрәкәтләр (йөрү һәм йөгерү) күнекмәләрен камилләштерү. Башкалар белән бергә һәм ялгыз гына атлап йөрергә, музыка астында җиңел, салмак һәм тиз темпта йөгерергә өйрәтү.

Бию хәрәкәтләрен башкару сыйфатын яхшырту: чиратлаштырып, ике аяк һәм бер аяк белән тыпырдау.

Парлап бөтерелү, туры галоп башкару, музыкаль әсәрнең темпына һәм ритмына карап, предметлар, уенчыклар белән һәм алардан башка музыка астында хәрәкәтләнә белү күнекмәләрен үстерү.

Уен һәм әкият образларын тәэсирле һәм эмоциональ чагылдыруны үстерүгә булышлык итү: аю килә, песи яшеренеп бара, тычкан балалары йөгерешә, куян сикерә-сикерә бара, әтәч йөри, чебиләр бөртекләр чүплиләр, кошчыклар очалар һ.б.

**Бию-уен иҗаты.** Бию көйләре астында бию хәрәкәтләрен мөстәкыйль башкаруны стимуллаштыру. Сурәтләнүче хайваннарның холкын чагылдыручы хәрәкәтләрне төгәлрәк башкарырга өйрәтү.

**Балалар музыка уен коралларында уйнау.** Балаларны кайбер балалар музыка уен кораллары — сыбызгы, металлофон, кыңгырау, шөлдерле барабан, шалтыравык, барабан, шулай ук аларның яңгырашы белән таныштыру.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны балалар бәрмә музыка уен коралларында уйнарга өйрәтү.

## Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

Балаларда музыкага карата кызыксыну, аны тыңлау теләге тәрбияләү, музыкаль әсәрләрне хис аша кабул итү тәрбияләү.

Музыкаль тәэсирләрне баету, музыка культурасы нигезләрен алга таба үстерүгә булышлык итү.

**Тыңлау.** Музыканы тыңлау культурасы (игътибарны башка нәрсәгә юнәлтмәү, әсәрне ахырынача тыңлап бетерү) күнекмәләре формалаштыру.

Музыканың характерын тоемларга, таныш әсәрләрне танып алырга, тыңланган әсәрдән туган тәэсирләреңне белдерергә өйрәтү.

Музыкаль әсәрнең тәэсир итү чараларын тоярга өйрәтү: акрын, көчле, салмак, тиз. Авазларны югарылык буенча аеру сәләтен үстерү (секста, септима чикләре эчендә югары, түбән).

**Җырлау.** Балаларны тәэсирле итеп җырларга өйрәтү, сузып, хәрәкәтчән, бертавышка (беренче октавадагы ре — си чикләре эчендә) җырлый белү күнекмәләре формалаштыру. Кыска музыкаль фразалар арасында тын алуны камилләштерү. Көйне чиста җырларга, фразалар ахырын йомшартырга, сүзләрне ачык итеп әйтергә, музыканың характерын чагылдырып, тәэсирле итеп җырларга өйрәтү. Музыка уен коралларына кушылып һәм алардан башка җырларга өйрәтү (тәрбияче ярдәмендә).

**Җыр иҗаты.** Бишек җыры көен мөстәкыйль иҗат итәргә һәм көйләп бирелгән сорауларга («Синең исемең ничек?», «Пескәй, сиңа ни кирәк?», «Син кайда?») җавап бирергә өйрәтү. Бирелгән текстка импровизация белән көй чыгару сәләте формалаштыру.

**Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр.** Балаларда музыка характерына тәңгәл рәвештә ритмик хәрәкәтләнү күнекмәсе формалаштыруны дәвам итү.

Музыканың ике яки өч кисәкле формасына карап, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләрне үзгәртергә өйрәтү.

Бию хәрәкәтләрен камилләштерү: туры галоп, «пружинка», ялгыз һәм парлашып бөтерелү.

Балаларны биюләрдә һәм әйлән-бәйләндә, һәм парлап биегәндә түгәрәк буенча хәрәкәт итәргә, аяк очына һәм үкчәгә басарга, кулларны ритмик чәбәкләргә, иң гади төрдәге башкача хәрәкәтләрне (түгәрәктән чыгып сибелү һәм кабат түгәрәккә басу), сикереп алуларны башкарырга өйрәтү.

Балаларда төп хәрәкәтләр (йөрү: «тантаналы», тыныч, «серле»; йөгерү: җиңелчә, ашкынулы) күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү.

**Бию-уен иҗаты.** Мимика һәм пантомима (шат һәм боек куян, хәйләкәр төлке, ачулы бүре һ.б.) кулланып, музыка-уен күнегүләрен (яфрак бөтерелә, кар бөртекләре төшә) эмоциональ-образлы башкаруны үстерүгә булышлык итү.

Җырларны сәхнәләштерергә һәм кечерәк музыкаль спектакльләр куярга өйрәтү.

**Балалар музыка уен коралларында уйнау.** Иң гади көйләрне агач кашыклар, шалтыравыклар, барабан, металлофон кулланып уйнау күнекмәләре формалаштыру.

## Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Музыкага карата кызыксыну һәм мәхәббәт, аны тоя белү сәләтен үстерүне дәвам итү.

Классик музыка, халык көйләре һәм хәзерге заман музыкасы белән таныштыру нигезендә музыка культурасын формалаштыру.

Балаларның музыкаль сәләтләрен: тавыш югарылыгын, ритмлы, тембрлы, динамикалы ишетү мөмкинлекләрен үстерүне дәвам итү.

Җырлау, музыка астында хәрәкәтләр ясау, балалар музыка уен коралларында уйнау һәм импровизацияләү күнекмәләрен алга таба үстерүгә; балаларның иҗади активлыгына булышлык итү.

**Тыңлау.** Музыкаль әсәрләрнең жанрларын (марш, бию, җыр) аерырга өйрәтү.

Музыкаль хәтерне көйләрне әсәрнең аерым өлешләре (кереш, йомгак, музыкаль фраза) буенча тану аша камилләштерү.

Квинта чикләре эчендә авазларның югарылыгын, яңгырашлары буенча музыка уен коралларын (клавишлы-бәрмә һәм кыллы: фортепиано, скрипка, виолончель, балалайка) аеру күнекмәләрен камилләштерү.

**Җырлау.** Җырлау күнекмәләре, беренче октавадагы «ре»дан икенче октавадагы «до»га кадәрге диапазонда җиңел аваз белән җырлау, җыр башлану алдыннан, музыкаль фразалар арасында тын алу, сүзләрне аермачык әйтү, җырны үз вакытында башлау һәм тәгәлләү, көйнең характерын эмоцио-

наль чагылдыру, салмак, кычкырып һәм акрын җырлау күнекмәләре формалаштыру.

Аерым гына, музыкага ияреп һәм музыкадан башка җырлау күнекмәләрен үстерүгә булышлык итү.

Мөстәкыйльлек күрсәтүгә һәм төрле характердагы җырларны иҗади башкаруга булышлык итү.

Җыр музыкаль зәвыгын үстерү.

**Җыр иҗаты.** Бирелгән текстка импровизация белән көй чыгарырга өйрәтү.

Балаларны төрле характердагы көйләр: йомшак бишек җыры көе, дәртле яки күтәренке марш, салмак вальс, күңелле бию көе иҗат итәргә өйрәтү.

**Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр.** Ритм хисе, хәрәкәтләр аша музыка характерын, музыканың эмоциональ-образлы эчтәлеген чагылдыру сәләтен үстерү.

Тирәлектә иркен ориентлашырга, иң гади төрдәге күчешләрне башкарырга, мөстәкыйль рәвештә салмак темптан тиз яки акрын темпка күчәргә, музыкаль фразага тәңгәл рәвештә хәрәкәтләрне үзгәртергә өйрәтү.

Бию хәрәкәтләрен башкару күнекмәләрен (сикергәндә чиратлаштырып аякларны алга ташлау; чүгәләп, алга күчеп адым ясау, бөтерелү; аякны алга сузып чүгү) формалаштыруга булышлык итү.

Түгәрәк уен җырлы биюләре, шулай ук башка халыкларның биюләре белән таныштыру.

Җырларны сәхнәләштерү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү; төрле уеннарда әкияти хайваннарны һәм кошларны (ат, кәҗә, төлке, аю, куян, торна, козгын һ.б.) гәүдәләндерергә өйрәтү.

**Музыкаль-уен һәм бию иҗаты.** Бию иҗатын үстерү; иҗатта мөстәкыйльлек күрсәтеп, биюләр өчен хәрәкәтләр уйлап чыгарырга, бию композициясен төзергә өйрәтү.

Мөстәкыйль рәвештә җырның эчтәлеген чагылдыручы хәрәкәтләр уйлап чыгарырга өйрәтү.

Җырларның, әйлән-бәйләннәрнең эчтәлеген сәхнәләштерү теләге уяту.

**Балалар музыка уен коралларында уйнау.** Балаларны иң гади көйләрне балалар музыка уен коралларында уйнарга; гомуми динамиканы һәм темпны саклап, таныш җырларны индивидуаль рәвештә һәм кечерәк төркемнәр белән башкарырга өйрәтү.

Балалар иҗатын үстерү, аларны актив мөстәкыйль гамәлләргә дәртләндерү.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Балаларның музыка культурасын үстерү, сәнгати зәвык тәрбияләүне дәвам итү.

Балаларны музыкаль тәэсирләр белән баетуны дәвам итү, төрле характердагы музыка башкарылганда ачык эмоциональ тойгылар кичерүләренә булышлык итү.

Тавыш югарылыгын, ритмлы, тембрлы, динамикалы ишетү сәләтен камилләштерү.

Җырлау тавышы аппараты формалашуга, музыкага ияреп хәрәкәт итү күнекмәләрен үстерүгә булышлык итү.

Балалар музыка уен коралларында уйнарга өйрәтү.

Элементар музыкаль төшенчәләр белән таныштыру.

**Тыңлау.** Квинта — терция чикләре эчендә авазларны югарылык буенча кабул итү күнекмәләрен үстерүне; балаларны музыкаль тәэсирләр белән баету һәм музыкаль зәвык формалаштыруны дәвам итү, музыкаль хәтерне үстерү. Фикерләү, фантазия, хәтер, ишетү сәләтен үстерүгә булышлык итү.

Элементар музыкаль төшенчәләр (темп, ритм); музыкаль жанрлар (опера, концерт, симфоник концерт), композиторлар һәм музыкантлар иҗаты белән таныштыру.

Балаларны Россия Федерациясенең Дәүләт гимны көе белән таныштыру.

**Җырлау.** Җырлау тавышы аппаратын һәм вокаль-ишетү координациясен камилләштерү.

Җырларны беренче октаваның «до»сыннан икенче октаваның «ре»сына кадәр чикләр эчендә тәэсирле башкаруның гамәли күнекмәләрен ныгыту; тын алырга һәм аны фраза ахырынача саклап торырга өйрәтү; артикуляциягә (дикциягә) игътибар юнәлтү.

Музыкага ияреп яки аннан башка мөстәкыйль, аерым һәм коллектив белән җырлау күнекмәләрен ныгыту.

**Җыр иҗаты.** Үрнәк сыйфатында халык җырларын файдаланып, мөстәкыйль рәвештә көйләр чыгарырга; таныш җырларны, музыкаль пьесаларны һәм биюләрне файдаланып, үрнәк буенча һәм үрнәктән башка гына, бирелгән темага мөстәкыйль рәвештә көйләр импровизацияләүгә өйрәтү.

**Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр.** Бию хәрәкәтләре күнекмәләрен, биюдә эмоциональ-образлы эчтәлекне чагылдырып, музыка характеры белән тәңгәл рәвештә тәэсирле һәм ритмик хәрәкәтләнү күнекмәләрен үстерүгә булышлык итү.

Милли биюләр (рус, татар, белорус, украин биюләре һ.б.) белән таныштыру.

Бию-уен иҗатын үстерү; җырларны, театраль күренешләрне (постановкаларны) сәхнәләштергәндә төрле образларны сәнгатьле итеп башкару күнекмәләрен формалаштыру.

**Музыкаль-уен һәм бию иҗаты.** Музыкаль башкару эшчәнлегенең аңлаешлы төрләрендә (оркестрда уйнау, җырлау, бию хәрәкәтләре һ.б.) балаларның иҗади активлыгы үсешенә булышлык итү.

Аерым характердагы музыка буенча импровизацияләүгә өйрәтү (чаңгычы, тимераякта йөгерүче, җайдак, балыкчы; хәйләкәр песи һәм ачулы кәҗә бәтие һ.б.).

Җырның эчтәлеген чагылдыручы хәрәкәтләр уйлап чыгарырга, күзалланган предметлар белән образ тудырырга өйрәтү. Хәрәкәтләрдә музыкаль образларны чагылдыру ысулларын мөстәкыйль рәвештә эзләргә өйрәтү.

Музыка сәләтен формалаштыру; активлык һәм мөстәкыйльлек чагылышына булышлык итү.

**Балалар музыка уен коралларында уйнау.** Төрле музыка уен кораллары башкаруында һәм оркестр өчен эшкәртүдә музыкаль әсәрләр белән таныштыру.

Металлофонда, курайда, сыбызгыда, бәрмә һәм электр музыка уен коралларында, халык музыка уен коралларында — шалтыравыкларда, өчпочмакларда уйнарга; музыкаль әсәрләрне оркестрда һәм ансамбльдә уйнарга өйрәтү.

## «ФИЗИК ҮСЕШ» белем бирү өлкәсе

«Физик үсеш балалар эшчәнлегенең түбәндәге төрләрендә тәҗрибә булдыруны үз эченә ала: хәрәкәтләнү, шул исәптән координация һәм сыгылмалылык кебек физик сыйфатларны үстерүгә юнәлтелгән, организмның терәк-хәрәкәт системасын дөрес формалаштыруга, тигезлек саклауга, хәрәкәтне координацияләүгә, кулларның эре һәм вак моторикасына булышлык итүче, шулай ук төп хәрәкәтләре дөрес һәм организмга зыян салмаслык итеп башкарылган атлап йөрү, йөгерү, җиңелчә сикерүләр, ике якка да борылулар кебек күнегүләрне эшләү белән бәйле хәрәкәт эшчәнлеге; спортның кайбер төрләре турында башлангыч күзаллаулар формалашу; кагыйдәләре белән бергә хәрәкәтчел уеннарны үзләштерү; хәрәкәтләнү өлкәсендә максатчанлык һәм үз-үзеңне көйләү формалашу; сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре формалашу, шул яшәү рәвешенең элементар нормаларын һәм кагыйдәләрен үзләштерү (туклануда, хәрәкәтләнү режимында, чыныгуда, файдалы гадәтләр формалаштыруда һ.б.»[1].

### Төп максатлар һәм бурычлар

**Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру.** Балаларда сәламәт яшәү турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру.

**Физик культура.** Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту; акыл һәм физик мөмкинлекләрен арттыру, талчыгуны искәртү.

Гармонияле физик үсешне тәэмин итү, төп хәрәкәт төрләрендә сәләт һәм күнекмәләрне камилләштерү, хәрәкәтләрнең матурлыгына, нәзакәтлелегенә, тәэсирлелегенә ирешү, гәүдәнең дөрес тотышын формалаштыру.

Көндәлек хәрәкәтләнү эшчәнлеге ихтыяҗы формалаштыру. Хәрәкәтләнү эшчәнлегендә инициативалылык, мөстәкыйльлек һәм иҗат, үз-үзеңне контрольдә тоту, хәрәкәтләр башкарганда үз-үзеңне бәяләү сыйфатларын үстерү.

Хәрәкәтле уеннарда һәм спорт уеннарында, физик күнегүләрдә катнашуга карата кызыксынуны, мөстәкыйль хәрәкәтләнү эшчәнлегендә активлыкны үстерү; спортка карата кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.

---

[1] МББ ФДББСның 2.6. пунктын кара.

## Психологик-педагогик эш эчтәлеге

### Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру

#### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Балаларда кешенең тормышы һәм эшчәнлеге өчен төрле органнарның әһәмияте турында күзаллаулар формалаштыру: күзләр — күрер өчен, колаклар — ишетер өчен, борын — ис тояр өчен, тел — тәмне татыр өчен, куллар — эләктерер, тотар, кагылу өчен; аяклар — басып тору, сикерү, йөгерү, йөрү өчен; баш — уйлар, хәтердә калдырыр өчен.

#### Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

Сизү органнарын (күзләр, авыз, борын, колаклар) аеру һәм атап әйтә белүне үстерү, аларның организмдагы роле һәм аларны ничек саклау һәм карау турында күзаллау булдыру.

Файдалы һәм зыянлы ризык; кеше сәламәтлеге өчен файдалы яшелчәләр һәм җимешләр, сөт ризыклары турында күзаллау булдыру.

Иртәнге зарядка, уеннар, физик күнегүләрнең яхшы кәеф тудырулары; йокы ярдәмендә көч яңару турында күзаллау формалаштыру.

Балаларны организмның төрле органнарын һәм системаларын ныгытучы күнегүләр белән таныштыру. Чыныгуның кирәклеге турында күзаллау булдыру.

Сәламәтлекнең кыйммәтле булуы турында күзаллау булдыру; сәламәт яшәү рәвеше алып бару теләге формалаштыру.

Үз-үзеңне ничек хис итү турында өлкәннәргә җиткерү, дәваланырга кирәклекне аңлый белү формалаштыру.

Көндәлек тормышта гигиена һәм пөхтәлек күнекмәләрен саклау һәм үтәү ихтыяҗын формалаштыру.

#### Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

Балаларны кеше гәүдәсенең төрле өлешләре һәм сизү органнары белән таныштыруны дәвам итү.

Кеше тормышы һәм сәламәтлеге өчен гәүдә өлешләренең һәм сизү органнарының әһәмияте турында күзаллау формалаштыру (куллар күп кенә файдалы эшләр эшли; аяклар хәрәкәтләнергә ярдәм итә; авыз сөйли, ашый; тешләр чәйни, тел чәйнәргә, сөйләргә ярдәм итә; тире тоя; борын сулый, исләрне сизә; колаклар ишетә).

Туклану режимын үтәү, туклану өчен яшелчәләр һәм җимешләр, башка файдалы ризыклар куллану ихтыяҗы тәрбияләү.

Кеше өчен кирәкле матдәләр һәм витаминнар турында күзаллау формалаштыру. Сәламәтлек өчен йокының, гигиена процедураларының, хәрәкәтләрнең, чыныгуның мөһимлеге турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Балаларны «сәламәтлек» һәм «авыру» төшенчәләре белән таныштыру.

Бала башкарган эшнең аның сәламәтлегенә йогынты ясавын аңларга өйрәтү («Мин тешләремне чистартам — димәк, алар ныклы һәм сәламәт булачак», «Мин урамда аякларымны чылаттым, һәм миңа салкын тиде».

Бәрелгәндә үз-үзеңә элементар ярдәм күрсәтү, авырганда, имгәнгәндә ярдәм сорап өлкәннәргә мөрәҗәгать итү күнекмәләре формалаштыру.

Сәламәт яшәү рәвеше; кеше организмы өчен физик күнегүләрнең әһәмияте турында күзаллаулар формалаштыру. Организмның төрле органнарын һәм системаларын ныгыту өчен физик күнегүләр белән таныштыруны дәвам итү.

## Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Кеше организмының эшчәнлек үзенчәлекләре һәм бөтенлеге турындагы күзаллауларны киңәйтү. Балаларның игътибарын алар организмының һәм сәламәтлегенең үзенчәлекләрендә туплау («Миңа апельсин ашарга ярамый — миндә аллергия», «Миңа күзлек кияргә кирәк»).

Сәламәт яшәү рәвешенең мөһим компонентлары (дөрес туклану, хәрәкәтләнү, йокы һәм кояш, һава һәм су — безнең иң яхшы дусларыбыз) һәм сәламәтлекне җимерүче факторлар турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Кеше сәламәтлегенең дөрес тукланудан; сизенү тойгыларына нигезләнеп продуктларның сыйфатын ачыклый белүеннән бәйле булуы турында күзаллаулар формалаштыру.

Гигиена һәм көндәлек режимның кеше сәламәтлеге өчен әһәмияте турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Авыру кешене карау кагыйдәләре турында күзаллаулар формалаштыру (аның турында кайгырту, шауламау, аның үтенечләрен һәм кушканнарын үтәү). Авыру кешенең хәленә керү хисе тәрбияләү. Үз-үзеңне хис итүне тасвирлый белүне формалаштыру.

Балаларны сәламәт кешенең мөмкинлекләре белән таныштыру.

Балаларда сәламәт яшәү рәвеше ихтыяҗы формалаштыру. Физик культурага һәм спортка карата кызыксыну, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү теләге тәрбияләү.

Олимпия хәрәкәте тарихыннан аңлаешлы мәгълүматлар белән таныштыру.

Куркынычсызлык техникасы нигезләре, спорт залында һәм спорт мәйданчыгында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Балаларның рациональ туклану (ризык күләме, ашау эзлеклелеге, туклануда төрлелек, су эчү режимы) турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Кеше тормышында хәрәкәтләнү активлыгының әһәмияте турында күзаллаулар; үз органнарыңны һәм системаларыңны ныгыту өчен махсус физик күнегүләр ясый белүне формалаштыру.

Актив ял итү турында күзаллаулар формалаштыру.

Чыныгу кагыйдәләре һәм төрләре, чыныктыручы процедураларның файдасы турындагы күзаллауларны киңәйтү.

Кеше тормышында кояш яктысының, һаваның һәм суның роле, аларның сәламәтлеккә йогынтысы турындагы күзаллауларны киңәйтү.

## Физик культура[1]

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Гәүдәнең тотрыклы халәтен, дөрес торышын саклый белү күнекмәләре формалаштыру.

Куллар һәм аякларны үзара көйле, иркен хәрәкәт иттереп, бер-береңә бәрелмичә йөрергә һәм йөгерергә өйрәтү. Күрү ориентирларына таянып, билгеле бер юнәлеш буенча бергәләп хәрәкәт итәргә, барганда һәм йөгергәндә, педагог күрсәтмәсе буенча, хәрәкәт итүнең юнәлешен һәм рәвешен үзгәртергә өйрәтү.

Шуышырга, үрмәләргә, туп белән төрлечә эш итәргә (тотып алу, тотып тору, күчерү, кую, ыргыту, тәгәрәтү) өйрәтү. Алга хәрәкәт ясап, ике аяк белән урында сикерергә, ике аяк белән урыннан этелеп озынлыкка сикерергә өйрәтү.

**Хәрәкәтле уеннар**. Балаларда тәрбияче белән бергәләп гади эчтәлекле, катлаулы булмаган хәрәкәтле уеннар уйнау теләге үстерү. Балаларның төп хәрәкәтләрне (йөрү, йөгерү, ыргыту, тәгәрәтү) камилләштерә торган уеннар уйнау күнекмәләре үсешенә булышлык итү. Хәрәкәтләрнең тәэсирлелегенә, кайбер персонажларның иң гади гамәлләрен чагылдыра белергә (куян балалары кебек сикерү; чебиләр кебек бөртекләр чүпләү һәм су эчү һ.б.) өйрәтү.

### Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

Төрле хәрәкәт төрләрен камилләштерүне дәвам итү. Балаларны аякларны шапылдатмыйча, башларны имичә, кул һәм аякларның дөрес координациясен саклап иркен йөрергә һәм йөгерергә өйрәтү. Бергәләп эш итәргә гадәтләндерү. Берәрләп колоннага, шеренгага тезелергә, түгәрәкләп басарга, тезелүләр вакытында үз урыныңны табарга өйрәтү.

Биеклектән, бер урында, алга таба сикергәндә ике аяк белән көчле итеп этелергә һәм җиргә дөрес төшәргә; урыннан озынлыкка һәм биеклеккә

[1] Хәрәкәтле уеннардагы төп хәрәкәтләрнең һәм күнегүләрнең үрнәк исемлеге Кушымтада тәкъдим ителә.

сикергәндә, ком тутырылган кечкенә капчыкларны, 15–20 см диаметрлы тупларны ыргытканда дөрес башлангыч торыш алырга өйрәтү.

Тәгәрәткәндә, ыргытканда тупларны көчле итеп этеп җибәрә белү күнекмәләрен ныгыту. Тупны берьюлы ике кул белән тотып алырга өйрәтүне дәвам итү.

Үрмәләгәндә аркылы борыска тотынырга өйрәтү. Шуыша белү күнекмәләрен ныгыту.

Утырганда, басып торганда, хәрәкәтләнгәндә, тигезлек буенча күнегүләр башкарганда гәүдәнең дөрес торышын сакларга өйрәтү.

Чанада шуарга, өч көпчәкле велосипедка утырырга, шул велосипедта йөрергә һәм аннан төшәргә өйрәтү.

Балаларны чаңгыларны кияргә һәм салырга, чаңгыда йөрергә, чаңгыларны урынына куярга өйрәтү. «Йөгер», «тот», «тукта» сигналларына һ.б. га хәрәкәт белән җавап бирергә; хәрәкәтле уеннарда кагыйдәләрне үтәргә өйрәтү.

Физик күнегүләр башкарганда, хәрәкәтле уеннарда мөстәкыйльлек һәм иҗат сәләте үстерү.

**Хәрәкәтле уеннар.** Хәрәкәтләнү эшчәнлеге процессында балаларның активлыгын һәм иҗади омтылышын үстерү. Кагыйдәле уеннар оештыру.

Мөстәкыйль рәвештә тәгәрәткечләр, автомобильләр, арбалар, велосипедлар, туплар, шарлар белән уйнауны хуплау. Үрмәләү, шуышу күнекмәләрен; җитезлекне, хәрәкәтләрнең тәэсирлелеген һәм матурлыгын үстерү. Хәрәкәт төрләрен үзгәртү белән бергә уеннарга катлаулырак кагыйдәләр кертү.

Балаларда элементар кагыйдәләрне үтәү, хәрәкәтләрне яраштыру, тирәлектә ориентлашу күнекмәләре тәрбияләү.

### Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

Гәүдәнең дөрес торышын формалаштыру.

Балаларның хәрәкәтләнү күнекмәләрен, аларны мөстәкыйль хәрәкәтләнү эшчәнлегендә иҗади куллана белүен үстерү һәм камилләштерү.

Куллар һәм аякларның үзара яраштырылган хәрәкәтләре белән йөрү һәм йөгерү күнекмәләрен ныгыту һәм үстерү. Аяк очлары белән көчле этелеп, җиңел, ритмлы йөгерергә өйрәтү.

Шуышырга, шуышып керергә, предметлар аша шуышып чыгарга өйрәтү. Гимнастика стенкасының бер аралыгыннан икенчесенә (уңга, сулга) шуышып керергә өйрәтү.

Ике аяк белән урында һәм алга таба сикергәндә көчле итеп этелергә һәм җиргә дөрес төшәргә, тирәлектә ориентлашырга өйрәтү. Урыннан озынлыкка һәм биеклеккә сикергәндә этелүне кулларны селтәп җибәрү белән яраштырырга, җиргә төшкәндә тигезлек сакларга өйрәтү. Кыска сикергеч аша сикерергә өйрәтү.

Ыргытканда дөрес басу, тупны уң һәм сул кул белән җиргә бәреп кире кайтару, аны кул чугы белән ыргыту һәм тотып ала белү күнекмәләрен (күкрәккә терәмичә) ныгыту.

Ике көпчәкле велосипедта туры юнәлештә, әйләнә буенча йөрергә өйрәтү.

Балаларны чаңгыда шуыштыру адымы белән йөрергә, борылышлар ясарга, тауга күтәрелергә өйрәтү.

Тезелеп басарга, хәрәкәт иткәндә ара сакларга өйрәтү.

Психофизик сыйфатларны: тизлек, чыдамлык, җитезлек һ.б. ны үстерү.

Хәрәкәтле уенда әйдәүче роль башкарырга, уен кагыйдәләрен үтәүгә аңлы карарга өйрәтү.

Хәрәкәтләнү эшчәнлеген оештыруның барлык төрләрендә балаларда оешканлык, мөстәкыйльлек, инициативалылык, яшьтәшләре белән дустанә мөнәсәбәтләр саклый белү сәләтен үстерү.

**Хәрәкәтле уеннар.** Туплар, сикергечләр, кыршаулар һ.б. белән уйнаганда балаларның активлыгын үстерүне дәвам итү.

Тизлек, көч, җитезлек, тирәлектә ориентлашуны үстерү.

Таныш уеннарны оештырганда мөстәкыйльлек һәм инициативалылык тәрбияләү.

Сигнал буенча гамәлләр башкаруга гадәтләндерү.

## Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Гәүдәнең дөрес торышын; хәрәкәтләрне аңлы рәвештә башкару күнекмәләре формалаштыру.

Балаларның хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерү.

Тизлек, көч, чыдамлылык, сыгылмалылыкны үстерү.

Терәктән көчле итеп этелеп җиңел йөрү һәм йөгерү күнекмәләрен ныгыту.

Тоткарлыклар аша чыгып, куышып йөгерергә өйрәтү.

Гимнастика стенкасы буйлап темпны үзгәртеп үрмәләргә өйрәтү.

Йөгереп килеп озынлыкка, биеклеккә сикерергә, сикерүнең төренә карап дөрес йөгереп килергә, этелергә һәм җиргә төшәргә, озын сикергеч аша йомшак өслеккә сикерергә, җиргә төшкәндә тигезлек сакларга өйрәтү.

Ыргытканда селтәнүне ыргыту белән яраштырырга, тупны бер кул белән ыргытырга һәм тотып алырга, урында һәм атлап барганда аны уң һәм сул кул белән бәреп кире кайтарырга өйрәтү.

Чаңгыда шуыштыру адымы белән йөрергә, сөзәк тауга күтәрелергә, таудан төшәргә, ике көпчәкле велосипедта йөрергә, бер (уң һәм сул) аяк белән этелеп самокатта йөрергә өйрәтү. Тирәлектә ориентлашырга өйрәтү.

Спорт уеннары элементларына, ярыш элементлары булган уеннарга, уен-эстафеталарга өйрәтү.

Физик күнегүләр белән шөгыльләнү өчен өлкәннәргә физкультура инвентаре әзерләргә, аны урынына кире алып куярга булышырга гадәтләндерү.

Балаларның спортның төрле төрләренә карата кызыксынуын хуплау, аларга илнең спорт тормышы вакыйгалары турындагы кайбер мәгълүматларны җиткерү.

**Хәрәкәтле уеннар.** Балаларны, инициатива һәм иҗадилык күрсәтеп, мөстәкыйль рәвештә таныш уеннар оештырырга өйрәтүне дәвам итү.

Балаларда ярыш элементлары булган уеннарда, уен-эстафеталарда катнашу теләге тәрбияләү.

Спорт уеннарына һәм күнегүләренә өйрәтү.

### Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Көндәлек хәрәкәтләнү эшчәнлеге ихтыяҗы формалаштыру.

Эшчәнлекнең төрле төрләрендә гәүдәнең дөрес торышын саклау күнекмәләре тәрбияләү.

Төп хәрәкәтләрне башкаруның табигыйлегенә, җиңеллегенә, төгәллегенә, тәэсирлелегенә ирешә барып, аларның техникасын камилләштерү.

Йөргәндә һәм йөгергәндә бирелгән темпны саклый белүне ныгыту.

Йомшак өслеккә, йөгереп килеп озынлыкка һәм биеклеккә сикергәндә, йөгереп килүне этелү белән яраштырырга өйрәтү.

Ыргытканда кул чугының актив хәрәкәтләнүенә ирешү.

Гимнастика стенкасында диагональ буенча бер аралыктан икенчесенә шуышып керергә өйрәтү.

Урында һәм хәрәкәт вакытында тиз арада тезелергә, колоннада, шеренгада, түгәрәктә тигезләнергә; күнегүләрне ритмлы, тәрбияче тарафыннан күрсәтелгән темпта башкарырга өйрәтү.

Психофизик сыйфатларны: көчне, тизлекне, чыдамлыкны, җитезлекне, сыгылмалылыкны үстерү.

Балаларны статик (урында) һәм динамик (хәрәкәттә) тигезлек саклауга өйрәтүне, хәрәкәтләрне координацияләүне һәм тирәлектә ориентлашуны үстерүне дәвам итү.

Спорт хәрәкәтләре башкару күнекмәләрен ныгыту.

Мөстәкыйль рәвештә физкультура инвентаренең, спорт формасының торышын күз уңында тотарга, аларны карап, төзек тотуда актив катнашырга өйрәтү.

Бала шәхесенең төрле яклап үсешен тәэмин итү: сабырлык, үз дигәнендә торучанлык, тәвәккәллек, кыюлык, оешканлык, инициативалылык, мөстәкыйльлек, иҗади омтылыш, фантазия тәрбияләү.

Балаларны мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтле уеннар оештырырга, үз уеннарын, уен вариантларын уйлап чыгарырга, хәрәкәтләрне аралаштырырга өйрәтүне дәвам итү.

Физик культурага һәм спортка, спорт өлкәсендәге аерым казанышларга карата кызыксынуны хуплау.

**Хәрәкәтле уеннар.** Балаларны психофизик сыйфатлар: җитезлек, көч, тизлек, чыдамлык, сыгылмалылыкны үстерүгә, хәрәкәтләрне координацияләүгә, тирәлектә ориентлашырга булышлык итүче төрле хәрәкәтле уеннарны (шул исәптән ярыш элементлары булган уеннарны) файдаланырга; яшьтәшләре белән бергә мөстәкыйль рәвештә таныш хәрәкәтле уеннар оештырырга, үз нәтиҗәләрен һәм иптәшләренең нәтиҗәләрен гадел бәяләргә өйрәтү.

Иҗади омтылыш күрсәтеп, уеннарның вариантларын уйлап чыгарырга, хәрәкәт төрләрен аралаштырырга өйрәтү.

Спорт уеннары һәм күнегүләренә (бура уены, бадминтон, баскетбол, өстәл теннисы, хоккей, футбол) карата кызыксынуны үстерү.

# ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ ФОРМАЛАРЫН, ЫСУЛЛАРЫН, АЛЫМНАРЫН ҺӘМ ЧАРАЛАРЫН ТАСВИРЛАУ

## ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ ПСИХОЛОГИК-ПЕДАГОГИК ШАРТЛАРЫ

### Белем бирү тирәлеген гомуми оештыру үзенчәлекләре

Үсешкә китерүче һәм бала өчен эмоциональ яктан уңайлы белем бирү мохите тудыру «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасын гамәлгә ашыруның иң мөһим шарты булып тора. Балалар бакчасында булу балага шатлык китерергә, ә белем бирү ситуацияләре мавыктыргыч булырга тиеш.

Иң мөһим белем бирү ориентирлары:

• балаларның эмоциональ иминлеген тәэмин итү;

• балаларның башка кешеләргә карата дустанә һәм игътибарлы мөнәсәбәтен формалаштыру өчен шартлар тудыру;

• балалар мөстәкыйльлеген (инициативалылыкны, автономия һәм җаваплылыкны) үстерү;

• балаларның эшчәнлекнең төрле төрләрендә формалашучы сәләтләрен үстерү.

Әлеге максатларны гамәлгә ашыру өчен педагогларга түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

• бала шәхесенә карата ихтирам күрсәтү, аның белән һәм башка педагоглар белән үзара мөнәсәбәтләрнең демократик стилен үстерү;

• баланың үз өстенә җаваплылык алу һәм башка кешеләргә карата үз итү хисләрен белдерү өчен шартлар тудыру;

• килеп туган низагларны балалар белән бергә тикшерү, аларны хәл итәргә булышу, гомуми кагыйдәләр булдыру, бер-береңә карата ихтирам күрсәтергә өйрәтү;

• балалар белән тормышның мөһим мәсьәләләрен тикшерү, баланың үз позициясен белдерүен стимуллаштыру;

• балаларның игътибарын кешеләрнең үз карашлары һәм кыйммәтләре буенча бер-берсеннән аерылып торуларына юнәлтү, моның аларның үз-үзләрен тотышына ничек йогынты ясавын тикшерү;

• ата-аналар (законлы вәкилләр) белән Оешма педагогларының эшчәнлеге юнәлтелгән, шул эшчәнлек ирешергә тиешле ориентирларны тикшерү, гаилә әгъзаларын әлеге максатларга ирешү буенча бергәләп эш итүгә тарту.

Мәгариф оешмасында мәктәпкәчә белем бирү системасы баланың уены һәм танып белү активлыгы үсешенә төбәлгән булырга тиеш. Оешмада ини-

циативалылык, күңел күтәренкелеге, кызыксынучанлык һәм яңаны белү омтылышы кебек сыйфатлар чагылсын өчен шартлар тудырылырга тиеш.

Белем бирү мохитен дөрес оештыру үз-үзеңә ышаныч, тормышка карата оптимистик караш үсешен стимуллаштыра, ялгышуга хокук бирә, танып белү мәнфәгатьләрен формалаштыра, хезмәттәшлек итәргә әзер булуны һәм башка кешегә авыр хәлдә ярдәм итүне хуплый, ягъни баланың уңышлы рәвештә социальләшүен һәм аның шәхесе үсешен тәэмин итә.

Балалар тарафыннан өйрәнелүче темалар белем бирү эшенең максатларына — баланың сәләтләрен һәм инициативасын үстерүгә, мәктәпкәчә яшьтәге балага аңлаешлы мәдәни чараларны (күрсәтмә модельләрне һәм символларны) үзләштерүгә ирешү өчен материал булып тора. Шунлыктан белем бирү программасы гомер буе барачак уку-өйрәнү сәләте (lifelonglearning) булдыруны, шул ук вакытта чынбарлыкка карата аңлы һәм иҗади мөнәсәбәттә булуны таләп иткән хәзерге җәмгыятьтә балаларны тормышка әзерләүнең нигезенә әверелә.

Балалар бакчасында балага яхшы таныш көн дә кабатлана торган хәлләр тәрбия-белем бирү әһәмиятенә ия: һавада йөргәндә һәм режим моментлары вакытында бала үзенә һәм башкаларга карата мөнәсәбәтләр булдыра, инициативалы булырга һәм карарлар кабул итәргә, үзенең фикерләвен һәм хыялын файдаланырга өйрәнә.

## Психологик-педагогик шартлар оештыруда педагогның роле

### Баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итү

Баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итүгә аның индивидуальлеген ихтирам итү, аның эмоциональ халәтенә карата игътибарлылык, аның үз дәрәҗәсен белү хисен хуплау хисабына ирешелә. Мәктәпкәчә учреждениедә педагоглар һәр бала үзен бәяләүләрен һәм аны ничек бар шулай кабул итүләрен; аны тыңлаячакларын һәм аңлаячакларын хис итәрлек атмосфера булдырырга тиешләр.

Төркемдә эмоциональ иминлек тәэмин итү өчен педагог түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:

• балалар белән дустанә, гаепләүләрсез һәм янауларсыз аралашу;

• балаларны игътибар белән тыңлау, аларның хисләрен аңлауны күрсәтү, аларның кичерешләрен һәм фикерләрен уртаклашырга булышу;

• балаларга үз-үзеңне тотуның конструктив вариантларын табарга булышу;

• балалар төрле мәдәни чаралар (уен, рәсем, хәрәкәт һ.б.) ярдәмендә алар өчен шәхси-мөһим, шул исәптән балалар бакчасында булган вакыйгаларга карата үз мөнәсәбәтләрен белдерә алган ситуацияләр тудыру;

• көн дәвамында балалар бергә уйнарлык һәм теләгәндә ялгыз калырлык яки кечерәк төркемдә уйнау мөмкин булган ситуацияләрне чиратлаштыру.

**Баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итү өчен предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре.** Балаларның эмоциональ иминлеген тәэмин итү өчен балалар бакчасындагы халәт өйдәгечә диярлек булырга тиеш, шундый очракта балалар ул шартларга тизрәк күнегәләр, үз эмоцияләрен иркен белдерәләр. Балалар бакчасының балалар өчен каралган барлык бүлмәләре бала үзен уңайлы һәм иркен хис итәрлек итеп җиһазландырылырга тиеш. Уңайлы шарт — бала өчен җайлы һәм ышанычлы, ул кызыклы, яраткан эше белән шөгыльләнә алган мохит. Мохитнең уңайлылыгы балага уңай йогынты ясаучы эмоцияләр, якты һәм кабатланмас тойгылар тудыручы сәнгати-эстетик бизәлеш белән тулыландырыла. Шундый эмоцияләр тудыручы мохиттә булу киеренкелектән, йомыклыктан, артык борчулардан арынуга булышлык итә, бала алдында шөгыль төрен, материаллар, урын-тирәлек сайлау мөмкинлекләре ача.

## Дустанә, игътибарлы мөнәсәбәтләр формалаштыру

Балаларда кешеләргә карата дустанә, игътибарлы мөнәсәбәт тәрбияләү педагог үзе балаларга карата дустанә һәм игътибарлы булган, туган низагларны конструктив рәвештә хәл итәргә булышкан очракта гына мөмкин.

Балаларда кешеләргә карата дустанә мөнәсәбәт формалаштыру өчен педагог:

• үзара тәэсир итешүнең балалар өчен аңлаешлы кагыйдәләрен билгеләргә;

• кагыйдәләрне тикшерү, балаларның аларны ачыклау ситуациясен тудырырга;

• мәктәпкәчә яшьтәге өлкәнрәк балаларның яңа формалар һәм кагыйдәләр булдыру инициативасын проблемалы ситуацияләрне җайга салу өчен балалар бергәләп кагыйдәләр тәкъдим иткәндә хупларга тиеш.

## Мөстәкыйльлекне үстерү

Мөстәкыйльлекне үстерү ике якны адаптив (гамәлдәге социаль нормаларны аңлау һәм аларга тәңгәл рәвештә эш итә белү һәм актив (мөстәкыйль карарлар кабул итү әзерлеге) якларны үз эченә ала.

Программаны гамәлгә ашыру барышында мәктәпкәчә яшьтәге балалар үз теләк-максатларын булдыруда һәм гамәлгә ашыруда позитив социаль тәҗрибә алалар. Балалар яңалыкны, шул исәптән көн дәвамындагы үз тормышларын планлаштырганда яңа нәрсәне сынап карау омтылышларының өлкәннәр тарафыннан хупланачагын тоярга тиешләр. Бу белем бирү ситуациясе балалар мәнфәгатьләрен исәпкә алып булдырылган очракта мөмкин. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар тормышындагы үзгәрешләр исәпкә алынып, балалар төркеменең белем бирү траекториясе үзгәрергә ихтимал.

Кешенең мөстәкыйльлеге (инициативалылык, автономия, җаваплылык) өлкәннәр шартлар тудырганда, нәкъ менә мәктәпкәчә яшьтә формалаша.

Балаларның мөстәкыйльлеген формалаштыру өчен педагог белем бирү мохитен алар түбәндәге гамәлләр башкара алырлык итеп төзергә тиеш:

• шәхси тәҗрибәгә таянып, төрле объектлар, шул исәптән үсемлекләр белән экспериментлар ясарга өйрәнү;

• көн дәвамында яшьтәшләре һәм төрле яшьтәгеләр төркемнәрендә булу;

• уен тирәлеген уен ситуацияләренә ярашлы рәвештә үзгәртү яки конструкцияләү;

• шәхси гамәлләрдә һәм аңлаешлы карарлар кабул иткәндә автоном хәлдә булу.

Балалар инициативасына булышлык итү өчен, педагоглар даими рәвештә мәктәпкәчә яшьтәге балалар түбәндәге күнекмәләрне үзләштерерлек ситуацияләр тудырырга тиеш:

• өлкән кеше катнашында яшьтәшләре белән мөһим вакыйгалар турында фикер алышырга;

• сайлап алырга һәм шул сайланышны нигезләргә (мәсәлән, балаларга аларның сайланышын теркәүнең махсус ысулларын тәкъдим итәргә мөмкин);

• үзләренең инициативасын (ниятләр, тәкъдимнәр һ.б.) белдерергә һәм аны нигезләргә;

• үзләренең индивидуаль һәм кечерәк төркемдәге, командадагы гамәлләрен планлаштырырга;

• үзләренең гамәлләрен индивидуаль рәвештә һәм кечерәк төркемдә, командада бәяләргә.

Барлык балалар бәйрәмнәрнең балалар инициативасын исәпкә алып оештырылуы һәм балалар иҗат иткән әсәрләрне һәм тәкъдир итүләрне импровизацияләүләрне үз эчләренә алулары мөһим.

**Мөстәкыйльлекне үстерү өчен предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре.** Мохит вариантлы булырга, балалар сайлап алырга теләгән төрле мәйданчыклардан (остаханәләр, тикшеренү мәйданчыклары, сәнгать студияләре, китапханәләр, уен урыннары, лабораторияләр һ.б.) торырга тиеш. Предмет-тирәлек мохите, балаларның мәнфәгатьләренә һәм проектларына тәңгәл рәвештә, ким дигәндә берничә атнага бер тапкыр үзгәрергә тиеш. Көн дәвамында балалар үз теләкләре буенча активлык тирәлеге (мәйданчык) сайлап алсыннар өчен вакыт билгеләү зарур.

## Иректе уен эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыру

Уен — мәктәпкәчә яшьтә беренче барлыкка килгән иң әһәмиятле кыйммәтләрнең формаларның берсе. Уйнаганда, кагыйдәләрне аңларга һәм аларны иҗади үзгәртергә өйрәнеп, бала дөньяны бөтен тулылыгы белән — мәгънәләр һәм нормалар җәһәтендә иркен һәм хозурланып үзләштерә.

Иректе уен эшчәнлеген үстерү өлкәннәр ярдәмен таләп итә. Бу очракта, балаларның яшенә, уен эшчәнлегенең үсеш дәрәҗәсенә, ситуация характерына һ.б. га карап, педагогның уендагы роле төрлечә булырга мөмкин. Педагог уенда актив катнашучы ролендә дә, игътибарлы күзәтүче ролендә дә чыгыш ясарга мөмкин.

Уен эшчәнлеген үстерү максатында педагоглар түбәндәгеләрне башкара белергә тиешләр:

• көн дәвамында балаларның ирекле уены өчен шартлар тудыру;

• балаларга ярдәм кирәкле уен ситуацияләрен ачыклау;

• уйнаучы балаларны күзәтү, уенда көннең кайсы вакыйгалары чагылуын аңлау;

• уен эшчәнлеге үсеш алган балаларны уен сәләте аз үскән балалардан аеру;

• уен үзгәрешсез барган очракта аның белән читләтеп җитәкчелек итү (мәсәлән, яңа идеяләр яки балалар идеяләрен гамәлгә ашыру ысулларын тәкъдим итү).

Моннан тыш педагоглар балаларның субкультурасын — балаларның аеруча типик рольләрен һәм уеннарын белергә, аларның әһәмиятен аңларга тиешләр.

Тәрбиячеләр уен һәм эшчәнлекнең башка төрләре арасында үзара бәйләнеш урнаштырырга тиешләр. Эчке сәбәпләр аркасында барлыкка килгән уен, өйрәтүне оештыру чарасы булудан бигрәк — балаларның үзкыйммәтле эшчәнлеге.

**Уен эшчәнлеген үстерү өчен предметлы тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре.** Уен мохите балалар активлыгын стимуллаштырырга һәм балаларның агымдагы мәнфәгатьләренә һәм инициативасына тәңгәл рәвештә даими яңартылырга тиеш. Балалар өчен уен мохитен булдыруда һәм яңартуда катнашу мөмкинлеге тудырылырга тиеш. Ата-аналарда да аны камилләштерүгә үз өлешләрен кертү мөмкинлеге булырга тиеш.

## Танып белү эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыру

Бала әйләнә-тирә дөньяны мөһим һәм кызыклы тикшерү белән мәшгуль булганда өйрәтү аеруча нәтиҗәле була. Бу тикшерү барышында бала мөстәкыйль рәвештә һәм өлкән кеше ярдәмендә ачышлар ясый. Педагог, балаларның мәгълүматны үзләштерүе белән генә чикләнмичә, балаларның танып белү активлыгы ачылу ихтималы булган ситуацияләр булдырырга тиеш. Танып белү үсешен стимуллаштыручы (ягъни балалардан аңга кабул итүне, фикерләүне, хыялны, хәтерне үстерүне таләп итүче) ситуацияләр балаларның көндәлек тормышында — һавада йөргәндә, ашаганда, йокларга яткырганда, киенгәндә, бәйрәмгә әзерләнгәндә һ.б. шартларда һәрдаим туып тора.

Балаларның танып белү активлыгын педагог түбәндәге ысуллар һәм юллар белән стимуллаштырырга мөмкин:

• балаларга даими рәвештә мәгълүматны кабатлауны гына түгел, фикерләүне таләп иткән сораулар тәкъдим итеп;

• балаларга даими рәвештә ачык, иҗади сораулар, шул исәптән төрле җаваплар бирелергә мөмкин булган проблемалы-каршылыклы ситуацияләр тәкъдим итеп;

• фикерләшү вакытында булышу-хуплау атмосферасын тәэмин итеп;

• теге яки бу ситуацияне тикшергәндә балаларга карар кылу буенча тәгаенләнү мөмкинлеге биреп;

• балаларның бер үк мәсьәлә буенча төрле караш белдерүе мөмкин булган фикер алышулар оештырып, фикерләрнең тәңгәл килмәвен күрергә ярдәм итеп;

• балаларның бәхәсләр барышын үзгәртүе ихтимал булган карашларын истә тотып фикер алышу оештырып;

• балаларга үз фикерләрендәге ялгышларны табарга ярдәм итеп;

• бәхәсләр оештырырга булышып;

• балалар өчен мәсьәләне хәл итү кыен булган очракларда өстәмә чаралар (хәрәкәтләндерү чаралары, образлы чаралар, шул исәптән күрсәтмә модельләр һәм символлар) тәкъдим итеп.

**Танып белү эшчәнлеген үстерү өчен предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре.** Мохит бай эчтәлекле булырга, балага актив тикшеренү һәм мәсьәләләрне хәл итү өчен мөмкинлекләр тудырырга, заманча материалларны (конструкторлар, сиземләү формалаштыру өчен материаллар, тәҗрибәләр үткәрү өчен җыелмалар һ.б.) үз эченә алырга тиеш.

## Проектлау эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыру

Мәктәпкәчә яшьләрдә балаларда үз уй-теләкләрен, ниятләрен булдыру һәм үз проектларын гәүдәләндерү тәҗрибәсе барлыкка килергә тиеш. Мәктәпкәчә яшьләрдә балалар тикшеренү, иҗади һәм норматив проектларны ниятләргә һәм гамәлгә ашырырга мөмкиннәр.

Проектлау эшчәнлеген үстерү максатында группада балаларны проектлау гамәленә рухландыручы һәм бу гамәлне хуплаучы ачык атмосфера булдырырга кирәк. Проектлау эшчәнлеге өчен даими рәвештә вакыт билгеләү, проектларны тәкъдир итү (презентацияләү) өчен шартлар тудыру зарур.

Проектлау эшчәнлеген үстерү максатында педагоглар түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

• балаларның кызыксынуын тудыручы, тикшеренүгә омтылышны стимуллаштыручы проблемалы ситуацияләр булдыру;

• балаларның төрле ситуацияләрдә килеп туган сорауларына карата игътибарлы булу; балалар тарафыннан бирелгән сорауларга җавап йөзеннән даими рәвештә проектта каралган белем бирү ситуацияләрен тәкъдим итү;

• балалар автономиясен хуплау: балаларга үз проект чишелешләрен күрсәтергә тәкъдим итү;

• үз ниятләрен башкарганда балаларга үз эшчәнлекләрен планлаштырырга ярдәм итү;

• балалар тарафыннан тәкъдим ителгән проект чишелешләрен тикшергәндә, күрсәтелгән һәр вариантның яңалыгына басым ясап, аларның идеяләрен хуплау;

• балаларга алар тарафыннан тәкъдим ителгән чишелеш вариантларын чагыштырырга, вариантны сайлауны нигезләргә булышу.

**Проектлау эшчәнлеген үстерү өчен предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре.** Балаларның тикшеренү һәм иҗат эшчәнлегенә стимуллаштырып, аларга күп санда мавыктыргыч материаллар һәм җиһазлар тәкъдим итәргә кирәк. Табигать һәм әйләнә-тирә — тәрбиячеләрнең һәм балаларның уртак тикшеренү эшчәнлегендә файдаланырга мөмкин булган күп кенә күренешләрне һәм объектларны үз эчләренә алган тикшеренү тирәлегенең мөһим элементлары.

## Үз мөмкинлекләреңне сәнгать чаралары аша күрсәтү өчен шартлар тудыру

Мәктәпкәчә яшьләрдә балалар вакыйгаларны фикерләү һәм төрле мәдәни чаралар — сызыклар, төс, форма, аваз (тавыш), хәрәкәт, сюжет һ.б. ярдәмендә шул вакыйгаларга карата үз мөнәсәбәтләрен белдерү тәҗрибәсе алырга тиешләр.

Балалар үз мөмкинлекләрен сәнгать чаралары аша күрсәтергә өйрәнсеннәр өчен, педагог түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

• көн дәвамында балалар үз эшләрен иҗат итәргә мөмкин булган вакытны планлаштыру;

• эшчәнлекнең иҗади төрләре белән шөгыльләнгәндә кабул итү һәм хуплау атмосферасы булдыру.

• шөгыль өчен кирәкле техник күнекмәләрне үзләштерергә ярдәм итү һәм булышу;

• балаларның иҗади эшләре бертөрле булмаслык, аларның ниятләрен чагылдырырлык биремнәр тәкъдим итү;

• уй-теләкләрне, ниятләрне гәүдәләндерүдә һәм моның өчен кирәкле чаралар сайлауда балалар инициативасын яклау;

• мәктәпкәчә яштәге балалар үз иҗади эшләрен төрле төркемнәрдәге балалар һәм ата-аналар игътибарына тәкъдим итәрлек вакыйгалар, чаралар, проектлар күргәзмәләре оештыру.

**Үз мөмкинлекләреңне күрсәтү өчен сәнгать чаралары аша предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре.** Белем бирү мохите кирәкле материаллар булуын, эшчәнлекнең төрле төрләре: сынлы сәнгать, музыка уен коралларында уйнау, җырлау, конструкцияләү, актерлык осталыгы, бию,

һөнәрләрнең төрле төрләре, агачтан, балчыктан әйберләр ясау һ.б. белән шөгыльләнү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

### Физик үсеш өчен шартлар тудыру

Физик үсеш балалар сәламәтлеге өчен бик тә мөһим, чөнки ул аларның тумыштан хәрәкәткә омтылышын гамәлгә ашыру мөмкинлеге бирә. Балаларның бердәйлеге, «Мин» образы үсеше баланың физик үсеше, аның җитезлеге, хәрәкәтчәнлеге, активлыгы белән тыгыз бәйләнгән.

Балаларның физик үсешен стимуллаштыру өчен түбәндәгеләр мөһим:

• көн саен балаларга актив хәрәкәтләнү мөмкинлеге бирү;

• балаларны куркынычсызлык кагыйдәләренә өйрәтү;

• эмоциональ кабул итүнең хәрәкәтләнү өлкәсендә барлык балаларның (шул исәптән бик үк актив булмаганнарның) активлыгы чагылышына булышлык итүче дустанә атмосферасын булдыру;

• физик үсеше төрле дәрәҗәдәге балаларга рәхәтләнеп йөгерергә, үрмәләргә, сикерергә ярдәм итүче төрле өйрәтү алымнарын куллану.

**Физик үсеш өчен предмет-тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре.** Мохит балаларның физик активлыгын, үзләре теләгәнчә хәрәкәтләнү, танып белү теләген стимуллаштырырга, хәрәкәтле уеннарга рухландырырга тиеш. Хәрәкәтле, шул исәптән махсус оештырылмаган уеннар барышында балалар уен һәм спорт җиһазларыннан файдалану мөмкинлегенә ия булырга тиешләр. Уен мәйданчыгында эре моторика үсеше өчен шартлар тудырылган булырга тиеш.

Уен тирәлеге (мәйданчыкта да, бүлмәләрдә дә) үзгәрүчән булырга (уенга карап үзгәрергә, хәрәкәтләнү активлыгы өчен җитәрлек урын бирелергә) тиеш.

## БАЛАЛАР БАКЧАСЫНЫҢ ГАИЛӘ БЕЛӘН БАГЛАНЫШЛАРЫ

### Төп максатлар һәм бурычлар

Гаилә белән конструктив багланышлар үстерү бала шәхесенең тулы үсешен тәэмин итүнең иң мөһим шарты булып тора.

Төп максат — тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән җаваплы үзара мөнәсәбәтләр формалаштыру һәм ата-аналарның компетентлыгын (бала тәрбияләү белән бәйле төрле типтагы социаль-педагогик ситуацияләрне хәл итә алу сәләтен) үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру; ата-аналарның ихтирамлы һәм аңлаулы мөнәсәбәткә, балалар бакчасы тормышында катнашуга хокукын тәэмин итү.

Ата-аналарга һәм тәрбиячеләргә үзара мөнәсәбәтләрдә субординациядән, монологизмнан арыну, бер-берләрен гаепләү гадәтеннән баш тарту, бер-берләрен үз проблемаларын хәл итү чарасы итеп түгел, ә тигез хокуклы партнерлар, хезмәттәшләр итеп күрә белү зарур.

Балалар бакчасының гаилә белән багланышларының төп бурычлары:

• педагогларның һәм ата-аналарның балаларны тәрбияләү, өйрәтү-укыту, үсешләренә ирешү, балалар бакчасында һәм гаиләдә төрле эшчәнлекне оештыру шартларына кагылышлы төрле мәсьәләләргә карата мөнәсәбәтләрен өйрәтү;

• педагогларны һәм ата-аналарны балалар бакчасында һәм гаиләдә тәрбияләүнең иң отышлы тәҗрибәсе, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларны гаиләдә һәм җәмгыятьтә тәрбияләүдә туган кыенлыклар белән таныштыру;

• балаларны тәрбияләүнең һәм өйрәтү-укытуның актуаль мәсьәләләре, балалар бакчасының һәм гаиләнең әлеге мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлекләре турында бер-берләренә җиткереп тору.

• балалар бакчасында педагогларның һәм ата-аналарның балалар белән үзара конструктив тәэсир итешүе үсешенә булышлык итүче, эчтәлеге һәм формасы буенча төрле булган хезмәттәшлеге өчен шартлар тудыру;

• тәрбияләнүчеләрнең гаиләләрен районда (шәһәрдә, өлкәдә, республикада) оештырыла торган, педагоглар белән бергә уздырылучы чараларда катнашуга җәлеп итү;

• баланың төрле омтылышларына һәм ихтыяҗларына карата игътибарлы мөнәсәбәт күрсәткән ата-аналарны хуплау, әлеге ихтыяҗларны гаиләдә канәгатьләндерү өчен кирәкле шартлар тудыру.

## Гаилә белән ике арадагы багланышларның төп юнәлешләре һәм формалары

### Үзара арадашлык һәм мәгълүмат алмашу

Үзара уңышлы багланышлар балалар бакчасы бала гаиләсенең тәрбия мөмкинлекләре белән таныш, ә гаилә баланы тәрбияләү ышанып тапшырылган мәктәпкәчә белем бирү оешмасы турында хәбәрдар булган очракта гына урнашырга мөмкин. Бу багланышлар бала үсешендә бер-береңә кирәкле ярдәм күрсәтергә, тәрбияләүдә гомуми мәсьәләләрне хәл итү өчен булган педагогик ресурсларны тартырга мөмкинлек бирә.

Тәрбия потенциалын ике яклап тирәнтен аңлау өчен әңгәмәләр уздыру, анкеталар төзү, иншалар язу белән бергә махсус оештырылучы социаль-педагогик диагностика; педагогларның тәрбияләнүчеләр гаиләләрендә булулары; балалар бакчасында ачык ишекләр көннәре оештыру; балаларны тәрбияләүче якларның казанышлары һәм кыенлыклары белән танышуга юнәлтелгән төрле җыелыш-очрашулар зур әһәмияткә ия.

Беренче җыелыш-очрашуларның максаты — педагогларның гаиләләр белән һәм тәрбияләнүчеләр гаиләләренең үзара, гаиләләрнең педагоглар

белән төрле яклап танышуы. Аралашудагы киртәләрдән арыну өчен, ата-аналарда уңай эмоцияләр тудыручы, педагоглар белән ышанулы мөнәсәбәтләр үстерүгә юнәлтелгән махсус алымнар («Дистанция сайла», «Ассоциацияләнгән рәт», «Фотосурәтләр теле», «Туктаусыз сөйләшү» һ.б.) куллану артык булмас. Шундый җыелышларны ел дәвамында уздыру, һәр җыелышта үз мәсьәләләреңне хәл итә бару урынлы.

Тәрбияләүче өлкән кешеләрнең бер-берләренә даими рәвештә балаларның балалар бакчасындагы һәм гаиләдәге тормышыннан төрле фактларны, һәм кәефе, эчке һәм тышкы халәте, үзен ничек хис итүе, балалар — өлкәннәр (шул исәптән балалар — ата-аналар) мөнәсәбәтләре турында хәбәр итеп торулары зарур.

Әлеге хәбәрләшү турыдан-туры аралашу аша (әңгәмәләр, консультацияләр барышында, җыелышларда, конференцияләрдә) яки читләтеп, төрле чыганаклардан — стендлардан, газеталардан, журналлардан (кулдан язып, электрон чыганакта), гаилә календарьларыннан, төрле буклетлардан, интернет-сайтлардан (балалар бакчасы, мәгариф идарәсе органнары сайтларыннан) мәгълүмат алу, шулай ук язышу (шул исәптән электрон чыганаклар аша) нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла.

**Стендлар.** Стендларда стратегик (күпьеллык) һәм тактик (еллык) мәгълүмат урнаштырыла. Стратегик мәгълүматка балалар бакчасы үсешенең ерак һәм уртача перспективага исәпләнгән максатлары, гамәлгә ашырылучы белем бирү программасы, мәктәпкәчә учреждениенең инновацион проектлары, шулай ук белем бирү буенча өстәмә хезмәтләр турындагы хәбәрләр керә. Тактик мәгълүматлар педагоглар һәм аларның графиклары, көндәлек режим, төркемдә бер елга исәпләнгән тәрбия-белем бирү эшенең бурычлары һәм эчтәлеге турындагы хәбәрләрне үз эченә ала. Тәрбияләүче өлкәннәрнең зур кызыксынуын тудыручы оператив стенд мәгълүматларына төркемдә (балалар бакчасында, районда) көтелә торган яки булып узган вакыйгалар: акцияләр, конкурслар, репетицияләр, күргәзмәләр, очрашулар, уртак проектлар, ял көннәрендәге экскурсияләр һ.б. турындагы хәбәрләр керә. Мәгълүматның бу төре тиз искергәнгә күрә, аны даими рәвештә яңартып торырга кирәк.

Стенд мәгълүматлары, әгәр аларны әзерләүдә ата-аналар катнашса, ул мәгълүматлар гаиләнең хәбәрләр җәһәтендәге мәнфәгатьләренә җавап бирсә, алар структура буенча уңышлы урнашсалар һәм эстетик яктан уңышлы бизәлсәләр (фотосурәтләр һәм иллюстратив материал кулланыла), ата-аналарда күбрәк кызыксыну уята.

Мәгълүмат (бигрәк тә оператив мәгълүмат) тәрбияләүче өлкәннәргә үз вакытында барып ирешсен өчен, аны балалар бакчасы сайтында, шулай ук гаилә календарьларында кабатлау мөһим.

## Тәрбияләүче өлкәннәрнең өзлексез белем алуы

Хәзерге тиз үзгәрүчән дөньяда ата-аналар һәм педагоглар өзлексез рәвештә үз белемнәрен күтәрергә тиешләр.

Ата-аналарның белемлелеге төшенчәсенә карата халыкара бергәлек балаларны карау һәм тәрбияләү, гаилә мөнәсәбәтләрен гармонияләштерү, гаиләдә һәм җәмгыятьтә ата-аналар ролен башкару өчен кирәкле белемнәрне, юнәлешләрне һәм сәләтләрне баетуны күздә тота. Ата-аналарның белемлелеген балаларны ничек тәрбияләргә кирәклеген өйрәтүче императив принципта түгел, шәхес үзәген үстерү принцибы буенча оештыру мөһим.

Ата-аналарны укыту-агарту функцияләрен балалар бакчасы гына түгел, аның партнерлары, шул исәптән ата-аналар җәмәгатьчелеген берләштерүче оешмалар да башкара. Хокукый, гражданлык, нәфис-эстетик, милли-патриотик, медицина өлкәсенә караган белемнәрнең әһәмияте торган саен арта бара. Тәрбияләүче өлкәннәрне мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбия итү өлкәсендәге фәнни казанышлар һәм алдынгы тәҗрибә белән таныштыруга юнәлтелгән фәнни агарту эшчәнлегенең актуальлеге саклана.

Өлкәннәр нинди генә мәдәни-агарту программасын сайламасыннар, өстәмә белемнәрнең ата-аналарны һәм белгечләрне үзлекләреннән үсешкә, камилләшүгә юнәлдерүе мөһим.

Белем күтәрүнең төп формалары сыйфатында конференцияләр (шул исәптән онлайн-конференцияләр дә), ата-аналар җыелышлары (балалар бакчасы, район, шәһәр, өлкә күләмендә үткәрелүче җыелышлар), ата-аналар һәм педагогларның укулары файдаланыла ала.

Ата-аналарга аларның белемлелеген тәэмин итүче партнерлар (социаль педагог, психолог, өлкән тәрбияче, ата-аналар төркеме белән багланышларның формаларын һәм эчтәлеген сайлау хокукы бирү, аларны «ата-аналар мәктәбе»нең белем бирү программалары эчтәлеген планлаштыруда һәм формалаштыруда катнашуга җәлеп итү әһәмиятле.

Ата-аналарның белемен күтәрү программаларын түбәндәге принциплардан чыгып төзү һәм гамәлгә ашыру мөһим:

• максатчанлык — ата-аналар белемен күтәрүнең максатларына һәм өстенлекле бурычларына юнәлдерелгәнлек;

• адреслылык — ата-аналарның белем алу ихтыяҗларын исәпкә алу;

• аңлаешлылык — ата-аналарның программада каралган уку материалын үзләштерү мөмкинлекләрен исәпкә алу;

• индивидуальләштерү — ата-аналарның белемнәре һәм сәләтләренең дәрәҗәсеннән чыгып, укытуның эчтәлеген, алымнарын һәм программаның үзләштерелү темпларын үзгәртү;

• кызыксынучы якларның (педагогларның һәм ата-аналарның) белем күтәрү программаларының эчтәлегенә һәм аңа төзәтмәләр кертүгә кагылышлы карарларны тәкъдим итүдә, тикшерүдә һәм кабул итүдә катнашуы.

Ата-аналарны укытуның төп формалары: лекцияләр, семинарлар, мастер-класслар, тренинглар, проектлар, уеннар.

**Мастер-класслар**. Мастер-класс — белгечнең, ата-аналарның игътибарын бала тәрбияләүнең актуаль мәсьәләләренә һәм аларны хәл итү чараларына юнәлтү максатында, үз һөнәри осталыгын күрсәтү-тәкъдим итүенең (презентацияләвенең) аерым бер формасы. Әйтелгән өлкәләрдә эшләүче ата-аналар үзләре дә шундый ук белгечләр булырга мөмкин. Мастер-класс әзер-

ләүдә гамәли һәм күрсәтмә алымнарга зур әһәмият бирелә. Мастер-класс балалар бакчасы хезмәткәрләре, ата-аналар, чакырылган белгечләр (рәссам, режиссер, эколог һ.б.) тарафыннан оештырылырга мөмкин.

**Тренинг** (Б.Д. Карвасарский билгеләмәсе буенча) — үз-үзеңне танып белү һәм үз-үзеңне көйләү-тәртипкә китерү күнекмәләрен, уку-укытуны һәм кешеләр арасындагы бағланышларны, аралашу һәм һөнәри сәләтләрне үстерүгә юнәлтелгән психотерапия, психокоррекция һәм укыту-өйрәтү алымнары җыелмасы. Тренинг процессында ата-аналар актив рәвештә педагог-психолог тарафыннан махсус эшләнгән, үзләренең шәхес ресурсларын аңларга мөмкинлек бирүче ситуацияләргә җәлеп ителәләр. Тренингны балалар бакчасы психологы да, чакырылган белгеч тә уздырырга мөмкин.

## Педагоглар, ата-аналар, балаларның уртак эшчәнлеге

«Педагоглар—ата-аналар—балалар» триадасындагы күптөрле уртак эшчәнлекнең төп максаты — баланың асыл (базис) омтылышларын һәм ихтыяҗларын гына түгел, ата-аналарның һәм педагогларның да омтылышларын һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

Тәрбияләүче өлкәннәрнең уртак эшчәнлеге күптөрле традицион һәм инновацион формаларда оештырылырга мөмкин (акцияләр, ассамблеялар, музыка һәм шигърият кичәләре, гаилә белән мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре тарафыннан, балалар бакчасы соравы буенча гаилә абонементы программалары нигезендә оештырылган тамашаларына бару; гаилә кунак бүлмәләре, фестивальләре, гаилә клублары, сорау һәм җавап кичәләре, салоннар, студияләр, бәйрәмнәр (шул исәптән гаилә бәйрәмнәре), һавада йөрүләр, экскурсияләр, проектлау эшчәнлеге, гаилә театры).

Уртак эшчәнлекнең әлеге формалары бала белән авторитар стильдә аралашуны өстен күрүче ата-аналарның һәм педагогларның үз-үзләрен тотышларына төзәтмәләр кертү; аларда балалар иҗатына карата кайгыртучан мөнәсәбәт тәрбияләү мөмкинлекләрен дә күздә тота.

**Гаилә сәнгать студияләре** — тәрбияләнүчеләрнең гаиләләрен педагог (рәссам, хореограф, актер) булышлыгында иҗат белән шөгыльләнү өчен берләштерүче үзенә бер үзенчәлекле сәнгать остаханәләре. Студиядә педагогның, балаларның һәм ата-аналарның үзара иҗади бәйләнешләре төрлечә: махсус оештырылган уртак дәресләр; ата-аналар өчен рәсем, нәкыш сәнгате, кул эшләре буенча мастер-класслар (ата-аналар сайлавы буенча); сәнгать белгечләре, рәссамнар, гамәли бизәлеш сәнгате осталары белән очрашулар; музейларга, сәнгать күргәзмәләренә бару формасында булырга мөмкин.

**Гаилә бәйрәмнәре.** Илебез тормышындагы истәлекле вакыйгаларга багышланган балалар бәйрәмнәре балалар бакчасы өчен традицион бәйрәмнәр булып торалар. Балалар бакчасындагы гаилә бәйрәме балаларның һәм тәрбияләүче өлкәннәрнең уртак иҗатын актуальләштерүче яңа форма тәшкил итә.

Балалар бакчасындагы гаилә бәйрәме — педагогларны һәм тәрбияләнүчеләрнең гаиләләрен берәр вакыйга уңаеннан берләштерүче үзенә бер төрле көн. Әниләр көне, Әтиләр көне, Яңа ел, Җиңү көне, Халыкара гаилә көне (15 май), Бөтенроссия гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне (8 июль) шундый үзгә көн итеп уздырылырга мөмкин.

Кече яшьтәге балалары булган гаиләләр өчен гаилә бәйрәмнәре аеруча мөһим, чөнки 3 яшькә кадәрге сабыйлар бәйрәмнәрендә яннарында әти-әниләре булганда үзләрен яхшырак хис итәләр.

**Гаилә театры.** Мәктәпкәчә иҗтимагый тәрбиянең бөтен тарихы буена театр эшчәнлеге гаилә тәҗрибәсен исәпкә алмыйча үстерелде. Гаилә белән партнерлык мөнәсәбәтләрен үстерү балаларның һәм өлкәннәрнең гаилә театры рәвешендәге театральләштерелгән эшчәнлеге үсеше өчен яңа мөмкинлекләр ача. Берничә гаиләнең һәм педагогларның (тәрбиячеләрнең, музыка җитәкчесенең һәм балалар бакчасының театр студиясе җитәкчесенең) иҗади берләшмәсе буларак, балалар бакчасында гаилә театры педагоглар катнашында гына түгел, мәдәният хезмәткәрләре (режиссер һәм театр актерлары) булышлыгы белән дә оештырылырга мөмкин.

**Гаилә абонементы.** Балалар бакчасы һәм аның якшәмбе (шимбә) гаилә абонементының алдан төзелгән программалары буенча сәнгать белән очрашу оештыручы партнерлары — сәнгать һәм мәдәният учреждениеләре гаилә өчен югары сәнгать белән очрашуның гаҗәеп мөмкинлекләрен тудыра ала. Программалар комплексы һәм сәнгатьнең теге яки бу төренә багышланган аерым эчтәлекле булырга мөмкин. Мәсәлән, «Саумы, музыка!», «Театр исемле могҗиза», «Рәссамда кунакта», «Музей һәм гаилә», «Китапханәдә гаилә очрашулары» һ.б.

**Гаилә ассамблеясы.** Гаилә ассамблеясы — үзара танышу, балаларны һәм өлкәннәрне җәлеп итәрлек күптөрле (нәфис-продуктив, аралашу, проектлау-тикшеренү һ.б.) уртак эшчәнлеккә тарту максатында тәрбияләнүчеләр гаиләләрен һәм мәгариф, мәдәният, сәнгать учреждениеләре педагогларын берләштерүче ял формасы.

Гаилә ассамблеясын аерым бер балалар бакчасы да, берничә оешма (мәгариф комитеты, газета редакциясе, югары уку йорты, музей, балалар музыка мәктәбе һ.б.) бергә дә оештырырга мөмкин. Ассамблеяларны елның теләсә кайсы вакытында уздырыга мөмкин, җәен ачык һавада уздыру урынлырак.

**Проектлау эшчәнлеге.** Уртак эшчәнлекнең проектлар кебек формасы торган саен актуальрәк була бара. Проектлар балалар бакчасы белән идарә итүдә, партнерлык мөнәсәбәтләре үсешендә тәрбияләүче өлкәннәрнең ролен үзгәртә, аларга «команда»да эшләргә өйрәнергә, коллектив фикерләү эшчәнлеге ысулларына ия булырга; бала ихтыяҗларыннан чыгып, проект төзү алгоритмын үзләштерергә; хезмәттәшләргә, тәрбияләнүчеләргә һәм ата-аналарга, үз шәхесләренә карата позитив ачык булуга ирешергә; проектны гамәлгә ашыру максатында педагогларның, ата-аналарның һәм балаларның тырышлыкларын берләштерергә ярдәм итә.

Педагоглар, балалар һәм ата-аналар мөнәсәбәтләрен яхшыртуга, җаваплылыкны, инициативалылыкны үстерүгә юнәлтелгән теләсә нинди тәкъдим (мәсәлән, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гаилә белән җәйге ялын оештыру, балалар бакчасында Гаилә көнен уздыру, тәрбияләүче өлкәннәрнең челтәрле интернет-бергәлеген булдыру һ.б.) проектлау өчен идеяләргә әверелергә мөмкин.

**Гаилә календаре.** Гаилә календаре проектлар өчен кызыклы идеяләр бирә. Гаилә календаре ата-аналарга үз эшчәнлекләрен планлаштырырга да, бала белән бергәләп эш итү һәм аралашу өчен вакыт табарга да булыша ала.

Гаилә календаре үзара бәйләнгән, бер-берсенә үтеп керүче ике өлештән торырга мөмкин: беренчесе — ярдәмче, инвариантлы, балалар бакчасы тарафыннан тәрбияләнүчеләрнең барлык гаиләләренә тәкъдим ителә; икенчесе — вариатив, һәр гаилә тарафыннан үз ихтыяҗлары һәм традицияләре эзлеклелегендә, кысаларында проектлана.

Календарьның ярдәмче инвариантлы, педагоглар тарафыннан балалар бакчасындагы тәрбия-белем бирү эшчәнлеге исәпкә алынып эшләнә торган өлеше түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга мөмкин: шулай ук сезонлы халык бәйрәмнәре турында һәм, балаларның яшен исәпкә алып, аларны гаиләдә үткәрү турындагы тәкъдимнәр; бөтендөнья, бөтенроссия дәүләт, өлкә (республика), шәһәр, район бәйрәмнәре турында һәм, балаларның яшен исәпкә алып, аларны гаиләдә үткәрү турындагы тәкъдимнәр; гаиләдә билгеләп үтелүче һөнәри бәйрәмнәр турында, һәм балалар белән һөнәрләр турында әңгәмәләр оештыру буенча тәкъдимнәр; тәрбияләнүчеләр гаиләләре өчен балалар бакчасында уздырылучы чаралар (консультацияләр, клуб утырышлары һ.б.) турында; театрлар репертуары турында һәм гаиләдә «театр көне» үткәрү турындагы тәкъдимнәр; музейлар һәм оештырылучы күргәзмәләр турында, гаиләдә «музей көне» үткәрү турындагы тәкъдимнәр; концертлар турында һәм балалар белән аларны карау турындагы тәкъдимнамәләр; тәрбия турындагы афоризмнар; гаиләдә күптөрле эшчәнлек — гаиләдә бергәләп китап уку, гаилә белән табигатьтә йөрүләр, музейга, күргәзмәләргә, истәлекле урыннарга (районның, шәһәрнең, авылның тарихына һәм мәдәниятенә тартылу) экскурсияләр, нәфис эшчәнлек оештыру буенча тәкъдимнәр һ.б.

Икенче, гаилә тарафыннан планлаштыручы вариатив өлешкә түбәндәге: гаилә бәйрәмнәре — гаилә әгъзаларының, туганнарның, гаилә дусларының (шул исәптән баланың дусларының) туган көннәре, шулай ук гаиләдәге хәтер көннәре турындагы; гаилә белән һавада йөрүләр, төрле җирләргә барулар һ.б. турындагы; гаиләнең ялы (ата-аналарның чираттагы ялы) турындагы; баланың казанышлары турындагы мәгълүматлар керергә мөмкин.

Гаилә календарен төзегәндә, педагоглар һәм ата-аналар үзләренең нәфис-бизәү сәләтләрен чагылдыра алалар.

Гаилә календаре ата-аналарда һәм әби-бабайларда гаиләдә һәм балалар бакчасында эшләнәчәк уртак эшләр идеяләрен тудыра.

## Бала белән өйдәге дәресләр өчен ярдәмлекләр

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасының мөһим өстенлеге аның бала белән өйдәге дәресләр өчен ярдәмлекләр — «Җиде Гном мәктәбе» сериясе китаплары белән тәэмин ителешеннән гыйбарәт. Серия бала белән туганнан алып мәктәпкәчә шөгыльләнүнең комплексы системасын үз эченә ала. Һәр яшь аралыгы өчен бала үсешенең барлык белем бирү-өйрәтү өлкәләрен һәм юнәлешләрен колачлаган 12 ярдәмлек нәшер ителде.

Мәктәпкәчә учреждениеләр педагоглары, ата-аналарга «Җиде Гном мәктәбе» сериясеннән тиешле ярдәмлекләр тәкъдим итеп, Оешма кысаларында башкарылучы белем бирү эшчәнлегенә өй дәресләре белән булыша алалар. Тәрбиячеләр ата-аналар өчен мәгълүмат тактасында агымдагы атнада өйдәге дәресләр өчен ярдәмлекләрнең файдаланылырга тиешле бүлекләрен күрсәтергә мөмкин.

«Җиде Гном мәктәбе» ярдәмлекләре өлкән кешенең һәм баланың үзара аралашуы үсешенә булышлык итәләр, ата-аналарның үз балаларын аңлауларын стимуллаштыралар. Һәр ярдәмлек эчендәге ата-аналар бите ата-аналарның педагогик белемнәрен күтәрүгә ярдәм итә.

# КОРРЕКЦИОН
# ҺӘМ ИНКЛЮЗИВ ПЕДАГОГИКА

## ИНКЛЮЗИВ ПРАКТИКА (КАТНАШ ЮНӘЛЕШТӘГЕ ТӨРКЕМНӘРДӘ)

Коррекцион һәм инклюзив педагогикага багышланган бүлектә түбәндәге атамалар һәм төшенчәләр кулланыла.

**Инклюзив белем бирү** — махсус белем бирү ихтыяҗларының һәм индивидуаль мөмкинлекләрнең төрлелеген исәпкә алып, барлык балаларның белем алуы өчен тигез мөмкинлекләр тәэмин итү.

**Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (СМЧ) укучы** — физик һәм (яки) психологик үсешендә психологик-медицина-педагогик комиссия тарафыннан расланган һәм махсус шартлар тудырылмыйча белем алуга тоткарлык тудыручы тайпылышлары булган физик зат.

**Җайлаштырылган (адаптацияләштерелгән) белем бирү программасы** — сәламәтлек мөмкинлекләре чикле затларны психофизик үсеш үзенчәлекләрен, индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып укыту өчен җайлаштырылган һәм кирәк очракта күрсәтелгән затларның үсеш тайпылышларын коррекцияләүне һәм социаль адаптацияләүне тәэмин итүче белем бирү программасы.

СМЧ затлар төркеменә: саңгыраулар, начар ишетүчеләр, башта ишетеп, соңрак ишетми башлаганнар, сукырлар, начар күрүчеләр, сөйләме нык бозылганнар, терәк-хәрәкәт аппараты (ТХА) тайпылышы булганнар, психик үсеш тоткарлыгы булганнар, интеллектуаль үсеш тоткарлыгы булганнар, аутистик спектры бозылганнар (АСБ), катлаулы дефектлары булганнар һ.б. керә.

Катнаш юнәлештәге төркемнәрдә сәламәт балаларга һәм СМЧ балаларга белем бирү мәктәпкәчә оешманың белем бирү программасы буенча, тәрбияләнүчеләрнең психофизик үсеш үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып, берләштереп алып барыла.

Катнаш юнәлештәге төркемнәр белән МББ ТББПн гамәлгә ашыруның төп шарты булып кадрлар белән тәэмин итү шартларын саклау — штат расписаниесендә укытучы-логопед, укытучы-дефектолог, сурдопедагог, тифлопедагог, олигофренопедагог, педагог-психолог булу тора.

# Белем бирү процессын оештыру үзенчәлекләре

## Күрү сәләте бозылган балаларны укыту һәм тәрбияләү шартлары

Күрү сәләте бозылган балаларны түбәндәге категорияләргә аералар:

• сукыр / күрмәүче балалар (иң яхшы күрә торган күзнең үткенлеге 0,01 дән 0,04 кә кадәр);

• начар күрүче балалар (күрүе яхшы күзнең үткенлеге коррекция вакытында 0,05 тән 0,2 гә кадәр);

• күзендә кылыйлык һәм амблиопия булган балалар (күз үткенлеге 0,3 тән кимрәк).

Күрү сәләте бозылу тирәлектә ориентлашуны кыенлаштыра, хәрәкәт күнекмәләрен, координацияне формалаштыруны тоткарлый; хәрәкәт һәм танып белү активлыгы кимүгә китерә. Кайбер балаларда физик үсешнең шактый артта калуы күзәтелә.

Күрү сәләте бозылганда, күреп аңга кабул итү нормаль күрүче кешеләрнең аңга кабул итүеннән чагылышның тулылык, төгәллек һәм тизлек дәрәҗәсе буенча кискен аерыла. Күрүенә зыян килгән балалар еш кына объектларның төп билгеләрен түгел, ә икенчел билгеләрен күрергә мөмкиннәр, шуңа бәйле рәвештә объект образы бозыла һәм хәтердә шундый булып сакланып кала. Начар күрүче балаларда булган күрү сәләте белән алган мәгълүмат, сиземләү һәм тою мәгълүматы белән комплекста кабул ителсә, тулылана төшә. Күрү сәләте бозылган балаларның сөйләмен формалаштыру өчен әйләнә-тирәдәге кешеләр белән актив бәйләнеш булдыру һәм төрле анализаторларны (ишетү, күрү, кинестетик) стимуллаштыру исәбенә предметлы гамәли тәҗрибә булдыру сорала.

Күрү сәләтләре нык зыян күргән балаларның әңгәмәдәшенең артикуляциясен тулы күләмдә кабул итү мөмкинлеге юк, шуңа күрә алар еш кына сүзнең аваз анализында һәм аның әйтелешендә хаталар җибәрәләр. Сүзнең авазлар составына ия булу һәм авазларның тәртибен билгеләү белән бәйле кыенлыклар язма сөйләмдә дә чагыла. Моннан тыш сүзнең һәм предметның тәңгәллеге шактый еш бозыла, сүзлек составының ярлылыгы һәм сүзләрнең мәгънәсен аңлауда артта калу күзәтелә. Күрү сәләте бозылган балалар аралашуның телгә бәйле булмаган чараларын, мимика, ымнар, интонацияне үзләштерү һәм куллану үзенчәлекләренә ия. Сукыр һәм начар күрүче балалар өчен ишетү хәтере аеруча әһәмияткә ия, чөнки аларга мәгълүматның зур күләмен хәтердә сакларга туры килә.

Күрү сәләте бозылган балалар юлларны күрмиләр, охшаш предметларны һәм хәрефләрне бутыйлар, тактага, таблицага язылганны күрмиләр, болар талчыгу һәм эшчәнлекнең кимүен китереп чыгара.

Күрүенә зыян килгән балаларга Оешманың бүлмәләренә күчеп йөргәндә, тирәлектә ориентлашуда булышырга кирәк. Бала Оешманың төп ориентирларын, дәрес уздырыла торган төркем бүлмәләрен, үз урынына юлны белергә тиеш. Начар күрүче бала тактаны һәм педагогны максималь күрә алсын өчен, оптималь яктыртылган эш урыны (өстәмә гомуми яктылык (1000 люкстан ким түгел) яки яктылык 400–500 люкстан ким булмаган эш урыны җайлау мөһим. Эшләгәндә тоюга һәм ишетүгә таяна торган бик начар күрүче балалар өчен төркемнең барлык зоналарында да тавышның яхшы ишетелүе кирәк. Күрү сәләте бозылган балаларга педагог рөхсәте белән күрсәтмә материалны янына килеп карау мөмкинлеге бирелергә тиеш. Махсус оештырылган дәресләрдә һәм режим моментларында аудиоязмалар кулланырга тәкъдим ителә. Күрү йөкләнеше күләмен төгәл билгеләргә кирәк: ул 10–20 минут өзлексез эштән артмаска тиеш.

Дәресләрдә күрү образларының ярлылыгын һәм схемалылыгын тулыландыру өчен бирелгән аңлатмаларның санына игътибар итү сорала. Ымнар һәм мимикага өстәп, фикерләрнең, тасвирламаларның, инструкцияләрнең төгәллегенә аеруча игътибар бирергә кирәк.

Балалар капшау яисә капшау һәм ишетү аша өйрәнергә мөмкиннәр, аларның предметларны тотып карау мөмкинлеге булырга тиеш. Дәреснең мөһим фрагментларын диктофонга язып алырга була.

Күрсәтмә һәм тарату материалы зур, төсе, контуры, силуэты буенча яхшы күренә торган булырга тиеш. Күрсәтмә материалларны бер сызык, тап булып җыелып тормаслык итеп урнаштырырга кирәк.

Кайбер балаларга зурайта торган ярдәмче чаралар: бөтен китап битен яки укыганда уңайлылык тудыручы сызыкны зурайта торган җайланмалар кирәк булырга мөмкин. Offise Web Apps (Майкрософт) кушымталарын куллану күрү сәләтләре бозылган балаларны укыту һәм тәрбияләү мөмкинлекләрен киңәйтә.

## Ишетү сәләте бозылган балаларны укыту һәм тәрбияләү шартлары

Ишетү сәләте төзәтеп булмаслык бозылган балаларның ике төп категориясен аерып карыйлар:

- саңгыраулар;
- начар ишетүчеләр (колакка катылар).

Саңгырау балалар колак янындагы артык каты тавышка илтифат итәргә мөмкиннәр, ләкин бу очракта алар махсус өйрәтүсез сүзләр һәм гыйбарәләрне аңламыйлар. Саңгырау балалар өчен колак аппаратын яисә кохлеар имплант куллану мәҗбүри. Әмма хәтта әлеге җайланмаларны кулланган очракта да ишетмәүче балалар әйләнә-тирәдәгеләрнең сөйләмен кабул итү һәм аңлауда кыенлыклар кичерәләр.Телдән сөйләү балаларда мөстәкыйль үсми, бу сөйләмнең лексик, грамматик һәм синтаксик якларын, аңга ишетү аша ка-

бул итүне һәм сөйләмне ишетүне үстерү, әйтелешне формалаштыру буенча системалы коррекцион-үсешкә китерүче эш кирәклеген аңлата. Сүзле сөйләм формалаштыру белән бергә танып белү эшчәнлеген үстерү һәм бала шәхесен һәр яктан үстерү процессы бара.

Колакка каты балаларда ишетү сәләте бозылу төрле дәрәҗәдә була (җиңелчә, уртача, каты, бик каты) — шыпырт сөйләмне кабул итүдә аз гына кыенлыклардан алып гадәти тавышлы сөйләмне кабул итә алу мөмкинлегеннән кискен мәхрүм булуга кадәр. Колак аппаратлары кирәклеге һәм куллану тәртибе, аеруча дәресләрдә, белгеч (табиб-сурдолог һәм сурдопедагог) тарафыннан билгеләнә. Начар ишетүче балалар саңгыраулар белән чагыштырганда мөстәкыйль рәвештә, минималь күләмдә булса да, сүзлек запасы тупларга һәм сөйләм телдән үзләштерергә мөмкиннәр. Шулай да мондый балалар сөйләменең тулы үсеше өчен сурдопедагог катнашында коррекцион-камилләштерүче махсус дәресләр таләп ителә, алар сөйләмне ишетүне үстерүнең алда санап үтелгән юнәлешләрен үз эченә ала.

Ишетү сәләте бозылган балаларның психик һәм сөйләм үсеше дәрәҗәсе ишетү сәләте киму дәрәҗәсенә һәм аның бозылу вакытына, медицина коррекциясенең адекват булуына, квалификацияле һәм системалы психологик-педагогик ярдәмнең үз вакытында күрсәтелү-күрсәтелмәвенә, баланың үзенчәлекләренә һәм аның гаиләдәге тәрбиясенә бәйле. Мондый балаларның Оешмага йөрүе махсус шартлар булдыруны таләп итә, кабул ителгәндә балаларның әзерлеге төрле дәрәҗәдә булу исәпкә алынырга тиеш.

Ишетү сәләте бозылган балаларның аерым булу ихтыяҗларын исәпкә алып, педагог мәҗбүри кагыйдәләрне үтәүгә әзер булырга тиеш:

• сурдопедагог һәм баланың ата-аналары белән хезмәттәшлек итәргә;

• саңгырау / колакка каты баланың яшьтәшләре белән үзара тулы аралашуын стимуллаштырырга һәм аның балалар коллективына тизрәк һәм мөмкин булганча нык җайлашуына булышлык итәргә;

• кирәкле методик таләпләрне үтәргә (ишетү сәләте бозылган балага карата дөрес урнашу; өлкән кешенең сөйләменә таләпләр; барлык дәресләрдә һәм режим моментларында күрсәтмә һәм дидактик материаллар булу, баланың куйган бурычларны һәм инструкцияләрне аңлавын аларны үтәгәнче тикшерү һ.б.);

• ишетү сәләте бозылган баланың эш урынын оештыру (төзек колак аппаратлары/ кохлеар имплант булуын тикшерү; индивидуаль дидактик кулланмалар әзерләп кую һ.б.);

• махсус ысуллар, алымнар һәм чаралар кулланып, баланың мөмкинлекләрен исәпкә алып һәм артык опекага юл куймыйча, шул ук вакытта дәреснең темпын да тоткарламыйча, саңгырау / каты колаклы баланы дәрескә тарту;

• дәрес барышында коррекцион юнәлештәге берничә бурычны хәл итү (ишетү-күрү игътибарын стимуллаштыру; сөйләм хаталарын төзәтү һәм грамматик яктан дөрес сөйләм күнекмәләрен ныгыту; сүзлек составын киңәйтү; эчтәлекне сөйләүгә әзерләнгәндә махсус ярдәм күрсәтү һ.б.).

## Терәк-хәрәкәт аппараты тайпылышлары булган балаларны укыту һәм тәрбияләү шартлары

ТХА төзек булмаган балалар — төп сыйфатламаларын хәрәкәт функцияләренең формалашуы, үсеше артка калу, тайпылышы яисә югалуы тәшкил иткән бертөрле булмаган төркем. Хәрәкәт тайпылышларына хәрәкәт мөмкинлеге булмауга яки хәрәкәтләрне гамәлгә ашыруның өлешчә зарарлануына китерүче координация, хәрәкәт темпы бозылу, аларның күләме һәм көче чикләнү хас.

ТХА тайпылышлары булган баларның күпчелеге — балалар церебраль параличы (БЦП) белән авыручылар. БЦП вакытында балада күрү, ишетү, психик функцияләр формалашу һәм үсү үзенчәлекләре бозылу, сөйләм телендәге тоткарлыклар (дизартрия, алалия) килеп чыгарга мөмкин.

БЦП белән авыручы балаларда тирәлектә ориентлашу бозылган була. Бу предметларның һәм үз гәүдәсе өлешләренең урынын аңлатучы төшенчәләрне бик акрын үзләштерүдә, геометрик фигураларны тану һәм аларның рәсемен ясауга, өлешләрдән бөтенне җыюга сәләтсез булуда күренә.

БЦП белән авыручы балаларда еш кына игътибар иреклелеге, аны туплый һәм юнәлешен үзгәртә белү зыян күрә. Бала күрсәтелгән объектка яки хәрәкәткә карата игътибарын кыенлык белән һәм кыска вакытка гына туплый, игътибары еш бүленә. Хәтер бер анализатор системасында (күрү, ишетү, хәрәкәт-кинестетик) бозылган булырга мөмкин. Фикерләү процесслары инертлык, гомумиләштерү операцияләрен формалаштыруның түбән дәрәҗәсе белән сыйфатлана.

Эмоциональ-ихтыяри өлкәдәге тайпылышлар кайбер балаларда чиктән тыш кабынып китү, ярсучанлык, башкаларында, киресенчә, акрынлык, сүлпәнлек рәвешендә чагылырга мөмкин.

ТХА тайпылышы булган балаларга белем бирүдә махсус ихтыяҗларны исәпкә алып, түбәндәге шартларны үтәргә кирәк:

• каршылыксыз архитектура-планлаштыру тирәлеген булдыру;

• ортопедик режимны үтәү;

• хәрәкәт патологиясе булган балалар белән эшләүче педагогларның профессиональ әзерлеген тәэмин итү һәм /яки квалификациясен күтәрү;

• дәвалаучы табибның йөкләнеш режимын билгеләү, белем бирү процессын оештыру буенча тәкъдимнәрен үтәү (көндәлек режимны, ортопедик аяк киеме киеп йөрү режимын, дәресләрдә эшчәнлек төрләрен алыштыруны, физкультура тәнәфесләрен уздыруны һ.б. оештыру);

• бозылган психик функцияләрне коррекцияләү буенча коррекцион-үсешкә китерүче дәресләр оештыру;

• хәрәкәт тайпылышлары булган балаларда үз-үзләренә хезмәт күрсәтү һәм гигиена күнекмәләре формалаштыру буенча эш алып бару;

• сөйләм тайпылышларын коррекцияләү буенча логопед ярдәме күрсәтү;

• балаларның ихтыяҗларына туры килгән җиһазлар сайлау;

• балага Оешмада үзе булдыра алган алым белән һәм үзенә җайлы темпта хәрәкәтләнү мөмкинлеге тудыру;

• СМЧ балаларның ата-аналары белән максатчан эш алып бару, аларны коррекцион-үсешкә китерүче мөмкин булган эш алымнарына өйрәтү;

• СМЧ балаларга карата нормаль үсештәге балаларда һәм аларның ата-аналарында толерантлык формалаштыру;

• балалар Оешма буйлап хәрәкәтләнгәндә, ашаганда, бәдрәфтән файдаланганда, физик ярдәм күрсәтүче персоналны эшкә тарту;

• СМЧ балаларны уртак ял һәм массакүләм-спорт чараларына катнашырга җәлеп итү.

Хәрәкәт тайпылышлары булган баланы Оешманың белем бирү процессына тартканда аның системалы, адекват, өзлексез психологик-медицина-педагогик күзәтүендә булуын оештыру мәҗбүри шарт булып тора.

## Аутистик спектры бозылган балаларны укыту һәм тәрбияләү шартлары

Хәзерге вакытта аутистик спектр тайпылышлары психик үсешнең махсус тибы буларак карала. АСБ балаларда коммуникация чаралары һәм социаль күнекмәләр үсеше тайпылышы күзәтелә. Алар өчен әйләнә-тирә дөньяда даимилекне саклау ихтыяҗын һәм үз-үзеңне тотуның үзгәрмәүчәнлеген билгеләүче эмоциональ-ихтыяри өлкә проблемалары һәм аралашудагы кыенлыклар уртак.

АСБ балаларның когнитив мөмкинлекләре чикле, һәм барыннан да элек бу бер гамәлдән икенчесенә күчүдәге нерв процессларының хәрәкәт, сөйләм, интеллектуаль өлкәләрдә чагыла торган инертлыгына бәйле кыенлыклар. Фикерләү өлкәсендәге инертлыктан арындыру аеруча авыр, моны АСБ балалар белән белем бирү эшчәнлеген оештырган вакытта исәпкә алырга кирәк.

АСБ балалар өчен педагог һәм тьютор белән контактларның дәвамчанлыгы һәм даимилеге мөһим. Аңга кабул итү үзенчәлекләре нәтиҗәсендә нормаль үсеш кичерүче яшьтәшләре мохитендә шөгыльләнү аутик бала өчен гади һәм җиңел процесс түгел. Еш кына сөйләм үсеше тоткарлану, түбән социаль мотивация, шулай ук аерым ярсыткычларга гипер- яки гипотәэсирчәнлек күзәтелгән аутик балага өлкәннәр ярдәменнән башка яшьтәшләре белән элемтә урнаштыру авыр, шуңа күрә аның тьютор карамагында булуы социализацияләү процессында уңышка китерүче төп компонент (бәлки, иң кирәклесе дә) булып китәргә мөмкин.

Аутистик спектрында тайпылыш булган балаларның махсус белем бирү ихтыяҗларына (О.С.Никольская буенча) түбәндәге ихтыяҗлар карый:

• укытуга индивидуальләштерелгән әзерлек чорына;

• балалар төркемендә укыту халәтенә индивидуаль рәвештә, акрынлап кертүгә;

• төркемнең гомуми темпын индивидуаль темп белән яраштыруга, педагогның балага килеп туган хәлләрне аңлап җиткерүдә ярдәм итәргә мөмкинлек бирүче эмоциональ элемтә булдыру һәм үстерү буенча махсус эшенә;

• балага сиземләү һәм эмоциональ яктан уңайлыкны тәэмин итүче укыту шартлары булдыруга;

• бала тормышына яңалыкны һәм катлаулылыкларны өлешләп кертүгә;

• яңа мәгълүматны, баланың темпын һәм эшкә сәләтен исәпкә алып, өлешләп бирүгә;

• символлар һәм пиктограммалар (бала күрә алырлык) рәвешендә күрсәтелгән көндәлек режимны төгәл үтәүгә һәм билгеле бер тәртиптәге предметлы белем бирү тирәлегенә;

• махсус рәвештә баланың үз-үзен дөрес тоту, аралашу күнекмәләре һәм өлкәннәр белән үзара бәйләнеше формаларын махсус булдыруга;

• тәртибендә тайпылышлар булганда тьютор ярдәменә;

• җайлаштырылган белем бирү программасы булдыруга;

• үзләштерелә торган биремнәр һәм күнекмәләрне төшенүдә даими ярдәмгә;

• психолог белән, ә кирәк булганда дефектолог һәм логопед белән индивидуаль һәм төркемле дәресләр үткәрүгә;

• әйләнә-тирә дөнья турында күзаллаулар формалаштыруга, коммуникация чараларын һәм социаль-көнкүреш күнекмәләрен ныгытуга булышлык итүче дәресләр оештыруга;

• баланың педагоглар һәм башка балалар белән үзара бәйләнешләрен көйләүче психологик ярдәмгә;

• гаиләнең һәм белем бирү оешмасының үзара бәйләнешен нормаль үсештәге балаларның ата-аналары белән дә җайлаучы психологик ярдәмгә;

• баланың белем бирү оешмасыннан читтә белем алу даирәсен индивидуаль рәвештә өлешләп һәм даими киңәйтүгә.

## Белем бирү процессын оештыру принциплары

Инклюзив практиканы гамәлгә ашыручы Оешмада белем бирү процессын оештыру педагогларны тәрбияләнүчеләрнең социаль, сәламәтлек саклау, коммуникатив, эшлекле, мәгълүмати компетенцияләрне үзләштерүенә юнәлтүче системалы, компетентлы һәм дифференциацияле якын килү интеграциясе нигезендә проектлаштырылган структуралы функциональ модель төзү кирәклеген таләп итә.

Инклюзив практиканы оештыру түбәндәге принципларда корыла:

• индивидуаль якын килү принцибы тәрбияләнүчеләрне һәрьяклы өйрәнүне һәм ачыкланган үзенчәлекләрне исәпкә алып, тиешле педагогик йогынты ясау чараларын эшләүне күздә тота (укыту һәм тәрбия формаларын, алымнарын һәм чараларын һәрбер баланың индивидуаль белем бирү ихтыяҗларын исәпкә алып сайлау);

• баланың мөстәкыйль активлыгына ярдәм итү принцибы (индивидуальләштерү). Баланың мөстәкыйль активлыгы өчен шартларны тәэмин итү инклюзив белем бирүнең уңышлылыгында мөһим урын тота. Әлеге принципны гамәлгә ашыру социаль хезмәтләрне пассив кулланучыны түгел, үз үсешенең субъекты булган, социаль яктан актив шәхес формалаштыру бурычын хәл итә;

• социаль үзара бәйләнеш принцибы гуманистик нигездә тулы үзара бәйләнешкә ирешү максаты белән белем бирү процессында катнашучыларның барысының бер-берсен аңлавы һәм кабул итүе өчен шартлар тудыруны күздә тота. Инклюзия — балалар, ата-аналар һәм белгечләрне реаль социум моделе буларак инклюзив бергәлек төзү өчен уртак уку-укыту эшчәнлегенә дә, социаль эшчәнлеккә дә актив тарту;

• дисциплинаара якын килү принцибы. Балаларның индивидуаль характеристикаларының төрлелеге тәрбия һәм укыту алымнары һәм чараларын эшләүгә комплекслы, дисциплинаара якын килүне таләп итә. Төркемдә эшләүче белгечләр (тәрбияче, логопед, социаль педагог, психолог, өлкән тәрбияче катнашында дефектолог) даими рәвештә балаларга диагностика үткәрәләр һәм фикер алышу процессында белем бирүне гамәлгә ашыруның аерым балага да, бөтен төркемгә дә юнәлтелгән планын төзиләр;

• укыту һәм тәрбия процессларын оештыруда вариативлык принцибы. Инклюзив төркемгә үсешләрендә төрле үзенчәлекләр булган балаларны кертү вариатив үсешкә китерүче тирәлек булуны, ягъни кирәкле үсешкә китерүче һәм дидактик кулланмаларны, укыту чараларын, каршылыксыз тирәлекне, укытуның һәм тәрбиянең вариатив методик базасын һәм педагогның гомуми һәм махсус педагогика буенча төрле эш алымнары һәм чараларын куллана белү сәләтен күздә тота;

• гаилә белән үзара тигез эшчәнлек принцибы. Педагогларның тырышлыгы ата-аналар тарафыннан ярдәм булган, аларга аңлаешлы һәм гаилә ихтыяҗларына туры килгән очракта гына нәтиҗәле була. Белгечнең бурычы — баланың ата-анасы яисә якыннары белән ышанычка корылган дусларча мөнәсәбәтләр булдыру, ата-аналарның таләпләренә игътибарлы булу, алар карашынча шул моментта бала өчен нәрсә мөһим һәм кирәкле булса, балага ярдәм итү өчен уртак гамәлләр турында килешү;

• балалар бакчасының белем бирү моделен динамик үстерү принцибы. Балалар бакчасы моделе яңа структур бүлекчәләр, белгечләр, үсешкә китерүче алымнар һәм чаралар хисабына үзгәрергә дә мөмкин.

Инклюзив практика оештыру процессында белем бирү учреждениесенең төп максаты — нормаль үсештәге балалар һәм СМЧ балаларны, ягъни белем бирү ихтыяҗлары төрле балаларны, бергә тәрбияләү һәм белем бирү өчен шартларны тәэмин итү.

## СМЧ балаларны ачыклау алгоритмы

СМЧ балаларны ачыклау һәм алар өчен махсус белем бирү шартлары тудыруның түбәндәге алгоритмы күздә тотыла.

1. Яңа уку елы башында белем бирү оешмасында педагоглар, шул исәптән педагог-психолог, укытучы-логопед, тәрбиячеләр, ягъни оешманың психологик-медицина-педагогик консилиумы (ПМПк) белгечләре, яисә психологик-педагогик медицина-социаль үзәге (ППМСҮ) белгечләре (белем бирү оешмасы һәм ППМСҮ арасында килешү буенча) СМЧ балаларны ачыклыйлар.

2. Шуннан соң консилиум утырышы уздырыла һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Психологик-медицина-педагогик комиссия хакында нигезләмәне раслау турында» 95 нче номерлы 2009 ел 24 март приказы нигезендә комплекслы тикшерү уздыру һәм балаларга психологик-медицина-педагогик ярдәм күрсәтү һәм аларны укытуны һәм тәрбияләүне оештыру буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында закон» Федераль законының 79 нчы маддәсе нигезендә белем алу өчен махсус шартлар билгеләү максатларыннан территориаль психологик-медицина-педагогик комиссиясе (ПМПК) узу зарурлыгы турында карар кабул ителә.

3. ПМПК тикшерүе нәтиҗәләре буенча бала өчен махсус белем бирү шартларын тудыру буенча тәкъдимнәр бирелә (273 нче номерлы Федераль закон, 79 нчы маддә («Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучылар тарафыннан белем алу өчен махсус шартлар дигәндә хәзерге Федераль законда андый укучыларны укыту, тәрбияләү һәм үстерү шартлары аңлана. Ул махсус белем бирү программаларын һәм укыту һәм тәрбия алымнарын, махсус дәреслекләрне, уку ярдәмлекләрен һәм дидактик материалларны, коллектив һәм индивидуаль файдалану өчен махсус укыту-техник чараларын, ассистент (ярдәмче) хезмәтләрен күрсәтүне үз эченә ала, укучыларга тиешле техник ярдәм күрсәтү, төркемле һәм индивидуаль коррекцион дәресләр үткәрү, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма биналарына керүне тәэмин итү, һәм алардан башка СМЧ укучыларның белем бирү программаларын үзләштерү мөмкин булмаган яисә кыенлашкан башка шартларны тудыра».)

4. ПМПК тәкъдимнәре нигезендә белем бирү оешмасы ПМПк белгечләре индивидуаль белем бирү маршруты һәм /яки җайлаштырылган белем бирү программасы эшлиләр.

СМЧ балалар өчен индивидуаль белем бирү маршрутын эшләү максатларында түбәндәге бурычлар хәл ителә:

• мәктәпкәчә белем алуның формасын һәм баланың мөмкинлекләренә һәм махсус ихтыяҗларына туры килүче белем бирү оешмасында булу режимын билгеләү;

• күләм һәм эчтәлекне — баланы һәм аның гаиләсен психологик-педагогик тәэмин итүнең төп юнәлешләрен, оештыру формаларын билгеләү;

• бала белән коррекцион-үсешкә китерүче эшчәнлекнең стратегиясен һәм тактикасын (формаларын һәм эчтәлеген) билгеләү. Биредә үк баланың танып белү һәм шәхси үсеше динамикасын бәяләү критерийлары һәм формалары, аның яшьтәшләре мохитендә җайлашу дәрәҗәләре билгеләнә;

• оешманың төп белем бирү программасын җайлаштыру кирәклеген, дәрәҗәсен һәм юнәлешләрен билгеләү;

• булган яисә яңа методик материалларны җайлаштыру кирәклеген билгеләү;

• баланың теге яки бу матди-техник ресурсларга индивидуаль ихтыяҗларын билгеләү. Кирәкле җайланмаларны сайлау, үсешкә китерүче предмет-тирәлек мохитен оештыру.

5. Индивидуаль белем бирү маршрутын һәм /яки җайлаштырылган белем бирү программасын эшләгәннән соң, белем бирү оешмасы педагоглары һәм белгечләре аларны гамәлгә ашыралар һәм баланың үсешенә динамик күзәтү алып баралар. Индивидуаль белем бирү маршрутын һәм /яки җайлаштырылган белем бирү программасын ачыклау буенча консилиум утырышлары ким дә 3 айга бер тапкыр уздырылырга тиеш.

## СМЧ балалар өчен белем алу формалары

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында СМЧ балаларның режимы һәм белем алу формалары Оешманың төрле структур бүлекчәләрендә тормышка ашырыла ала.

Инклюзив белем бирү старт мөмкинлекләре төрле булган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең яңа формаларын тәкъдим итүгә нигезләнә. Нинди дә булса сәбәп белән мәктәпкәчә төркемгә тулы көн режимында йөри алмаган балалар өчен өстәмә структур бүлекчәләр оештырыла: үсешкә уен белән булышлык итү үзәге, консультация пункты, лекотека иртә срокларда, ярдәм күрсәтү хезмәте, «Үзгә бала» тулы булмаган көн төркеме. Аларның эшчәнлеге 2 айдан алып 7 яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә вариатив белем бирү хезмәтләре күрсәтүгә юнәлтелгән.

Бүлекчәләрнең һәрберсендә СМЧ балаларга белем бирү хезмәтләре индивидуаль белем бирү маршрутына туры китереп күрсәтелә. Белем бирү процессының уңышлы бару шартларының берсе булып гаиләне белем бирү даирәсенә кертү тора. Биредә ата-аналар өчен индивидуаль консультацияләр (өлкәннәрнең теләге буенча), мастер-класслар яки семинарлар кулланылырга мөмкин.

Оешманың структур бүлекчәләрендә бала мәктәпкә кадәр була ала яисә әзерлек дәрәҗәсенә карап тулы булмаган көн төркеменә, инклюзив төркемгә һ.б. күчә ала. Структур бүлекчәләрнең булуы оешмага белем бирү формаларын төрлеләндерергә, ата-аналарга теләкләренә һәм психологик-медицина-педагогик комиссия тәкъдимнәренә туры килә торган белем бирү хезмәтләрен сайларга мөмкинлек бирә.

## Җайлаштырылган белем бирү программасы

Җайлаштырылган белем бирү программасында билгеләнгән белем бирү өлкәләрендә каралганнарны тормышка ашыру расланган һәм тәкъдим ителгән коррекцион программалар, автор технологияләре һәм белгечләрнең практик тәҗрибәсен кулланып гамәлгә куела. Җайлаштырылган белем бирү программасын төзү өчен Л.Б. Баряева, О.П. Гаврилушкина, А.П. Зарин, Н.Д. Соколованың «Интеллектуаль җитешсезлеге булган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү һәм укыту программасы»н; Т.Б. Филичева, Г.В. Чиркинаның «Балаларда фонетик-фонематик артта калуны бетерү буенча логопед эше программасы»н; Т.Б. Филичева, Г.В. Чиркина, Т.В. Тумановaның «Балаларда сөйләмнең җитешсезлекләреннән арыну буенча логопед эше программасы»н; үсешендә тайпылышлар булган балаларга «Кечкенә баскычлар» башлангыч педагогик ярдәм программаларын; акылы, сөйләме, терәк-хәрәкәт аппараты һ.б. тайпылышлары булган балаларга мәктәпкәчә белем бирү программаларын кулланырга мөмкин.

## Катнаш юнәлештәге төркемнәр эшчәнлеген оештыру

Катнаш юнәлештәге төркем эшчәнлеге үзендә оештыруның ике ягын берләштерергә тиеш:

• төркем расписаниесендә СМЧ балаларның җайлаштырылган белем бирү программасында күздә тотылган һәм индивидуаль, һәм төркемле дәресләр исәпкә алынырга (уздыру урыны, вакыты, белгечләр билгеләнергә) тиеш;

• төркем расписаниесендә төп белем бирү программасы бурычларын гамәлгә ашыручы төркемле дәресләр исәпкә алынырга тиеш.

Катнаш юнәлештәге төркемдә көндәлек һәм атналык режим төрле балалар өчен сыгылмалы булырга мөмкин (кемдер бакчада тулы көн режимында булырга, кемдер 2–3 көн төшке ашка кадәр генә). Кемгәдер билгеле бер эш формалары туры килмәскә мөмкин (мәсәлән, бассейн) — андый балалар өчен аларның активлыгын оештыруның башка төрләре карала ала.

Төркемнең эшчәнлеген оештыру төркемдәге халәтнең үсеш динамикасы белән ярашлы рәвештә үзгәрергә мөмкин. Эшне планлаштырганда тыныч һәм актив дәресләр, бинада һәм һавада уздырыла торган дәресләр, индивидуаль дәресләр, кече һәм зур төркемнәрдә эш, структуралашкан һәм структуралашмаган укыту арасында балансны исәпкә алу сорала. Программаларны гамәлгә ашырганда, балаларның кечкенә төркемнәрдә һәм тулы төркемдә активлыгының төрле формаларын эшләргә, төрле дәрәҗәдәге биремнәр, балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алырга кирәк.

Инклюзив практика программаларын гамәлгә кую процессында да, режим моментлары барышында да тормышка ашырыла:

• укытучы-логопед, укытучы-дефектолог, укытучы-психолог һәм Оешманың башка белгечләре белән индивидуаль дәресләрдә;

• махсус оештырылган тирәлектәге актив гамәлләрдә (төркем бүлмәсендә, махсус җиһазландырылган бүлмәләрдә иректе уен, һавада йөрү);

• кечкенә төркемнәрдә башка балалар белән уртак эшчәнлектә һәм уеннарда;

• ашаганда;

• көндезге йокыда;

• фронталь дәресләрдә;

• балалар-ата-аналар төркемнәрендә үзара багланыш оештырганда;

• бәйрәмнәрдә, конкурсларда, экскурсияләрдә, ял көне походларында.

**Индивидуаль дәресләр** мөмкинлекләренә карап баланың сәләтләрен үстерүгә һәм аңа булышлык итүгә юнәлтелгән. Алар баланың казанышларын бәяләүгә һәм аның якын үсеше зоналарын билгеләүгә нигезләнеп корыла. Һәр дәрес бала белән эшләүче барлык белгечләрнең гамәлләрен исәпкә алып оештырыла. Мәсәлән, логопедның сөйләм телен үстерү буенча эшен психологның аралашу функцияләрен үстерү буенча эше тулыландыра.

Инклюзив белем бирү процессын гамәлгә ашыруның нәтиҗәле шарты булып баланың мөстәкыйльлеге, инициативасы һәм активлыгы үсешен стимуллаштыручы, балаларның мөмкинлекләрен үстерүне тәэмин итүче **предметлы-үсешкә китерүче мохит оештыру** тора.

Предметлы-үсешкә китерүче мохитнең сыйфатламалары:

• куркынычсызлык;

• уңайлылык;

• үсешнең яшь үзенчәлекләренә һәм балаларның кызыксынуларына туры килүе;

• вариативлык;

• мәгълүматлылык.

СМЧ балалар үсешенең мәҗбүри шарты булып **микротөркемнәрдә башка балалар белән үзара бәйләнеш** исәпләнә, ул аралашу һәм үзара йогынты ясауның социаль күнекмәләре формалашуга ярдәм итә. Педагоглар кечкенә төркемнәрдә балаларның үзара багланышына уен, проектлау һәм тикшеренү эшчәнлеген оештыру аша булышлык итәләр. Моның өчен өстәмә үсешкә китерүче программаларны кулланырга мөмкин («Кечкенә тикшеренүче», керамика һәм столяр остаханәсендә дәрес программалары, проектлау эшчәнлеген оештыру буенча программалар, физик тәрбия, музыкаль үсеш программалары һ.б.). Микротөркемнәрдә гомуми мәсьәләләрне хәл итеп, балалар аралашырга, бер-берсенә йогынты ясарга, үз гамәлләрен яраштырырга, уртак чишелешләр табарга, низаглардан чыгарга өйрәнәләр. Яшьтәшләренең кызыксынуларында, сәләтләрендә, күнекмәләрендә аермаларны күреп алып, балалар өлкән кеше ярдәме белән аларны үзара бәйләнешләрдә исәпкә алырга өйрәнәләр.

**Балалар активлыгын оештыруның фронталь формалары** танып белү бурычларын да, социаль бурычларны да хәл итә ала.

Балалар — ата-аналар төркемнәрендә үзара багланышны оештыру балалар һәм ата-аналар өчен комплекслы дәресләрне күздә тота, уеннарны, иҗа-

ди шөгыльләрне, музыка дәресләрен үз эченә ала. Бу дәресләрне белгечләр: педагог-психолог, укытучы-логопед, укытучы-дефектолог, музыка җитәкчесе алып бара. Үзара багланыш барышында белгечләр барлык балаларга карата уңай мөнәсәбәт, үз-үзен тотуның конструктив ысулларын күрсәтәләр, ата-аналарга мәгълүмати ярдәм тәкъдим итәләр. Дәресләр барышында ата-аналар уеннарда, күнегүләрдә, җырлауда, сурәтләү эшчәнлегендә катнашалар һәм шуның белән, бер яктан, балаларга уенга кереп китәргә ярдәм итәләр, ә икенче яктан, үзләре эмоциональ бушаналар, ял итәләр һәм үз балалары белән яңа аралашу тәҗрибәсе алалар. Дәрестән соң ата-аналар белгечләргә сораулар бирә, үзләрен борчыган проблемалар турында фикер алыша, мәгълүмати һәм психологик ярдәмгә исәп тота алалар. Нормаль үсештәге балалар белән бергә дәресләрдә катнашу СМЧ балаларга яшьтәшләре артыннан калышмаска һәм алардан өйрәнергә мөмкинлек бирә, ә алар үз чиратында СМЧ балалар белән уңай аралашу тәҗрибәсе туплый.

**Бәйрәмнәр, экскурсияләр, конкурслар, ял көне походлары** — инклюзив процессның мөһим состав өлешләре. Алар уңай эмоциональ хисләр тудыралар, балалар һәм өлкәннәрне берләштерәләр, төркемнең һәм бөтен балалар бакчасының әһәмиятле ритуаллары булып торалар.

## Инклюзив белем бирү процессы мониторингы

Инклюзив практиканы гамәлгә ашыручы Оешманың белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләрен бәяләү процедуралары берничә булырга мөмкин.

Шундый процедураларның берсе булып оешма эшчәнлегенең инклюзив белем бирү максатлары, бурычлары һәм принципларына туры килүен бәяләү тора.

**Инклюзия принципларына ярашлы рәвештә белем бирү процессының нәтиҗәлелеге критерийлары**

| № | Критерий | Күрсәткечләр | Индикаторлар |
|---|---|---|---|
| 1 | Индивидуаль якын килүне гамәлгә ашыру | СМЧ бала өчен диагностика мәгълүматларын исәпкә алып җайлаштырылган белем бирү программасын төзү | Җайлаштырылган белем бирү программалары, аларның үтәлешләре барышына бәяләмә булу |
| 2 | Баланың мөстәкыйль активлыгы өчен шартлар булдыру | Үсешкә китерүче мохит оештыру, көндәлек режимда балаларның мөстәкыйль активлыгы өчен вакыт һәм формалар булу | Көндәлек режимда балаларның мөстәкыйль активлыгы өчен вакытны планлаштыру. Мөстәкыйль активлык процессында белем бирү ихтыяҗлары төрле булган балаларны психологик-педагогик күзәтүгә алу буенча методик тәкъдимнәр |

Таблицаның ахыры

| № | Критерий | Күрсәткечләр | Индикаторлар |
|---|---|---|---|
| 3 | Барлык катнашучыларның актив белем бирү процессына рәвештә керүе | Психологик-медицина-педагогик консилиум уздырылу | Оешмада эшнең төрле формалары, шул исәптән өлкәннәр һәм балалар бәйләнеше гамәлгә куелу |
| 4 | Дисциплинаара якын килү | СМЧ балаларның аерым белем бирү ихтыяҗларын ПМПк белгечләре тикшерүе, җайлаштырылган белем бирү программасын төзү һәм гамәлгә ашыру | ПМПк үткәрү циклограммасы, нәтиҗәләрне теркәү формалары |
| 5 | Укыту һәм тәрбия процессларын оештыруда вариативлык | Вариатив белем бирү программалары, белем бирү алымнары, ысуллары, оештыру формалары, вариатив белем бирү мохите | Оешма белгечләре тарафыннан укытуның һәм тәрбиянең төрле алымнарын һәм технологияләрен куллану, белем бирү процессын тәэмин итүче методик материаллар булу |
| 6 | Гаилә белән үзара партнерлык бәйләнешләре | Гаилә белән үзара багланышның партнерлык формаларын оештыру, ата-аналарның Оешма тормышында катнашуы, ата-аналарга консультацияләр | Ата-аналарның җайлаштырылган белем бирү программаларын һәм индивидуаль белем бирү маршрутын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашуы |
| 7 | Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының эшләве | Белем бирү процессын балалар контингенты ихтыяҗларына яраштырып оештыру, белем бирү шартларын белем бирү ихтыяҗлары диагностикасы белән бәйле рәвештә үзгәртү | Балалар контингентының сыйфат ягыннан составының, штат расписаниесенең, методик базаның һәм предметлы-үсешкә китерүче мохитнең ярашуы. Балаларның ачыкланган ихтыяҗлары белән ярашлы рәвештә яңа технологияләр куллану |

## МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАСЫНДА КОРРЕКЦИОН ЭШ (белем бирү өлкәләре буенча)

Хәзерге этапта инклюзив белем бирү һәм тәрбияләү концепциясе илебездә махсус белем бирү үсешендә әйдәп баручы юнәлеш булып тора. Бу тайпылышлар (психик, физик, интеллектуаль) шартларында үсә баручы шәхеснең социумдагы барлык мөмкин булган һәм кирәкле тормыш сфераларына тигез хокуклы керүен, лаеклы социаль статусын һәм җәмгыятьтә үз урынын табуын аңлата.

Илебездә белем бирү учреждениеләрендә психик яисә физик сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар инклюзиясе процессы җәелә бару вакыт гәүдәләнеше генә түгел, бәлки, Мәгариф турындагы закон нигезендә балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру да. Инклюзив тәрбия һәм укытуны гамәлгә ашыру өчен мәктәпкәчә яшьтәге балаларда хезмәттәшлек һәм үзара аңлашу нигезендә үзара багланышлар кору сәләтен формалаштырырга кирәк. Толерантлык җәмгыятьнең тормыш позициясе нигезенә әверелергә тиеш. Инклюзия сәламәт балаларда яшьтәшләренең физик һәм психик кимчелекләренә карата түземлелекне, үзара ярдәмләшү һәм хезмәттәшлеккә омтылу хисләрен үстерергә ярдәм итә. Инклюзия сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (СМЧ) балаларда яшьтәшләренә уңай мөнәсәбәт һәм тиңдәш социаль тәртип формалаштыруга, шулай ук укытуда һәм тәрбиядә үсеш потенциалын тагын да тулырак гамәлгә ашыруга булышлык итә. Инклюзив укыту теге яки бу төр белем алуны тигез оештыруның һәм белем алуда барлык балаларның уңышка ирешүе өчен кирәкле шартлар тудыруның тәэмин ителешен тормышка ашыра.

СМЧ балаларны гомуми белем бирү даирәсендә тәрбияләү һәм укыту проблемасы үтә нечкә һәм сизгер якын килүне таләп итә, үсешләрендә тайпылышлар булган барлык балаларның да сәламәт яшьтәшләре мохитенә уңышлы тоташа алмавы аңлашыла. Индивидуаль белем бирү маршруты андый балаларны яшьтәшләре коллективына өлкән кеше булышлыгы белән кертүне күздә тота, бу исә педагогтан үсешендә тайпылышлар булган балаларда бердәм балалар коллективында үзара бәйләнештә булу сәләтен формалаштыруда яңа юнәлешләр билгеләүне таләп итә. СМЧ балалар үз потенциалларын бары үз вакытында башланган һәм белеп оештырылган тәрбия һәм уку-укыту процессы, нормаль үсештәге балалар белән уртак, шулай ук психик үсешләрендәге тайпылулар характерына бәйле үз белем ихтыяҗларын канәгатьләндерү шартларында гына гамәлгә ашыра алалар (Н.Н. Малофеев, О.И. Кукушкина, Е.Л. Гончарова, О.С. Никольская).

Гадәти мәктәпкәчә учреждение төркемендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле баланың булуы тәрбиячеләр тарафыннан игътибар, ата-аналар белән бергә аны тәрбияләү һәм укыту, мәктәпкә әзерләү өчен җаваплылыкны бүлешүгә әзерлек таләп итә. Төркем тәрбиячесенең бала белән эшләүгә психологик әзерлеге, аңа һәм аның ата-аналарына булышырга, андый баланың төркемдә булуын аның үзе өчен файдалы һәм кызыклы итәргә теләве иң мөһим аспект булып тора.

Хәзерге вакытка үсешендә төрле тайпылышлар булган мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен махсус (коррекцион) белем бирү программалары эшләнгән, алар компенсацияләүче һәм катнаш төрдәге учреждениеләрдә тормышка ашырыла. Әйтергә кирәк ки, хәзерге вакытта гомуми белем бирү учреждениеләрендә әлеге категориядәге балалар белән коррекцион-педагогик процессның эчтәлеген ача торган программа-методик материаллар юк. Программаның бу бүлеге мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре педагоглары, психологларын коррекцион-педагогик эш технологияләре белән таныштыа-

руны, аларга балалар бакчасы шартларында бу эшне гамәлгә ашырырга ярдәм итүне максат итеп куя.

## СМЧ балалар — составы буенча бертөрле булмаган мәктәпкәчә яшьтәгеләр төркеме

СМЧ балалар төркеменә сәламәтлекләренең торышы махсус тәрбия һәм укыту шартларыннан тыш мәктәпкәчә учреждениенең белем бирү программасының барлык яисә кайбер бүлекләрен үзләштерүдә каршылыклар тудыра торган балалар карый.

СМЧ мәктәпкәчә яшьтәгеләр төркеме бертөрле түгел, аңа үсешләрендә төрле тайпылышлар булган, алар төрлечә гәүдәләнеш алган балалар керә.

Хәзерге вакытта үсешләрендә тайпылышлар булган балалар берничә категориягә бүлеп карала:

• ишетү сәләте бозылган балалар (ишетмәүчеләр һәм начар ишетүчеләр), беренчел бозылу сиземләү характерында — ишетү анализаторы зарарлану сәбәпле, ишетү аша кабул итү бозылган;

• күрү сәләте бозылган балалар (сукырлар, начар күрүчеләр), беренчел тайпылыш сиземләү характерында, күрү анализаторы органик зарарлану аркасында, күрү аша кабул итү кыенлыклар тудыра;

• сөйләмнәренә зур зыян килгән балалар, беренчел дефект булып сөйләм үсеше артта калу тора;

• терәк-хәрәкәт аппараты тайпылышы булган балалар, беренчел тайпылыш булып баш мие кабыгының хәрәкәт үзәкләре органик зарарлану сәбәпле, хәрәкәткә зыян килү тора;

• психик үсеше тоткарланган балалар, алар үзәк нерв системасындагы (ҮНС) көчсез чагылыш тапкан органик зарарланулар аркасында югары психик функцияләрнең формалашу темпы акрын булу белән характерлана;

• интеллектуаль үсеше тоткарланган балалар, беренчел бозылу — баш миенең органик зарарлануы сәбәпле, югары танып белү процессларына зыян килү;

• аутистик спектр үсеше бозылган балалар, төрле клиник билгеләр һәм психологик-педагогик үзенчәлекләр белән характерлана торган полиморф төркемне тәшкил итә — аралашу чаралары һәм социаль күнекмәләр үсеше бозылган, динамик үзгәреп торучы мохит белән актив үзара мөнәсәбәтләр булдыруда аффектив проблемалар;

• үсешенә комплекслы (катлаулы) тайпылышлар хас балалар, аларда берьюлы ике яки берничә беренчел (сиземләү, хәрәкәт, сөйләм, акыл) тайпылыш күзәтелә, мәсәлән, балалар церебраль параличы белән начар ишетүчеләр, психик үсеше тоткарланган начар күрүчеләр һ.б. Тайпылышларның чагылыш дәрәҗәсе төрле, шуңа күрә комплекслы тайпылышлы балаларның психик үсеше өч дәрәҗәгә бүлеп карала, бу психологик-педагогик эшнең үзенчәлеген билгели.

Балаларда булган тайпылышлар акыл эшчәнлеге бозылуга, гомуми һәм вак моторика җитешсезлекләренә, әйләнә-тирә дөнья белән үзара бәйләнештә

кыенлыкларга, аралашу ысуллары һәм бәйләнеш чаралары үзгәрешенә, телдән әйтелгәнне турыдан-туры түгел, башка юл белән кабул итеп фикерләүнең җитәрлек булмавына, аерым алганда — вербализациягә, әйләнә-тирә дөньяны танып белүнең бозылуына, социаль тәҗрибәнең ярлылануына, шәхес формалашудагы үзгәрешләргә китерә. Беренчел тайпылыш алга таба бөтен үсеш барышына йогынты ясый. Гомуми үсеш закончалыкларыннан тыш, үсешендә төрле психик, физик тайпылышлар булган балаларның һәрбер категориясе бер категория балаларны башкаларыннан аерып тора торган үзенә генә хас психологик-педагогик үзенчәлекләргә ия, боларны интеграцияле белем бирү даирәсендә коррекцион эшне билгеләгәндә исәпкә алырга кирәк.

Балаларның сан буенча шактый зур төркемен үсеш дәрәҗәләре гадәти үсеш дәрәҗәсеннән бик үк аерылып тормаган, димәк, хәрәкәт, сиземләү яисә интеллектуаль өлкәләрдәге тайпылышлары кыен билгелеләнүче балалар тәшкил итә. Минималь яки парциаль тайпылышларга дучар булган балалар төркеме полиморф һәм түбәндәге вариантлар белән күрсәтелә ала:

• ишетү сәләте минималь бозылган балалар;

• күрү сәләте минималь бозылган балалар, шул исәптән кылыйлык һәм амблиопия белән;

• сөйләмнәре бозылган балалар (дислалия, минималь дизартрик тайпылышлар ябык ринолалия, дисфания, тотлыгу, полтерн, тахилалия, брадилалия, лексик-грамматик төзелешнең бозылуы, фонематик кабул итүнең бозылуы);

• психик үсешләрендә җиңелчә тоткарлыклар булган балалар (конституциональ, соматоген, психоген);

• педагогик яктан ташландык хәлдәге балалар;

• негатив психик халәттәге балалар (талчыгу, психик киеренкелек, хафалану, фрустрация, йокы, аппетит бозылу) соматоген яисә церебраль-органик тайпылышлары, акыл үсеше камил балалар (еш авыручы, посттравматик, аллергияле, компенсацияләнгән һәм субкомпенсацияләнгән гидроцефалияле, цереброэндокрин авырулы);

• үз-үзләрен тотышларының психопатка тартым формалары күзәтелүче балалар (аффектив ярсынучанлык, истероидлык, психастения һ.б. тибы буенча);

• органик генез тәртибе формалары бозылган балалар (гиперактивлык, игътибар дефициты синдромы);

• неврозлы балалар;

• психик авыруларның башлангыч билгеләре күзәтелүче балалар (шизофрения, башлангыч балалар аутизмы, эпилепсия);

• церебраль-органик тайпылышлы җиңелчә хәрәкәт патологиясе булган балалар;

• баш миенең аерым структуралары җитлегүендә асинхрония булган яисә аларның функциональ яки органик генезы (шул исәптән баш миенең минималь дисфункциясе тибы буенча) бозылган балалар.

Соңгы вакытта мәктәпкәчә учреждениеләргә кохлеар имплантация кичергән балалар килә, алар белән педагогик эшчәнлектә шулай ук махсус ярдәм кирәк.

Психик үсешләрендә минималь һәм парциаль тайпылышлар булган балалар категориясен «нормаль» һәм «тайпылышлы» үсеш арасында торучы буларак карау һәм аны «хәвеф төркеме» буларак билгеләү максатка ярашлы. Балалардагы тайпылышларның сыйфат ягыннан үзенчәлекләре һәм тирәнлеге алар өчен махсуслаштырылган учреждениеләр оештыру таләп итә торган түгел, әмма булган проблемаларның алга таба катлаулануына юл куймау өчен, мондый балаларга үз вакытында коррекцион ярдәм оештырылуга мохтаҗ.

Хәзерге вакытта массакүләм мәктәпкәчә учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләр контингентын психик үсеше нормаль булган балалар да, психик дизонтогенезның төрле вариантлары күзәтелгән балалар да тәшкил итә, шуңа күрә гамәлдәге укыту һәм тәрбия практикасын яңадан күздән кичерү һәм СМЧ балаларга, психофизиологик һәм индивидуаль үсеш мөмкинлекләрен исәпкә алып, индивидуаль юнәлтелгән психологик-педагогик ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыруда иң оптималь юлларны билгеләү кирәк.

## СМЧ балаларны психологик-медицина-педагогик тикшерү

СМЧ балаларны тәрбияләүнең һәм укытуның уңышлы булуы өчен, аларның мөмкинлекләрен дөрес бәяләү һәм үзенчәлекле белем алу ихтыяҗларын ачыклау зарур. Моңа бәйле рәвештә психологик-медицина-педагогик диагностикага аерым роль бирелә. Психологик-медицина-педагогик диагностика ярдәмендә түбәндәгеләргә ирешү өчен шартлар тудырыла:

- мөмкинлекләре чикле балаларны үз вакытында ачыклау;
- СМЧ балаларның индивидуаль психологик-педагогик үзенчәлекләрен ачыклау;
- оптималь педагогик маршрут билгеләү;
- мәктәпкәчә учреждениедә һәр СМЧ баланы индивидуаль булышлык белән тәэмин итү;
- коррекция чараларын планлаштыру, коррекцион эш программаларын эшләү;
- коррекцион эшнең үсеш динамикасын һәм нәтиҗәлелеген бәяләү;
- баланы тәрбияләү һәм укыту шартларын билгеләү;
- СМЧ балаларның ата-аналарына консультация бирү.

Тайпылышлы үсеш буенча диагностика уздыруның төп принципларының берсе — СМЧ баланың үсеш үзенчәлекләрен барлык белгечләр тарафыннан тикшерүдән һәм бәяләүдән гыйбарәт, танып белү эшчәнлеген, үз-үзеңне тотышны, эмоцияләрне, ихтыяр көчен, күрү, ишетү сәләтләре, хәрәкәтләнү өлкәсе торышын, соматик халәтен, неврологик статусны колачлаучы комплекслы якын килү. Баланы өйрәнү медицина тикшерүен һәм психологик-педагогик тикшерүне үз эченә ала.

Медицина тикшерүе анамнез мәгълүматларын өйрәнүдән башлана. Анамнез табиб тарафыннан туплана һәм баланың документлары белән танышу, ата-аналар (аларны алыштыручы затлар) белән әңгәмә нигезендә төзелә.

Баланың шәхси анамнезына түбәндәге мәгълүматлар кирә: ананың йөклелек үзенчәлекләре; дару препаратларын куллану дәвамлылыгы һәм зарарлы факторларның йөклелеккә тәэсире; бала тудыру үзенчәлекләре; бала тудырганда күрсәтелгән ярдәмнең асылы; балада тумыштан килгән зәгыйфьлекләр, көзән җыерулар һ.б. булу; баланың тугандагы авырлыгы, ашата башлау вакыты, бала тудыру йортында булу срогы. Бала кичергән авырулар, дәвалау үзенчәлекләре, өзлегүләр булу санап үтелә. Мәктәпкәчә учреждениегә килгәнче баланың кайда, ничек һәм кем тарафыннан тәрбияләнүе күрсәтелә.

Гаилә анамнезында баланың гаиләсе һәм нәселдәнлек турындагы мәгълүматлар анализлана; гаилә составы, аның һәр әгъзасының яше һәм белем дәрәҗәсе, ата-аналарның характеры үзенчәлекләре тасвирлана; туганнарның психик, неврологик, хроник соматик авырулары, аларның тышкы кыяфәтләренең патологик үзенчәлекләре теркәлә. Бала тәрбияләнә торган гаилә-көнкүреш шартлары, ата-аналарның эш урыны һәм характеры тасвирлана; гаиләдәге үзара мөнәсәбәтләргә, балага карата мөнәсәбәткә бәя бирелә; ата-аналарның берсенең яки икесенең дә алкогольгә яки наркотикларга бәйле-бәйле булмавы теркәлә.

Педагоглар һәм тәрбиячеләр медицина тикшерүе нәтиҗәләре белән документлар аша танышалар: баланың үсеше тарихын, белгечләр чыгарган нәтиҗәләрне өйрәнәләр. Бу исә балада булган проблемалар асылын ачыкларга һәм аның мәктәпкәчә учреждениедәге үсеше өчен шартлар тудырырга ярдәм итә.

Психологик-педагогик тикшеренү СМЧ балаларның акыл ягыннан үсешен өйрәнүдә комплекслы якын килүнең бер компоненты булып тора. Аның нәтиҗәләре бала турындагы башка мәгълүматлар белән бергә каралырга мөмкин.

СМЧ балаларны тәрбияләүне һәм укытуны оештыру баланың танып белү эшчәнлеге үзенчәлекләрен өйрәнү һәм ачу, тайпылышларның асылын, баланың потенциаль мөмкинлекләрен ачыклау мәсьәләләрен алга куя, аның үсешен фаразлау мөмкинлеге бирә.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның СМЧ категориясе гаять күптөрле булганлыктан, психологик диагностика куллануның төп максаты шул категориягә керүче балаларның акыл ягыннан үсеш дәрәҗәсен, интеллекты торышын билгеләүдән гыйбарәт.

Психологик тикшерүне психолог уздыра. Үсешендә проблемалар булган баланы психологик тикшерү системалы булырга һәм психиканың барлык якларын (танып белү эшчәнлеге, сөйләм, эмоциональ-ихтыяри өлкә, шәхес буларак үсеш) үз эченә алырга тиеш.

Диагностика чаралары чыганаклары сыйфатында С.Д. Забрамная, И.Ю. Левченко, Е.А. Стребелева, М.М. Семаго һ.б.ның фәнни-гамәли эшләнмәләрен кулланырга мөмкин. Сыйфатлы анализ баланың биремнәрне башкару процессы үзенчәлекләрен һәм аның хаталарын сыйфат күрсәткечләре системасы нигезендә бәяләүне күздә тота.

Баланың эмоцияләр өлкәсен һәм үз-үзен тотышын характерлаучы түбәндәге сыйфат күрсәткечләре ачыклана:

• баланың контактлылык үзенчәлекләре;
• тикшерү ситуациясенә карата эмоцияләр чагылышы;
• хуплауга карата мөнәсәбәт чагылышы;
• уңышсызлыкларга карата мөнәсәбәт чагылышы;
• биремнәрне үтәү вакытында эмоциональ халәт;
• эмоциональ хәрәкәтчәнлек;
• аралашу үзенчәлекләре;
• нәтиҗәгә карата мөнәсәбәт чагылышы.

Баланың эшчәнлеген характерлаучы сыйфат күрсәткечләре:
• биремгә карата кызыксыну булу һәм аның тотрыклылыгы;
• инструкцияне аңлау;
• биремне үтәүдә мөстәкыйльлек;
• эшчәнлек характеры (максатчанлык һәм активлык);
• эшчәнлек темпы һәм динамикасы, эшчәнлекне көйләү үзенчәлекләре;
• эшләү сәләте;
• ярдәм оештыру.

Баланың танып белү өлкәсе һәм моторика функциясе үзенчәлекләрен характерлаучы сыйфат күрсәткечләре:
• игътибарга алу, аңга кабул итү, хәтер, фикерләү, сөйләм үзенчәлекләре;
• белем бирүнең моторика функциясе үзенчәлекләре.

Алга таба, белем бирүнең эчтәлеген билгеләү өчен, СМЧ балаларның психик үсешен комплекслы бәяләүдә һәм аларның потенциаль мөмкинлекләрен ачыклауда педагогик тикшерү мөһим.

Педагогик тикшерү бала турында ул билгеле бер яшьтәге чорда ия булырга тиешле белемнәрне, сәләтләрне, күнекмәләрне күрсәтүче мәгълүматлар алуны, укытудагы төп проблемаларны, уку материалын үзләштерү темпын билгеләүне, белем бирү эшчәнлегенең үзенчәлекләрен ачыклауны күздә тота. Кызыксындырган мәгълүматларны бала һәм ата-аналар белән турыдан-туры әңгәмә, баланың эшләрен (рәсемнәрен, эшләнмәләрен һ.б.ны) анализлау, педагогик күзәтү кебек алымнар ярдәмендә алырга мөмкин.

Педагогик күзәтү махсус планлаштырылган, төгәл юнәлтелгән һәм системалы булырга тиеш. Ул, гомуми алганда, эшчәнлекнең формалашу дәрәҗәсен — аның максатчанлыгын, оешканлыгын, иреклелеген, гамәлләрне планлаштыру сәләтен бәяләү мөмкинлеге бирә.

Баланың төп эшчәнлеген, аның танып белү активлыгын күзәтү аеруча мөһим; әлеге күзәтү процессында мәктәпкәчә яшьтәге бала эшчәнлегенең аның шәхес буларак җитлегүен чагылдыручы мотивлаштыру аспекты билгеләп үтелә.

Педагогик күзәтү барышында балага:
• үзенең тулысынча исемен, фамилиясен, яшен, өй адресын атарга;
• гаиләсе турында сөйләргә, әнисенең һәм әтисенең исемнәрен һәм аларның әтиләре исемнәрен, эш урыннарын атарга;
• якын өлкән кешеләренең исемнәрен һәм аларның әтиләре исемнәрен, яшьтәшләренең исемнәрен атарга;

• урамда, җәмәгать урыннарында үз-үзеңне тотуның төп кагыйдәләре, өйдәге яраткан шөгыле һ.б. турында сөйләргә тәкъдим итәлә.

Алынган мәгълүматлар киләчәктә СМЧ балаларны тәрбияләү һәм укыту процессын оештыруга максатчан рәвештә төзәтмәләр кертү мөмкинлеге бирә.

## Мәктәпкәчә белем бирү программасының белем бирү өлкәләре

Коррекцион-педагогик эшнең төп бурычы — СМЧ баланың социаль тәҗрибәсен баету һәм аны гармонияле рәвештә яшьтәшләре коллективына кертү максатында аның төрле яклап үсеше өчен шартлар тудыру.

Төп белем бирү өлкәләрен тасвирлыйбыз.

### «Социаль-коммуникатив үсеш» белем бирү өлкәсе

Төп максат — аралашу күнекмәләрен үзләштерү һәм СМЧ балаларның иҗтимагый тормышка оптималь керүен тәэмин итү. Социаль-коммуникатив үсешнең бурычлары:

• балада үзе турында күзаллаулар булдыру, үзенә шәхес буларак тәңгәл аңлы рәвештә бәяләмә бирү һәм үзенә карата позитив мөнәсәбәт системасын төзү өчен элементар күнекмәләре формалаштыру;

• үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләре формалаштыру;

• өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән хезмәттәшлек итү; тирәлектәге предметларны һәм күренешләрне аңлап кабул итү, аларга карата уңай мөнәсәбәттә булу күнекмәләре формалаштыру;

• тирә-юньне экологик тоемлау, позитив милли традицияләргә һәм гомумкешелек кыйммәтләренә карата әхлакый мөнәсәбәт алшартлары һәм нигезләре формалаштыру;

• балалар эшчәнлегенең төрле төрләре контекстында һәм ирекле аралашуда телдән (вербаль) аралашу чараларын аларның телдән булмаган (вербаль булмаган) чаралары белән аңлы рәвештә ярашуы шартларында куллана белү күнекмәләре формалаштыру.

Әлеге өлкәгә караган белем бирү бурычларын гамәлгә ашырганда, СМЧ балаларда әйләнә-тирә дөньяның күптөрлелеге, шулай ук социаль күренешләргә, кагыйдәләргә, җәмгыятьнең (социумның) гомуми кабул ителгән нормаларына карата мөнәсәбәтләрнең күптөрлелеге турындагы күзаллаулар формалаша һәм мөмкинлекләре чикләнгән балаларны мөстәкыйль тормыш эшчәнлегенә әзерләү эше башкарыла. Балаларның эшчәнлеге педагог тарафыннан системалы рәвештә формалаштырылганда, СМЧ балаларның иҗтимагый тәҗрибәне үзләштерүе ачык күренә. Шул рәвешле якын килү нәтиҗәсендә балада психик яңалыклар — охшату, тиңләштерү, чагыштыру, өстенлек бирү кебек социаль форма күнекмәләре барлыкка килә.

Яшьтәшләр белән үзара багланышлар нигезендә шәхси позицияләр һәм бәяләмәләр дә үсеш кичерә, бу исә СМЧ балага сәламәт яшьтәшләре коллективында билгеле бер урын биләү мөмкинлеге бирә.

Социаль характердагы башлангыч күзаллауларны үзләштерү һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән мәктәпкәчә яшьтәге балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертүгә юнәлтелгән аралашу күнекмәләрен үстерү буенча эш берничә юнәлештә башкарыла:

• балаларның игътибарын бер-берсенә җәлеп итү, үзара ярдәмләшү, коллектив чараларда катнашу юлы белән көндәлек тормышта;

• үзе, тирәлектәге өлкәннәр һәм яшьтәшләре турындагы күзаллауларны үстерүгә юнәлтелгән махсус уеннар һәм күнекмәләр процессында;

• катнашучылар арасындагы, аңлы рәвештә үзара мөнәсәбәтләрнең элементар гомуми кабул ителгән нормаларына һәм кагыйдәләренә тартылу мөмкинлеге тудыручы социаль мөнәсәбәтләрне чагылдырган сюжетлы-рольле һәм театральләштерелгән уеннарга, уен-тамаша өйрәтү процессында;

• хуҗалык-көнкүреш хезмәте процессында һәм эшчәнлекнең төрле төрләрендә.

Социаль-коммуникатив сәләтләрне формалаштыру эше көн саен башкарылырга һәм органик рәвештә эшчәнлекнең барлык төрләренә (көнкүрешкә, уенга, укыту-өйрәтүгә) үтеп керергә тиеш.

СМЧ балаларда социаль белемнәр формалаштыру эшендә һәр баланың сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, культура-гигиена күнекмәләрен, сәламәт яшәү рәвеше алып бару ихтыяҗын формалаштыру; үз сәламәтлегең һәм аны саклау чаралары турындагы күзаллауларны үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру мөһим.

Культура-гигиена күнекмәләре үстерү эшенең якынча эчтәлеге:

• ашау: кашык, чәнечке, чынаяк, салфетка кулланырга (индивидуаль мөмкинлекләрне исәпкә алып); ашаганда пөхтәлек сакларга, ашаганнан соң рәхмәт белдерергә (билге, хәрәкәт, сүзләр белән) өйрәтү;

• гигиена күнекмәләре: иртәнге һәм кичке гигиена процедураларын башкару (бәдрәф, кулларны юу, аякларны юу һ.б.); чисталык, киенү-ясану кирәк-яракларыннан (кәгазь, сыек һәм каты сабын, паста, салфетка, губка, сөлге, тарак, щетка, көзге), кулъяулыктан файдалану;

• өс киеме һәм тышкы кыяфәт: файдалануга карап өс киеменең төрле төрләрен аеру; киенү һәм чишенү эзлеклелеге тәртибен үтәү; өс киеме предметларын тиешле урыннарда саклау; төймәләр, молния, шнурлар һ.б. белән дөрес эш итү; киемне һава торышына, сезонга карап сайлау; көзге, тәрбияче күрсәтмәләре ярдәмендә тышкы кыяфәтеңнең пөхтәлеген контрольдә тоту күнекмәләренә өйрәтү.

Бурычларны гамәлгә ашыру өчен, балалар бакчасында һәм өйдә көндәлек режимны дөрес оештыру, эшчәнлекнең һәм ялның организмның төгәл эшләвенә булышучы төрле төрләрен чиратлаштыру зарур.

СМЧ балалар сәламәтлек, тормыш өчен куркыныч төрле хәлләрдә калырга мөмкиннәр, шуңа күрә кешенең җәмгыятьтәге тормышы белән

бәйле белемнәр, сәләтләр һәм күнекмәләр формалаштырганда педагог, тәрбияче, актив тормыш позициясе тудырып, теге яки бу хәлдә үз-үзеңне тотуның берничә моделен «уйнап күрсәтә», балаларны мөстәкыйль карар кылуга юнәлтә ала.

Түбәндәге аеруча типик хәлләрне тәкъдим итәргә һәм үз-үзеңне тотуның иң гади алгоритмнарын формалаштырырга мөмкин:

• җәмәгать транспортыннан файдалану;

• юл хәрәкәте куркынычсызлыгы кагыйдәләре;

• өй аптечкасы;

• электр приборларыннан файдалану;

• җәмәгать урыннарында (вокзал, кибет) үз-үзеңне тоту һ.б.

• кеше өчен куркыныч тудыручы предметлар һәм күренешләр (ут, һәлакәтләр, агулы матдәләр) турында мәгълүматлар.

Охшаш тормыш хәлләре мисалында балалар кагыйдәләр үзләштерәләр, аларга тормыш тирәлеген үзләштерергә мөмкинлек бирүче уңай гадәтләр үзләштерәләр. Кешеләрнең катлаулы хәлләрдә үз-үзләрен тотышын анализлау, кайбер мәсьәләләрне хәл итү юлларын белү баланың үз-үзенә ышанычын арттыра, эмоциональ халәтен ныгыта.

Социаль-коммуникатив сәләтләрне формалаштыру буенча белем бирү өлкәсендә СМЧ балаларны элементар хезмәт күнекмәләренә, иң гади кораллар белән эш итү күнекмәләренә өйрәтү аерым урын били. Әлеге эш түбәндәгеләрне үз эченә ала:

• балаларда үз-үзләренә хезмәт күрсәтү күнекмәләре, хуҗалык-көнкүреш хезмәте һәм табигатьтәге хезмәт күнекмәләре формалаштыру максатында аларның гамәли эшчәнлеген оештыру;

• балаларны өлкәннәр хезмәте, кешеләр тормышында хезмәтнең, хезмәткә карата хөрмәт тәрбияләүнең роле белән таныштыру;

• хезмәт гамәлләрен, һөнәрләрне һәм кайбер хезмәт коралларын исемләп атарга өйрәтү;

• үсемлекләрне, хайваннарны карарга өйрәтү;

• кул хезмәтенә өйрәтү (кәгазь, катыргы, табигый материал белән эшләү, җилем, кайчы куллану, кәгазь кисү, кисеп алынган формаларны кәгазьгә ябыштыру, тартмачыклардан һәм табигый материалдан әйберләр эшләү һ.б.);

• коллектив эшләнмәләр ясау;

• эшләнгән әйберләрне уенда куллану күнекмәләре формалаштыру.

Иҗтимагый тәҗрибәне үзләштерүнең төрле ысулларына ия булып, СМЧ балалар охшату, күрсәтү, үрнәк һәм телдән күрсәтмә буенча эш итәргә өйрәнәләр. СМЧ балаларның хезмәт эшчәнлеген формалаштыру аларның психофизик мөмкинлекләрен һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Социаль-коммуникатив сәләтләрне үзләштерү СМЧ балаларны аралашуга — кешеләр белән уртак эшчәнлеккә ихтыяҗ нигезендә туучы элемтәләрне урнаштыру һәм үстерү процессына кертү белән тәэмин итә.

Аралашуны үстерү эшендә үзәк буын буларак коммуникатив ситуацияләре — баланың телдән (вербаль) һәм телдән булмаган (вербаль булмаган) аралашу чаралары аша үзенчәлекле рәвештә оештырылган әйләнә-тирә объектлары һәм субъектлары белән үзара тәэсир итешү ситуацияләре файдаланыла.

Мәктәпкәчә яшьтәге СМЧ балаларга белем бирү эшчәнлеген аларга очраучы күренешләр даирәсен максималь дәрәҗәдә колачлап, балаларга якын һәм аңлаешлы материалга нигезләнеп кору кулайрак. Яңа материал белән балаларга аңлаешлы югарылыкта таныштырырга кирәк. Балалар бакчасы төркемендә һәм гаиләдә ишетү-сөйләм мохитен оештыру сөйләм телен үзләштерүгә, аралашу шартларында реаль кулланугa йогынты ясаучы мөһим факторларның берсе булып тора. Бу мохитне булдыруда тәрбиячеләр, төркем педагоглары, ата-аналар, башка өлкәннәр һәм балаларның яшьтәшләре катнаша.

## «Танып белү үсеше» белем бирү өлкәсе

Төп максат — акыл эшчәнлеге процессларын һәм ысулларын формалаштыру, табигать һәм җәмгыять турындагы белемнәрне үзләштерү, баету; танып белү мәнфәгатьләрен үстерү.

Мәктәпкәчә яшьтәге мөмкинлекләре чикләнгән балаларның танып белү процесслары тоемлау, аңга кабул итү, фикерләү, игътибар, хәтер процесслары белән тәэмин ителә.

Моңа тиңдәшле рәвештә танып белү үсешенең түбәндәге бурычлары алга куела:

• перцептив гамәлләрне формалаштыру һәм камилләштерү;
• сиземләү белән таныштыру һәм сиземләү эталоннарын формалаштыру;
• игътибарны, хәтерне үстерү;
• күрсәтмә-гамәли һәм күрсәтмә-образлы фикерләүне үстерү.

«Танып белү үсеше» белем бирү өлкәсенә керәләр:

**Сиземләү үсеше.** Аның процессында мөмкинлекләре чикләнгән балаларның аңга кабул итүенең барлык төрләре — күрү, ишетү, капшау-хәрәкәтләнү, ис сизү, тәм тою сәләтләре үсеш кичерә. Алар нигезендә предметларның тышкы үзлекләре, аларның формасы, төсе, зурлыгы, исе, тәме, тирәлектә һәм вакыт җәһәтендә урнашулары турындагы тулы күзаллаулар формалаша.

Сиземләү үсеше фикерләү — тиңләштерү, чагыштыру, анализлау, синтезлау, гомумиләштерү, классификацияләү һәм абстракцияләү процесслары үсешен күздә тота, шулай ук сөйләмнең барлык якларын — номинатив функция, фразалы сөйләм үсешен стимуллаштыра, баланың сүзлеге баюга һәм киңәюгә булышлык итә.

Күрү, ишетү, терәк-хәрәкәт аппараты тайпылышлары тулы сыйфатлы сиземләү үсешен тоткарлыйлар, шунлыктан сиземләүне үстерү эшен оештырганда һәр СМЧ баланың психофизик үзенчәлекләрен исәпкә алу зарур. Бу исә материалны тәкъдим итү ысулларында (күрсәтү, биремнәр текстлары яки предмет атамалары язылган табличкалар куллану, сүз-ишарә белән аңлату формасы, телдән аңлату); күрсәтмәләрнең яраклы формаларын сайлауда чагылыш таба.

Сиземләү үсеше буенча эшне планлаштырганда һәм күнекмәләр сайлаганда, балалардагы тайпылышларны, аларның катлаулылык дәрәҗәсен исәпкә алып, бу күнекмәләрне башкаруның никадәр мөмкин булуыннан чыгып эш итәргә кирәк.

**Танып белү-тикшеренү эшчәнлеген һәм конструкцияләү эшчәнлеген үстерү тирәлекне дөрес кабул итүне формалаштыруга,** предметны бар тулылыгы белән кабул итүгә, язу күнекмәләрен үзләштерергә әзерләү өчен кулның вак моторикасын үстерүгә һәм күрү-хәрәкәтне координацияләүгә, кызыксынучанлыкны, хыялны үстерүгә; әйләнә-тирә дөнья турындагы белемнәр һәм күзаллаулар запасын киңәйтүгә юнәлтелә.

Бала үз эшчәнлегенең нәтиҗәсен күрә алсын өчен, СМЧ балаларның тиз талчыгуын исәпкә алып, эш аңлаешлы материалда планлаштырылырга тиеш. Эш барышында биремнәрне башкару аеруча кыен булган (церебраль параличлы) мәктәпкәчә яшьтәге балаларны төрлечә хуплау формаларын кулланырга кирәк.

**Элементар математик күзаллаулар формалаштыру** балаларны төрле күплекләрне һәм күплекләр элементларын капма-каршы кую, чагыштыру, алар арасындагы тәңгәллекне ачыклау, вакыт эчендә һәм тирәлектә ориентлаша белергә өйрәтүне күздә тота.

СМЧ балаларны укытканда-өйрәткәндә саклау анализаторларына таяну, гадидән катлаулыга күчү барып, күрсәтмәлелек принципларын куллану зарур. Микъдарлы күзаллауларны эшчәнлекнең төрле төрләре процессында баетырга кирәк. Элементар математик күзаллаулар формалаштыру эшен планлаштырганда программа материалы күләмен мәктәпкәчә яшьтәге балаларның реаль мөмкинлекләрен (үсеш процессы тоткарланган, интеллектуаль тайпылышлары булган балалар) исәпкә алып уйлап куярга кирәк, бу балаларның түбән башлангыч үсеш дәрәҗәсе һәм өйрәнелүче предметның акрынайган үзләштерелү темпы белән бәйле.

## «Сөйләм үсеше» белем бирү өлкәсе

Төп максат — баланың аралашу, танып белү, үз мөмкинлекләрен күрсәтү, балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен үстерү чарасы буларак, үз халкыңның телен үзләштерү нигезендә сөйләм теленең үз вакытында һәм нәтиҗәле үсешен тәэмин итү.

Сөйләмне үстерү бурычлары:

• тел системасының структур — фонетик, лексик, грамматик компонентларын формалаштыру;

• телне аның аралашу функциясендә куллану күнекмәләрен формалаштыру — бәйләнешле сөйләм, сөйләм аша аралашуның ике формасын — диалог һәм монолог формаларын үстерү;

• тел һәм сөйләм күренешләрен элементар аңлау сәләтен формалаштыру.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләмен үстерү эшенең төп юнәлешләре:

• **сүзлекне үстерү.** Сүз телнең аеруча мөһим берәмлеге булганга күрә, сүзлек запасына ия булу балаларның сөйләм үсешенең нигезен тәшкил итә. Сүзлектә сөйләмнең эчтәлеге чагыла. Сүзләр предметларны һәм күренешләрне, аларның билгеләрен, сыйфатларын, үзлекләрен һәм алар белән эш итүне белдерәләр. Балалар үз тормыш эшчәнлекләре һәм әйләнә-тирәдәгеләр белән аралашу өчен кирәкле сүзләрне үзләштерәләр;

• **сөйләмнең аваз культурасын тәрбияләү.** Әлеге юнәлеш ишетү сәләтен (аның нигезендә телнең фонологик чараларын аңга кабул итү һәм аеру гамәлгә ашырыла) үстерүне; авазларны дөрес әйтергә өйрәтүне; сөйләмнең орфоэпик дөреслеген тәрбияләүне; сөйләмнең аваз тәэсирлелеге чараларын (сөйләмнең тоны, тавыш тембры, темп, басым, тавышның көче, интонация) үзләштерүне күздә тота;

• **сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру.** Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру сөйләмнең морфологик ягын (сүзләрнең сан һәм килешләр буенча үзгәреше), сүз ясалышы һәм синтаксис ысулларын (сүзтезмәләрнең һәм җөмләләрнең төрле типларын үзләштерү) үстерүне күздә тота;

• **бәйләнешле сөйләмне үстерү.** Бәйләнешле сөйләмне үстерү диалог (сөйләшү) һәм монолог сөйләмнәрен үстерүне үз эченә ала. Диалог сөйләме — мәктәпкәчә яшьтәге балаларның төп аралашу формасы. Баланы диалог алып барырга өйрәтү, үзенә юнәлтелгән сөйләмне тыңлау һәм аңлау, әңгәмәгә кереп китү һәм аны дәвам итү, сорауларга җавап бирү һәм үзе сорау бирү, аңлату, төрле тел чараларын куллану, үз-үзен аралашу ситуациясен исәпкә алып тота белү күнекмәләрен үстерү мөһим. Диалог сөйләмендә аралашуның катлаулырак монолог формасы, бәйләнешле текстларны тыңлый һәм аңлый белү, кабатлап сөйләү, фикерне мөстәкыйль рәвештә төрле типта белдерү өчен кирәкле күнекмәләрне үстерү шулай ук әһәмияткә ия;

• **тел һәм сөйләм күренешләрен элементар аңлау сәләтен формалаштыру** балаларны хәреф таныргa, укырга һәм язарга өйрәтүгә әзерләүне тәэмин итә;

• **фонематик ишетү сәләтен үстерү, кулның вак моторикасын үстерү.**

СМЧ балалар белән эшләүдә сөйләмне үстерү бурычларын конкретлаштыру шартлы характерда була, әлеге бурычлар үзара тыгыз бәйләнгән. Бу мөнәсәбәтләр телнең төрле берәмлекләре арасындагы бәйләнешләр белән билгеләнә. Мәсәлән, сүзлекне баета барып, без бер үк вакытта баланың сүзләрне дөрес һәм ачык итеп әйтүе, аларның төрле формаларын үзләштерүе, сүзләрне сүзтезмәләрдә, җөмләләрдә, бәйләнешле сөйләмдә

кулланы турында кайгыртабыз. Бәйләнешле сөйләмдә сөйләм үсешенең барлык башка мәсьәләләре (сүзлекне, грамматик төзелешне, фонетик якны формалаштыру) чагылыш таба. Анда баланың туган телне үзләштерүдәге барлык казанышлары күренә. Сөйләмнең төрле мәсьәләләрен хәл итүгә комплекслы якын килү нигезендә аларның үзара бәйләнеше сөйләм күнекмәләрен тагын да нәтиҗәлерәк үстерү өчен алшартлар тудыра.

Мәктәпкәчә яшьтәге СМЧ балаларның сөйләмен үстерү эшчәнлекнең барлык төрләрендә (уен, физик үсеш дәресләре, сынлы сәнгать (рәсем ясау, әвәләп ясау, аппликация, конструкцияләү), музыка һ.б.); ирекле эшчәнлектә, бала тирәлегендәге барлык затлар белән аралашуда гамәлгә ашырыла. Матур әдәбият уку сөйләм үстерү эшенең аеруча мөһим өлеше булып тора. Кешеләрнең рухи байлыклары хәзинәсе буларак, матур әдәбият СМЧ балаларның әйләнә-тирәдәге кешеләр белән аралашуының җитәрлек күләмдә булмавын тулыландырырга, дөньяга карашны киңәйтергә, тормыш тәҗрибәсен һәм әхлакый тәҗрибәне баетырга мөмкинлек бирә.

Әдәби әсәрләр балаларны кешеләрнең гамәлләре, төрле вакыйгалар турында уйлануларга җәлеп итә; аларны бәяләүгә этәрә, эмоциональ өлкәне баета. Матур әдәбият уку коррекцион юнәлештә бара, чөнки ул балаларның сүзле сөйләмне үзләштерүен, телгә осталыгын, сөйләм эшчәнлеге үсешен стимуллаштыра.

Төрле дәрәҗәдәге сөйләм сәләтенә ия СМЧ балаларның сөйләм телен камилләштерү шартларны үтәгәндә нәтиҗәлелеккә ирешә:

• әсәрләрне аларның аңлаешлык дәрәҗәсен һәм эчтәлекләренең балаларның тормыш тәҗрибәсенә якынлыгын исәпкә алып сайлау;

• башта балалар белән кешеләр тормышының әдәби әсәрләрнең эчтәлегенә якын вакыйгалары турында сөйләшү һәм әсәрне үзләштерү, сәбәп-нәтиҗә бәйлелеге турында фикерләү дәрәҗәсен ачыклау өчен йомгаклау әңгәмәсе уздыру;

• әсәрләргә ярашлы иллюстрацияләр, рәсемнәр сайлау, макетлар ясау;

• уен-тамашалар, сәхнәләштерүләр оештыру;

• хәрәкәтчән фигуралар кулланып, конструкцияләнгән картина (рәсем) буенча гамәлләр күрсәтү;

• сүзлек белән эшләү;

• баланың сөйләм үсеше дәрәҗәсен исәпкә алып, текстларны лексик һәм грамматик төзелешләре буенча яраклаштыру (сөйләм, ишетү интеллектуаль тайпылышлары булган балалар өчен);

• балаларга сорауларга җавап бирергә тәкъдим итү;

• балаларга төрле төрдәге эшләр — укылган текстка карата иллюстрацияләр сайларга, укылган текстны сөйләргә; бирелгән текстның ахырын уйлап чыгарырга тәкъдим итү. Боларның барысы да әдәби әсәрнең эчтәлеген фикерләргә ярдәм итә.

Ишетү, күрү сәләтләре, терәк-хәрәкәт аппараты, сөйләм, эмоциональ-ихтыяри өлкә, интеллект тайпылышлары сөйләм теленең төрле дәрәҗәсен билгели. Бу һәр СМЧ баланың сөйләмен үстерү эшен проектлаганда нигез булып тора.

Интеллектуаль тайпылышлары булган балалар өчен сүзлек эше аерым әһәмияткә ия, ул әйләнә-тирә тормыш белән таныштыру нигезендә алып барыла. Аның бурычлары һәм эчтәлеге балаларның танып белү мөмкинлекләрен исәпкә алып билгеләнә, алар сүзләрнең мәгънәләрен элементар төшенчәләр дәрәҗәсендә үзләштерүне күздә тоталар. Балалар сүзлеге үсешендә иң әһәмиятлесе — сүзләрнең мәгънәләрен үзләштерү һәм аларны әйтелүче фикер контекстына, аралашу барган ситуациягә ярашлы рәвештә урынлы куллану.

Күрү анализаторының эшчәнлеге бозылган балаларда сөйләм үсешенең үзгәлеге күзәтелә. Бу үзгәлек сөйләмнең этаплап үсешенең тагын да акрынайган темпында, охшату эшчәнлегенең мөмкинлекләре чикләнүдә, сүз һәм аның нәрсә белдерүен күзаллау арасында тәңгәллек булмауда чагыла. Шуңа күрә сөйләмне үстерү эшендә сүзләрнең мәгънәләрен ачыклауга һәм аларга төгәллек кертүгә, сүзләрнең чынбарлык объекты белән предметлы яраклаштырылуына аерым игътибар бирелә.

Ишетү анализаторы бозылган балаларның сөйләмен үстерү эше аерым бер төрле рәвештә оештырыла. Ишетү сәләте бозылуның авазлы-сүзле сөйләмне үзләштерүдә төп каршылык булуы мәгълүм. Ишетү сәләте бозылган баланың сөйләмне үзләштерүе өчен сиземләү базасын бәяләгәндә күрү, тою, хәрәкәт һәм калдык ишетү анализаторларының һәрберсенең мөмкинлекләрен исәпкә алу зарур. Күрү анализаторы аеруча мөһим роль уйный; аның ярдәмендә бала сөйләм органнарының кайбер хәрәкәтләрен аңга кабул итәргә, димәк, аңа юнәлтелгән сөйләмне яхшырак аңларга мөмкин. Биремнәрне башкарганда, үзара яхшырак аңлашу өчен, график алымнар — билгеле бер предметларны белдерүче сүзләр язылган табличкалар, табличка-күрсәтмәләр кулланыла. Ишетү сәләте бозылган балаларның сөйләм эшчәнлеге төрле формаларда — ишетеп-күреп һәм ишетү аша кабул итеп сөйләү, уку (глобаль һәм аналитик), язу, бармаклар ярдәмендә сөйләшү рәвешендә гамәлгә ашырыла. Сөйләм эшчәнлегенең әлеге төрләре сөйләмле аралашу процессында багланышларның төп төрләре буларак карала.

Ишетү сәләте бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту процессында сөйләм эшчәнлегенең һәр төренә аерым игътибар бирелә, аралашу ихтыяҗларыннан чыгып, аларның дөрес нисбәте һәм эзлеклелеге исәпкә алына.

Сөйләмнең аваз үзенчәлекләрен просодик берәмлекләр — сүз басымы, интонация (сөйләмнең аһәңлелеге, тавыш көче, сөйләм темпы) чагылдыра. Алар терәк-хәрәкәт аппараты бозылган (БЦП) минималь дизартрия тайпылышлары булган балалар белән махсус логопед эшенең аерым катламын тәшкил итәләр.

Сөйләм сәләте бозылган балалар өчен әлеге белем бирү өлкәсе буенча эшне индивидуаль рәвештә оештыру зарур.

Барлык категорияләрдәге СМЧ балалар өчен сөйләмдә авазларны әйтә белүне тәрбияләү, грамматик төзелешне үзләштерү, бәйләнешле сөйләм үстерү зур катлаулылык тудыра. Мәсәлән, грамматик категорияләр абстрактлык һәм читләшкәнлек белән характерлана. Норма буенча балалар

грамматик төзелешне гамәли рәвештә, өлкәннәрнең сөйләменә охшату һәм гомумиләштерүләр юлы белән үзләштерәләр. СМЧ балаларның бәйләнешле сөйләмен үстерү, грамматик формаларны үзләштерүләре өчен махсус шартлар тудыру — грамматик схемалар, төрле күрсәтмә дидактик материаллар булдыру, предметлы-гамәли эшчәнлеккә керешү һ.б. зарур. СМЧ балаларның төрле категорияләрендә күзәтелә торган авазлар әйтелешендәге тайпылышлардан белгеч ярдәмендә генә арынырга мөмкин.

## «Сәнгати-эстетик үсеш» белем бирү өлкәсе

Төп бурыч — балаларда дөньяга карата эстетик мөнәсәбәт формалаштыру, эстетик күзаллаулар һәм образлар туплау, эстетик зәвык, сәнгать мөмкинлекләрен үстерү, сәнгать эшчәнлегенең төрле төрләрен үзләштерү. Әлеге юнәлештә гомуми белем бирү һәм коррекцион бурычлар хәл ителә; аларны гамәлгә ашыру СМЧ балаларның сиземләү сәләтләре, ритм, төс, композиция тойгысы; шәхси иҗади сәләтләрне сәнгати образларда чагылдыру осталыгы үсешен стимуллаштыра.

Әлеге белем бирү өлкәсендә балалар белән эшләүнең төп юнәлешләре:

**«Сәнгати иҗат».** Төп максат — балаларны иҗат эшләре тудырырга өйрәтү. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны сурәтләү эшчәнлегенең төрле төрләренә өйрәтү алымнарының үзенчәлеге аларның психофизиологик үзенчәлекләренә җавап бирүче чараларны куллануга исәпләп корылырга тиеш.

Әвәләп ясау кулларның вак моторикасы үсешенә булышлык итә, башкарылучы хәрәкәтләрнең төгәллеген үстерә, эш процессында балалар төрле материаллар, аларның үзлекләре белән танышалар. Аппликация конструкцияләү мөмкинлекләре үсешенә, форма, төс турында күзаллаулар формалаштыруга булышлык итә. Рәсем ясау кулларның манипулятив (катлаулы хәрәкәтләр) эшчәнлеген, координациясен үстерүгә, мускулларын ныгытуга юнәлдерелә.

Баланың күрү, ишетү, хәрәкәтләнү өлкәсе сәләтләренең саклану дәрәҗәсенә бәйле рәвештә максималь чиктә кулланырга уңайлы (зурлык, форма, күләм, төс, контрастлык) төрле планлы инструментлар сайларга, материалларны тәкъдим итү ысулларын (күрсәтү, биремнәр тексты яки предмет атамалары язылган табличкалар куллану, аңлатуларның сүзле-ишарәле формасы, сүзләр белән телдән аңлату) уйларга; күрсәтмәләрнең ярашлы формаларын сайларга кирәк.

БЦП авырулы балалар белән эшләгәндә, вак моторика җитешсезлеге тәэсирен киметүгә юнәлдерелгән түбәндәге шартларны үтәү зарур:

• баланы мускуллар тонусын нормальләштерүгә, киеренкелекне киметүгә ярдәм итүче уңайлы позада утырту;

• БЦП тайпылышлары булган һәр баланың әйдәүче кулын билгеләү;

• гиперкинезларны киметү өчен баланың кул чугын ныгытып беркетү (аерым очракларда баланың кулына беләзекләр — авырайткычлар кидерү таләп итела) кебек алымнарны куллану зарур;

• эшнең барлык этапларында актив-пассив алым киң кулланыла (өлкән кеше үз кулы белән бала кулына булыша).

**«Музыкаль эшчәнлек».** Төп максат — балаларның музыка тыңлавы, җырлау, музыкаль-ритмик хәрәкәтләр ясау, биюләр, музыка уен коралларында уйнау. СМЧ балалар контингенты дефектлар чагылышы һәм теге яки бу функцияләрнең саклану дәрәҗәсе буенча бертөрле генә түгел, шуңа күрә музыка уен кораллары яңгырашын ишеттерү ысулларына (ишетү сәләте бозылган балалар өчен), бию хәрәкәтләренә, аларда уйнау өчен музыка уен коралларына (хәрәкәт тайпылышлары булган балалар өчен) игътибар итәргә кирәк.

## «Физик үсеш» белем бирү өлкәсе

Төп максат — формалашучы организмның функцияләрен камилләштерү, хәрәкәт күнекмәләрен, кулның нечкә моторикасын, күрү-тирәлек координациясен үстерү. Физик үсеш баланың гаиләдәге һәм мәктәпкәчә учреждениедәге барлык тормышын оештыруның нигезендә ята. Бу предметлы һәм социаль тирәлеккә, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, балалар эшчәнлегенең барлык төрләренә кагыла. Режимда физкультура дәресләре, ачык һавадагы уеннар һәм күңел ачулар каралырга тиеш; аларны уздырганда төбәк һәм климат шартлары исәпкә алына.

Физик тәрбия эше гомуми һәм коррекцион бурычлар хәл ителерлек итеп корыла. Төп бурыч — тормыш эшчәнлеген тәэмин итүгә, организмны үстерүгә һәм камилләштерүгә юнәлтелгән кирәкле хәрәкәтләнү күнекмәләрен, физик сыйфатларны һәм сәләтләрне формалаштырып, организмдагы позитив үзгәрешләрне стимуллаштыру.

Физик культура дәресләрендә белем бирү һәм сәламәтләндерү бурычлары белән бергә махсус коррекция бурычлары хәл ителә; алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

• физик тәрбия процессында тирәлек һәм вакыт турында күзаллаулар формалаштыру;

• предметлы эшчәнлек процессында материалларның төрле үзлекләрен, шулай ук предметларның кулланылышын өйрәнү;

• хәрәкәт аша сөйләм үстерү;

• хәрәкәт эшчәнлеге процессында танып белү эшчәнлегенең төрле төрләрен формалаштыру;

• баланың эмоциональ даирәсе белән идарә итү, шәхеснең махсус хәрәкәт дәресләре, уеннар, эстафеталар процессында формалашучы әхлакый-ихтыяри сыйфатларын үстерү.

Эш эчтәлегенә физик күнегүләр: шеренгага (сызык буйлап), колоннага бер-бер артлы, түгәрәккә тезелү; йөрү; йөгерү, сикерүләр; үрмәләү; шуышу; ыргыту; җилкә, кулбаш поясы һәм аяклар мускулларын ныгытучы, хәрәкәтләрне координацияләүче, гәүдәнең дөрес торышын формалаштыручы, тигезлек саклау сәләтен үстерүче гомуми үсеш күнегүләре кертелә. Хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерүгә, балалар арасындагы бәйләнешләрнең уңай формаларын булдыруга юнәлтелгән хәрәкәтле уеннар уйнарга тәкъдим ителә.

Хәзерге вакытта физик үсеш дәресләре системасына СМЧ балалар өчен адаптив физик культура (АФК) — спорт-сәламәтләндерү характерындагы, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне тернәкләндерүгә һәм нормаль социаль тирәлеккә җайлаштыруга, тулы сыйфатлы тормышны тоярга комачаулаучы психологик киртәләрдән арынуга, шулай ук җәмгыятьнең социаль үсешенә үзеңнең шәхси өлешеңне кертү зарурлыгын аңлауга юнәлтелгән чаралар комплексы кертелә. Адаптив физкультура дәвалау, гомуми ныгыту, тернәкләндерү, профилактика һ.б. эффектларны тәэмин итә. Адаптив физик культура алдында торган төп бурычлар:

• балада, сәламәт яшьтәшләренең көчләре белән чагыштырганда үз көченә карата аңлы мөнәсәбәт формалаштыру;

• тулы сыйфатлы тормышка комачаулаучы физик киртәләрне генә түгел, психологик каршылыкларны да җиңү сәләтләрен үстерү;

• компенсацияләү күнекмәләре, булмаган яки бозылган органнар урынына төрле система һәм органнарның функцияләрен файдалану сәләте формалаштыру;

• җәмгыятьтә тулы сыйфатлы яшәү өчен кирәкле физик йөкләнешләрне җиңү сәләтен үстерү;

• мөмкин кадәр сәламәт булу һәм сәламәт яшәү рәвеше алып бару ихтыяҗы; акыл эшенә һәм физик эшкә сәләтлелек формалаштыру;

• җәмгыять тормышына үзеңнең шәхси өлешеңне кертү зарурлыгын аңлау сәләте формалаштыру;

• үзеңнең шәхес буларак сыйфатларыңны яхшырту теләге формалаштыру.

АФК физик активлыкның һәм спортның үсешләрендә проблемалар булган балалар мәнфәгатьләренә туры килүче һәм аларның мөмкинлекләрен киңәйтүгә булышлык итүче барлык төрләрен берләштерә. АФКның максаты — физик активлык һәм спорт аркылы СМЧ балалар тормышының сыйфатын яхшырту. Төп бурыч баланың үзен үзгәртү, шул ук вакытта аңа сәламәтрәк, активрак тормыш рәвеше алып бару, спорт белән шөгыльләнү өчен сәламәт яшьтәшләре белән тигез мөмкинлекләр булдыру юнәлешендәге киртәләрдән арындырырлык итеп, әйләнә-тирә мохитне үзгәртү юлы белән конкрет психомоторика проблемаларын хәл итүдән гыйбарәт.

Тәрәк-хәрәкәт аппараты тайпылышлары булган (БЦП) мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен физик тәрбия дәресләре системасы индивидуаль рәвештә (дәвалау физкультурасы (ДФК) инструкторы белән бергә) эшләнә. Баланы беренче мәртәбә кабул иткәндә, физкультура буенча тәрбияче катнаша. Ул ДФК инструкторы белән бергә медицина документларын (авыру тарихын өйрәнә, ортопед, невролог, стационар табиблары тәкъдимнәрен һ.б.) анализлый, ата-аналар белән аралаша, ирекле халәттәге баланы күзәтә. ДФК инструкторы белән берлектә төп неврологик синдромнар — моторика функциясе, кулларның халәте, тоник рефлекслар буенча хәрәкәт статусы билгеләнә. Шуннан соң баланы тикшерүнең беренчел беркетмәсе тутырыла, беркетмәдә баланың хәрәкәт статусы җентекләп тасвирлана. Икенче этапта комплекслы тикшерү оештырыла, аның нәтиҗәләре картага кертелә. Шуннан чыгып, хәрәкәтләнү күнекмәләрен формалаштыру буенча һәр бала өчен индивидуаль программа эшләнә.

Программада хәрәкәтләнү һәм ортопедик режим (йөрү, кулларның һәм бармакларның халәтен коррекцияләү, башны тотып тору өчен төрле ортопедик җайланмалардан файдалану), йөкләнешләрне өлешләргә бүлү билгеләнә, теге яки бу алымны куллануга карата каршылыклар күрсәтелә.

Физик тәрбия эше барышында барлык белгечләрнең тәкъдимнәре исәпкә алына. БЦП авырулы бала өчен гомуми хәрәкәтләнү режимы мөһим. Ул бер үк төрле позада 20 минуттан да артык утырырга тиеш түгел. Һәр бала өчен индивидуаль рәвештә иң отыш позалар сайлап алына. Балалар белән эшләү процессында физкультура минутлары, физкультура паузалары файдаланыла. Буш вакытта балалар массакүләм физкультура чараларында, интеграцион (үзара якынайтучы, туплаучы) спорт бәйрәмнәрендә, күңел ачуларда катнашалар. Бала катнашында үткәреләчәк барлык чаралар белгечләр консилиумында тикшерелә. Церебраль параличлы балаларны физик тәрбияләүнең максаты — коррекцияләүче физик күнегүләр һәм махсус хәрәкәтләнү режимнары ярдәмендә көнкүрештә, укуда һәм социаль мохиттә балаларның тормыш шартларына уңышлы җайлашуы, аларның җәмгыятьтә интеграцияләнүе өчен шартлар тудыру. Тәрәк-хәрәкәтләнү аппараты тайпылышлары булган балаларның физик үсеше буенча программалар эшләгәндә, М.В. Ипполитова, И.Ю. Левченко, Е.М. Мастюкова, О.Г. Приходько һ.б. хезмәтләренә таянырга кирәк.

Күрсәтелгән белем бирү өлкәләре тулаем гомуми үсеш бурычларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәләр. Шул ук вакытта һәр эшчәнлек төренең үз коррекцион бурычлары һәм аларны хәл итүнең тиешле алымнары бар. Бу СМЧ балаларның уртак һәм турыдан-туры тайпылышлар белән бәйле үзенчәлекләре булу белән аңлатыла.

Тәрбия һәм белем бирү программаларында эшнең төп юнәлешләрдәге эчтәлеге махсус коррекцион өлкәләрдәгеләр белән яраклаша. Мәсәлән, эмоциональ тайпылышлы балалар аларның эшчәнлек өлкәсен коррекцияләүгә, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән үзара бәгланыш күнекмәләре формалаштыруга юнәлтелгән махсус мөнәсәбәткә мохтаҗлык кичерәләр.

Сиземләү, хәрәкәтләнү сәләтләре бозылган очраклар өчен программа эчтәлегенә «Күреп кабул итүне үстерү» (күрү сәләтендә тайпылышлар булган балалар өчен), «Ишетеп кабул итүне үстерү һәм дөрес әйтелешкә өйрәтү» (ишетү сәләтендә тайпылышлар булган балалар өчен), «Гомуми хәрәкәтләрне үстерү һәм коррекцияләү, кул чукларының һәм бармакларның физиологик мөмкинлекләрен камилләштерү» (хәрәкәтләнү өлкәсендә җитешсезлекләре булган балалар өчен) кебек коррекцион бүлекләр кертелә.

## СМЧ балаларны тәрбияләү һәм укыту шартлары

Мәктәпкәчә балалык чоры — СМЧ баланың беренче иҗтимагый белем бирү системасына — мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү өлкәсенә кушылу вакыты. Интеграцияне уңышлы тормышка ашыру өчен, мәктәпкәчә балалык чорында СМЧ балаларны тәрбияләү һәм белем бирү махсус шартларын үтәү, аларга каршылыксыз тормыш эшчәнлеге тирәлеген оештыру сорала.

Мәктәпкәчә учреждениедә белем бирү эшчәнлеге процессында индивидуаль һәм дифференцияле мөнәсәбәтне сыгылмалы яраштыру мөһим; бу коллектив тормышында барлык балаларның да катнашуына булышлык итә.

Коррекцион-педагогик эшнең нәтиҗәлелеген күтәрү шартларының берсе — баланың мөмкинлекләренә тәңгәл педагогик-сак һәм предметлы-үсешкә китерүче мохит, ягъни балалар эшчәнлегенең бөтен төрләренең тулы үсешен, югары психик функцияләре тайпылышларын коррекцияләүне һәм бала шәхесен формалаштыруны тәэмин итүче шартлар системасы (мәдәни ландшафтлар, физкультура-уен һәм сәламәтләндерү корылмалары, предмет-уен мохите, балалар китапханәсе, уен бүлмәсе, музыка-театр мохите) булдыру.

СМЧ мәктәпкәчә яшьтәгеләрне тәрбияләү һәм белем бирү коррекцион-үсешкә китерүче эшнең формаларына үзгәрешләр кертүне күздә тота. Күпчелек балалар өчен моторика кыенлыклары, хәрәкәт тоткарлыгы, түбән эш сәләте хас, болар белем бирү эшчәнлеген һәм көндәлек режимны планлаштыруга үзгәрешләр кертүне таләп итә. Көндәлек режимда гигиена процедураларына, ашауга бирелгән вакытны арттыру каралырга тиеш. Коррекцион-белем бирү эшенең оештыру формаларын — төркемле, кечкенә төркемле, индивидуаль формаларын киң төрлеләндерү күздә тотыла.

СМЧ балаларның күбесенә баштарак җайлашу (адаптация) чоры кирәк. Җайлашу — интеграция тирәлегенә кергәндә кыенлыклар кичерүче элемтәгә керми, ата-аналарын үзеннән җибәрми, ризыктан, уенчыклардан баш тарта һ.б. баланың яраклашу реакцияләренең бер өлеше булып тору. Бу чорда тәрбияче мәктәпкәчә яшьтәге баланы стресстан коткарырга, уңай эмоциональ халәтен тәэмин итәргә, тыныч тирәлек тудырырга, бала һәм аның ата-анасы белән элемтәне көйләргә тиеш.

СМЧ балаларны тәрбияләү һәм белем бирү процессын массакүләм балалар бакчасы кысаларында оештыруның иң мөһим шарты булып аны махсус җиһазлар белән тәэмин итү тора:

• терәк-хәрәкәт системасында тайпылышлар булган балалар өчен култыксалы махсус кресло, махсус өстәлләр, гәүдә торышын дөресләүче җайланмалар (реклинаторлар); пандус булу карала;

• күрү сәләте бозылган балалар өчен тоемларга һәм төрле манипуляцияләр ясарга мөмкинлек бирүче махсус оптик чаралар (күзлек, лупа, линзалар һ.б.); тоемлана торган (тактиль) панельләр (төрле текстурадагы материал җыелмалары). Балаларның күрү сәләтен саклау буенча гигиена чараларының нигезендә бүлмәне һәм эш урынын рациональ яктырту ята;

• ишетү сәләте бозылган балалар өчен колак аппаратлары һәм башка техник җайланмалар булу зарур.

Коррекцион чараларны оештыру һәм үткәрү өчен дидактик материалның кайбер үзенчәлекләрен белергә: күрү сәләте бозылган балалар өчен материал сайлаганда аның үлчәмнәрен, төсләр контрастын исәпкә алырга кирәк; терәк-хәрәкәт тайпылышлары булган балалар өчен күренеп тора, җиңел тоемлана торган өслек сайлау отышлы.

СМЧ балаларның мөмкинлекләренә карап укыту алымнары билгеләнә. Эшне планлаштырганда иң аңлаешлы методларны — күрсәтмә, гамәли, телдән сөйләү алымнарын файдалану мөһим. Психологлар материалны өйрәнү процессында кулланылган анализаторлар саны күбрәк булган саен белемнәрнең шулкадәр тулырак, ныклырак булуын раслыйлар. Альтернатив алымнар сайлау укыту процессының нәтиҗәлелегенә ярдәм итүче шартлар тудыра.

Методлар һәм методик алымнар системасын рациональ сайлау мәсьәләсе һәр конкрет очракта педагог тарафыннан хәл ителә. Мәсәлән, ишетү сәләте бозылган, интеллектуаль тайпылышлы балалар үсешенең үзенчәлекләренең берсе — төшенчәләрнең бик акрын формалашуы. Бу төшенчәләрнең асылын ачуга ярдәм итүче төрле күрсәтмә чараларны демонстрацияләү хисабына гомумиләштерүнең сиземләү нигезен көчәйтү кирәклеген алга куя.

Гамәлләрнең, күренешләрнең мәгънәсен тирәнрәк аңлау өчен — күрсәтмә-гамәли методлар; предметлар турында белемнәрне төгәлләштерү өчен язма сөйләм (табличкалар), дактилалогия киң кулланыла. Күрүе зарарланган балаларга карата иң киң таралганы — телдән сөйләү методы, аны программа материалын аңлатканда гамәли метод белән яраштырырга тәкъдим ителә.

Программа СМЧ балалар тарафыннан тулысынча үзләштерелә алмаганда, тәрбия һәм укытуның индивидуаль программалары проектлана. Индивидуаль программаны проектлаганда берничә принципка таянырга кирәк:

• мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең мөмкинлекләренә, ягъни СМЧ балаларның индивидуаль-психологик, клиник үзенчәлекләренә ориентлашу принцибы;

• өйрәнелә торган материалның күләмен өлешләргә бүлү принцибы. Үзләштерү темпы акрын булу сәбәпле, программа материалы күләмен про-

грамманың бөтен бүлекләре буенча регламентацияләү һәм аерым темаларны өйрәтү өчен вакытны рациональрәк файдалану;

• сызыклылык һәм тупланганлык принцибы. Программаны сызык буенча корганда, темаларны системалы, катлаулылыгы дәрәҗәсенә һәм күләм артуга карап эзлекле урнаштыру сорала; программаны тупланганлык принцибы буенча төзегәндә, материал үткән темага кире кайту юлы белән кабатлана. Бу материалны ныграк үзләштерергә мөмкинлек бирә;

• программа эчтәлеген үзгәртүне, бүлекләрне катнаштыру, аерым очракларда темаларны өйрәнүдә эзлеклелекне үзгәртү, төзәтмәләр кертүне күздә тоткан инвариантлык принцибы.

СМЧ балалар өчен программага әйләнә-тирә дөнья турында күзаллаулар һәм белемнәрне элементар формада тутыру мөмкинлеге бирүче пропедевтик бүлекләр кертү максатка ярашлы. СМЧ балаларның аерым үсеш үзгәлекләренә ия кайбер категорияләре өчен инновацион технологияләр, оригиналь методикалар, предметлар куллануны кертү күздә тотыла. Мәсәлән, сөйләмендә, акылында, ишетүендә зур тоткарлыклар булган балалар белән эшләгәндә, аралашуның вербаль булмаган чаралары — пиктограммалар, ишарәләр системасы, календарь системасы (күренеш — символ) кулланыла.

Әгәр физик, психик тайпылышларның көчле булуы аркасында СМЧ балалар өчен белем бирү өлкәләренең күбесен үзләштерү мөмкин булмаса, тәрбияләнүчеләрне социализацияләүгә юнәлтелгән һәм эмоциональ халәтне нормальләштерүгә, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, уен гамәлләре, предметлы эшчәнлек, социаль-көнкүреш ориентациясе күнекмәләре формалашуга ярдәм итүче индивидуаль программалар эшләнә.

СМЧ баланы сәламәт яшьтәшләре мохитенә уңышлы алып керүнең мөһим компоненты булып педагогларны мәктәпкәчә учреждение белгечләре өчен квалификация күтәрү программалары, ата-аналарның компетентлыгын арттыру программалары ярдәмендә интегратив процесска әзерләү тора.

Ата-аналарны белгечләр, педагоглар белән бергә уртак эшчәнлеккә кертү ата-аналарны этаплап педагогик технологияләргә өйрәтүне күздә тота, чөнки алар үзләренең СМЧ балалары өчен белем бирү хезмәтләренең төп заказчылары булып торалар.

Ата-аналарның бурычы баланың тормышын ул үзен җәмгыятьнең бер кисәге сыйфатында тоярлык итеп оештырудан гыйбарәт.

# ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ

# 2 АЙДАН 1 ЯШЬКӘ КАДӘРГЕ БАЛАЛАРНЫҢ КӨН ТӘРТИБЕ ҮРНӘГЕ
(сабыйлар төркеме)

## Көндәлек режим үрнәге

Балалар тормышының беренче елы бер-берсеннән сыйфат ягыннан аерылып торучы дүрт яшь чорына бүленә: туганнан алып 2–3 айга кадәр; 2–3 айдан 5–6 айга кадәр; 5–6 айдан 9–10 айга кадәр; 9–10 айдан 12 айга кадәр.

Һәрбер яшь чоры өчен балаларның физиологик ихтыяҗларын һәм физик мөмкинлекләрен исәпкә алучы режим каралган.

Режим бер тәүлеккә билгеләнә һәм баланың өй шартларындагы режимы белән яраштырыла. Ул ата-аналар тарафыннан эш көннәрендә дә, ял көннәрендә дә төгәл үтәлергә тиеш.

Баланың көн дәвамында эмоциональ яктан уңай халәте, аның әйләнә-тирә чынбарлыкны кабул итүенең уңышы тулы кыйммәтле һәм вакытында ашатуга, сыйфатлы һәм җитәрлек вакыт йоклавына, педагогик яктан белеп оештырылган уяулык халәтенә бәйләнгән. Йокы, ашату, уяулык халәтен, чиратлаштыруның билгеле бер эзлеклелеген сакларга кирәк (9–10 айдан мондый эзлеклелек өлешчә саклана).

**Тәүлек дәвамында йокының, уяулык халәтенең дәвамлылыгы һәм ашатулар саны**

| Яшь | Ашату | | Уяулык вакыты | Көндезге йокы | |
|---|---|---|---|---|---|
| | саны | интервал, сәг. | озынлык, сәг. | кабатлану саны | озынлык, сәг. |
| 1–3 ай | 7 | 3 | 1–1,5 | 4 | 1,5–2 |
| 3–5–6 ай | 6 | 3,5 | 1,5–2 | 3–4 | 1,5–2 |
| 5–6–9 ай | 5 | 4 | 2–2,5 | 3 | 1,5–2 |
| 9 ай –1яшь | 4–5 | 4–4,5 | 2,5–3 | 2 | 2–2,5 |

Төнге йокының озынлыгы даими (10–12 сәгать). Сабыйлар төркемендә тәрбияләнүчеләр ике (кайчак өч) режим буенча яшиләр, бу балаларның тыгызлыгын булдырмаска мөмкинлек бирә, каршылыклы хәлләр килеп чыгуын кисәтә, тәрбия-сәламәтләндерү эшенең сыйфатын арттырырга булыша. Балаларның зур булмаган төркеме белән эшләү һәр балага индивидуаль мөнәсәбәт булдыруны тәэмин итә.

| | Туганнан 2–3 айга кадәр | 2–3 тән 5–6 айга кадәр | 5–6 дан 9–10 айга кадәр | 9–10 нан 12 айга кадәр |
|---|---|---|---|---|
| **Өйдә** | | | | |
| Уянуга карап тору | | | | |
| Уяулык халәте | 6.00 –7.00 | 6.00–7.30 | 6.00–8.00 | 6.30–9.00 |
| Ашату | 6.00 | 6.00 | 6.00 | – |
| **Өйдә** | | **Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында** | | |
| Балаларны кабул итү | – | – | 7.00–8.00 | 7.00–8.00 |
| Саф һавада йокы | 7.00–9.00 | 7.30–9.30 | 8.00–10.00 | – |
| Ашату | 9.00 | 9.30 | 10.00 | – |
| Уяулык халәте | 9.00–10.00 | 9.30–11.00<br>10.00–12.00 | 10.00–10.30 | – |
| Уен-дәресләр | 9.30–9.40 | 10.00–10.30 | 10.30–11.30 | 8.00–8.40 |
| Саф һавада йокы | 10.00–12.00 | 11.00–13.00 | 12.00–14.00 | 9.00–11.30 |
| Ашату | 12.00 | 13.00 | 14.00 | 11.30 |
| Уяулык халәте | 12.00–13.00 | 13.00–14.30 | 14.00–16.00 | 11.30–14.00 |
| Уен-дәресләр | 12.20–12.40 | 13.30–4.00 | 14.30–15.30 | 12.00–13.30 |
| Саф һавада йокы | 13.00–15.00 | 14.30–16.30 | 16.00–18.00 | 14.00–16.00 |
| Ашату | 15.00 | 16.30 | 18.00 | 16.00 |
| Балаларны өйгә озату | – | – | 15.00–19.00 | 16.00–19.00 |
| **Өйдә** | | | | |
| Уяулык халәте | 15.00–16.00 | 16.30–18.00 | 18.00 –20.00 | 16.00 –20.00 |
| Йокы | 16.00–18.00 | – | – | – |
| Ашату | 18.00 | – | – | 19.00 |
| Уяулык халәте | 18.00–19.00 | – | – | – |
| Йокы | 19.00–20.00 | 18.00 –19.30 | – | – |
| Уяулык халәте | 20.00–21.00 | 19.30 –21.00 | – | – |
| Коендыру | 20.45 | 20.30 | 19.45 | 19.45 |
| Ашату | 21.00 | 20.45 | – | – |
| Төнге йокы | 21.00–6.00 | 21.00–6.00 | 20.00–6.00 | 20.00–6.30 |
| Төнге ашату | 24.00 (3.00) | 23.30 (3.00) | 22.00 (3.30) | 23.00 (10 айга кадәр) |

Яңа режимга күчерү баланың яшенә, сәламәтлеге торышына һәм үз-үзен тоту үзенчәлекләренә карап гамәлгә ашырыла.

Баланы үзеннән өлкәнрәкләр төркемчәсенә алданрак күчерү, шулай ук аны кече яшьтәгеләр режимында озаккарак калдыру һич ярамый.

Баланың уяулык халәтендә үз-үзен хәрәкәтчән, актив тотышы, яхшы аппетиты, әйбәт һәм җитәрлек вакыт йоклавы аның режимының яшь һәм индивидуаль мөмкинлекләренә ярашу күрсәткечләре булып тора.

# 1–2 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАРНЫҢ КӨН ТӘРТИБЕ ҮРНӘГЕ
## (беренче кече яшьтәгеләр төркеме)

### Көндәлек режим үрнәге

Яшәүләренең икенче елында балалар психофизиологик үзенчәлекләр буенча ике төркемчәгә бүленәләр: беренчесе — 1 яшьтән 1 яшь 6 айга кадәр; икенчесе — 1 яшь 6 айдан 2 яшькә кадәр.

Актив уяулык халәтенең оптималь дәвамлылыгын һәм йокының озынлыгы буенча җитәрлек булуын тәэмин итүне исәпкә алып, балаларның һәр яшь төркемчәсенә үз режимы тәкъдим ителә.

Беренче төркемчәгә керүче балалар көндез ике тапкыр йоклыйлар, ә 1 яшь 6 айдан аларны көндез бер мәртәбә йоклатуга күчерәләр. Баланың төнге йокысы 10–11 сәгать дәвам итә.

Режимнар һәрбер төркемчәнең уяулык халәтен һәм йокы вакытын мөмкин булганча аерырлык итеп төзелгән (беренче төркемчәдәге балалар йоклаганда, икенче төркемчәдәгеләр йокламый, һәм киресенчә). Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге өчен бирелгән вакытны рациональ файдалану сорала.

Бер үк вакытта уяулык халәтендәге балаларның аз санлы булуы һәр балага игътибар итәргә, аның белән ешрак аралашырга, аның хәле, тәртибе, кәефе белән кызыксынырга һәм балаларга аларның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып йогынты ясарга мөмкинлек бирә.

Балаларны өлкән кеше ярдәмгә мохтаҗ бала белән мәшгуль булганда нәрсә белән булса да шөгыльләнергә өйрәтергә; вакытында эшчәнлек төрен алыштырырга ярдәм итәргә; уеннар һәм мөстәкыйль эшчәнлекнең башка төрләре вакытында балаларның уңай кичерешләрен тәэмин итәргә кирәк.

Һәрбер яшь төркемчәсе өчен елның салкын һәм җылы вакытына туры килә торган режимнар эшләнгән. Салкын чорда беренче төркемчәдәге балаларның уяулык халәте шөгыльләре бина эчендә оештырыла.

Йөрергә чыгу кичке якта каралган (ата-аналар белән). Икенче төркемчәдәге балалар көнгә 1–2 тапкыр йөрергә чыгалар (һава торышына бәйле рәвештә).

Елның җылы вакытында балаларның барлык төркемнәре белән эш балалар бакчасының махсус җиһазландырылган, яшелләндерелгән участогында оештырыла.

Бина эчендә ашату, йокы, гигиена һәм сәламәтләндерү-ныгыту процедуралары үткәрелә.

## Елның салкын вакыты өчен көндәлек режим үрнәге

| | 1 яшь–1 яшь 6 ай | 1 яшь 6 ай–2 яшь |
|---|---|---|
| **Өйдә** | | |
| Йокыдан тору, иртәнге юыну-киенү | 6.30–7.30 | 6.30–7.30 |
| **Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында** | | |
| Балаларны кабул итү, уен | 7.00–8.00 | 7.00–8.00 |
| Иртәнге ашка әзерлек, иртәнге аш | 7.30–8.30 | 7.30–8.30 |
| Мөстәкыйль эшчәнлек | 8.30–9.30 | 8.30–9.20 |
| 1 нче уен-дәрескә әзерләнү һәм уздыру (төркемчәләр буенча) | – | 8.50–9.00–9.10 |
| Йокыга әзерлек, 1 нче йокы | 9.30–12.00 | – |
| Һавада йөрүгә әзерлек, һавада йөрү | – | 9.10–11.20 |
| Һавада йөреп кайту, уеннар | – | 11.20–11.30 |
| Төшке ашка әзерлек, төшке аш | – | 11.30–12.00 |
| Акрынлап йокыдан тору, төшке аш | 12.00–12.30 | – |
| Йокыга әзерлек, йокы | – | 12.00–15.00 |
| Мөстәкыйль эшчәнлек | 12.30–14.30 | – |
| 1 нче уен-дәрескә әзерләнү һәм уздыру (төркемчәләр буенча) | 13.00–13.10–13.20 | – |
| 2 нче уен-дәрескә әзерләнү һәм уздыру (төркемчәләр буенча) | 15.50–14.00–14.10 | – |
| Йокыга әзерлек, 2 нче йокы | 14.30– 16.00 | – |
| Акрынлап йокыдан тору, җиңелчә аш | 16.00–16.30 | 15.00–15.20 |
| Мөстәкыйль эшчәнлек | 16.30–18.20 | 15.20–16.30 |
| 2 нче уен-дәрескә әзерләнү һәм уздыру (төркемчәләр буенча) | – | 16.00–16.15– 16.30 |
| Һавада йөрүгә әзерлек, һавада йөрү | – | 16.30–18.00 |
| Һавада йөреп кайту, мөстәкыйль эшчәнлек | – | 18.00–18.20 |
| Кичке ашка әзерлек, кичке аш | 18.20–18.40 | 18.20–18.40 |
| Мөстәкыйль эшчәнлек, өйгә кайтып китү | 18.40–19.00 | 18.40–19.00 |
| **Өйдә** | | |
| Һавада йөрү | 19.00–20.00 | 19.00–20.00 |
| Һавада йөреп кайту, тыныч уеннар, гигиена процедуралары | 20.00–20.30 | 20.00–20.30 |
| Йокыга әзерлек, төнге йокы | 20.30–6.30 (7.30) | 20.30–6.30 (7.30) |

## Елның җылы вакыты өчен көндәлек режим үрнәге

| | 1 яшь –1 яшь 6 ай | 1 яшь 6 ай –2 яшь |
|---|---|---|
| **Өйдә** | | |
| Йокыдан тору, иртәнге юыну-киенү | 6.30–7.30 | 6.30–7.30 |
| **Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында** | | |
| Балаларны кабул итү, мөстәкыйль эшчәнлек | 7.00–8.00 | 7.00–8.00 |
| Иртәнге ашка әзерлек, иртәнге аш | 7.30–8.30 | 7.30–8.30 |
| Мөстәкыйль эшчәнлек | 8.30–9.30 | 8.30–11.00 |
| 1 нче уен-дәрескә әзерләнү һәм уздыру (төркемчәләр буенча)[1] | – | 9.00–9.15–9.30 |
| Һавада йөреп кайту, йокыга әзерлек, 1 нче йокы | 9.30–12.00 | – |
| Һавада йөреп кайту, юыну процедуралары, төшке аш | – | 11.00–12.00 |
| Акрынлап йокыдан тору, төшке ашка әзерлек, төшке аш | 12.00–12.30 | – |
| Йокыга әзерлек, йокы | – | 12.00–15.00 |
| Һавада йөрү, мөстәкыйль эшчәнлек | 12.30–14.00 | – |
| 1 нче уен-дәрескә әзерләнү һәм уздыру (төркемчәләр буенча) | 13.00–13.10–13.20 | – |
| 2 нче уен-дәрескә әзерләнү һәм уздыру (төркемчәләр буенча) | 13.40–13.50–14.00 | – |
| Һавада йөреп кайту, юыну процедуралары | 14.00–14.30 | – |
| Йокыга әзерлек, 2 нче йокы | 14.30–16.30 | – |
| Акрынлап йокыдан тору, җиңелчә аш | 16.30–17.00 | 15.00–15.20 |
| Һавада йөрү, мөстәкыйль эшчәнлек | 17.00–18.30 | 15.20–18.30 |
| 2 нче уен-дәрескә әзерләнү һәм уздыру (төркемчәләр буенча) | – | 16.00–16.15–16.30 |
| Һавада йөреп кайту, кичке ашка әзерлек, кичке аш | 18.30–19.00 | 18.30–19.00 |
| Өйгә кайтып китү | 17.00–19.00 | 17.00–19.00 |
| **Өйдә** | | |
| Һавада йөрү | 19.00–20.00 | 19.00–20.00 |
| Һавада йөреп кайту, тыныч уеннар, гигиена процедуралары | 20.00–20.30 | 20.00–20.30 |
| Йокыга әзерлек, төнге йокы | 20.30–6.30 (7.30) | 20.30–6.30 (7.30) |

[1] Тәрбияче балаларның бер төркемчәсе белән уен-дәрес үткәргәндә, тәрбияче ярдәмчесе икенче төркемчә белән уйный тора. Уен-дәрес тәгәлләнгәннән соң, ярдәмче балаларны йокларга алып китә.

Баланы икенче төркемчә (1 яшь 6 айдан) режимына күчерү акрынлап бара. Күчерү өчен күрсәткечләр: балада уяулык халәтендә озаграк булуга ихтыяҗ үсә бару, йокларга салганда аның тәртибендәге үзгәрешләр, физик үсеше һәм сәламәтлек торышы.

## Сәламәтләндерү-ныгыту процедуралары

Табигый факторлар — һава, кояш, су ярдәмендә сәламәтләндерү-ныгыту процедураларын гамәлгә ашыру. Төркем бүлмәләрендә һаваның даими температурасын (+21–22°С) саклау. Бина эчендә балаларның киеме ике катлы булырга тиеш.

Йокы вакытында йокы бүлмәсендә температураның салкынча (+15–16°С) булуын тәэмин итү. Йокыдан торгач киендергәндә һәм көн дәвамында киемнәрен алыштырганда балаларны чыныктыруны гамәлгә ашыру.

Балалар белән, һава торышы нинди булуга карамастан, (кышкы чорда — –15°С) 4 сәгатькә кадәр һавада йөрү нәтиҗәле чыныктыру чараларының берсе булып тора. Явым-төшемле көннәрдә балалар белән түбәсе ябык верандага йөрергә чыгып, хәрәкәтле уеннар (куяннар күлләвектә сикерә, тычканнар мәчедән куркып өннәренә кача һ.б.) оештырырга мөмкин.

Елның җылы чорында һавага чыккач, балаларның аз гына вакыт (3–5 минут) туры төшкән кояш нурлары астында булуларын тәэмин итү. Керер алдыннан 2–3 минут җылы комда яланаяк йөрергә рөхсәт итү (алдан ук комның чисталыгын һәм куркынычсызлыгын тикшерү).

Җәйге чорда һавадан кергәннән соң гигиена һәм чыныктыру процедураларын юыну һәм аякларны юу белән яраштыру, бу очракта һәрбер баланың сәламәтлеге торышын һәм аның су тәэсиренә күнегү дәрәҗәсен исәпкә алу.

Махсус чыныктыру процедураларының характеры турындагы мәсьәлә мәктәпкәчә учреждение администрациясе һәм медицина хезмәткәрләре тарафыннан ата-аналарның теләкләрен исәпкә алып хәл ителергә тиеш.

# 2 ЯШЬТӘН АЛЫП МӘКТӘП ЯШЕНӘ КАДӘРГЕ БАЛАЛАРНЫҢ КӨН ТӘРТИБЕ ҮРНӘГЕ

## Көндәлек режим үрнәге

Дөрес көн тәртибе — тәүлек дәвамында балалар эшчәнлегенең төрле төрләренең һәм ялының рациональ дәвамлылыгы һәм уйлап чиратлаштырылуы. Көн тәртибен дөрес төзүдә аның балаларның яшенә карап психофизиологик үзенчәлекләргә туры килүе төп принцип булып тора. Көндәлек режимны баланың индивидуаль үзенчәлекләренә якынайтырга омтылырга кирәк.

Таблицада төрле яшь төркемнәре өчен көндәлек режим үрнәкләре китерелә. Көндәлек режим баланың балалар бакчасында 12 сәгать булуына исәпләп төзелгән. Баланың бакчада булу дәвамлылыгы башкача булган очракта мәктәпкәчә оешма көндәлек режимны мөстәкыйль төзи.

Көндәлек режимда дәресләрнең, аларның төрле төрләре арасындагы тәнәфесләрне дә кертеп, гомуми дәвамлылыгы күрсәтелгән. Педагог белем бирү йөкләнеше күләмен, санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар буенча максималь рөхсәт ителгән эш күләмен арттырмыйча, мөстәкыйль билгели. Елның җылы чорында дәресләрнең бер өлешен һавада йөрү вакытында участокта уздырырга мөмкин.

Статик характердагы дәресләрнең уртасында физкультминутлар үткәрергә тәкъдим ителә.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен өстәмә белем бирү дәресләрен (студияләр, түгәрәкләр, секцияләр һ.б.) һавада йөрүгә һәм көндезге йокыга бирелгән вакыт исәбенә уздыру һич ярамый.

Көндәлек режим якынча төзелгән, аңа конкрет мәктәпкәчә учреждениенең эш үзенчәлекләрен (балалар контингентын, төбәк климатын, бассейн булу-булмауны, ел вакытын, көн озынлыгын һ.б.ш.) исәпкә алып төзәтмәләр кертергә мөмкин.

Һәрбер баланың үзен балалар бакчасында уңайлы, хәвефсез хис итүе; биредә аны яратуларын, аның турында кайгыртуларын белүе мөһим. Ата-аналарыннан авыр аерыла һәм төркемдә калырга теләми торган балаларга карата, аеруча балалар бакчасына ияләшү чорында, күбрәк игътибар бирергә кирәк.

| Режим моментлары | Икенче кече яшьтәгеләр төркеме | Кечкенәләр төркеме | Уртанчылар төркеме | Зурлар төркеме | Мәктәпкә әзерлек төркеме |
|---|---|---|---|---|---|
| Балаларның бакчага килүе, ирекле уен, мөстәкыйль эшчәнлек | 7.00-8.00 | 7.00- 8.20 | 7.00-8.25 | 7.00-8.25 | 7.00-8.30 |
| Иртәнге ашка әзерлек, иртәнге аш | 8.00-8.30 | 8.20-8.55 | 8.25-8.55 | 8.25-8.50 | 8.30-8.50 |
| Уеннар, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге | 8.30-8.40; 8.40-9.10 (төркемчәләр буенча) | 8.55-9.20 | 8.55-9.10 | 8.50-9.00 | 8.50-9.00 |
| Оештырылган балалар эшчәнлеге, белгечләр белән дәресләр[1] | 8.40-9.10 (төркемчәләр буенча) | 9.20-10.00 | 9.10-10.00 | 9.10-10.30 | 9.10-10.50 |
| Икенче иртәнге аш (тәкъдим ителә торган)[2] | 9.10-9.20 | 10.00-10.10 | 10.00-10.10 | 10.30-10.50 | 10.50-11.00 |
| Һавада йөрүгә әзерлек, һавада йөрү | 9.20-11.30 | 10.10-12.05 | 10.10-12.15 | 10.50-12.30 | 11.00-12.40 |
| Һавада йөреп кайту, мөстәкыйль эшчәнлек | 11.30-11.55 | 12.05-12.20 | 12.15-12.30 | 12.30-12.40 | 12.40-12.50 |
| Төшке ашка әзерлек, төшке аш | 11.55-12.30 | 12.20-12.50 | 12.30-13.00 | 12.40-13.10 | 12.50-13.15 |
| Йокыга әзерлек, көндезге йокы | 12.30-15.00 | 12.50-15.00 | 13.00-15.00 | 13.10-15.00 | 13.15-15.00 |
| Акрынлап йокыдан тору, мөстәкыйль эшчәнлек | 15.00-15.15 | 15.00-15.25 | 15.00-15.25 | 15.00-15.25 | 15.00-15.25 |
| Җиңелчә аш[3] | 15.15-15.25 | 15.25-15.50 | 15.25-15.50 | 15.25-15.40 | 15.25-15.40 |
| Уеннар, мөстәкыйль һәм оештырылган балалар эшчәнлеге | 15.25-16.15 | 15.50-16.30 | 15.50-16.30 | 15.40-16.30 | 15.40-16.40 |

Таблицаның ахыры

| Режим моментлары | Икенче кече яшьтәгеләр төркеме | Кечкенәләр төркеме | Уртанчылар төркеме | Зурлар төркеме | Мәктәпкә әзерлек төркеме |
|---|---|---|---|---|---|
| Һавада йөрүгә әзерлек, һавада йөрү | 16.15-17.30 | 16.30-17.50 | 16.30-17.50 | 16.30-18.00 | 16.40-18.00 |
| Һавада йөреп кайту, мөстәкыйль эшчәнлек | 17.30-18.00 | 17.50-18.15 | 17.50-18.15 | 18.00-18.20 | 18.00-18.20 |
| Кичке ашка әзерлек, кичке аш | 18.00-18.30 | 18.15-18.45 | 18.15-18.45 | 18.20-18.45 | 18.20-18.45 |
| Мөстәкыйль эшчәнлек, өйгә кайтып китү | 18.30-19.00 | 18.45-19.00 | 18.45-19.00 | 18.45-19.00 | 18.45-19.00 |

[1] Тәнәфесләрне дә кертеп, гомуми дәвамлылык күрсәтелгән.

[2] Икенче иртәнге аш режимның мәҗбүри элементы түгел һәм администрация теләге буенча тиешле карар булган очракта кертелә. СанПиН 2.4.1.3049-13кә ярашлы рәвештә, икенче иртәнге ашка эчемлек яки сок һәм (яки) җиләк-җимешләр керә.

[3] 12 сәгатькә исәпләнгән очракта аерым җиңелчә аш оештырырга да, җиңелчә ашны кичке аш ризыклары белән тулыландырырга да мөмкин (к. СанПиН 2.4.1.3049-13).

## Режим моментларын оештыру үзенчәлекләре

Режим моментларын гамәлгә ашырганда, балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен (йокы озынлыгын, яраткан ризыкларын, эшчәнлек темпын һ.б.) исәпкә алу сорала. Баланың индивидуаль үзенчәлекләренә якынайтылган балалар бакчасы режимы аңа уңайлык, яхшы кәеф һәм активлык тудыруга ярдәм итә.

**Ашау.** Балаларны ашарга мәҗбүр итәргә кирәкми, аларның аппетит белән ашаулары мөһим. Сайлау мөмкинлеге бирелсә (ике төрле ризыктан булса да), теләбрәк ашыйлар. Балаларның төрле тизлек белән ашавын исәпкә алып, балалар аларга үз темпларында ашау мөмкинлеге тудырырга кирәк.

Баланы, аш китергәнне көтеп яисә ашап туйганнан соң, өстәл янында утырырга мәҗбүр итәргә ярамый. Ашаганнан соң бала, рәхмәт белдереп, мөстәкыйль уеннар белән шөгыльләнә ала.

**Һавада йөрү.** Балаларның сәламәтлеген ныгыту, аларның хәрәкәт активлыгына ихтыяҗын канәгатьләндерү, талчыгуларын кисәтү өчен, көндәлек һавада йөрүләр кирәк.

Һавада йөрүнең дәвамлылыгын кыскартырга ярамый. Балаларның көн дәвамында саф һавада җитәрлек күләмдә булуларын тәэмин итү мөһим.

**Көндәлек уку.** Көндәлек режимда балаларга көн саен китап уку өчен даими вакыт билгеләү максатка ярашлы. Матур әдәбият әсәрләре генә түгел, танып белүгә ярдәм итүче китаплар, рәсемле балалар энциклопедияләре, туган ил һәм чит илләр тарихы һәм мәдәнияте буенча балалар өчен хикәяләр дә укырга кирәк. Китаплар уку һәм укылганнар буенча фикер алышу әдәби геройлар мисалында балаларда, ялыктыргыч һәм файдасыз акыл өйрәтүләргә һәм үгет-нәсыйхәтләргә бирелмичә, социаль-әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итә. Шуның белән бергә китап укуны дәрескә дә әйләндерергә ярамый — баланың һәрвакыт укыганны тыңлауны яисә үз эшләре белән шөгыльләнүне сайлап алу мөмкинлеге булырга тиеш. Педагогның бурычы — уку процессын барлык балалар өчен дә мавыктыргыч һәм кызыклы итү.

**Көндезге йокы.** Балаларның яхшы сыйфатлы көндезге йокысы өчен шартлар тудырырга кирәк. Моның өчен балалар йоклый торган бинада тынычлык, тынлык булуын, даими саф һава кереп торуын тәэмин итү мөһим. Моннан тыш, балаларның тиз йоклап китүенә һәм тирән йокысына көн дәвамындагы сыйфатлы хәрәкәт активлыгы һәм ярсынуны киметә торган тыныч уеннар да булышлык итә.

## Физкультура-сәламәтләндерү эше

Мәктәпкәчә оешмада балаларның сәламәтлеген ныгыту, организмын чыныктыру һәм аның функцияләрен камилләштерү буенча даими эш алып барырга кирәк.

Медицина хезмәткәрләре җитәкчелегендә табигать факторларын — һава, кояш һәм суны файдаланып, балаларның сәламәтлеген һәм төбәктәге шартларны исәпкә алып, чыныктыру процедуралары комплексын гамәлгә ашыру сорала. Чыныктыра торган чараларны уздырганда, балаларга аерым якын килергә, аларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алырга кирәк.

Администрация, мәктәпкәчә тәрбия оешмасы һәм ата-аналар карары буенча махсус чыныктыру процедуралары (мәсәлән, контраст коенулы сауна һ.б.) үткәрү зарур.

Балаларда гәүдәнең дөрес торышын булдыруны тәрбияләүгә игътибар бирү мөһим.

Бина эчендә дөрес температура режимын саклауны, даими җилләтүне тәэмин итәргә; бүлмәдә балаларны җиңелчә киемнәрдән йөрергә гадәтләндерергә кирәк.

Көндәлек режимга яраклы рәвештә балаларның һавада булуын тәэмин итәргә кирәк.

Оптималь хәрәкәт режимын — хәрәкәт активлыгы формалары һәм дәресләренең төрле төрләрен рациональ оештыруны тәэмин итү мөһим, биредә хәрәкәт активлыгының гомуми дәвамлылыгы барлык уяулык вакытының 60 % ыннан да ким булмаска тиеш.

Һавада йөргәндә балаларның бергәләп физик күнегүләрдә һәм хәрәкәтле уеннарда катнашуларын хупларга кирәк. Балаларның мөстәкыйль хәрәкәтле һәм спорт уеннары һәм күнегүләре оештыруда инициативасын үстерү, аларның гамәлдәге физкультура һәм спорт-уен җиһазларын мөстәкыйль куллануларын хуплау.

Балаларда физик күнегүләргә карата кызыксыну тәрбияләү, физкультура җиһазлары белән дәресләрдән тыш (буш вакытта) файдаланырга өйрәтү.

Теләгән балалар белән көн саен иртәнге гимнастика ясау.

Югары акыл эшчәнлеген таләп итүче белем бирү эшчәнлеге процессында һәм өзлексез белем бирү эшчәнлегенә бирелгән вакытның уртасында 1–3 минутлык физкультминутлар үткәрү тәкъдим ителә.

Тиешле шартлар булганда балаларны йөзәргә һәм гидроаэробикага өйрәтергә мөмкин (зурлар һәм әзерлек төркемнәрендә).

**Хәрәкәт активлыгы режимы**

| Эш формалары | Дәрес төрләре | Балаларның яшенә бәйле рәвештә дәресләрнең саны һәм дәвамлылыгы (минутларда) | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 3–4 яшь | 4–5 яшь | 5–6 яшь | 6–7 яшь |
| Физкультура дәресләре | а) бина эчендә | Атнага 2 тапкыр 15–20 | Атнага 2 тапкыр 20–25 | Атнага 2 тапкыр 25–30 | Атнага 2 тапкыр 30–35 |
| | б) урамда | Атнага 1 тапкыр 15–20 | Атнага 1 тапкыр 20–25 | Атнага 1 тапкыр 25–30 | Атнага 1 тапкыр 30–35 |
| Көндәлек режимда физкультура-сәламәтләндерү эше | а) иртәнге гимнастика (балаларның теләге буенча) | Көн саен 5–6 | Көн саен 6–8 | Көн саен 8–10 | Көн саен 10–12 |
| | б) һавада йөрү вакытында хәрәкәтле һәм спорт уеннары | Көн саен 2 тапкыр (иртән һәм кич) 15–20 | Көн саен 2 тапкыр (иртән һәм кич) 20–25 | Көн саен 2 тапкыр (иртән һәм кич) 25–30 | Көн саен 2 тапкыр (иртән һәм кич) 30–40 |
| | в) физкультминутлар (статик дәрес уртасында) | Дәрес төренә һәм эчтәлегенә карап көн саен 3–5 | Дәрес төренә һәм эчтәлегенә карап көн саен 3–5 | Дәрес төренә һәм эчтәлегенә карап көн саен 3–5 | Дәрес төренә һәм эчтәлегенә карап көн саен 3–5 |
| | г) бассейнда дәресләр[1] | 15–20 | 20–25 | 25–30 | 25–30 |

Таблицаның ахыры

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Актив ял | а) физкультуралы ял | айга 1 тапкыр 20 | айга 1 тапкыр 20 | айга 1 тапкыр 30–45 | айга 1 тапкыр 40 |
| | б) физкультура бәйрәме | – | Елга 2 тапкыр 45 минутка кадәр | Елга 2 тапкыр 60 минутка кадәр | Елга 2 тапкыр 45 минутка кадәр |
| | в) сәламәтлек көне | Кварталга бер тапкыр | Кварталга бер тапкыр | Кварталга бер тапкыр | Кварталга бер тапкыр |
| Мөстәкыйль хәрәкәт эшчәнлеге | а) физкультура һәм спорт-уен җиһазын мөстәкыйль куллану | Көн саен | Көн саен | Көн саен | Көн саен |
| | б) мөстәкыйль хәрәкәтле һәм спорт уеннары | Көн саен | Көн саен | Көн саен | Көн саен |

[1] Бассейнда дәресләр мәктәпкәчә учреждениедә шартлар булганда уздырыла.

## Тәрбия-белем бирү процессын проектлаштыру

Тәрбия-белем бирү процессы тәрбияләнүчеләр контингентын, аларның индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләрен, ата-аналарның социаль заказын исәпкә алып оештырыла.

Тәрбия-белем бирү процессын оештырган вакытта тәрбия, үстерү һәм өйрәтү максатларының һәм бурычларының бердәмлеген тәэмин итү кирәк, шуның белән бергә куелган максат һәм бурычларны балаларга чамадан артык эш йөкләмичә, кирәкле һәм җитәрлек материалга таянып, тиешле «минимум»га максималь якынаеп хәл итү сорала. Белем бирү процессын белем бирү өлкәләре интеграциясен исәпкә алып комплекслы тематик принципка нигезләнеп кору әлеге максатны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

Барлык белем бирү процессын бер үзәк тема тирәсендә оештыру балаларның үсеше өчен зур мөмкинлекләр тудыра. Темалар мәгълүматны оптималь юл белән тупларга ярдәм итә. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда практика, экспериментлар ясау, төп күнекмәләрне үстерү, төшенчәле фикерләү өчен күптөрле мөмкинлекләр барлыкка килә.

Чорның төп темасын аерып алу һич тә балаларның бөтен эшчәнлеге әлеге темага багышланырга тиеш дигән сүз түгел. Чорның төп темасын кертүнең максаты — белем бирү эшчәнлеген интеграцияләү һәм балалар эшчәнлеген белем бирү өлкәләре буенча аклый алмаслык ваклауга юл куймау.

Төрле яшьтәге төркемнәрдә охшаш темаларны гамәлгә кертү бөтен мәктәпкәчә чор дәвамында балалар үсешендә дәвамчанлыкка һәм белем бирү максатларының бердәмлегенә ирешүне, балаларның индивидуаль мөмкинлекләренә ярашлы рәвештә аларның органик үсешен тәэмин итә.

Белем бирү процессын оештыруның тематик принцибы төбәк һәм мәдәни компонентларны органик кертергә, мәктәпкәчә учреждениенең үзгәлеген исәпкә алырга мөмкинлек бирә.

Бер темага бирелгән вакыт бер атнадан да ким булмаска тиеш. Оптималь вакыт — 2–3 атна. Тема төркемдә һәм үсеш үзәкләрендә (почмакларында) булган материалларны сайлауда чагылырга тиеш.

Программада һәр яшь төркеме өчен комплекслы тематик планлаштыру бирелә (к. Кушымта), аны үрнәк びуларак карарга кирәк. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төбәк һәм мәдәни компонентларны кертү өчен, үз мәктәпкәчә учреждениесенең үзенчәлекләрен исәпкә алу өчен үз карашлары буенча темаларны яки аларның атамаларын, эш эчтәлеген, вакытын һ.б. ны өлешчә яисә тулысынча үзгәртергә мөмкин.

Программада биш көнлек атна буенча эшләгәндә белем бирү эшчәнлеген планлаштыру үрнәге китерелә. Мәктәпкәчә учреждение төбәкнең үзгәлеген һәм мәктәпкәчә учреждениенең үзенчәлекләрен исәпкә алу өчен планлаштыруга үзгәрешләр кертә ала.

СанПиН 2.4.1.3049-13 буенча, мәктәпкәчә учреждениедә балалар белән үткәрелә торган дәресләр саны билгеләнми; бары белем бирүдә эшнең күләм дәвамлылыгы гына күрсәтелә:

«11.9. 1.5 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге кече яшьтәге балалар өчен өзлексез турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге дәвамлылыгы 10 минуттан артмаска тиеш. Белем бирү эшчәнлеге көннең беренче һәм икенче яртысында гамәлгә ашырыла ала (8–10 ар минут). Белем бирү эшчәнлеген һавада йөргәндә уен мәйданчыгында оештырырга мөмкин.

11.10. 3 яшьтән алып 4 яшькә кадәрге балалар өчен өзлексез турыдан-туры белем бирү эшчәнлегенең дәвамлылыгы 15 минуттан, 4 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге балалар өчен — 20 минуттан, 5 яшьтән 6 яшькә кадәрге балалар өчен — 25 минуттан, ә 6 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар өчен — 30 минуттан артык булырга тиеш түгел.

11.11. Көннең беренче яртысында кечкенәләр төркемендә һәм уртанчы төркемдә рөхсәт ителә торган максималь белем бирү йөкләнеше күләме, төркемгә карап, 30 һәм 40 минуттан, ә зурлар һәм әзерлек төркемнәрендә — төркемгә карап, 45 минуттан һәм 1,5 сәгатьтән артмый. Өзлексез белем бирү эшчәнлегенә бирелгән вакыт уртасында физкультура минутлары үткәрелә. Өзлексез белем бирү эшчәнлеге вакытлары арасындагы тәнәфесләр 10 минуттан ким түгел.

11.12. Мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең зурлар төркеме белән белем бирү эшчәнлеге көннең икенче яртысында көндезге йокыдан соң гамәлгә ашырылырга мөмкин. Аның дәвамлылыгы көнгә 25–30 минуттан артмаска тиеш. Статик характердагы турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге уртасында физкультура минутлары үткәрелә».

## Биш көнлек атна өчен белем бирү-тәрбия эшен планлаштыру үрнәге

| Оештырылган белем бирү эшчәнлеге | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Эшчәнлекнең төп төре | Кабатлану тәртибе | | | | |
| | Икенче кече яшь-тәгеләр төркеме | Кечкенәләр төркеме | Уртанчылар төркеме | Зурлар төркеме | Мәктәпкә әзерлек төркеме |
| Бина эчендә физик культура | атнага 2 тапкыр | атнага 2 тапкыр | атнага 2 тапкыр | атнага 2 тапкыр | атнага 2 тапкыр |
| Һавада физик культура | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр |
| Әйләнә-тирә дөнья белән танышу | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр |
| Элементар математик күзаллаулар булдыру | атнага 1 тапкыр[1] (көннең икенче яртысында) | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр |
| Сөйләм үстерү | атнага 2 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 2 тапкыр | атнага 2 тапкыр |
| Рәсем ясау | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 2 тапкыр | атнага 2 тапкыр |
| Әвәләп ясау | атнага 1 тапкыр | 2 атнага 1 тапкыр | 2 атнага 1 тапкыр | 2 атнага 1 тапкыр | 2 атнага 1 тапкыр |
| Аппликация | – | 2 атнага 1 тапкыр | 2 атнага 1 тапкыр | 2 атнага 1 тапкыр | 2 атнага 1 тапкыр |
| Музыка | атнага 2 тапкыр | атнага 2 тапкыр | атнага 2 тапкыр | атнага 2 тапкыр | атнага 2 тапкыр |
| **Эшчәнлекнең төрле төрләрендә өлкәннәрнең балалар белән үзара бәйләнеше** | | | | | |
| Матур әдәбият уку | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен |
| Конструкцияләү-модельләр ясау эшчәнлеге | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр | атнага 1 тапкыр |
| Уен эшчәнлеге | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен |
| Режим моментларын үткәргәндә аралашу | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен |
| Кизү торулар | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен |
| Һавада йөрүләр | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен |
| **Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге** | | | | | |
| Мөстәкыйль уен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен |

Таблицаның ахыры

| Эшчәнлекнең төп төре | Кабатлану тәртибе | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Икенче кече яшь-тәгеләр төркеме** | **Кечкенәләр төркеме** | **Уртанчылар төркеме** | **Зурлар төркеме** | **Мәктәпкә әзерлек төркеме** |
| Танып белү-тикшеренү эшчәнлеге | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен |
| Үсеш үзәкләрендә (почмакларында) балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен |
| **Сәламәтләндерү эше** | | | | | |
| Иртәнге гимнастика | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен |
| Чыныктыру процедуралары комплексы | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен |
| Гигиена процедуралары | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен | көн саен |

[1] Белем бирү оешмасы каравы буенча көннең икенче яртысында уздырыла.

# МӘДӘНИ-ЯЛ ЭШЧӘНЛЕГЕ
## (традицион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар үзенчәлекләре)

МББ ФДББС таләпләре буенча, программага традицион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чараларның үзенчәлекләренә багышланган «Мәдәни-ял эшчәнлеге» бүлеге кертелгән. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның кызыксынулары буенча мәдәни-ял эшчәнлеген үстерү һәр баланың ялын (пассив һәм актив), эмоциональ иминлеген тәэмин итәргә мөмкинлек бирә, үзенә шөгыль таба белергә өйрәтә. Бүлектә педагогның балаларның һәр яшь төркеменең ялын оештыру буенча бурычлары билгеләнә. Кушымтада вакыйгалар, бәйрәмнәр һәм чараларның якынча исемлеге китерелә.

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Төркемдә һәм балалар бакчасында эмоциональ-уңай климат булдыруга ярдәм итү, балаларга уңайлылык һәм яклангалык тойгысын тәэмин итү.

Балаларны, булдыра алганнарыча, уеннарда, уен-көлкеләрдә, күңел ачуларда һәм бәйрәмнәрдә катнашуга тарту.

Борып хәрәкәтләндерелә торган уенчыкларның, әкият геройларының хәрәкәтләрен күзәтә, аларны дөрес кабул итә белергә өйрәтү.

Әкият геройлары образларына әверелү күнекмәләрен формалаштырырга ярдәм итү.

Бәйрәмнәрне балаларның яшь мөмкинлекләренә һәм кызыксынуларына туры китереп үздыру.

### Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

**Ял.** Балаларның кызыксынулары буенча мәдәни-ял эшчәнлеген үстерү. Һәрбер баланың ялын (пассив һәм актив), эмоциональ иминлеген тәэмин итү. Үзенә уен таба белергә өйрәтү.

**Күңел ачулар.** Театральләштерелгән тамашалар күрсәтү. Тавыш язмаларын тыңлауны; мультфильмнар карауны оештыру. Төрле тематикага караган күңел ачулар уздыру (үткән материалны ныгыту һәм гомумиләштерү өчен). Яңа темаларга карата кызыксыну уяту, балаларның күңел ачулар вакытында күргәннәреннән һәм ишеткәннәреннән канәгатьләнү алуларына омтылу.

**Бәйрәмнәр.** Балаларны бәйрәм культурасына күнектерү. Дәүләт бәйрәмнәрен уздыру (Яңа ел, «Әниләр көне»).

Гомуми шатлык, яхшы кәеф мохитен булдыруга булышлык итү.

**Мөстәкыйль эшчәнлек.** Балаларда сурәтләү эшчәнлеге белән шөгыльләнү, китаплардагы рәсемнәрне карау, төрле уеннар уйнау теләге уяту, тәрбияче ярдәме белән таныш әкиятләрне уйнап карау, халык җырларын, такмакларын башкарырга өйрәнү.

Балаларның җырлау, бию, музыкаль уенчыклар белән уйнау теләкләрен хуплау. Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеген уңышлы гамәлгә ашыру өчен тиешле мохит булдыру.

## Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

**Ял.** Балаларның буш вакытларында кызыклы мөстәкыйль эшчәнлек белән шөгыльләнү, табигать күренешләренең матурлыгына соклану: кошлар җырын, яңгыр шавын, музыканы тыңлау, нәрсәдер ясау, рәсемгә төшерү, музыка инструментларында уйнау һ.б. теләкләрен хуплау.

**Күңел ачулар.** Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге, ялы һәм яңа тәэсирләр алуы өчен шартлар тудыру. Халык традицияләре һәм йолалары, мәдәният чыганаклары белән таныштыручы танып белүгә юнәлтелгән күңел ачуларга карата кызыксыну уяту.

Балаларны төрле төрдәге күңел ачуларга әзерлек процессына тарту; курчаклар белән спектакльдә, музыкаль әдәби концертларда; спорт уеннарында һ.б.да катнашырга теләк формалаштыру.

Патриотик һәм әхлакый тәрбия бирүне гамәлгә ашыру.

Сәнгать культурасы белән таныштыру. Кызыклы иҗади эш белән (рәсем ясау, әвәләү һ.б.) шөгыльләнү теләген һәм осталыгын үстерү.

**Бәйрәмнәр.** Балаларны халыкның бәйрәм культурасы белән таныштыру. Бәйрәмнәрдә катнашу теләген үстерү.

Балалар бакчасында, илдә бара торган вакыйгаларга катнашы булу хисен формалаштыру. Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.

Яңа елга, 8 Мартка, Ватанны саклаучылар көненә, халык календаре бәйрәмнәренә багышланган балалар бәйрәмнәре оештыру.

**Мөстәкыйль эшчәнлек**. Эшчәнлек төрләрен, төрле эчтәлектәге дәресләрне (танып белү, спорт, сәнгать, хезмәт) сайлауда индивидуаль өстенлек бирүне үстерүгә булышлык итү. Һәрбер баланың иҗади һәвәслекләрен формалаштыру.

Балаларда сайлап алынган эшчәнлек төрен мөстәкыйль оештыруга теләк уяту.

Эстетик тәрбия һәм үсеш студияләренә йөрү теләген үстерү (балалар бакчасында яисә иҗат үзәкләрендә).

## Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

**Ял.** Буш вакытта кызыклы һәм эчтәлекле эшчәнлек белән шөгыльләнү теләген үстерү. Ял культурасы нигезләрен формалаштыру (уеннар, китаплар уку, рәсем ясау, әвәләү, конструкторлык, һавада йөрүләр, походлар һ.б.).

**Күңел ачулар.** Мәдәни-танып белү ихтыяҗларын, кызыксынуларын, теләкләрен тормышка ашыру һәм шулай ук алган белем һәм күнекмәләрен ял вакытын уздыруда файдалану өчен шартлар тудыру. Спортка карата кызыксыну уятуга, спорт белән шөгыльләнүгә омтылыш булдыруга булышлык итү.

**Бәйрәмнәр.** Балаларда гадәти һәм бәйрәм көннәре турында күзаллаулар булдыру. Бәйрәмнәргә карата эмоциональ уңай мөнәсәбәт, аларны әзерләүдә актив катнашу теләге уяту (төркем бүлмәсен, музыка залын, балалар бакчасы участогын һ.б.ны бизәү). Әйләнә-тирәдәге кешеләргә игътибарлылык, аларны истәлекле вакыйгалар белән котлау, үз кулың белән ясалган бүләкләр бирү омтылышы тәрбияләү.

**Мөстәкыйль эшчәнлек.** Балаларның индивидуаль сәләтләрен һәм кызыксынуларын үстерү өчен шартлар тудыру (күзәтүләр, экспериментлар ясау, коллекцияләр туплау һ.б.). Үз эшчәнлекләрен оештыруга ихтыяҗ һәм сәләт формалаштыру, тәртипне һәм чисталыкны саклау. Яшьтәшләре, тәрбиячеләре һәм ата-аналары белән үзара аралаша белү тәрбияләү.

**Иҗат.** Җырлауда, рәсем ясауда, музыка белән шөгыльләнүдә сәнгати һәвәслекләрен үстерү. Балаларның төрле сәнгать һәм танып белү эшчәнлеге белән кызыксынуларына булышлык итү, түгәрәкләр һәм студияләргә йөрү өчен шартлар тудыру.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

**Ял.** Балаларны кызыклы һәм файдалы эшчәнлеккә тарту (уеннар, спорт, рәсем ясау, әвәләү, модельләштерү, музыка тыңлау, мультфильмнар карау, китаптагы рәсемнәрне карау һ.б.).

**Күңел ачулар.** Күңел ачуларда актив катнашу, аралашу, дустанә һәм ярдәмчел булу омтылышы тәрбияләү; алынган белем һәм күнекмәләрен мөстәкыйль эшчәнлектә аңлап куллану.

Иҗади сәләтләрне, кызыксынучанлыкны, хәтерне, күзаллауны, үзеңне төрле хәлләрдә дөрес тота белү сыйфатларын үстерү.

Россия халыклары сәнгате, традицияләре һәм йолалары турында күзаллауларны киңәйтү, алган белем һәм күнекмәләрне тормышта куллана белүне ныгыту.

**Бәйрәмнәр.** Балаларның халыкара һәм дәүләт бәйрәмнәре хакындагы күзаллауларын киңәйтү.

Халык тантаналарына катнашы булу хисләрен үстерү.

Балаларны бәйрәмгә әзерлектә һәм аны уздыруда актив, төрлечә катнашуга тарту.

Коллектив бәйрәм алды эшчәнлегендә катнашудан канәгатьлек хисе алу тәрбияләү. Бәйрәм культурасы нигезләрен будыру.

**Мөстәкыйль эшчәнлек.** Балаларга төрле материаллар белән (су, ком, балчык һ.б.) тәҗрибәләр ясап карау өчен; үсемлекләрне, хайваннарны, әйләнә-тирә табигатьне күзәтүләр өчен мөмкинлекләр бирү.

Өстәл уеннары, басма һәм дидактик уеннар уйнау осталыгын үстерү.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үз коллекцияләрен күрсәтү (открыткалар, конфет кәгазьләре һ.б.), аларның эчтәлеге турында сөйләү теләген хуплау.

Үз мөстәкыйль эшчәнлекләрен планлаштыра һәм оештыра белү күнекмәләре формалаштыру, яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән үзара бәйләнештә булу.

**Иҗат.** Мөстәкыйль музыкаль-сәнгать һәм танып белү эшчәнлеген камилләштерү.

Буш вакытны социаль яктан мөһим максатларны хәл итү юнәлешендә төрле эшчәнлек: музыкаль, тасвирлау, театр һ.б. белән шөгыльләнеп, иҗади үткәрүгә ихтыяҗ булдыру.

Баланың кызыксынулары буенча сәнгать-эстетика студияләренә йөрүенә этәргеч бирү.

# ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ШАРТЛАРЫ

## ПРЕДМЕТЛЫ ТИРӘЛЕК МОХИТЕ ОЕШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Мохит төшенчәсе астында табигый, социаль-көнкүреш һәм (яки) мәдәни-эстетик характердагы тирәлек күздә тотыла. Бу — кешенең яшәеш шартлары, аның тормыш даирәсе. Мохит махсус проектлана торган юнәлеш алырга мөмкин, һәм бу очракта аның турында шәхесне формалаштыручы мөһим фактор — белем бирү тирәлеге буларак карау күзәтелә (Т.С. Комарова, С.Л. Новоселова, Г.Н. Пантелеев, Л.П. Печко, Н.П. Сакулина, Е.О. Смирнова, Е.И. Тихеева, Е.А. Флерина, С.Т. Шацкий һ.б.).

Балалар бакчасында белем бирү мохите баланың мәктәпкәчә балачагын тулы кыйммәтле уздыру өчен кирәкле махсус шартларны таләп итә. Предметлы үсеш мохите дигәндә баланың танып белүдә, аралашуда, хезмәт, тулаем физик һәм рухи үсеш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен җайлаштырылган, оештыру ягыннан формалаштырылган һәм предметлар белән тулыландырылган билгеле бер тирәлек аңлана. Үсешкә булышлык итүче предметлы мохитне заманча күзаллау баланың актив эшчәнлеген тәэмин итүне, аның субъектив позициясен формалаштыруны, иҗади сәләтләрен, мөмкинлекләрен барлык чаралар белән үстерүне үз эченә ала.

### Мохит оештыруга төп таләпләр

Мәктәпкәчә оешманың үсешкә китерүче предметлы тирәлек мохите:
• тулы эчтәлекле, үсешкә илтүчән;
• үзгәрүчән;
• күп функцияле;
• вариатив;
• аңлаешлы;
• куркынычсызлыкны тәэмин итүчән;
• сәламәтлекне саклаучан;
• эстетик җәлеп итүчән булырга тиеш.

«МОЗАИКА-СИНТЕЗ» нәшриятында үсешкә китерүче предметлы тирәлек мохитен оештыру принципларыннан тыш, балалар бакчасы бинасын (төркем бүлмәләрен, музыка һәм спорт залларын һ.б.) һәм участогын тәэмин итү өчен материаллар һәм җиһазларның киңәйтелгән исемлеге күрсәтеләчәк тиешле махсус кулланма әзерләнә.

## Мохитне оештыруның төп принциплары

Мәктәпкәчә учреждениенең бүлмәләрен җиһазлау куркынычсызлыкны тәэмин итә, сәламәтлекне саклый, эстетик җәлеп итә торган һәм үсешкә китерүчән булырга тиеш. Җиһазлар балаларның буена һәм яшенә туры килергә, уенчыклар әлеге яшь өчен максималь үсеш эффектын тәэмин итәргә тиеш.

Үсешкә китерүче предметлы тирәлек мохите тулы эчтәлекле, өлкән кешенең һәм баланың уртак эшчәнлеге һәм балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге өчен яраклы, бала яшенең ихтыяҗларына җавап бирерлек булырга тиеш.

Кечкенәләр төркемнәрендә балалар уенының идеясе нигезендә предмет тора, шуңа күрә өлкән кеше, сабыйларда кызыксыну, танып белү омтылышы, уен бурычын кую һәм аны чишү теләге уяту өчен, һәрвакыт уен мохитен (корылмалар, уенчыклар, материаллар һ.б.) яңартып торырга тиеш. Төркем бүлмәсендә балаларның мөстәкыйль хәрәкәт активлыгы өчен шартлар тудыру: җиһазлар һәм уенчыклардан буш урын карап кую, балаларны хәрәкәтле уен эшчәнлегенә тарта торган уенчыклар белән тәэмин итү, хәрәкәт активлыгын стимуллаштыручы уенчыкларны көнгә берничә тапкыр алмаштыру сорала.

Зурлар төркемнәрендә идея уенның темасына нигезләнә, шуңа күрә төрле рәвештәге күп функцияле предметлар мохите балаларның актив хыялын уята, һәм алар, сыгылмалы модульләр, ширмалар, пәрдәләр, кублар, урындыклар кулланып, гамәлдәге уен тирәлеген һәрдаим яңача үзгәртеп коралар. Предмет-уен мохитенең үзгәрүчәнлеге балага уен тирәлегенә башка ноктадан карарга, уен урынын җиһазлауда активлык күрсәтергә һәм аның нәтиҗәләрен күрә белергә мөмкинлек бирә.

Үсешкә китерүче предметлы тирәлек мохите табигый характердагы объектлардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә; даими һәм эпизодик рәвештә балалар бакчасы участогында үсемлекләр үскәнне күзәтү, элементар хезмәттә катнашу, табигый материал белән тәҗрибә һәм экспериментлар үткәрү теләкләрен уятырга тиеш.

Үсешкә китерүче предметлы тирәлек мохите балаларга тәрбияви йогынты ясаучы мәдәни тирәлек ( халык сәнгате эшләнмәләре, репродукцияләр, бөек кешеләр портретлары, борынгы көнкүреш предметлары һ.б.) буларак оештырылырга тиеш.

Төркемдәге тирәлекне үсешкә китерүче күпсанлы материаллар (китаплар, уенчыклар, иҗат өчен материаллар, җиһазлар һ.б.) белән тәэмин

ителгән аерым зоналар («үзәкләр», «почмаклар», «мәйданчыклар») рәвешендә оештырырга тәкъдим ителә. Барлык предметлар да балаларның кул астында булырга тиеш.

Тирәлекне шул рәвешчә оештыру мәктәпкәчә яшьтәгеләргә үзләре кызыксынган шөгыльләрне табарга, аларны көн дәвамында чиратлаштырырга ярдәм итә, ә педагогка белем бирү процессын балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып нәтиҗәле оештырырга мөмкинлек бирә.

Почмакларны җиһазлау белем бирү процессын тематик планлаштыру белән туры китереп алышынырга тиеш.

Үсеш үзәкләре сыйфатында:

• сюжетлы-рольле уеннар өчен почмак;

• киенү-ясану почмагы (театральләштерелгән уеннар өчен);

• китаплар почмагы;

• басма һәм өстәл уеннар өчен зона;

• күргәзмә (балалар рәсемнәреннән, балалар иҗаты, халык осталары эшләнмәләреннән һ.б.);

• табигать (табигатьне күзәтү) почмагы;

• спорт почмагы;

• су һәм ком белән уеннар өчен почмак;

• балаларның мөстәкыйль эшчәнлегенең төрле төрләре — конструкцияләү, сәнгати, музыкаль һ.б. эшчәнлек өчен почмаклар;

• уен тирәлеген җиңел үзгәртү өчен зур күләмле йомшак конструкцияләр (блок уенчыклар, өй, тоннельләр һ.б.) белән уен үзәге;

• уен почмагы (уенчыклар, төзү материаллары белән) булдырырга мөмкин.

Үсешкә китерүче предметлы тирәлек мохите хәрәкәтчән һәм җиңел үзгәрә торган динамик тирәлек булырга тиеш. Предметлы мохитне проектлаштырганда шуны онытмаска кирәк: «катып калган» (статик) предмет тирәлеге, баланың фантазиясен уятудан туктау сәбәпле, үзенең үсешкә булышлык итү функциясен үти алмый башлый. Гомумән, динамиклык-статиклык принцибы уен тирәлекләренең хәрәкәтчәнлек дәрәҗәсенә, предмет шартларының вариантлылыгына һәм балалар эшчәнлеге характерының һәркайсына кагыла. Шуның белән бергә мохитнең билгеле бер тотрыклылыгы һәм даимилеге — аның балалар өчен гадәтилеген, ияләнгән тирәнлек булуын тәэмин итә. Бигрәк тә бу гомуми файдалану урыннарына (китапханә, уенчыклар шкафы, күп функцияле материаллар салынган тартма һ.б.) мөнәсәбәттә шулай.

Төрле психологик-педагогик бурычларны хәл итү өчен үсешкә китерүче предметлы тирәлек мохитен оештыру үзенчәлекләре «Программаны гамәлгә ашыруның психологик-педагогик шартлары» бүлегендә бәян ителә.

# ПРОГРАММАНЫҢ МАТДИ-ТЕХНИК ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕ

ФДББС буенча программаны матди-техник тәэмин итү укыту-методик комплектын, җиһазларны, предметларны үз эченә ала. Шуның белән бергә Оешма Программаны гамәлгә ашыру өчен кирәкле уку-укыту чараларын, шул исәптән техник чараларны, тиешле материалларны (шул исәптән сарыф ителәчәк материалларны), уен, спорт, сәламәтләндерү җиһазларын, инвентарьны мөстәкыйль рәвештә билгели.

## Программа өчен укыту-методик комплект

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы укыту-методик комплект белән тәэмин ителгән, авторлар коллективы даими рәвештә аны камилләштерү өстендә эш алып бара.

Комплектка түбәндәгеләр керә:

- мәктәпкәчә белем бирүнең «Туганнан алып мәктәпкәчә» төп белем бирү программасы;
- комплекслы-тематик планлаштыру;
- мәктәпкәчә оешмада эшне оештыру һәм идарә итү буенча кулланмалар;
- инклюзив белем бирү буенча кулланмалар;
- психолог эше буенча кулланмалар;
- бала үсешенең барлык юнәлешләре буенча педагоглар өчен методик кулланмалар;
- күрсәтмә-дидактик кулланмалар;
- эш дәфтәрләре;
- иҗат өчен комплектлар;
- вариатив парциаль (авторлык) программалар;
- электрон белем бирү ресурслары.

Кулланмаларның тәфсилле исемлеге «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасына Кушымтада тәкъдим ителә.

Программаны укыту-методик яктан тәэмин итү профессиональ эшчәнлекнең даими камилләшеп торучы, илкүләм һәм дөньякүләм мәктәпкәчә белем бирүдәге заманча казанышларны һәм тенденцияләрне чагылдыручы инструменты булып тора.

## Җиһазларга һәм җиһазландыруга карата таләпләр

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы җиһазлауга, материалларга, җиһазларга, инвентарьга махсус таләпләр куймый — Программаны гамәлгә ашыру өчен нинди дә булса аерым, стандарт булмаган җиһазландыру таләп

ителми. Программа мәктәпкәчә оешманың кулланууда булган матди-техник базасында, аның гамәлдәге дәүләт стандарты һәм таләпләренә туры килүе шартларында тормышка ашырыла ала. Әмма матди база киңрәк булган саен, педагогның һәр баланың үсеше өчен оптималь шартлар тудыру мөмкинлекләре дә арта.

Авторлар программаны гамәлгә ашыру шартларына таләпләрнең өч дәрәҗәсен эшләделәр:

• минималь дәрәҗә — дәүләт нормативларына туры килә торган дәрәҗә;

• база дәрәҗәсе — омтылырга тиешле дәрәҗә;

• оптималь дәрәҗә — программаны гамәлгә ашырырга ярдәм итүче өстәмә мөмкинлекләрне ача торган дәрәҗә.

**Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының биналарына һәм эчке бүлмәләренә карата таләпләр**

| Матди-техник база элементлары | Минималь дәрәҗә | База дәрәҗәсе | Оптималь дәрәҗә |
|---|---|---|---|
| Бина | СанПиН таләпләренә туры килгән теләсә нинди бина | Типик проект буенча балалар бакчасы өчен салынган бина | Индивидуаль проект |
| Янәшәдәге территория | Балаларның һавада йөрүе өчен җайланган теләсә нинди территория | Һәр төркем өчен җиһазландырылган мәйданчыклар | Һәр төркем өчен җиһазландырылган мәйданчыклар, мини-стадион, балаларны табигать белән таныштыру өчен участок (бакча, чәчәклек, яшелчә бакчасы) |
| Балалар бакчасы бүлмәләре | СанПиН таләпләренә туры килгән теләсә нинди бүлмә | Музыка һәм физкультура дәресләре өчен аерым зал; өстәмә бүлмәләр (медицина блогы, азык-төлек блогы, кер юу бүлмәсе) | Музыка дәресләре өчен зал, физкультура дәресләре өчен зал; бассейн, сауна, тоз бүлмәсе, тренажерлар залы, сәнгать студиясе, компьютер классы, логопед, психолог кабинеты. Өстәмә бүлмәләр (медицина блогы, азык-төлек блогы, кер юу бүлмәсе) |
| Төркем бүлмәсе | СанПиН таләпләренә туры килгән теләсә нинди бүлмә | Уен бүлмәсе, йокы бүлмәсе, чишенү бүлмәсе, бәдрәф бүлмә | Уен бүлмәсе, спорт почмагы, йокы бүлмәсе, чишенү бүлмәсе, бәдрәф. Дизайнер бизәлеше. Тәрбияченең компьютерны да кертеп җиһазландырылган эш урыны |

Хәтта тыйнак матди мөмкинлекләр белән дә балаларның югары үсешен тәэмин итәргә була, чөнки үсешкә китерүче эффектка үсешкә китерүче мохитнең объектлары үзләре түгел, бәлки балаларның зурлар тарафыннан оештырылган яисә мөстәкыйль эшчәнлеге ия. Эшнең нәтиҗәсе беренче чиратта педагогларның профессиональлегенә һәм иҗади потенциалына бәйле.

Сатып алынган укыту чараларының, шул исәптән техник чараларның, тиешле материаллар (шул исәптән сарыф ителүче), уен, спорт, сәламәтләндерү җиһазлары, инвентарь һәм уенчыкларның саны һәм төгәл ассортименты мәктәпкәчә оешма тарафыннан, аның матди мөмкинлекләренә, балаларның составына һәм ихтыяҗларына һәм ата-аналарның теләгенә карап, мөстәкыйль рәвештә билгеләнә. Җиһазларны сайлаганда РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2011 ел 17 ноябрь 03-877 нче номерлы хатында тәкъдим ителгән «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын укыту-матди тәэмин итү өчен уен җиһазларының якынча исемлеге»нә һәм «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы тәкъдимнәренә таянырга мөмкин.

# ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ КАДРЛАР ШАРТЛАРЫ

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасын гамәлгә ашыруның кадрлар белән бәйле шартларына таләпләр түбәндәгеләрне колачлый:

1) мәктәпкәчә белем бирү оешмасының җитәкче, педагогик һәм башка хезмәткәрләр белән комплектлаштыру;

2) Оешманың җитәкче, педагогик һәм башка хезмәткәрләренең квалификация дәрәҗәсе;

3) Оешмадагы педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше һәм профессиональ компетентлыгы дәрәҗәсен арттыруның өзлексезлеге.

## Мәктәпкәчә оешманы кадрлар белән комплектлаштыруга карата таләпләр

Программаны гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә белем бирү оешмасы квалификацияле җитәкче, педагогик, административ-хуҗалык хезмәткәрләре һәм укыту-ярдәмче персонал белән комплектлаштырылган булырга тиеш.

Оешманың белем бирү эшчәнлеге белән идарә итүне, Программаны гамәлгә ашыруны методик тәэмин итү, бухгалтер исәбен, финанс-хуҗалык, медицина эшчәнлеген алып бару, тормышны һәм сәламәтлекне зарури саклау, тәрбияләнүчеләрнең туклануын оештыру өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәткәрләре сыйфатында тиешле квалификацияле персонал алына һәм (яки) тиешле хезмәтләр күрсәтүче оешмалар белән килешүләр төзелә.

Һәрбер мәктәпкәчә белем бирү оешмасы үз штат расписаниесен мөстәкыйль төзи. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасында мәктәпкәчә белем бирү оешмасын кадрлар белән комплектлаштыруның өч дәрәҗәсе: минималь, база, оптималь дәрәҗәләре тәкъдим ителә.

## Минималь дәрәҗә

1. Төркемнәрнең СанПиН нормалары буенча тутырылуы.

2. Программаны гамәлгә ашыру өчен кирәкле хезмәткәрләрнең вазифаи составы һәм саны белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

## База дәрәҗәсе

1. Төркемнәрнең тутырылу чиге — мәктәпкәчә төркемнәрдә — 25 баладан, кече яшьтәгеләр төркемнәрендә — 20 баладан, сабыйлар төркемнәрендә 15 баладан артмаска тиеш.

2. Мәктәпкәчә балалар оешмасында педагогик белгечләр:

• музыка җитәкчесе;
• физик культура буенча инструктор булу.

## Оптималь дәрәҗә

1. Төркемнәрнең тутырылу чиге — мәктәпкәчә төркемнәрдә — 25 баладан, кече яшьтәгеләр төркемнәрендә 20 баладан, сабыйлар төркемнәрендә 15 баладан артмаска тиеш.

2. Мәктәпкәчә балалар оешмасында педагогик белгечләр:

• музыка җитәкчесе;
• физик культура буенча инструктор;
• йөзү буенча инструктор;
• сынлы сәнгать эшчәнлеге буенча педагог;
• логопед;
• психолог;
• инглиз теле укытучысы булу.

## Идарә итүче һәм педагогик кадрларның квалификациясенә карата таләпләр

Программаны гамәлгә ашыру квалификация сыйфатламалары Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 761 н нче номерлы 2010 ел 26 август приказы белән расланган (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 18638 нче номер белән теркәлгән, 2010 елның 6 октябрендә), Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында» 1155 нче номерлы 2013 ел 17 октябрь приказы белән үзгәрешләр кертелгән (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 30384 нче номер белән 2013 елның 14 ноябрендә теркәлгән) «Җитәкче, белгечләр һәм хезмәткәр вазифаларының Бердәм квалификация белешмәлеге»ндә («Мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының квалификация сыйфатламалары» бүлеге) билгеләнгән педагогик хезмәткәрләр тарафыннан тәэмин ителергә тиеш.

Педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукына урта һөнәри яисә югары белеме булган һәм квалификация белешмәлекләрендә күрсәтелгән квалификация таләпләренә һәм (яки) профессиональ стандартларга туры килә торган затлар ия. («Мәгариф турында Россия Федерациясе Законы» 273-ФЗ номерлы 2012 ел 29 декабрь Федераль законы, 5 нче бүлек, 46 нчы маддә).

Педагогик хезмәткәр — белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм укучыларны укыту, тәрбияләү һәм (яки) мәгариф эшчәнлеген оештыру бурычларын үтәүче оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы физик зат. («Мәгариф турында Россия Федерациясе Законы» 273-ФЗ номерлы 2012 ел 29 декабрь Федераль законы, 2 нче маддә, 21 нче пункт).

Программаны гамәлгә ашыручы Оешмадагы җитәкче һәм педагогик хезмәткәрләрнең квалификация дәрәҗәсе һәрбер вазифа өчен тиешле квалификация сыйфатламаларына, ә дәүләт яисә муниципаль мәгариф учреждениеләре педагогик хезмәткәрләре өчен шулай ук квалификация категориясенә дә туры килергә тиеш.

Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының бердәм квалификация белешмәлегендә («Мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының квалификация сыйфатламалары» бүлеге) җитәкче (директор, мөдир), мәгариф учреждениесе җитәкчесе урынбасары вазифалары, шулай ук педагогик хезмәткәрләр вазифалары исемлеге һәм аларга квалификация таләпләре билгеләнә.

**Идарәче кадрлар:** «Дәүләти һәм муниципаль идарә», «Менеджмент», «Персонал белән идарә итү» әзерлек юнәлешләре буенча югары һөнәри белем һәм педагогик вазифаларда 5 елдан ким булмаган эш стажы яисә югары һөнәри белем һәм дәүләти, һәм муниципаль идарә яки менеджмент һәм икътисад өлкәсендә өстәмә һөнәри белем һәм педагогик яки җитәкче вазифаларда 5 елдан ким булмаган эш стажы.

**Укытучы-дефектолог, укытучы-логопед:** дефектология өлкәсендә эш стажына таләпләр куймыйча югары һөнәри белем.

**Педагог-психолог:** «Педагогика һәм психология» әзерлек юнәлеше буенча эш стажына таләпләр куймыйча югары яки урта һөнәри белем яисә югары яки урта һөнәри белем һәм «Педагогика һәм психология» әзерлек юнәлеше буенча эш стажына таләпләр куймыйча өстәмә һөнәри белем.

**Тәрбияче:** «Мәгариф һәм педагогика» әзерлек юнәлеше буенча эш стажына таләпләр куймыйча югары яки урта һөнәри белем яисә эш стажына таләпләр куймыйча югары һөнәри белем яки «Мәгариф һәм педагогика» әзерлек юнәлеше буенча урта һәм өстәмә һөнәри белем.

**Өлкән тәрбияче:** «Мәгариф һәм педагогика» әзерлек юнәлеше буенча югары һөнәри белем һәм тәрбияче вазифасында 2 елдан ким булмаган эш стажы.

**Өстәмә белем бирү педагогы:** түгәрәк, секция, студия, клуб яки башка балалар берләшмәсе профиленә туры килә торган өлкәдә югары яки урта һөнәри белем яисә «Мәгариф һәм педагогика» әзерлек юнәлеше буенча эш стажына таләпләр куймыйча югары һөнәри белем яки урта һәм өстәмә һөнәри белем.

**Музыка җитәкчесе:** «Мәгариф һәм педагогика» әзерлек юнәлеше буенча эш стажына таләпләр куймыйча югары яки урта һөнәри белем, музыка инструментында профессиональ башкару техникасына ия булу.

**Физик культура буенча инструктор:** физкультура һәм спорт өлкәсендә эш стажына таләпләр куймыйча югары яки урта һөнәри белем яисә югары яки урта һөнәри белем һәм физкультура, һәм спорт, табибка кадәр ярдәм өлкәсендә өстәмә һөнәри белем.

Программаны гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен кирәкле төрле категория хезмәткәрләрнең вазифаи составы һәм саны аның максат һәм бурычлары, шулай ук балаларның үсеш үзенчәлекләре белән билгеләнә. Программаны гамәлгә ашыру кысаларында фәнни-тикшеренү, эксперименталь эшчәнлек алып бару өчен фәнни хезмәткәрләр чакырылырга мөмкин.

## Мәктәпкәчә белем бирү педагогларының һөнәри вазифалары

«Мәгариф турында Россия Федерациясе Законы» 273-ФЗ номерлы 2012 ел 29 декабрь Федераль законының 5 нче бүлек, 48 нче маддәсе нигезендә Оешманың педагогик хезмәткәрләре түбәндәгеләрне башкарырга бурычлы:

• үз эшчәнлекләрен югары һөнәри дәрәҗәдә башкару, тулы күләмдә Программаны гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

•хокукый, әхлакый һәм этик нормаларны саклау, һөнәри этика таләпләрен үтәү;

• тәрбияләнүчеләрнең белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучы һәм башкаларның намусын һәм дәрәҗәсен хөрмәт итү;

• тәрбияләнүчеләрдә танып белү активлыгын, мөстәкыйльлек, инициатива, иҗади сәләтләр үстерү;

• гражданлык позициясе, хәзерге дөнья шартларында хезмәт һәм тормыш күнекмәләре формалаштыру, сәламәт һәм имин тормыш рәвеше культурасы формалаштыру;

• педагогик яктан нигезләнгән һәм белем бирүнең югары сыйфатын тәэмин итүче формалар, укыту һәм тәрбия алымнары куллану;

• балаларның психофизик үсеш үзенчәлекләрен һәм аларның сәламәтлеге торышын исәпкә алу, кирәк булганда медицина оешмалары белән үзара бергәләп эш итү.

МББ ФДББС нигезендә Оешмада (төркемдә) педагогик хезмәткәрләрнең эшчәнлеге аларның үз һөнәри вазифаларын тиешенчә башкаруына йогынты ясаучы, шул рәвешле тәрбияләнүчеләргә карата зарури индивидуаль игътибарны киметүче һәм балаларның иминлегендә һәм үсешендә тискәре чагылулары ихтимал булган чамадан артык эш йөкләүгә юл куймаска тиеш.

Программаның сыйфатлы гамәлгә ашырылуының зарури шарты булып Оешмада яки төркемдә гамәлгә ашыру дәвамында аның өзлексез рәвештә педагогик һәм укыту-ярдәмче хезмәткәрләр тарафыннан тәэмин ителеше тора.

## Инклюзив белем бирүдә кадрлар шартлары

Инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы Оешма өчен кадрлар шартлары аерым үзенчәлеккә ия.

СМЧ балаларны гомуми белем бирү төркеменә керткәндә, мәктәпкәчә белем бирү оешмасында өстәмә рәвештә балаларның конкрет категориясе белән эшләү өчен аларның белем ихтыяҗларының үзгәлегенә туры килгән квалификациягә ия педагогик хезмәткәрләр, шул исәптән балаларга тиешле ярдәм күрсәтүче ассистентлар (ярдәмчеләр) вазифалары каралырга мөмкин. Инклюзив белем бирү оештырылган һәрбер төркем өчен тиешле педагогик хезмәткәрләр тарту тәкъдим ителә. Андый балалар категорияләре һәм аларны кадрлар белән тәэмин итү үзенчәлекләре Россия Федерациясе субъектларының хакимият органнары тарафыннан билгеләнә.

Төркемгә махсус белем ихтыяҗлары булган, шул исәптән авыр тормыш хәлендә яшәгән башка категорияләрдәге балаларны алганда, тиешле квалификациягә ия өстәмә педагогик хезмәткәрләр җәлеп ителә ала.

Программаны гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләр балаларның үсешен тәэмин итү өчен кирәк булган МББ ФДББС да билгеләнгән төп компетенцияләргә ия булырга тиеш.

## Педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше

Оешманың педагогик хезмәткәрләре:

• системалы рәвештә үзләренең һөнәри белем дәрәҗәләрен күтәрергә;

• «Мәгариф турында Россия Федерация Законы» 273-ФЗ номерлы 2012 ел 29 декабрь Федераль законының 5 нче бүлек, 49 нчы маддәсе белән билгеләнгән тәртиптә биләгән вазифаларына туры килүләрен раслау өчен аттестация узарга бурычлы.

Педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өзлексезлеге билгеләнгән күләмдә, һәр 5 елга бер тапкырдан да сирәк булмаган тәртиптә, белем бирү эшчәнлегенең күрсәтелгән төрен алып бару хокукына лицензиясе булган белем бирү учреждениеләрендә өстәмә һөнәри белем бирү программаларын үзләштерү процессында тәэмин ителергә тиеш.

Педагогларда Стандартка тиңдәшле рәвештә мәктәпкәчә белем бирүнең эчтәлеген билгеләүче биш төп белем бирү өлкәсен (социаль-коммуникатив үсеш, танып белү үсеше, сөйләм үсеше, сәнгати-эстетик үсеш, физик үсеш) уңышлы гамәлгә ашыру өчен кирәкле һөнәри компетенцияләр формалашырга тиеш. Хәзерге педагогтан шәхес үсешен, эшчәнлекнең төрле төрләрендә, аларның үзара тыгыз бәйләнешендә балаларның мотивацияләрен һәм сәләтләрен тәэмин итә белү таләп ителә.

Хәзерге вакытта белем бирүдә катнашучыларның уку-укыту-танып белү һәм һөнәри бурычларны мәгълүмати-коммуникацион технологияләр (МКТ) кулланып нәтиҗәле хәл итүгә һөнәри әзерлеге проблемасы, шулай ук мәктәпкәчә белем бирү оешмасында МКТ куллануга булышлык итүче хезмәтләрнең булуы актуальләште. Мәгълүмати белем бирү мохитенең уңышлы эшләве электрон белем бирү ресурслары белән генә түгел, аларны кулланучы хезмәткәрләрнең һөнәри компетентлыгы белән дә тәэмин ителә.

Мәктәпкәчә мәгариф системасында Оешманың җитеп бетмәгән кадрлар ресурсларын тутыру, башка белем бирү оешмаларының инновацион тәҗрибәсен тарату, белем бирү процессы нәтиҗәләренә һәм инновацияләрнең нәтиҗәлелегенә комплексы мониторинг тикшеренүләре үткәрү мөмкинлеген тәэмин итүче үзара хезмәттәшлек шартлары тудырылырга тиеш.

## Мәктәпкәчә оешма педагогларын аттестацияләү

Оешма педагогларын аттестацияләү педагогик хезмәткәрләрнең биләгән вазифаларына туры килүен раслау максатында һәм педагогик хезмәткәрләрнең теләге буенча квалификация категорияләрен билгеләү максатында уздырыла. Педагогик хезмәткәрләрнең үз вазифаларына туры килүен ачыклау өчен, аттестация 5 елга бер тапкыр белем бирү эшчәнлеге алып баручы оеш-

малар мөстәкыйль рәвештә формалаштырылган аттестация комиссияләре тарафыннан аларның һөнәри эшчәнлеген бәяләү нигезендә үткәрелә.

Белем бирүне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнары карамагында булган оешмалар педагогик хезмәткәрләренең квалификацион категорияләрен билгеләү максатында аттестация уздыру әлеге федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан формалаштырылган аттестация комиссияләре, ә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм Россия Федерациясе субъекты карамагында булган муниципаль һәм хосусый оешмалар педагогик хезмәткәрләренә мөнәсәбәттә әлеге аттестацияне үткәрү Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимият органнары вәкаләтләре белән формалаштырылган аттестация комиссияләре тарафыннан тормышка ашырыла («Мәгариф турында Россия Федерациясе Законы» 273-ФЗ номерлы 2012 ел 29 декабрь Федераль законы, 5 нче бүлек, 49 нчы маддә).

## ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ ФИНАНС ШАРТЛАРЫ

### МББ ТББПн гамәлгә ашыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә норматив чыгымнарны исәпләү үрнәге

МББ ТББПн гамәлгә ашыруның финанс ягын тәэмин итү Оешманың ихтыяҗлары белән ярашлы рәвештә МББ ТББПн үтәү барышындагы барлык тиешле чыгымнарны ябу юлы белән билгеләнә. МББ ТББПн гамәлгә ашыруның финанс ягын тәэмин итү ихтыяҗларын билгеләгәндә шул исәптән түбәндәге шартлар исәпкә алына:

• төркемнең юнәлеше (шул исәптән коррекцион, катнаш һәм сәламәтләндерү юнәлешенә караучы төркемнәр өчен);

• балаларның төркемдә булу режимы (тәүлек эчендә булу сәгатьләре саны);

• тәрбияләнүчеләрнең яше (төркемдәге балаларның яшь категориясе);

• МББ ТББПн гамәлгә ашыруның башка үзенчәлекләре.

Финанс ягыннан тәэмин итүдәге ихтыяҗларны билгеләгәндә өстәмә буларак Оешманың тибы исәпкә алына, шуңа бәйле рәвештә, 2012 ел 7 май 597 нче номерлы Россия Федерациясе Президентының Указы («Мәгариф һәм фән өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында») нигезендә педагогик хезмәткәрләрнең уртача дәрәҗәдәге хезмәт хакына гарантияләре билгеләнә.

МББ ТББПн гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү күләме Оешманың:

• МББ ТББПн гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын (педагогик персонал, шул исәптән тәрбиячеләр, балаларның үсеш юнәлешләре буенча МББ ТББПн гамәлгә ашыруны тәэмин итүче баш-

ка педагогик хезмәткәрләр, укыту-ярдәмче персонал, финанс-хуҗалык, административ-хуҗалык эшчәнлеген, балаларның гомерен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итүче персонал һ.б);

• уку-укыту чаралары, кирәкле материаллар (шул исәптән басма һәм электрон укыту ярдәмлекләре, дидактик материаллар, аудио- һәм видеоматериалларны); укыту чаралары сатып алу (шул исәптән белем бирү эшчәнлегенең барлык төрләрен оештыру һәм үсешкә китерүче предметлы тирәлек мохите булдыру өчен кирәкле материаллар, җиһазлар, махсус киемнәр, уеннар һәм уенчыклар, электрон белем бирү ресурслары (шул исәптән СМЧ балалар һәм инвалид балалар өчен махсус)); яңартылып торучы белем бирү ресурслары сатып алу (шул исәптән электрон ресурсларны актуальләштерү материалларына язылу, укыту чаралары комплектын тулыландыру һәм укыту чаралары эшчәнлеген техник тәэмин итүгә язылу, спорт, сәламәтләндерү җиһазлары, инвентарь); элемтә хезмәтенә түләү (шул исәптән Интернет мәгълүмати челтәренә тоташтыру белән бәйле) чыгымнарын;

• педагогик хезмәткәрләргә аларның педагогик эшчәнлеге профиле буенча өстәмә һөнәри белем бирү белән бәйле чыгымнарны;

• хезмәт күрсәтүләрдән файдалану, шул исәптән коммуналь хезмәт чыгымнарын;

• Оешманың МББ ТББПн гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка чыгымнарын каплау өчен җитәрлек булырга тиеш.

Дәүләти һәм муниципаль белем бирү оешмаларында РФ бюджет системасының үзләренә каралган бюджетлары хисабына гомуми һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга дәүләт гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итү белем бирү оешмасының МББ ФДББС таләпләрен үтәргә тиешлеге белән нигезләнүче чыгымнарын тулысынча каплауны исәпкә алып тормышка ашырыла.

Дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында МББ ТББПн гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү төбәк дәрәҗәсендәге һәм җирле хакимиятләр арасында вәкаләтләр бүлешү исәпкә алынып башкарыла.

Бюджет һәм (яки) автономияле белем бирү учреждениесендә МББ ТББПн гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү мәгариф программаларының барлык юнәлешләре буенча ведомство хезмәтләре исемлегенә тиңдәш рәвештә МББ ФДББС таләпләрен исәпкә алып билгеләнә торган норматив чыгымнарга туры китереп, гамәлгә куюның МББ ТББПн гамәлгә ашыру буенча дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) биреме нигезендә тормышка ашырыла. МББ ТББП аз комплектлы һәм (яки) авыл җирлегендә урнашкан белем бирү оешмасында гамәлгә ашырылганда, МББ ТББПн гамәлгә ашыру буенча дәүләт (муниципаль) хезмәтләренең норматив чыгымнарыннан белем бирү оешмасында укучыларның санына бәйле булмаган чыгымнар да исәпкә алырга тиеш.

МББ ТББП казна белем бирү учреждениесендә гамәлгә ашырылган очракта гамәлгә куючы аның эшчәнлеген финанслауны смета буенча бюджет акчаларын эшчәнлеккә керем китерүче керемнәр күләмен исәпкә алып, бүлү нигезендә тормышка ашыра.

МББ ТББПн гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны билгеләгәндә, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимият органнары тарафыннан каралган финанс ягыннан тәэмин итү нормативлары исәпкә алынырга тиеш, аларга яраклы рәвештә җирле бюджетларга муниципаль белем бирү оешмаларында гомуми һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алу хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә субвенцияләр бирелә.

МББ ТББПн гамәлгә ашыру буенча дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен күрсәтүгә карата гамәлгә куючының дәүләт (муниципаль) биремен үтәвен сыйфатлаучы күрсәткечләре МББ ТББПн гамәлгә ашыру шартларына нисбәттә МББ ФДББС таләпләренә нигезләнергә тиеш. Телгә алынган күрсәткечләр белем бирү программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен исәпкә ала алмый. Дәүләт (муниципаль) биремен үтәү күрсәткечләре сыйфатында белем бирү оешмасының йөреш күрсәткечләрен (балаларның авыруын исәпкә алып) исәпләргә тәкъдим ителми.

Балаларның мәктәпкәчә белем алуын хосусый белем бирү оешмаларында, шулай ук укытуны индивидуаль эшмәкәрләр хисабына оештыручы оешмаларда да, финанс ягыннан тәэмин итү ата-аналар (законлы вәкилләр) акчасы хисабына яисә әлеге учреждениеләргә чыгымнарны Россия Федерациясе субъекты акчасы исәбенә кайтаруга субсидияләр бирү ярдәмендә гамәлгә ашырыла. МББ ТББПн гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтүгә булган чыгымнарга субсидия алган очракта, аерым (барлык) тәрбияләнүчеләр өчен МББ ТББПн гамәлгә ашыру күрсәтелгән тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары (законлы вәкилләре) өчен түләүсез нигездә оештырыла. Хосусый белем бирү оешмалары өчен чыгымнарны каплауга киткән субсидияләр күләменә туры килгән финанс ягын тәэмин итү нормативы муниципаль белем бирү оешмасының тиешле тибы өчен Россия Федерациясе субъекты дәрәҗәсендә тәгаенләнгән финанс ягын тәэмин итү нормативларына туры килергә тиеш (финанслауның тиешле нормативлары күчемсез милекне тотуга киткән чыгымнарны һәм коммуналь чыгымнарны үз эченә алмый).

Дәүләти һәм муниципаль белем бирү оешмаларында МББ ТББПн гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү коммуналь хезмәтләр һәм биналарны карап тотуга киткән чыгымнар өлешендә тиешле белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар акчалары хисабына тормышка ашырыла.

СМЧ балалар, шул исәптән инвалид балалар өчен җайлаштырылган МББ ТББПн гамәлгә ашырганда, МББ ТББПн гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү күрсәтелгән балаларны махсус персонал карап йөртүне дә капларга тиеш.

МББ ФДББС таләпләренә ярашлы рәвештә норматив чыгымнарны исәпләгәндә, Программаны гамәлгә ашыру кысаларында оешмаларның педагогик хезмәткәрләренең бөтен төр эшләрне үтәүгә киткән вакытка ихтыяҗлары һәм шулай ук тиешле предметлы тирәлек мохитен булдыру чыгымнары, шул исәптән укыту чараларын сатып алуга киткән чыгымнар исәпкә алынырга тиеш. МББ ТББПн гамәлгә ашырганда якынча норматив чыгымнар төрле

яшьтәге балалар, МББ ТББП гамәлгә ашырыла торган торак пункт типлары, төркемнәрнең юнәлешләре һәм режимнары өчен аерым каралалар.

МББ ТББПн ($N_{хк}$) гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$N_{хк} = N_{ук} + N_{хт} + N_{ком} + N_{б} \quad (Nусл = Nобуч + Nот + Nком + Nзд).$$

$N_{ук}$ — МББ ТББПн гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүнең РФ субъекты дәрәҗәсендә тәгаенләнгән, Оешма җитәкчесенең хезмәтенә түләү билгеләнеп төгәлләштерелгән нормативы.

$N_{хт}$ — Оешманы гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнгән, биналарны һәм кыйммәтле мөлкәтне карап тотуны, төп гомуми белем бирү программалары буенча гомуми һәм түләүсез мәктәпкәчә белем бирүне оештыруны тәэмин итүче һәм карау һәм тәрбия кылуны тормышка ашыру өчен шартлар тудыручы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә киткән норматив чыгымнар.

$N_{ком}$ — билгеләү тәртибе Оешманы гамәлгә куючы тарафыннан тәгаенләнә һәм Программаны гамәлгә ашыру һәм аның буенча укучы балаларны карау һәм тәрбия кылу өчен шартлар тудыру вакытында коммуналь хезмәтләр куллану үзенчәлекләрен исәпкә ала торган норматив чыгымнар.

$N_{б}$ — МББ ТББПн гамәлгә ашыруны оештыру процессында кулланыла торган сарыф ителүче материалларга, оешманың биналары һәм корылмаларын карап тотуга карата норматив чыгымнар.

Югарыда китерелгән норматив чыгымнар, МББ ТББПн гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүнең Россия Федерациясе субъекты дәрәҗәсендә каралган нормативыннан кала, Оешманың, шулай ук ул урнашкан торак пунктның үзенчәлекләреннән чыгып индивидуаль билгеләнә һәм тиешле норматив чыгымнар аерым муниципаль районнар (шәһәр округлары) дәрәҗәсендә билгеләнү сәбәпле, бер-берләреннән аерылып тора.

## МББ ТББПн гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүнең РФ субъекты дәрәҗәсендә тәгаенләнгән нормативын исәпләү үрнәге

МББ ТББПн гамәлгә ашыруның кадрлар шартларына карата таләпләргә, предметлы тирәлек мохитенә һәм матди-техник тәэмин итүгә куелган таләпләргә тиңдәшле рәвештә оешмада МББ ТББПн гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү ($N_{ук}$ ) түбәндәге формула белән исәпләнә:

$$N_{ук} = N_{пед} + N_{ях} + N_{һб} + N_{уч} + N_{пк}$$

$N_{пед}$ — **педагогик хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү һәм хезмәткә түләүне өстәмә финанслау нормативы.** МББ ТББПн гамәлгә ашыруның төрле үзенчәлекләре өчен тиешле финанслау нормативлары күрсәткечләре Кушымтада (1–5 нче таблицалар) китерелә. Исәпләүләр Программаның кадрлар белән комплектлаштырылуга булган төп таләпләреннән чыгып башкарылды. МББ

ТББПн нәтиҗәле гамәлгә ашыруны өстәмә белгечләр тарту хисабына тәэмин итү өчен финанслау нормативларын кадрлар белән комплектлаштырылуга төп таләпләрне үтәү өчен кирәк булган финанслау нормативыннан 10–20 % ка артыграк билгеләүне күздә тотарга тәкъдим ителә.

$N_{ях}$ — **укыту-ярдәмче хезмәткәрләрнең (тәрбияче ярдәмчеләре һәм кече тәрбиячеләр) хезмәтенә түләү һәм хезмәткә өстәмә түләүне финанслау нормативы.** 2015 ел өчен МББ ТББПн гамәлгә ашыруның төрле үзенчәлекләре өчен тиешле финанслау нормативлары Кушымтада (6–8 нче таблицалар) китерелә.

$N_{һб}$ — **МББ ТББПн гамәлгә ашыру өчен кирәк булган башка персоналның хезмәтенә түләү хезмәткә һәм өстәмә түләүне финанслау нормативы.** 2015 ел өчен МББ ТББПн гамәлгә ашыруның төрле үзенчәлекләре өчен тиешле финанслау нормативларының аңлатмалары Кушымтада (9 нчы таблица) китерелә.

$N_{уч}$ — **МББ ТББПн гамәлгә ашыруда кулланыла торган укыту һәм тәрбия чаралары чыгымнарын тәэмин итүне финанслау нормативы.** Нормативның күләме Оешманың төп средстволарны финанс ягыннан тәэмин итү үзенчәлекләренә туры китереп билгеләнә. 2015 ел өчен уку-укыту чараларының төп комплектын булдыруны финанслау нормативы РФ буенча бер тәрбияләнүчегә елына уртача 4000 — 9000 сум тәшкил итә. МББ ТББПн нәтиҗәле гамәлгә ашыруны предметлы тирәлек мохитенең нәтиҗәлелеген арттыру хисабына тәэмин итү өчен, уку-укыту чараларын финанслау нормативларын төп комплектны финанслау нормативларыннан 20–30 % ка артыграк билгеләүне күздә тотарга тәкъдим ителә.

$N_{пк}$ — **МББ ТББПн гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне финанслау нормативы.** Квалификацияне күтәрүнең уртача бәясен, аның кабатлану санын, шулай ук өстәмә һөнәри программалар буенча укыту уздырыласы урынга баруның уртача юл чыгымнарын бәяләүне, уку барышында торак өчен түләү бәясен кертеп, бер тәрбияләнүчегә исәпләгәндә финанслау нормативы күрсәткече елга якынча 635 сумга якын тәшкил итә.

Хезмәткә түләүнең төбәк системасы үзенчәлекләрен исәпкә алу, педагогик хезмәткәрләрнең ($N_{пед}$), укыту-ярдәмче хезмәткәрләрнең ($N_{ях}$) һәм башка персоналның ($N_{һб}$) хезмәтенә түләү хезмәткә өстәмә түләүне финанслау нормативларын билгеләү өчен күрсәтелгән финанслау нормативларын МББ ТББПнда бирелгән коррекцияләү коэффициенты зурлыгына үзгәртергә тәкъдим ителә (10 нчы таблица).

Өстәмә рәвештә, Оешманың эш режимын (атнадагы көннәрне һәм елдагы айларны) исәпкә алу өчен МББ ТББПн гамәлгә ашыруны тәэмин итү ягыннан тәкъдим ителгән финанс нормативларына төзәтмә кертелергә мөмкин.

МББ ТББПн гамәлгә ашыруның 2016 елга һәм алдагы елларга чыгым нормативларын исәпләү өчен аерым категория хезмәткәрләрнең хезмәт хаклары артуын һәм шулай ук уку-укыту чаралары бәяләренең үзгәрүне билгеләүче күрсәткечләр файдаланылырга тиеш.

МББ ТББПн гамәлгә ашыруны финанс ягыннан Оешма дәрәҗәсендә тәэмин итү күләме агымдагы финанс елына бүленгән акча күләме чикләрендә башкарыла һәм МББ ТББПн гамәлгә ашыру өчен кирәкле чыгымнарны каплау, шул исәптән аны гамәлгә ашыруда катнашучы барлык категория персоналның хезмәтенә түләү, уку-укыту һәм тәрбия чаралары белән тәэмин итү, педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эшчәнлек профиле буенча өстәмә һөнәри белем алу хокукын гамәлгә ашыру, Оешманың эшчәнлеген тәэмин итү файдаланыла.

Оешманың аерым категория хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе, күләме һәм шартлары, шул исәптән стимуллаштыручы түләүләр Оешманың локаль хокукый актларында һәм /яки коллектив килешүләрдә билгеләнә. Стимуллаштыручы түләүләр турында локаль хокукый актларда МББ ТББПн гамәлгә ашыру шартларына карата МББ ФДББС таләпләренә туры китереп эшләнгән нәтиҗәлелек һәм сыйфат критерийлары билгеләнә. Хезмәткә түләү фондының стимуллаштыручы өлешен бүлүдә Оешманың үзидарә органнары катнашуы күздә тотыла.

Оешма сатып алу предметларын, уку-укыту чараларының санын һәм бәясен, шулай ук МББ ТББПн гамәлгә ашыру шартларына ярашлы таләпләргә җавап бирерлек эшчәнлек төрләре исемлеген мөстәкыйль рәвештә билгели.

# МББнең ТӨП ПРОГРАММАСЫН ЯЗУ БУЕНЧА ТӘКЪДИМНӘР

## ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының төп белем бирү программасы (алга таба — МББ ТББП) Оешма тарафыннан МББ ФДББС таләпләренә туры китереп, «Мәктәпкәчә белем бирүнең үрнәк төп белем бирү программасы»н исәпкә алып һәм гамәлдәге мәктәпкәчә белем бирү программаларының киң спектры материалларына таянып эшләнергә һәм расланырга тиеш.

МББ ТББП белем бирү эшчәнлеге эчтәлеген һәм оештыруны билгели, шуның белән бергә бер Оешмадагы структур бүлекчәләр (алга таба — Төркемнәр) төрле программаларны гамәлгә ашыра ала. МББ ТББПн эшләгәндә белем бирү оешмасы балаларның оешмада булу дәвамлылыгын, белем бирү эшчәнлегенең хәл ителергә тиешле бурычлар күләменә ярашлы рәвештә оешманың эш режимын, Төркемнәрнең тутырылу чиген билгели. Оешма Төркемнәрдә балаларның тәүлек эчендә төрле вакыт дәвамында булуына корылган төрле программалар эшли һәм гамәлгә ашыра ала (балалар Оешмада булган бөтен вакыт дәвамында; кыска вакытка килү Төркемнәре, тулы һәм озынайтылган көн Төркемнәре, тәүлек буе булу Төркемнәре, ике айдан алып сигез яшькә кадәрге балаларның яшь буенча Төркемнәре, шул исәптән төрле яшьтәгеләр Төркемнәре кысаларында һ.б.).

МББ ФДББС таләпләренә туры китереп, МББ ТББП **мәҗбүри өлештән** һәм **белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырылган өлештән** торырга тиеш, шуның белән бергә ике өлеш тә бер-берсен үзара тулыландыручы һәм зарури булып тора.

Мәҗбүри өлеш бер-берсен үзара тулыландыручы барлык биш белем бирү өлкәсендә балаларның комплекслы үсешен тәэмин итә.

Белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырылган өлештә балаларны бер яисә берничә белем бирү өлкәсендә, эшчәнлек төрләрендә һәм/ яки мәдәни практикаларда үстерүгә юнәлтелгән сайлап алынган һәм/ яки мөстәкыйль эшләнгән парциаль программалар, методикалар, мәгариф эшен оештыру формалары тәкъдим ителергә тиеш. Шуның белән бергә, әгәр МББ ТББП гамәлдәге үрнәк һәм парциаль программалар базасында төзелсә, бу программаларны күчереп язу ихтыяҗы юк, аларга сылтама бирү дә җитә. Бу МББ ФДББСның 2.12 пунктында ачык күрсәтелә: «Программаның мәҗбүри өлеше үрнәк программага туры килгән очракта, ул

үрнәк программага сылтама рәвешендә формалаштырыла. Мәҗбүри өлеш үрнәк программаларның берәрсенә туры килмәгән очракта, ул Стандартның 2.11 пунктына тиңдәшле рәвештә киңәйтелгән хәлдә тәкъдим ителергә тиеш.

Программаның белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырылган өлеше белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан сайланган парциаль программалар, методикалар, мәгариф эшен оештыру формалары эчтәлеге белән танышырга мөмкинлек бирүче тиешле методик әдәбиятка сылтама рәвешендә тәкъдим ителергә мөмкин».

МББ ФДББС буенча программаның мәҗбүри өлеше күләменең аның гомуми күләменең 60 % ыннан ким булмаска; белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырылган өлеше күләме 40 % тан артмаска тиеш.

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы нигезендә белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырылган өлешне җиңел һәм конструктив кертеп җибәрү бер дә авыр түгел. Аерым алганда, «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасында барлык эчтәлек өлеше белем бирү өлкәләре буенча төркемләнгән тематик блоклар ярдәмендә бирелә. Мәктәпкәчә оешма тематик блокларның берсен яисә берничәсен үзенең парциаль программаларына алыштырырга мөмкин. Мәсәлән, мәктәпкәчә оешманың балаларның математик яктан үсешен көчәйтү теләге булганда, программада «Элементар математик күзаллаулар формалаштыру» блогын В.Н.Новикованың «Балалар бакчасында математика» авторлык программасына яисә, парциаль программа «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы максатларына һәм бурычларына каршы килмәгән шартта, элементар математик күзаллауларны формалаштыру буенча нинди дә булса башка парциаль программага алыштырырга мөмкин.

## МББ ТӨП БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫ СТРУКТУРАСЫ

МББ ФДББС буенча МББ ТББП **өч төп бүлекне** (максатлар, эчтәлек, оештыру) һәм өстәмә бүлекне колачларга тиеш.

Төп бүлекләрнең һәркайсы мәҗбүри өлешне (бу «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы) һәм белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырылган, Оешманың үзенчәлеген һәм өстенлекле эш юнәлешләрен чагылдыра торган өлешне үз эченә алырга тиеш.

Моннан тыш МББ ТББП төп төшенчәләр, шартлы билгеләр, кыскартулар һ.б. күрсәтелгән кереш сүз белән тәэмин ителергә мөмкин.

МББ ФДББСнда программаның структурасында булырга тиешле бүлекләр билгеләнә (2.11 пунктны кара: «Программа өч төп бүлекне: максатлар, эчтәлек һәм оештыру бүлекләрен эченә ала, аларның һәркайсында мәҗбүри

өлеш һәм белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырылган өлеш чагылыш таба»). Әмма МББ ФДББСнда **бүлекләрнең эзлеклелеге тәртибенә карата катгый таләпләр юк.** Программа авторлары бүлекләрне түбәндәге тәртиптә урнаштыруны уңайлырак һәм эзлеклерәк дип таптылар: максатлар, эчтәлек һәм оештыру бүлекләре.

Шулай итеп, МББ ФДББСна туры китереп, МББ ТББП структурасы түбәндәге структур элементларны үз эченә алырга тиеш.

**Максатлар бүлеге.**

- Аңлатма язуы.
- МББ ТББПн үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.

**Эчтәлек бүлеге.**

- Биш белем бирү өлкәсе буенча белем бирү эчтәлеге.
- МББ ТББПсын гамәлгә ашыру формалары, ысуллары, алымнары һәм чаралары.
- Балалар үсешендәге тайпылышларны профессиональ коррекцияләү буенча белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге.

**Оештыру бүлеге.**

**МББ ТББПн кыскача презентацияләү (өстәмә бүлек).**

МББ ТББПның төп өч бүлегенең һәркайсы бер-берсен тулыландыручы мәҗбүри өлешне һәм белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырылган өлешне колачлый һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмасының белем бирү эшчәнлеген күз алдына китерүче тулы документ буларак теркәлә.

## МББ программасы бүлекләрен язу үзенчәлекләре

### Максатлар бүлеге

**Аңлатма язуы.** Аңлатма язуында:

- МББ ТББПн гамәлгә ашыру максатлары һәм бурычлары;
- МББ ТББПн формалаштыруга кагылышлы принциплар һәм карашлар;
- МББ ТББПн эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен мөһим сыйфатламалар ачыклана.

МББ ТББПның мәҗбүри өлешендәге «Максатлар һәм бурычлар» бүлекчәсе мәктәпкәчә белем бирү оешмасының төр үзенчәлегенә, өстенлекле эшчәнлек юнәлешләре булуга (МББО статусы, проектларда катнашу һ.б.), белем бирү эшчәнлеге тормышка ашырыла торган милли, этномәдәни, демографик, климатик һәм башка шартлар үзгәлегенә бәйле максатлар һәм бурычлар белән тулыландырыла һәм конкретлаштырыла торган үрнәк программа максатлары һәм бурычларына туры килә.

«МББ ТББПн формалаштыруга кагылышлы принциплар һәм карашлар» бүлекчәсе ТББПн формалаштыручы, кулланыла торган үрнәк һәм парциаль мәгариф программалары һәм принципларына күрсәтмәне эченә ала.

«МББ ТББП н эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен мөһим сыйфатламалар» бүлекчәсендә кече һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсешенең яшь үзенчәлекләре, Оешма һәм Оешмадагы яшь төркемнәре турында кыскача мәгълүмат, әлеге оешмада тәрбияләнүче балаларның үзенчәлекләре һәм шулай ук, әгәр дә булса, өстәмә белем бирү хезмәтләре турында мәгълүмат китерелә.

**МББ ТББПн үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.** МББ ТББПның бу өлеше үрнәк программаның тиңдәшле бүлеге, бу очракта «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы (мәҗбүри өлеш) нигезендә төзелә һәм белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырылган өлештә планлаштырылучы нәтиҗәләрне тасвирлау белән тулыландырыла һәм конкретлаштырыла (бу өстенлекле юнәлешләр буенча эшләр, СМЧ балаларның һәм инвалид балаларның үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алучы нәтиҗәләр һ.б.).

## Эчтәлек бүлеге

**МББ ТББПн гамәлгә ашыру формалары, ысуллары, алымнары һәм чаралары.** МББ ТББПның бу өлеше «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасының «Программаны гамәлгә ашыруның психологик-педагогик шартлары» бүлегенә туры килә һәм кирәк булган очракта вариатив өлеш белән тулыландырыла.

МББ ФДББС буенча, бу өлештә:

• мәгариф эшчәнлегенең төрле төрләре һәм мәдәни практика үзенчәлекләре;

• балалар инициативасына булышлык итү ысуллары һәм юнәлешләре;

• педагогик коллективның тәрбияләнүчеләр гаиләләре белән үзара багланышы үзенчәлекләре;

• авторлар карашынча программаның бик мөһим булган башка сыйфатламалары тәкъдим ителергә тиеш.

**Психологик-педагогик эшнең эчтәлеге.** Психологик-педагогик эшнең эчтәлеге биш белем бирү өлкәсе буенча бирелергә тиеш:

• социаль-коммуникатив үсеш;

• танып белү үсеше;

• сөйләм үсеше;

• сәнгати-эстетик үсеш;

• физик үсеш.

МББ ТББПның әлеге бүлеге «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы (мәҗбүри өлеш) нигезендә төзелә һәм белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырылган өлешне гамәлгә ашыруга юнәлтелгән материаллар белән тулыландырыла.

Белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан формалаштырылган өлештә балаларны бер яисә берничә белем бирү өлкәсендә, эшчәнлек төрендә һәм (яки) мәдәни практика үстерүгә юнәлтелгән сайлап алынган һәм/ яки мөстәкыйль эшләнгән парциаль программалар, методикалар, мәгариф эшен оештыру формалары тәкъдим ителергә тиеш.

ФДББС буенча МББ ТББПның бу өлеше балаларның, аларның гаилә әгъзаларының һәм педагогларның белем бирү ихтыяҗларын, кызыксынуларын һәм мотивларын исәпкә алырга тиеш һәм, аерым алганда, түбәндәгеләргә юнәлтелә ала:

• белем бирү эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган милли, социомәдәни һәм башка шартларның үзгәлегенә;

• балалар белән эшне оештыру формаларын һәм парциаль мәгариф программаларын балаларның ихтыяҗларына һәм кызыксынуларына мөмкин булган дәрәҗәдә туры китереп һәм шулай ук педагогик коллективның мөмкинлекләренә яраштырып сайлау;

• Оешманың яисә Төркемнең ныгып урнашкан традицияләре.

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасында эчтәлек өлешенең тематик блоклар буенча бәян ителүе сәбәпле, мәктәпкәчә оешма бер яки берничә тематик блокны үз парциаль программаларына алыштырып, үз вариатив өлешен җиңел генә кертеп җибәрә ала.

**Коррекцион эш һәм /яки инклюзив белем бирү.** Бу бүлектә балалар үсешендәге тайпылышларны профессиональ коррекцияләү буенча белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге күрсәтелергә тиеш. Әлеге бүлек «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасының шуңа туры килгән бүлегенә нигезләнә һәм МББ ТББПна сәламәтлек мөмкинлекләре чикле ( СМЧ) балалар тарафыннан үзләштерелүе планлаштырылган очракта кертелә.

## Оештыру бүлеге

Оештыру бүлеге мәктәпкәчә белем бирү оешмасы коллективы тарафыннан үрнәк программа материалларына, норматив-хокукый документларга, методик хатлар һәм тәкъдимнәргә таянып әзерләнә.

Оештыру бүлеге МББ ТББПның нинди шартларда гамәлгә ашырылуы турында күзаллаулар тудыра. Әлеге бүлектә түбәндәгеләр булырга тиеш:

• көн тәртибе һәм/ яки көндәлек режим;

• мәктәпкәчә белем бирү оешмасы өчен традициягә әверелгән вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар;

• үсешкә китерүче предметлы мохит тирәлеген оештыру үзенчәлекләре;

• МББ ТББПн гамәлгә ашыруның матди-техник шартларына карата таләпләр (шул исәптән методик материаллар һәм уку-укыту һәм тәрбия чаралары белән тәэмин ителгәнлек).

МББ ТББПның әлеге бүлеген язганда нигез итеп «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасының шуңа охшаш бүлеге алынырга мөмкин һәм кирәк

булганда, ул дәүләт биремен (муниципаль бирем) формалаштырганда, МББ ТББП өстенлекләренә туры китереп тулыландырыла яисә үзгәртелә ала. Шуның белән бергә зарури үзгәрешләрне гамәлдәге шартларда МББ ТББП өстенлекләре белән туры китереп нигезләргә кирәк: белем бирү процессында аларның кирәклеген дәлилләргә мөмкинлек бирүче өстәмә уку-укыту чараларын һәм методик материалларны тасвирлау; кадрлар белән тәэмин итүдә өстәмә штат берәмлекләре кертү кирәклеген нигезләү һ.б.

### Кыскача презентацияләү (өстәмә бүлек)

МББ ТББПн кыскача презентацияләү ТББПның өстәмә бүлеге булып тора. Кыскача презентацияләү ата-аналарга юнәлтелгән һәм алар таныша алырлык булырга тиеш (Оешманың сайтында урнаштырыла).

ФДББС буенча МББ ТББПның кыскача презентациясендә:

• әгәр МББ ТББПнда балаларның яшь аермасы буенча яки башка категорияләренә, шул исәптән СМЧ балалар категориясенә юнәлтелгән МББ ТББПн тормышка ашыруда үзенчәлекләр каралса, шул төр категорияләр;

• кулланыла торган үрнәк программалар;

• педагогик коллективның балалар гаиләләре белән үзара бәйләныш сыйфатламалары күрсәтелергә тиеш.

# КУШЫМТАЛАР

# Балалар үсешенең яшь үзенчәлекләре

## Сабыйлар төркеме (туганнан алып 1 яшькә кадәр)

**Бала яшәешенең беренче елы үзе дә, ерак перспектива җәһәтендә дә аеруча мөһим.** Ләкин өлкән кешенең җитәкчелек эше җиренә җиткерелеп башкарылганда, ул балалар үсешенең үзенчәлекләрен белгән очракта гына педагогик йогынты үз максатына ирешә.

Бала яшәешенең бу чоры аның тормышының алдагы чорлары белән чагыштырмаслык дәрәҗәдә **физик, психик һәм хәтта социаль үсешнең тиз темпы белән аерылып тора.**

Яшәешнең беренче елында баланың һәм өлкән кешенең эмоциональ аралашуы формалаша, ул исә ситуациячел-эшлекле аралашуга әверелә. Балалар өчен якын-тирәлекне сиземләп кабул итү, күрсәтмә-хәрәкәтле фикерләү, югары хәрәкәтләнү активлыгы һәм нерв системасының аз хәрәкәтчәнлеге, тормоз процессларының формалашмаганлыгы, игътибарның читкә китүе хас.

Туганда уртача авырлык (гәүдә массасы) — 3200–3400 г булса, 5–6 айга җиткәндә ул ике тапкыр, бер яшь тулганда өч тапкыр арта. Баланың туганда уртача буе — 50–52 см, бер яшькә кадәр сабый 20–25 см га үсә.

Тулы сыйфатлы йокы, актив уяулык сәләте балага тумыштан бирелми. Фәкать беренче айларда (хәтта ел дәвамында) ул акрынлап тирән итеп һәм тыныч йокларга, актив уяулыкка «өйрәнә».

Көн дәвамында баланың йокысы берничә тапкыр актив уяулык халәте белән чиратлаша; тора-бара уяулык халәтенең дәвамлылыгы ел эчендә бик тиз рәвештә — 1 сәгатьтән 3,5–4 сәгатькә кадәр арта. Бу исә югары нерв эшчәнлеге үсешен һәм бер үк вакытта сабыйның нерв системасын талчыгудан саклау зарурлыгын күрсәтә.

Актив уяулык сәләте — хәрәкәтләр, сөйләмне һәм тирәлектәгеләр белән аралашуны аңга кабул итеп алу өчен нигез.

Яңа туган бала хәтта туклану чыганагына — әнисенең күкрәгенә дә үрелә алмый. Ә менә 7–8 айлык вакытта инде сабый актив шуыша, ул мөстәкыйль рәвештә утыра һәм уенчык белән эш иткәндә шул позада кала ала. Яшь тулганда, кагыйдә буларак, мөстәкыйль рәвештә йөри.

Беренче елда бала үсешенең төрле якларының үзара бәйләнеше төп хәрәкәтләрне үзләштергәндә ачык чагыла.

Бала яшәешенең беренче көннәреннән аның күрү һәм ишетү сәләте интенсив рәвештә үсеш кичерә. Алар контролендә һәм катнашында куллар

хәрәкәтләнә башлый: сабый үзе күргән предметны эләктереп ала һәм тотып тора (4–5 ай). Һәм, ниһаять, ачык төсле уенчыкны күрү һәм якын кешесенең тавышы баланы кулларына таянып үрмәләргә һәм аннары тотынып йөрергә этәрә (икенче яртыеллык).

Беренче ел дәвамында **ишетеп һәм күреп аңга кабул итү** үсеш кичерә. Беренче айларда сабый өлкән кешенең йөзенә яки уенчыкка текәлеп карый, аларның хәрәкәтен күзәтә, тавышка колак сала, кулларын суза, карават өстенә эленгән уенчыкларны үрелеп эләктерә башлый. 4,5–5 ай узгач, балалар төп төсләрне һәм формаларны аера алалар. Алар интонациягә һәм төрле характердагы музыкага эмоциональ мөнәсәбәт белдерәләр.

9–10 айдан соң уенчык белән гади хәрәкәтләр ясау (тотып тору, болгау) катлаулы булмаган предметлы-уен хәрәкәтләренә әверелә. Сабый шакмакларны тартмага сала, тупны ыргыта, курчакны тибрәтә. Яраткан уенчыклар барлыкка килә.

Яшәешенең беренче айларында бала кыска, өзек-өзек авазлар («гы, кхы») чыгара, 4–5 айларда ул көйләп гүли («ә-ә-ә») — болар сөйләм сулышы өчен бик мөһим. Шуннан соң өлкән кешегә охшатып тәтелди башлый, ягъни иҗекләр әйтә, соңрак шул иҗекләрдән сүзләр ясала.

Беренче сөйләм алды реакцияләре мисалында шулай ук үсешнең төрле якларының үзара бәйләнешен күзәтергә мөмкин. Сөйләм үсеше нигезендә яткан тавыш реакцияләре бары тик җанлы кул һәм аяк хәрәкәтләре белән тулыланган уңай эмоциональ халәт фонында гына туалар, ягъни «җанлану комплексы» формасында чагылалар.

Яшь тулганда инде сөйләм үсеше турында сөйләргә мөмкин, чөнки **аңлау нигезләре формалаша** (30–50 сүзгә кадәр), бала берничә гади сүз (6–10 сүз) куллана башлый. Өлкән кешенең балага сөйләм аша мөрәҗәгать итүе аны тынычландырырга, катлаулы булмаган шөгыль башкарырга этәргеч бирергә мөмкин.

Балаларның социальләшүе төрле юнәлешләрдә бара. Сабыйлар яшәешенең беренче айларыннан ук әниләрен башка объектлар арасыннан аера башлыйлар. Икенче яртыеллыкта өлкәннәргә карата ачык рәвештә төрле мөнәсәбәтләр белдерәләр: якын кешеләрен күреп сөенәләр, ят кешеләргә сагаеп карыйлар. Якын өлкәннәргә карата инициативалы мөнәсәбәт белдерү (авазлар, елмаюлар, хәрәкәтләр аша) формалаша бара. Ике, өч айлык балалар, манежда янәшә ятканда, бер-берсен күреп сөенәләр, күршеләрен кызыксынып күзәтәләр. Өлкәнрәк яшьтә, бер-берсе белән янәшә булганда, иптәшенең гамәлләренә игътибар итәләр, аның көлүенә эмоциональ мөнәсәбәт белдерәләр.

Бала, өлкән кеше кулында булганда, тирәлектә ориентлаша башлый (ачык төсләрдәге картинага, тәрәзәгә, ишеккә таба башын бора). Мөстәкыйль хәрәкәтләнгәндә (шуышу, йөрү), үзенә эндәшкән өлкән кешегә, үзен кызыксындырган предметка таба хәрәкәт итәргә омтыла.

**Үз-үзенә хезмәт күрсәтүнең иң гади** элементлары барлыкка килә: 5–6 айда бала шешәне кулларында тотып тора, яшь тулганда чынаякны тота, баш киемен, оекларын сала, өлкән кеше соравы буенча кием предметларын алып бирә.

**Яшәешнең беренче елы ахырына төп сәләтләр:** бала якын арада йөрү күнекмәләрен үзләштерә, аерым предметларны һәм уенчыкларны вазифалары буенча куллана башлый. Гади йомышларны үти һәм аңлатуларга төшенә, гади сүзләрне (8–10 сүзгә кадәр) куллана ала. Өлкән кеше белән эмоциональ һәм объектив юнәлтелгән аралашуга ихтыяҗ кичерә.

## Беренче кече яшьтәгеләр төркеме (1 яшьтән 2 яшькә кадәр)

Яшәешнең икенче елында балаларның мөстәкыйльлеге үсә, предметлы уен эшчәнлеге формалаша, сюжетлы уен элементлары барлыкка килә. Өлкән кеше белән аралашу ситуацияле-эшлекле, аннары эшлекле хезмәттәшлек төсе ала. Аңга кабул итү, сөйләм, күрсәтмә-хәрәкәтле фикерләү, чынбарлыкны sиземләп кабул итү камилләшә.

Авырлык ай саен 200–250 г га арта, буй үсеше 1 см тәшкил итә. Эчке органнарның, сөяк, мускуллар һәм үзәк нерв системасының төзелеше һәм функцияләре камилләшү дәвам итә. Нерв күзәнәкләренең эшчәнлеге арта. Актив уяулык халәтенең дәвамлылыгы яшь ярымга кадәрге балаларда — 3–4 сәгать, ике яшьлек балаларда 4–5,5 сәгать тәшкил итә.

Баланың төп хәрәкәтләре үсешенә өлешчә аның гәүдә пропорцияләре (кыска аяклар, озын гәүдә, зур баш) йогынты ясый. Яшь ярымга кадәр сабый йөргәндә еш егыла, вакытында туктап кала, тоткарлыкны әйләнеп уза алмый. Гәүдәнең торышы да тотрыклы түгел. Мускуллар системасының җитәрлек дәрәҗәдә үсмәве нәтиҗәсендә балага озак вакыт бер типтагы хәрәкәтләр башкару, мәсәлән, әнисе белән «кулга тотынып кына» йөрү кыен. Яшәешнең икенче елында балаларга югары хәрәкәтләнү активлыгы хас.

Акрынлап, **йөрү камилләшә.** Балалар һавада йөргәндә иркен хәрәкәтләнергә өйрәнәләр: алар калкулыкларга меңәләр, үләндә йөриләр, кечерәк тоткарлыклар, мәсәлән, җирдә яткан таяк аша атлап чыгалар. Аякны ышкып йөрү юкка чыга. Хәрәкәтле уеннарда һәм музыка дәресләрендә балалар янга атлау күнекмәләрен үзләштерәләр, акрын гына урында бөтереләләр.

Икенче яшькә кергәч, балалар күп һәм теләп үрмәлиләр: биек урыннарга, диваннарга, ә соңрак (бер аяклап) швед стенкасына менәләр, шулай ук бүрәнә аркылы, кыршау аша шуышып чыгалар, эскәмия астына шуышып керәләр. Яшь ярымнан соң төп хәрәкәтләрдән тыш сабыйларның охшату хәрәкәтләре дә (аю баласына, куян баласына) үсеш кичерә.

Гади хәрәкәтле уеннарда һәм биюләрдә балалар үз хәрәкәтләрен һәм гамәлләрен бер-берсенеке белән яраклаштырырга гадәтләнәләр (катнашучылар саны 8–10 кешедән артмаганда).

Эшчәнлекнең төрле төрләрендә **сиземләү тәҗрибәсе баетыла.** Предметлар белән танышу процессында бала аларның формалары атамаларын (шакмак, кечкенә кирпеч, шар, «түбә» — призма) ишетә, бер үк вакытта аларны өйрәнә, физик сыйфатларын ачыклый: предметны сыпыра-сыйпый, бармакларын аның контуры буйлап йөртә, шакый-шакылдата, ыргыта һ.б. Шул үк вакыт-

та ул төп фигуралар (квадрат, турыпочмаклык, түгәрәк, өчпочмак) белән дә таныша. Өлкән кеше ярдәмендә бала бер үк атамалы предметлар арасындагы охшашлыкларны һәм аерымлыкларны билгеләргә өйрәнә (зур кызыл туп — кечкенә зәңгәр туп, зур ак аю баласы — кечкенә кара аю баласы һ.б.).

Өйрәнгәндә һәм уен материалын дөрес сайлаганда, балалар төрле уенчыклар — җыелма (пирамидалар, матрешкалар һ.б.) һәм сюжетлы уенчыклар (атрибутлы курчаклар, аю балалары), төзелеш материалы белән төрле гамәлләр кылуны үзләштерәләр. Бу гамәлләрне бала өлкән кеше күрсәткәннән соң кабатлый.

Акрынлап аерым гамәлләрдән «чылбырлар» оеша, сабый предметлы шөгыльләрне ахыргача җиткерергә өйрәнә: төсләре һәм зурлыклары буенча сайлап алып, тишекле түгәрәкләр белән бөтен пирамиданы җыеп бетерә, үрнәк буенча, шуннан соң хәтергә таянып, төзелеш материалыннан койма, паровоз, манара һ.б. катлаулы булмаган корылмалар төзи.

Сюжетлы уенчыклар белән эш итүдә дә зур үзгәрешләр бара. Алар бер уенчык (курчак) белән өйрәнелгән гамәлне башка уенчыкларга (аю балалары, куян балалары) күчерә башлыйлар; алар актив рәвештә гамәлне төгәлләү өчен кирәкле предметны (курчакны йокларга яткыру өчен юрган, аю баласын ашату өчен савыт) эзлиләр.

Бер-бер артлы 2–3 гамәлне башкарганда, балалар башта моның тормышта ничек булуына ориентлашмыйлар: мәсәлән, йоклаучы курчакны кинәт машинада йөртә башлыйлар. Ике яшь тулганда инде уен гамәлләрендә алар өчен гадәти тормыш эзлеклелеге чагыла: курчакны һавада йөрткәннән соң, аны ашаталар һәм йокларга яткыралар.

Балалар сюжетлы уенчыклар белән көнкүрештәге гамәлләрне мәктәпкәчә чорның бөтен дәвамында башкаралар. Ләкин шул ук вакытта 3–5 яшьлек балалар һәм өлкәнрәкләр һәр гамәлдән «күпбуынлы ритуал» ясыйлар. Ашату алдыннан курчакның кулларын юдыралар, салфетка бәйлиләр, ботканың кайнар булу-булмавын тикшерәләр, кашыктан ашаталар, чынаяктан эчертәләр. Яшәешнең икенче елында боларның берсе дә юк. Бала бары тик савытны курчак авызы янына китерә. Башка ситуациядә дә ул шулай итә. Сюжетлы уенчыклар һәм аларга карата атрибутлар сайлау гадилеге әлеге үзенчәлекләр белән аңлатыла.

Яшәешнең икенче елында аерым гамәлләрдән мәктәпкәчә балачакка хас эшчәнлек элементлары (предметлы уен, конструктив һәм сюжетлы уен) оеша. Предметлы эшчәнлектә тәңгәлләштерүче эш коралы кулланыла торган гамәлләр барлыкка килә.

Предметлы-уен эшчәнлегендәге уңышлар бу эшчәнлекнең тотрыксызлыгы белән чиратлаша. Күз уңына эләккән теләсә кайсы предмет янына бару мөмкин булганлыктан, бала кулындагы әйберне ташлый һәм шул предмет янына омтыла. Өлкән кеше ярдәмендә ул, нәтиҗәгә ирешү өчен, тора-бара башлаганны ахыргача җиткерергә өйрәнә.

Яшәешнең икенче елы — **сөйләмнең интенсив формалашу чоры.** Предмет, гамәл һәм аларны белдерүче сүзләр арасындагы бәйләнешләр яшәешнең беренче елы ахырындагыга караганда 6–10 тапкыр тизрәк формалаша.

Балалар предметларның, гамәлләрнең исемнәрен, кайбер сыйфатларның һәм халәтләрнең аталышларын үзләштерәләр. Шуның нәтиҗәсендә сабыйларның эшчәнлеген һәм үз-үзләрен тотышларын оештырырга, аңга кабул итүне, шул исәптән сиземләү аша кабул итү нигезен хасил итүче сыйфатларны формалаштырырга һәм камилләштерергә мөмкин.

Өлкәннәр белән бергә төрле эшчәнлек процессында балалар бер үк төрле гамәлнең төрле предметларга карата ярашырга мөмкин булуын үзләштерәләр («башлыкны ки, пирамидага боҗралар (түгәрәкләр) кидер» һ.б.). Яшәешнең икенче елында формалашучы гомумиләштерү сәләте сөйләмнең һәм фикерләүнең мөһим казанышы булып тора. Бала аңында сүз, бер предмет белән генә ассоциацияләшеп калмыйча, төсләрендә, зурлыкларында һәм хәтта тышкы кыяфәтләрендә аермалар булуга карамастан, шул төркемгә кергән барлык предметларны белдерә башлый (зур һәм кечкенә, ялангач һәм киенгән курчак, малай курчак һәм кыз курчак). Ел башында берәр төрле предметны күрсәтергә кушканда сабый очраклы, мөһим булмаган билгеләргә ориентлашкан булса, хәзер инде гомумиләштерү сәләте балаларга рәсемдә күрсәтелгән предметларны танырга мөмкинлек бирә. Элек, мәсәлән, «кх» сүзе белән сабый песине дә, мехлы яканы да белдерергә мөмкин иде.

Сабый предметлар арасында төрле бәйләнешләр булуына, өлкәннәрнең һәм балаларның төрле хәлләрдә һәм шартларда эш итүләренә күнегә, шуңа күрә сюжетлы сәхнәләштерүләр (уенчыклар, курчак һәм өстәл театры персонажларын күрсәтү) аның өчен аңлаешлы була.

Шундый күрсәтүләр, кызыксынып күзәтү вакытында алган тәэсирләр хәтердә саклана. Шуңа күрә яшь ярымнан өлкәнрәк балалар үз тәҗрибәләренә бәйле күптән түгел булган вакыйгалар яки әйберләр турында өлкән кеше белән диалог-истәлек алып барырга сәләтле («Кем йөргән?» — «Нәрсә күргәннәр?» — «Көчекне». — «Кемгә ярма бөртекләре ашатканнар?» — «Кошчыкка».

Ел дәвамында актив сүзлек тигезсез рәвештә арта. Яшь ярымлык вакытта ул 20–30 сүз чамасы тәшкил итә. 1 ел 8–10 айдан соң сикереш күзәтелә, актив кулланыштагы сүзлек үсә. Ул сүзлектә фигыльләр һәм исемнәр күп була, гади сыйфатлар һәм рәвешләр (монда, тегендә, шунда һ.б.), шулай ук бәйлекләр очрый.

Гадиләштерелгән сүзләр (ту-ту, ау-ау һ.б.) гадәти, фонетик яктан камил булмаган сүзләр белән алыштырыла. Яшь ярымнан соң бала сүзнең контурын (төрле сандагы иҗекләр) ешрак куллана, аны ишетелүче сүзнең яңгырашына азмы-күпме якын алмаш авазлар белән тутыра.

Бу яшьтә өлкән кеше артыннан кабатлап, әйтелешне яхшырту омтылышлары уңыш китерми. Бу фәкать яшәешнең өченче елында гына мөмкин була. Яшь ярымнан соң күпчелек очракларда бала ирен-ирен авазларын (п, б, м), алгы аңкау-тел (т, д, н), арткы аңкау-тел (г, х) авазларын дөрес әйтә. Бала кулланган сүзләрдә сызгырулы, чыжылдаучы һәм сонор авазлар, шулай ук кушылма фонемалар бик сирәк очрый.

Башта бала әйткән сүз тулы бер җөмләне аңлата. Мәсәлән, «ап итте» сүзләре бер очракта — сабыйның уенчыкны төшереп җибәрүен, башка очракта аның егылуын һәм бәрелүен белдерә.

Яшь ярымга җиткәндә, балалар сөйләмендә ике сүзле җөмләләр барлыкка килә, икенче ел ахырында өч, дүрт сүзле җөмләләр куллану гадәти күренешкә әверелә.

Яшь ярымнан өлкәнрәк бала актив рәвештә өлкәннәргә сораулар бирә. Сорауларны ул башлыча интонация рәвешендә белдерә («Гү әм?» — «Гүзәл ашадымы?»). Сорау сүзләрен балалар сирәгрәк куллана, алар «Яулык кайда?», «Әби кая китте?», «Бу нәрсә?» дип сорарга мөмкин.

Балалар өлкәннәрнең кушканын күренерлек, күрсәтмәле шартларда үтәргә өйрәнәләр.

Яшәешнең икенче елында бала үзе көн саен аралаша торган өлкәннәрнең һәм балаларның исемнәрен, шулай ук кайбер туганлык мөнәсәбәтләрен (әни, әти, әби) үзләштерә. Ул «сөенә», «ачулана», «курыкты», «кызгана» сүзләре белән белдерелүче элементар кеше хис-тойгыларын һәм кичерешләрен аңлый. Сөйләмдә бәяләмә фикерләүләр — «начар», «яхшы», «матур» сүзләре барлыкка килә.

**Балаларның мөстәкыйльлеге предметлы-уен эшчәнлегендә һәм үзүзеңә хезмәт күрсәтүдә камилләшә.** Акрынлап сабый теләсә нинди ризыкны мөстәкыйль ашау, юыну һәм кулларын юу сәләтен, пөхтәлек, җыйнаклык күнекмәләрен үзләштерә.

**Якын-тирәлектә ориентлашу киңәя.** Төркем бүлмәсе өлешләренең ничек аталышын (йорт җиһазлары, кием-салым, савыт-саба) белү балага зурларның катлаулы булмаган (бер, ә ел ахырына 2–3 гамәлдән торган) йомышларын үтәргә ярдәм итә. Акрынлап ул үз-үзеңне тотуның «мөмкин», «ярамый», «кирәк» сүзләре белән белдерелүче элементар кагыйдәләрен үтәргә гадәтләнә. Өлкән кеше белән аралашу эшлекле, объектлы-юнәлтелгән асылга ия.

Яшәешнең икенче елында өлкән кеше белән **эшлекле хезмәттәшлек**, төрле сәбәпләр аркасында аның белән аралашу ихтыяҗы ныгый һәм **тирәнәя.** Ике яшь тулганда балалар акрынлап ишарәләр, мимика, тәэсирле сүзтезмәләр теленнән үтенечләрне, теләкләрне, тәкъдимнәрне сүзләр һәм кыска гыйбарәләр белән белдерүгә күчәләр. Шулай итеп, сөйләм өлкән кеше белән аралашуда төп чарага әверелә; бу яшьтә бала якыннары, аңа яхшы таныш кешеләр белән генә теләп сөйләшә.

Яшәешнең икенче елында балалар арасында үзара эмоциональ аралашу тибы саклана һәм үсеш кичерә. Алар мөстәкыйль рәвештә бер-берсе белән (икешәрләп-өчәрләп) элегрәк өлкән кеше ярдәмендә өйрәнелгән уеннарны («Качышлы», «Куышлы») уйныйлар.

Ләкин балаларның үзара аралашу тәҗрибәсе зур түгел, һәм аның нигезе әле формалашмаган. Фаразланган партнер ягыннан аңлашмау очрагы күзәтелә. Бала елап җибәрергә һәм хәтта аны кызганучыга сугарга да мөмкин. Ул үз уенына тыкшынуга каршы актив рәвештә протест белдерә.

Башка бала кулындагы уенчык, янәшә торганына караганда, сабый өчен күпкә кызыклырак. Күршесеннән уенчыкны тартып алып, алга таба нишләргә

белмичә, сабый ул уенчыкны ташлый. Балаларда аралашу теләге юкка чыкмасын өчен, тәрбияче андый фактларга юл куймаска тиеш.

Кагыйдә буларак, көн дәвамында балаларның үзара аралашуы предметлы-уен эшчәнлегендә һәм режим процессларында туа. Предметлы-уен гамәлләре һәм үз-үзенә хезмәт күрсәтү әлегә формалашып кына килгәнгә күрә, аларны башкаруга карата кызыксыну хисен төрле юллар белән сакларга кирәк.

Балаларны «ара дисциплинасы»н сакларга өйрәтәләр, алар башта бер-берсенә комачауламыйча янәшә уйнау һәм эш итү, аннары 2–3 кеше бергә уйнау, төркемдә үз-үзләрен тиешенчә тоту (күршенең тәлинкәсенә үрелмәү, тагын бер бала утыра алсын өчен диванда күчеп утыру, йокы бүлмәсендә шауламау һ.б.) сәләтен үзләштерәләр. Бу очракта алар гади сүзләр («мә» («ал»), «бир», «җибәр», «кирәк түгел» һ.б.) кулланалар.

Һәр сабыйның эшчәнлеген «саклау» фонында бергәләп эш итүне формалаштырырга кирәк. Башта өлкән кешенең әйтеп җибәрүе буенча, ә инде ике яшь тулганда, балалар мөстәкыйль рәвештә бер-берсенә ярдәм итәргә (күршесенә уенны дәвам итү өчен кирәкле предметны (шакмаклар, пирамида өчен түгәрәкләр, курчакка ябарга юрган) алып килү) сәләтле. Әнисенә яки тәрбиячегә охшатып, бер сабый икенчесен «ашатырга, чәчен тарарга» тырыша.

Музыка дәресләрендә сабыйларның парлашып катлаулы булмаган бию хәрәкәтләре башкарулары мөмкин.

Яшәешнең икенче елындагы төп казанышларның берсе итеп төп хәрәкәтләрне, бигрәк тә йөрүне камилләштерүне санарга мөмкин.

Баланың хәрәкәтчәнлеге кайчакта хәтта аңа тыныч дәресләрдә тупланырга комачаулык итә.

Баланың үз-үзен тотышында предметлы-уен халәтенең тиз һәм төрле планлы үсеше күзәтелә, нәтиҗәдә кече яшьтәгеләрнең икенче төркемендә булуларының ахырына балаларда барлык эшчәнлек төрләренең мәктәпкәчә балачак чорына хас компонентлары формалаша.

Сөйләмнең барлык яклары һәм функцияләре тиз үсеш кичерә. Сөйләү сәләтенең элеккечә үк тирәлектәгеләрнең сөйләмен аңлау үсеше темпыннан калышуына карамастан, икенче ел ахырына инде актив сүзлек 200–300 сүздән тора. Сөйләм ярдәмендә баланы оештырырга мөмкин, ә баланың үзенең сөйләме өлкәннәр белән төп аралашу чарасына әверелә.

Бер яктан, тормышның барлык өлкәләрендә баланың мөстәкыйльлеге үсә, икенче яктан — ул төркемдә үз-үзен тоту кагыйдәләрен үзләштерә (башкаларга комачауламыйча янәшәдә уйнау, аңлашылса һәм кыен булмаса — булышу). Болар барысы да киләчәктә уртак уен эшчәнлеген үстерү өчен нигез булып тора.

## Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

Яшәешнең өченче елында балалар мөстәкыйльрәк булалар.

Предметлы эшчәнлек, баланың һәм өлкән кешенең эшлекле хезмәттәшлеге үсеше дәвам итә; аңга кабул итү, сөйләм, үз-үзеңне ирекле тотышның башлангыч формалары, күрсәтмә-гамәли фикерләү камилләштерелә, ел ахырында күрсәтмә-образлы фикерләү нигезләре барлыкка килә.

Предметлы эшчәнлекнең үсеше төрле предметлар белән эш итүнең культуралы ысулларын үзләштерү белән бәйле. Тәңгәлләштерүче һәм эш коралы кулланыла торган гамәлләр камилләштерелә.

Кораллы гамәлләр башкару сәләте, өлкәннәр тарафыннан тәкъдим ителүче, охшату өчен объект кына булып калмыйча **баланың үз активлыгын көйләүче үрнәк** буларак та алга чыгучы модель нигезендә активлыкның натураль формаларын культуралы формаларга үзгәртеп, иреклекне үстерә.

Өлкәннәр белән уртак предметлы эшчәнлек барышында **сөйләмне аңлау үсеше дәвам итә.** Сүз ситуациядән аерыла һәм мөстәкыйль мәгънә ала. Якын-тирәлек чикләрендә ориентлашып, балалар тирәлектәге предметларның атамаларын үзләштерүне дәвам итәләр, өлкәннәрнең телдән әйтелгән йомышларын үтәргә өйрәнәләр.

Аңлаешлы сүзләр саны күпкә арта. Өлкәннәрнең балага мөрәҗәгате нәтиҗәсендә үз-үзеңне тотуны көйләү камилләштерелә, бала күрсәтмәне генә түгел, өлкәннәрнең сөйләвен дә аңлый башлый.

Балаларның сөйләме актив үсеш кичерә. Өч яшь тулганда, алар төп грамматик структураларны үзләштерәләр, кушма һәм иярченле кушма җөмләләр төзергә тырышалар, өлкән кеше белән сөйләшкәндә, асылда барлык сүз төркемнәрен кулланалар. Актив сүзлек чама белән 1500–2500 сүзгә кадәр җитә.

Яшәешнең өченче елы ахырына сөйләм баланың яшьтәшләре белән аралашу чарасына әверелә. Бу яшьтә балаларда эшчәнлекнең яңа төрләре (уен, рәсем ясау, конструкцияләү) формалаша.

Уен процессуаль характерда була, аның төп эчтәлеге — чынбарлыкка якынайтылган предметлар белән башкарулы гамәлләр. **Яшәешнең өченче елы уртасында алмаш предметлар белән гамәлләр киң кулланыла.**

Үз сурәтләү эшчәнлеге барлыкка килү баланың инде **нинди дә булса предметны сурәтләү ниятен формалаштырырга сәләтле булуын** күрсәтә. Кешене «баш-аяк» — түгәрәк һәм аңа тоташкан сызыклар рәвешендә сурәтләү типик булып тора.

Яшәешнең өченче елында күрү һәм ишетү юнәлешләре камилләшә, бу балаларга берничә биремне хатасыз үтәргә мөмкинлек бирә: 2–3 предметтан формасы, зурлыгы һәм төсе буенча аерып сайлау; көйләрне аерып тану; җырлау.

**Ишетеп кабул итү,** барыннан да бигрәк **фонематик ишетү камилләшә.** Өч яшькә җиткәндә, балалар туган телдәге барлык авазларны да кабул итәләр, тик аларны шактый бозып әйтәләр.

Фикерләүнең төп формасы — күрсәтмә-гамәли. Аның төп үзенчәлеге шунда ки: бала тормышында килеп туган проблемалы хәлләр предметлар белән реаль гамәлләр аша чишелә.

Яшәешнең өченче елы ахырына балаларда күрсәтмә-образлы фикерләү яралгылары барлыкка килә. Предметлы уен эшчәнлеге барышында бала үз алдына максат куя, гамәлләренең планын билгели һ.б.

Бу яшьтәге балалар өчен мотивларны төшенеп бетмәү, сүлпәнлек һәм кичереш һәм теләкләренең килеп туган хәлләргә бәйлелеге хас. Балалар яшьтәшләренең эмоциональ халәтенә җиңел кушылып китәләр. Әмма бу чорда **үз-үзен тотуның иреклелегенә дә формалаша башлый.** Ул кораллы гамәлләр һәм сөйләм үсеше белән бәйле. Балаларда горурлык һәм оялу хисләре барлыкка килә, исем һәм җенес белән тиңләштерүгә бәйле үзаң элементлары формалаша башлый. Кече яшь 3 яшьлекләр кризисы белән тәмамлана. Бала үзен өлкәннәрдән аерылып торучы аерым кеше буларак таный. Анда «Мин» образы формалаша. Кризис негативлык, кирелек, зурлар белән аралашу, бозылу һ.б. белән бара. Кризис берничә айдан ике елга кадәр дәвам итәргә мөмкин.

## Кечкенәләр төркеме
## (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

3–4 яшендә бала әкренләп гаилә даирәсе чикләреннән чыга. Аның аралашуы аерым хәлләргә генә бәйле булмый башлый. Өлкән кеше, бала өчен гаилә әгъзасы гына булып калмыйча, билгеле бер иҗтимагый функция йөртүчегә әверелә. Баланың шундый ук функция башкару теләге аны реаль мөмкинлекләре белән каршылыкка китерә. Бу каршылык мәктәпкәчә яшьтә эшчәнлекнең әйдәүче төренә әверелүче уен үсеше аша хәл ителә.

Шартлылык — уенның төп үзенчәлеге; бертөрле гамәлләрне бертөрле предметлар белән башкару аларны башка предметлар белән башкарылучы башка гамәлләргә кертүне күздә тота. Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр уенының төп эчтәлеге уенчыклар һәм алмаш уенчыклар белән эш итүдән гыйбарәт. Уенның дәвамлылыгы зур түгел. Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр бер-ике рольле һәм гади, җәенке булмаган сюжетлы уен белән чикләнәләр. Бу яшьтә кагыйдәле уеннар формалаша гына башлый.

**Баланың сурәтләү эшчәнлеге аның предмет турындагы күзаллауларына бәйле.** Бу яшьтә әлеге күзаллаулар формалаша гына башлыйлар. График образлар ярлы. Бериш балаларның рәсемнәрендә детальләр булмый, башкаларның рәсемнәре күбрәк детальләштерелгән булырга мөмкин. Балалар инде төс кулланырга мөмкин.

**Вак моторика үсеше өчен әвәләп ясау зур әһәмияткә ия.** Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр өлкән кеше җитәкчелегендә гади предметларны әвәләп ясарга сәләтле.

Аппликациянең аңга кабул итү үсешенә уңай йогынты ясавы мәгълүм. Бу яшьтә балалар аппликациянең гади төрләрен башкара алалар.

Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр конструкцияләү эшчәнлеге үрнәк буенча һәм уйланылганча катлаулы булмаган корылмалар төзү белән чикләнә.

Бу яшьтә перцептив эшчәнлек үсеш кичерә. Балалар эталон алды берәмлекләрен (предэталон) — аңга кабул итүнең индивидуаль берәмлекләрен файдаланудан сиземләү эталоннарына — аңга кабул итүнең культура буларак үзләштерелгән чараларына күчәләр. Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр төркеменнән күчү ахырына балалар 5 һәм күбрәк формадагы предметларны, 7 һәм күбрәк төсне кабул итәргә, предметларны зурлыклары буенча аерырга, балалар бакчасы төркемендә һәм, белем бирү процессын билгеле бер тәртиптә оештырганда, бөтен мәктәпкәчә учреждение бинасында да ориентлашырга сәләтле.

Хәтер һәм игътибар үсеш кичерә. Өлкәннәр соравы буенча балалар 3–4 сүзне һәм предметларның 5–6 атамасын истә калдыра алалар. Мәктәпкәчә кечкенәләр яше ахырына алар яраткан әсәрләреннән зур өзекләрне истә калдырырга сәләтле.

Күрсәтмә-гамәли фикерләү үсеше дәвам итә. Ситуацияләрне үзгәртү күп очракларда көтелгән нәтиҗәне исәпкә алып, максатчан сынаулар нигезендә гамәлгә ашырыла. **Мәктәпкәчә яшьтәге балалар предметлар арасындагы кайбер яшерен бәйләнешләрне һәм мөнәсәбәтләрне билгеләргә сәләтле.**

Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләрдә хыял үсеше башлана. Уенда, бер төрле объектлар башкаларын алыштырганда, хыял аеруча ачык чагыла.

Балаларның үзара мөнәсәбәтләре нормалар һәм кагыйдәләр белән бәйле. Максатчан йогынты нәтиҗәсендә балалар чагыштырмача күп санда нормалар үзләштерә алалар, ул нормалар шәхси гамәлләрне һәм башка балаларның гамәлләрен бәяләү өчен нигез хасил итәләр.

Балаларның үзара мөнәсәбәтләре уен эшчәнлегендә ачык чагыла. Актив рәвештә үзара багланышларга керүгә караганда, алар янәшә уйнауга ныграк тартылалар. Шулай да әлеге яшьтә үк үзара мөнәсәбәтләрне тотрыклы рәвештә сайлап кору күзәтелергә мөмкин. Балалар арасындагы низаглар башлыча уенчыклар аркасында килеп чыга. **Баланың яшьтәшләре төркемендәге урыны күп очракта тәрбияче фикере белән билгеләнә.**

Мәктәпкәчә кечкенәләр яшендә чагыштырмача гади ситуацияләрдә үз-үзеңне тоту мотивларының бер үк вакытта бер үк нәрсәгә буйсындырылганлыгын күзәтергә мөмкин. Үз-үзеңне тоту белән аңлы рәвештә идарә итү әле формалаша гына башлый; күпчелек җәһәттә **баланың үз-үзен тотышы ситуацияләргә бәйле.** Шул ук вакытта баланың, телдән бирелгән күрсәтмәләргә кушылып, омтылышларын үзе үк чикләү очракларын күзәтергә мөмкин. Үз-үзеңне бәяләү үсеше башлана, бу очракта балалар күбесенчә тәрбияче бәяләмәсенә ориентлашалар. Шулай ук аларда җенси идентификация үсеше дәвам итә, бу исә сайлап алынган уенчыклар һәм сюжетлар асылында чагылыш таба.

## Уртанчылар төркеме
## (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

Мәктәпкәчә урта яшьтәге балаларның уен эшчәнлегендә үзара рольләр бәйләнешләре барлыкка килә. Бу исә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үзләрен кабул ителгән рольдән аера башлауларын күрсәтә. Уен барышында рольләр алмашынырга мөмкин. Уен гамәлләре балаларның үзләре өчен түгел, уен мәгънәсе өчен башкарыла башлый. Балаларның уендагы һәм чынбарлыктагы арадашлыгы бер-берсеннән аерыла.

Сурәтләү эшчәнлеге шактый зур үсеш кичерә. Рәсем предметлы һәм детальләштерелгән төс ала. Кешенең график сурәте гәүдә, күзләр, авыз, борын, чәчләр, кайбер чакта кием һәм аның детальләре булуы белән сыйфатлана. **Сурәтләү эшчәнлегенең техник ягы камилләшә.** Балалар төп геометрик фигураларны ясый, кәгазьдән кайчы белән кисеп ала, сурәтләрне кәгазьгә ябыштыра алалар һ.б.

Конструкцияләү эшчәнлеге катлаулана. Корылмалар 5–6 детальдән торырга мөмкин. Бала үзе уйлаганча конструкцияләү күнекмәләре, шулай ук гамәлләрнең эзлеклелеген планлаштыру формалаша.

**Баланың хәрәкәтләнү өлкәсе вак һәм эре моториканың позитив үзгәрешләре белән сыйфатлана.** Җитезлек, хәрәкәтләр координациясе үсеш кичерә. Балалар бу яшьтә, үзләреннән кечерәкләргә караганда, тигезлекне яхшырак саклыйлар, кечерәк киртәләр аша атлап чыгалар. Туплы уеннар катлаулана.

Мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең уртанчы төркеменнән күчү ахырына балаларның аңга кабул итүе югарырак баскычка күтәрелә. Балалар теге яки бу предмет охшаган форманы атау сәләтенә ия булалар. Катлаулы объектларда гади формаларны аерып ала һәм гади формалардан катлаулы объектларны торгыза алалар. Балалар предметлар төркемнәрен сиземләнүче билге (зурлык, төс) буенча тәртипкә салырга; биеклек, озынлык һәм киңлек кебек параметрларны аерырга сәләтле.

Тирәлектә ориентлашу камилләшә.

Хәтер күләме үсә. Балалар 7–8 предметның атамасын истә калдыралар. **Ирекле хәтер сәләте үсә башлый:** балалар истә калдыру биремен кабул итәргә сәләтле, өлкәннәр кушкан йомышларны хәтерлиләр, зур булмаган шигырьләр ятлый алалар һ.б.

**Образлы фикерләү үсә башлый.** Балалар, катлаулы булмаган мәсьәләләрне чишү өчен, схемалаштырылган  гади сурәтләр кулланырга сәләтле. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар схема буенча төзи, лабиринт мәсьәләләрне чишә алалар. Алдан күзаллау сәләте үсеш кичерә. Объектларның тирәлектә урнашулары буенча балалар аларның үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә нәрсә булачагын әйтә алалар. Ләкин бу очракта аларга башка күзәтүче позициясенә басу һәм образны эчке планда үзгәртү кыен бирелә.

Әлеге яшьтәге балалар өчен Ж. Пиаженың мәгълүм феноменнары (микъдар, күләм һәм зурлык саклану) хас. Мәсәлән, аларга кара төстәге өч кәгазь

түгәрәк һәм ак төстәге җиде кәгазь түгәрәк тәкъдим итеп, «Нинди түгәрәкләр күбрәк — караларымы әллә акларымы?» дип сорасак, балаларның күпчелеге ак түгәрәкләрнең күбрәк булуын әйтер. Әгәр инде «Кайсы түгәрәкләр күбрәк — акларымы әллә кәгазьдән киселгәннәреме?» дигән сорау куйсак, җавап шундый ук булачак — аклары күбрәк.

Хыял алга таба үсеш кичерә. Аның оригинальлек һәм иреклелек кебек үзенчәлекләре формалаша. Балалар бирелгән темага мөстәкыйль рәвештә әкият уйлап чыгара алалар.

Игътибарның тотрыклылыгы арта. Бала 15–20 минут дәвамында тупланып эшли ала. Ул, ниндидер гамәлләр кылганда, хәтерендә катлаулы булмаган шартны саклап торырга сәләтле.

Мәктәпкәчә урта яшьтә авазларны әйтү һәм дикция яхшыра. **Сөйләм балалар активлыгы предметына әверелә.** Балалар уңышлы рәвештә хайваннар тавышларын охшатып кабатлыйлар, интонация белән теге яки бу персонажларның сөйләмнәрен күрсәтә алалар. Сөйләмнең структурасы, рифмалар аларда кызыксыну уята.

Сөйләмнең грамматик ягы үсеш кичерә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар грамматик кагыйдәләр нигезендә сүзләр иҗат итү белән шөгыльләнәләр. Балалар бер-берсе белән аралашканда, аларның сөйләменә ситуациягә бәйлелек хас, өлкән кеше белән аралашканда, баланың сөйләме ситуациягә бәйсез рәвеш ала.

**Бала һәм өлкән кеше аралашуының эчтәлеге үзгәрә.** Ул баланың конкрет халәте чикләреннән чыга. **Танып белү әйдәүче мотивка әверелә.** Бала аралашу процессында алган мәгълүмат катлаулы һәм аңлау өчен кыен булырга мөмкин, әмма ул аңарда кызыксыну уята.

Балаларда өлкән кеше ягыннан ихтирам ителү ихтыяҗы формалаша, алар өчен аның мактавы аеруча мөһим булып чыга. Бу исә балаларның кисәтүләргә карата артык үпкәләүчәнлегенә китерә. **Артык үпкәләүчәнлек яшь феномены булып тора.**

Яшьтәшләре белән үзара мөнәсәбәтләргә сайланганлык хас, бу бер баланы икенчесенә караганда якынрак итүдә күренә. Уеннар уйнаганда даими партнерлар барлыкка килә. **Төркемнәрдә лидерлар аерылып чыга башлый. Көндәшлек, ярышучанлык барлыкка килә.** Соңгысы үзеңне башкалар белән чагыштыру өчен мөһим, ул «Мин» образының үсешенә, аны детальләштерүгә китерә.

Яшьнең төп казанышлары уен эшчәнлеге үсеше белән, роль һәм чынбарлык арасында үзара бәйләнешләр барлыкка килү килү; сурәтләү эшчәнлеге үсеше; уйлаган буенча конструкцияләү, планлаштыру; аңга кабул итүне камилләштерү, образлы фикерләү һәм хыял үсеше, танып белү позициясенең эгоцентриклыгы; хәтер, игътибар, сөйләм, танып белү ихтыяҗы үсеше; өлкәннәр ягыннан ихтирамга ихтыяҗ формалашу, үпкәләүчәнлек, көндәшлек, яшьтәшләре белән ярышучанлык барлыкка килү; «Мин» образының алга таба үсеше, аны детальләштерү белән бәйләнгән.

## Зурлар төркеме
## (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

Яшәешнең алтынчы елында балалар инде уен башланганчы ук рольләрне бүлә һәм рольгә карап үз-үзләрен тота беләләр. Уендагы үзара бәйләнешләр сөйләм белән бергә бара, эчтәлеге буенча да, интонация ягыннан да алынган рольгә туры килә. Балаларның реаль мөнәсәбәтләре вакытындагы сөйләм рольдәге сөйләмнән аерылып тора. Балалар социаль мөнәсәбәтләрне үзләштерә һәм өлкәннәрнең төрле эшчәнлек төрләрендә позицияләр бәйлелеген аңлый башлыйлар, кайбер рольләр аларны башкаларына караганда ныграк җәлеп итә. Рольләрне бүлгәндә рольдә үз-үзеңне тоту тәртибе субординациясе белән бәйле низаглар да туарга мөмкин. Уен тирәлеген оештыру, анда мәгънәви «үзәк» һәм «периферия» аерылып чыгу күзәтелә. («Хастаханә» уенында андый үзәк — табиб кабинеты, «Чәчтарашханә» уенында — чәч кисү залы, ә көтеп утыру залы уен тирәлегенең периферияce сыйфатында күренә.) Балаларның уеннардагы гамәлләре төрлеләнә.

Балаларның сурәтләү эшчәнлеге үсә. Бу **иң актив рәсем ясау яше.** Ел буена балалар ике меңгә якын рәсем ясарга сәләтле. Рәсемнәр эчтәлеге буенча төрледән төрле булырга мөмкин: бу балаларның тормыш тәэсирләре дә, хыялларындагы вакыйгалар да, фильмнарга һәм китапларга иллюстрацияләр дә. Гадәттә рәсемнәр төрле объектларның схематик сурәтләрен гәүдәләндерәләр, шулай да композиция чишелешенең оригинальлеге белән аерылып торырга, статик һәм динамик мөнәсәбәтләрне чагылдырырга мөмкин. Рәсемнәр сюжетлы төсмер ала; зур булмаган яки, киресенчә, зур үзгәрешләр булган күп тапкырлар кабатланучы сюжетлар шактый еш очрый. Кешене сурәтләү детальләштерелгәнрәк һәм пропорциональрәк була бара. Рәсем буенча сурәтләнгән кешенең кайсы җенескә каравы һәм эмоциональ халәте турында хөкем йөртергә мөмкин.

Конструкцияләү бу эшчәнлек барышындагы шартларны анализлый белү белән сыйфатлана. Балалар агач конструкторның төрле детальләрен файдаланалар һәм атыйлар. Төзү детальләрен кул астындагы материалга бәйле рәвештә алыштырырга мөмкиннәр. **Үрнәкне өйрәнүнең гомумиләштерелгән ысулын үзләштерәләр.** Балалар булачак корылманың төп өлешләрен аерырга сәләтле. **Конструкцияләү эшчәнлеге схема нигезендә, уйлау һәм шартлар буенча тормышка ашырылырга мөмкин.** Конструкцияләү уртак эшчәнлек барышында барлыкка килә.

Балалар кәгазьдән, аны берничә мәртәбә бөкләп (ике, дүрт, алты бөгелеш); табигый материаллардан конструкцияләргә мөмкин. Алар конструкцияләүнең ике ысулын үзләштерә: 1) табигый материалдан — сәнгати образга (бала табигый материалны, аны төрле детальләр белән тулыландырып, бөтенлекле образ дәрәҗәсенә җиткереп «төзеп бетерә»); 2) сәнгати образдан — табигый материалга (бала образны гәүдәләндерү өчен кирәкле табигый материал сайлап ала).

Төсне, форманы һәм зурлыкны; предметларның төзелешен аңга кабул итүнең камилләшүе дәвам итә; балаларның күзаллаулары системалаша.

Алар төп төсләр һәм аларның төсмерләрен генә түгел, арадаш төс төсмерләрен; турыпочмаклыклар, оваллар, өчпочмакларның формаларын да атыйлар. Объектларның зурлыгын билгелиләр, 10 төрле предметны артуга яки кимүгә таба бер рәткә җиңел тезәләр.

Әмма балалар, формалары һәм тирәлектәге урыннары ярашмаган очракта, объектларның тирәлектәге урынын анализлауда кыенлыклар кичерергә мөмкин. Бу ситуацияләрдә аңга кабул итүнең мәктәпкәчә яшьтәгеләр өчен, аеруча аларга бер үк вакытта берничә төрле һәм шуның белән бергә капма-каршы билгеләрне исәпкә алырга туры килсә, билгеле кыенлыклар тудыруы турында дәлилле.

Мәктәпкәчә өлкән яшьтәгеләрдә образлы фикерләү үсеше дәвам итә. Балалар мәсьәләне күрсәтмә планда чишәргә генә түгел, объектны үзгәртеп коруны хәл итәргә, объектларның нинди эзлеклелектә үзара бәйләнешкә керүен күрсәтергә дә һ.б. сәләтле. Әмма моңа охшаш чишелешләр балалар адекват фикерләү чаралары кулланган очракта гына дөрес булып чыгачак. Алар арасында күрсәтмә модельләштерү процессында барлыкка килә торган схемалаштырылган күзаллауларны; объектларга хас билгеләр системасы турында күзаллауларны чагылдыручы комплекслы күзаллауларны, шулай ук төрле объект һәм күренешләрнең үзгәреш стадияләрен чагылдырган күзаллауларны (үзгәреш цикллары турында): ел фасыллары, көн һәм төн алмашу, төрлечә тәэсир итү нәтиҗәсендә объектларның зураюы һәм кечерәюе турында күзаллауларны, үсеш турында күзаллауларны һ.б. аерып күрсәтергә мөмкин. Моннан тыш, **гомумиләштерүләр камилләшә бара, бу сүзле-логик фикерләүнең нигезе булып тора.** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда әле объектларны төркемләү хакында күзаллаулар булмый. Балалар объектларны үзгәрергә мөмкин булган билгеләре буенча төркемлиләр, шул ук вакытта төркемнәрне логик кушу һәм күбәйтү операцияләре формалаша башлый. Мәсәлән, мәктәпкәчә өлкән яшьтәгеләр объектларны төркемләгәндә ике билгене: төсне һәм форма (материал) һ.б. исәпкә алырга мөмкиннәр.

Илебез психологлары тикшеренүләре күрсәткәнчә, мәктәпкәчә өлкән яшьтәгеләр анализлана торган мөнәсәбәтләр аларның үз тәҗрибәсе чикләреннән чыкмаса, фикер йөртергә һәм дөрес аңлатмалар бирергә сәләтле.

Хыял үсеше бу яшьтә балаларга шактый үзенчәлекле һәм үстерелешле вакыйгалар уйлап чыгарырга мөмкинлек бирә. Хыял бары **аны активлаштыру буенча махсус эш алып барылган шартта гына актив үсеш алачак.**

Игътибарның тотрыклылыгы, аны бүлә һәм башка нәрсәгә күчерә белү үсә. Бәйсез игътибардан тиешле игътибарга күчү күзәтелә.

Сөйләм, шул исәптән аваз юнәлеше, камилләшү дәвам итә. Балалар чыжылдаучы, сызгырулы һәм сонор тартыкларны дөрес әйтә алалар. Фонематик ишетү, сюжетлы-рольле уеннар вакытында шигырь сөйләгәндә һәм көндәлек тормышта сөйләмнең интонацион тәэсирлелеге үсә бара.

Сөйләмнең грамматик төзелеше камилләшә. Балалар гамәлдә барлык сүз төркемнәрен кулланалар, актив рәвештә сүзләр ясау белән шөгыльләнәләр. Лексика байый: синоним һәм антонимнар актив кулланыла.

Бәйләнешле сөйләм үсә. Балалар, картина буенча сөйләгәндә, төп вакыйга-предметларга гына түгел, детальләргә дә игътибар бирәләр.

Әлеге яшь казанышларына уен эшчәнлегендә рольләрне бүлү; уен тирәлеген структуралаштыру; югары нәтиҗәлелек белән аерылып торучы сурәтләү эшчәнлегенең алга таба үсеше; конструкцияләүдә үрнәкне өйрәнүнең гомумиләштерү ысулын куллану; бер формадагы предметларны сурәтләүнең гомумиләштерелгән ысулларын үзләштерү хас.

Бу яшьтә аңга кабул итү объектларның катлаулы формаларын анализлау белән билгеләнә; фикерләү үсеше фикерләү чараларын үзләштерү белән бергә бара (схемалаштырылган күзаллаулар, комплекслы күзаллаулар, үзгәрешләрнең цикллылыгы турында күзаллаулар); гомумиләштерү сәләте, сәбәпле фикерләү, хыял, бәйсез игътибар, сөйләм, «Мин» образы үсә бара.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Сюжетлы-рольле уеннарда мәктәпкә әзерлек төркемендәге балалар кешеләр арасындагы характерлы тормышчан хәлләрне чагылдырган, мәсәлән, туй, бала туу, авыру, эшкә урнашу һ.б. катлаулы үзара бәйләнешләрне үзләштерә башлыйлар.

**Балаларның уен гамәлләре катлаулырак була бара,** өлкән кешегә һәрвакытта да анык булмаган үзенә бер төрле мәгънә ала. Уен тирәлеге катлаулана. Бу тирәлектә һәрберсе үз сюжет сызыгын алып барган берничә үзәк булырга мөмкин. Шул ук вакытта балалар бөтен уен тирәлегендәге партнерларының үз-үзләрен тотышын күзәтергә һәм, шул үз урыннарына бәйле рәвештә, үзләре үк үз-үзләренең тотышын үзгәртергә сәләтле. Мәсәлән, бала инде сатучыга гади сатып алучы булып кына түгел, ә сатып алучы-әни яки сатып алучы-шофер һ.б. буларак мөрәҗәгать итә. Рольнең башкарылуына рольнең үзе тарафыннан гына түгел, рольнең уен тирәлегенең кайсы өлешендә гәүдәләндерелүе белән дә басым ясала. Мәсәлән, автобус йөртүче ролен башкарганда, бала пассажирлар белән җитәкчелек итә һәм ЮХИДИ инспекторына буйсына. Әгәр уен логикасы яңа рольнең барлыкка килүен таләп итсә, бала, элеккеге ролен саклап, уен барышында үзенә яңа роль алырга мөмкин. Балалар уенда теге яки бу катнашучыга рольнең башкарылуын шәрехли алалар.

Сурәтләү эшчәнлегендә балалар тарафыннан чагылдырылучы әйләнә-тирә тормыштан һәм әдәби әсәрләрдән китерелгән образлар катлаулана бара. **Рәсемнәр тагын да детальләштерелгәнрәк рәвеш ала, аларның төсләр гаммасы баетыла.** Малайлар һәм кызлар ясаган рәсемнәр арасындагы аерымлыклар ачыграк күренә. Малайлар бик теләп техниканы, космосны, сугыш хәрәкәтләрен һ.б. ны сурәтлиләр. Кызлар гадәттә хатын-кыз образларын — принцессаларны, балериналарны, модельләрне һ.б. ны рәсемгә төшерәләр. Көнкүреш сюжетлары да (әни һәм аның кызы, бүлмә һ.б.) еш очрый.

Кешене сурәтләү детальләштерелгәнрәк һәм пропорциональрәк төс ала. Кулларда бармаклар, күзләр, авыз, борын, кашлар, ияк барлыкка килә. Кием төрле детальләр белән бизәлергә мөмкин.

Дөрес педагогик караш булганда, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сурәтләү эшчәнлегендә иҗади-нәфис сәләтләр формалаша.

Мәктәпкә әзерлек төркеменә кергәндә, балалар шактый дәрәҗәдә төзелеш материалыннан конструкцияләүне үзләштерәләр. Алар сурәтләрне һәм корылмаларны гомумиләштереп анализлау ысуллары белән иркен эш итәләр; төрле детальләрнең төп конструкция үзенчәлекләрен анализлау белән генә чикләнмичә, үзләренә таныш күләмле предметлар белән охшашлык нигезендә детальләрнең формаларын билгелиләр. Ирекле корылмалар симметрияле һәм пропорциональ рәвешкә керә, аларны төзү күрү ориентациясе нигезендә башкарыла.

Балалар кирәкле материалны тиз һәм дөрес сайлыйлар. Алар корылманың нинди эзлеклелектә төзеләчәген һәм төзү өчен кирәкле материалны җитәрлек дәрәҗәдә төгәл күзаллыйлар; **үзләре уйлаганча һәм куелган шартлар буенча төрле катлаулылыктагы корылмалар төзи алалар.**

Бу яшьтә инде балалар **кәгазь битен бөкләүләрнең катлаулы формаларын үзләштерәләр** һәм үз формаларын уйлап чыгара алалар, ләкин аларны моңа махсус өйрәтергә кирәк. **Эшчәнлекнең бу төре** балалар өчен аңлаешлы гына түгел, ул **аларның фәзаи (пространстволы) күзаллауларын тирәнәйтү өчен мөһим.**

Табигый материалдан конструкцияләү катлаулана. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар алдан ниятләп, катлаулы мөнәсәбәтләрне чагылдырырлык, кешеләр һәм хайваннар фигураларын үз эчләренә алган тулы композицияләр тудырырга сәләтле.

Балаларда аңга кабул итү үсеше дәвам итә, ләкин алар берьюлы берничә төрле билгене һәрвакытта да исәпкә ала алмыйлар.

Образлы фикерләү үсә, ләкин үлчәмнәрне чагылдыруда кыенлык кичерелә. Моны балаларга бер туры сызык өстендә урнашмаган тугыз нокта төшерелгән үрнәкне кәгазь битендә күчереп ясарга тәкъдим итеп җиңел тикшерергә мөмкин. Кагыйдә буларак, күчереп ясаганда, балалар нокталар арасындагы араларны дөрес билгеләмиләр: рәсемнәрне бер-берсе өстенә куйганда, бала рәсеменең нокталары үрнәктәге нокталар белән тәңгәлләшми.

Гомумиләштерү һәм фикерләү күнекмәләре үсеше дәвам итә, әмма алар күбесенчә ситуациянең күренеп торган билгеләре белән чикләнә.

Хыял сәләте үсеше дәвам итә, ләкин, зурлар төркеме белән чагыштырганда, бу яшьтә хыял үсешенең акрынаюы күзәтелә. Моны төрле йогынтылар, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларының балалардагы образларның стереотиплылыгына, үзгәрмәүчәнлегенә китерүче тәэсире белән аңлатырга мөмкин.

**Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның игътибарлылык үсеше дәвам итә**, игътибар ихтыяри төс ала. Эшчәнлекнең кайбер төрләрендә ихтыяри туплану вакыты 30 минутка җитә.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда сөйләм, аның аваз ягы, грамматик төзелеше, лексика үсеше дәвам итә. Бәйләнешле сөйләм үсеш кичерә. Балаларның сөйләмнәрендә сүзлекнең баюы һәм шул яшьтә формалашучы гомумиләштерүләрнең үзенчәлеге чагыла. Балалар актив рәвештә гомумиләштерүче исемнәр, синонимнар, антонимнар, сыйфатлар һ.б. куллана башлыйлар.

Дөрес оештырылган белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәсендә балаларда диалогик сөйләм һәм монологик сөйләмнең кайбер төрләре үсеш кичерә.

Мәктәпкә әзерлек төркемендә мәктәпкәчә чор төгәлләнә. Аның төп казанышлары әйберләр дөньясын кеше мәдәнияте предметлары буларак үзләштерү; кешеләр белән позитив аралашу формаларын үзләштерү; җенси идентификация үсеше, мәктәп укучысы позициясе формалашу белән бәйле.

Мәктәпкәчә чор ахырына бала танып белү һәм шәхес үсешенең югары дәрәҗәсенә ирешә, бу аңа киләчәктә мәктәптә уңышлы уку мөмкинлеге бирә.

# Уен эшчәнлеге үсеше

## Төп максатлар һәм бурычлар

Балаларның уен эшчәнлеге өчен шартлар тудыру. Уйный белү сәләтен, уенның үсеш алган мәдәни формаларын булдыру. Балаларда уеннарның төрле төрләренә карата кызыксынуны үстерү. Балаларны төрле яклап тәрбияләү, аларның уенда гармонияле (хисси-рухи, акыл җәһәтендә, физик, сәнгати-эстетик һәм иҗтимагый-коммуникатив) үсеше.

Мөстәкыйльлекне, инициативаны, иҗатны, үзкөйләнү күнекмәләрен үстерү; яшьтәшләргә карата дустанә мөнәсәбәт, бергәләп эш итү, сүз куешу, мөстәкыйль рәвештә низаглы ситуацияләрне хәл итү сәләтен үстерү.

## Психологик-педагогик эш эчтәлеге

### Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

**Сюжетлы-рольле уеннар.** Балаларны яшьтәшләренең уен гамәлләренә карата кызыксыну белдерергә; янәшә уйнарга ярдәм итәргә, бер-berенә комачауламаска өйрәтү.

Бер предмет белән берничә төрле уен гамәле башкарырга һәм таныш гамәлләрне бер объекттан икенчесенә күчерергә; өлкән кеше ярдәмендә сюжет җирлегендә берләштерелгән берничә уен гамәле башкарырга өйрәтү. Балаларның мөстәкыйль рәвештә уен өчен уенчыклар һәм атрибутлар сайлау, алмаш предметлар куллану теләгенә булышлык итү.

Балаларны уенда рольне аңлауга китерү. Рольдә үз-үзеңне тотуның башлангыч күнекмәләрен формалаштыру; сюжетлы гамәлләрне роль белән бәйләргә өйрәтү.

Иҗатның алшартларын үстерү.

**Хәрәкәтле уеннар.** Балаларда тәрбияче белән бергә гади эчтәлекле хәрәкәтле уеннар уйнау теләге үстерү. Кечерәк төркемнәргә берләшеп, бергәләп уйнарга өйрәтү. Хәрәкәтләрне (йөрү, йөгерү, ыргыту, утырып йөрү) үстерүче уеннарны хуплау.

**Театральләштерелгән уеннар.** Персонаж белән аралашуда беренче тәҗрибә (курчак концерт күрсәтә), өлкән кеше белән элемтәләрне киңәйтү (әби авылдагы ишегалдына чакыра) юлы аша театральләштерелгән уенга карата кызыксыну уяту.

Балаларда тавышлы уен-гамәлләргә (терек һәм терек булмаган табигать) карата мөнәсәбәт белдерү, музыкага ияреп, яңгыраучы сүзгә ияреп (кече фольклор формалары әсәрләрендә) охшату теләге уяту.

Персонаж-уенчыклар катнашындагы уенда мөстәкыйльлек, активлык чагылдыруга булышлык итү.

Педагогик театрның театральләштерелгән (өлкәннәр) чыгышларын системалы рәвештә аңга кабул итү өчен шартлар тудыру.

**Дидактик уеннар**[1]. Дидактик материаллар катнашындагы уеннарда балаларның тоемлау тәҗрибәсен баету. Предметларның зурлыгы, формасы, төсе турындагы белемнәрне ныгыту. Төрле зурлыктагы 5–8 боҗрадан (түгәрәктән) пирамида (манара) җыярга, «Геометрик мозаика»ның яссылыклы фигуралары (түгәрәк, өчпочмак, квадрат, турыпочмаклык) нисбәтендә ориентлашырга; дүрт өлештән (киселгән рәсемнәрдән, җыелма шакмаклардан) бербөтен төзергә; бертөрле предметларны сиземләнүче билгеләрнең (төс, форма, зурлык) берсе буенча чагыштырырга, тиңләштерергә, төркемләргә, аларның тәңгәллеген һәм аерымлыгын табарга өйрәтү.

Игътибар һәм хәтер («Нәрсә юкка чыкты?» һ.б.), ишетеп аеру («Бу нәрсә тавышы яңгырый?» һ.б.), сиземләү-тоюлар, температура аерымлыклары («Хикмәтле капчык», «Җылы — салкын», «Җиңел — авыр» һ.б.); кулларның вак моторикасы (төймәләре, каптырмалары, молнияләре, шнурлары һ.б. булган уенчыклар) үсешенә юнәлтелгән дидактик уеннар уздыру.

## Кечкенәләр төркеме (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

**Сюжетлы-рольле уеннар.** Балаларда әйләнә-тирә дөнья темаларына, әдәби әсәр мотивлары (такмазалар, җырлар, әкиятләр, шигырьләр) буенча уеннар уйнауга; аерым гамәлләрне бердәм сюжет сызыгына берләштерү аша балаларның уен тәҗрибәсен баетуга булышлык итү.

Роль сайлау, курчаклар катнашындагы уенда үзара бәйләнешле берничә гамәл башкару (аш әзерләү, табын кору, ашату) сәләтен үстерү. Ике катнашучы (шофер — пассажир, әни — кыз, табиб — авыру кеше) булган сюжетларда үзара мөнәсәбәткә керергә; алмаш уенчыклар катнашындагы индивидуаль уеннарда үзең һәм уенчык өчен роль башкарырга өйрәтү.

Өйрәтүче уеннардан файдаланып, рольдә үз-үзеңне тоту ысулларын күрсәтү.

Балаларның мөстәкыйль рәвештә теге яки бу уен өчен атрибутлар сайлау; уен халәтен җитешмәгән предметлар, уенчыклар белән тулыландыру омтылышларын хуплау.

[1] «Дидактик уеннар» бүлеге «Танып белү» белем бирү өлкәсенең шундый ук бүлеге белән тәңгәл килә һәм биредә бәян итүнең тулылыгы өчен китерелә.

Ярымфункциональ кулланышлы предметлардан файдалану һәм уенчыклар санын арттыру хисабына предметлы уен тирәлеген катлауландыру, баету. Балаларны уеннарда төзелеш материалы (кублар, борыслар, пластиналар), иң гади агач һәм пластмасса конструкторлар, табигый материал (ком, кар, су) кулланырга; алар белән төрлечә эш итәргә (курчаклар өчен тау, күпер, юл төзү; кардан койма, өй әвәләп ясау; суда уенчыклар йөздерү) өйрәтү.

Озакка сузылмаган уртак уенда үзара мөнәсәбәтләр һәм тату булу сәләтен үстерү.

**Хәрәкәтле уеннар.** Хәрәкәтләнү эшчәнлегендә балаларның активлыгын үстерү. Төркемдәге барлык балалар белән уеннар оештыру. Тәгәрәткечләр, автомобильләр, арбалар, велосипедлар белән уйнауны; үрмәләү, шуышу күнекмәләрен үстерүче уеннарны; хәрәкәтләрнең җитезлеген үстерүче, туплы, шарлы уеннарны хуплау.

Эзлекле рәвештә катлаулырак кагыйдәле һәм хәрәкәт төрләрен үзгәртүгә исәпләнгән уеннарны кертә бару.

**Театральләштерелгән уеннар.** Балаларның театральләштерелгән уенга карата кызыксынуын уяту, аны уздыру өчен шартлар тудыру. Өлкәннәр һәм өлкәнрәк балалар көче белән оештырылган уен-тамашаларда һәм курчак спектакльләрендә вакыйга үсешен күзәтү сәләте формалаштыру.

Балаларны персонажларга хас гамәлләрне (кошчыклар очалар, кәҗә бәтие сикергәләп йөгерә) охшатып кабатларга, кешенең эмоциональ халәтен чагылдырырга (мимика, поза, ишарә, хәрәкәт белән) өйрәтү.

Балаларны өстәл театры курчакларын йөртү алымнары белән таныштыру. Хәрәкәтләрне катлаулы булмаган җыр белән тулыландырырга өйрәтү.

Роль символлары буларак, кием элементлары (башлыклар, якалар һ.б.) һәм атрибутлар файдалану теләге уяту.

Җырларның, әкиятләрнең катлаулы булмаган сюжетларына импровизацияләү омтылышын үстерү. Чыгыш ясау өчен урын җиһазлап, курчаклар һәм яшьтәшләр алдында чыгыш ясау теләген уяту.

Театр турындагы әңгәмәләрдә катнашу теләге тудыру (театр — актерлар — тамашачылар, тамашалар залында кешеләрнең үз-үзләрен тотышы).

**Дидактик уеннар.** Балаларның предметларны (2–3 төстәге зур, уртача һәм кечкенә шарлар) төс һәм зурлык буенча сайлау, билгеле бер эзлеклелектә 2–3 төсне чиратлаштырып, зурлыклары буенча кечерәя баручы боҗралардан (түгәрәкләрдән) пирамида җыю сәләтен ныгыту. 4–6 өлештән рәсем җыярга өйрәтү («Безнең савыт-саба», «Уенчыклар» һ.б.).

Уртак дидактик уеннарда балаларны акрынлап катлауланучы кагыйдәләрне үтәргә өйрәтү.

## Уртанчылар төркеме (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

**Сюжетлы-рольле уеннар.** Балалар белән бергә уеннарның сюжетларын үстерү һәм баету эшен дәвам итү; читләтелгән җитәкчелек алымнарын кулланып, балаларны мөстәкыйль рәвештә уен планнары төзүгә китерү.

Тәрбияче белән уртак, 2–3 роль кергән уеннарда балаларның уенда берләшү, рольләрне бүлешү (әни, әти, балалар), уен гамәлләрен башкару, кагыйдәләр һәм уртак уен фикере буенча эш итү сәләтен камилләштерү.

Уен өчен предметлар һәм атрибутлар сайларга өйрәтү.

Сюжетлы-рольле уенда төзелеш материалыннан төзелгән корылмаларны файдалану сәләтен үстерү. Балаларда төрле катлаулы конструкцияле корылмалар (мәсәлән, берничә машина өчен гараж, 2–3 катлы йорт, ике юнәлештә йөрүче автомобильләр һәм поездлар хәрәкәте өчен киң күпер һ.б.) төзү теләге тудыру.

Балаларны нәрсә төзиячәкләре турында сүз куешырга, материалны үзара бүлешергә, гамәлләрне килештерергә һәм уртак тырышлыклар белән нәтиҗәгә ирешергә өйрәтү.

Балалар арасында үзара дуслык мөнәсәбәтләре тәрбияләү, иптәшләрнең мәнфәгатьләре белән исәпләшү сәләтен үстерү.

Балаларның роль сайлауда, план төзү һәм аны гамәлгә ашыруда, атрибутлар файдалануда мөстәкыйль гамәлләр кылу өлкәсен киңәйтү; өлкәннәрнең һөнәри эшчәнлеге турында фикер ияту юлы белән уйнаучыларның социаль мөнәсәбәтләрен үстерү.

**Хәрәкәтле уеннар.** Хәрәкәтләнү активлыгын; җитезлекне, тизлекне, тирәлектә ориентлашуны үстерүне дәвам итү.

Яшьтәшләрнең кечерәк төркеме белән таныш уеннарны оештыруда балаларның мөстәкыйльлеген тәрбияләү.

Кагыйдәләрне мөстәкыйль үтәргә гадәтләндерү.

Уеннарда балаларның иҗади сәләтләрен (уеннарның вариантларын уйлап чыгару, хәрәкәтләрне катнаштыру) үстерү.

**Театральләштерелгән уеннар.** Катлаулырак уен сәләтләрен һәм күнекмәләрен (сәнгати образны аңга кабул итү, персонажларның үсешен һәм үзара мөнәсәбәтләрен күзәтү) үзләштерү юлы белән балаларның театральләштерелгән уеннарга карата кызыксынуын үстерүне һәм аңа булышуны дәвам итү.

Музыкаль, ишетеп һәм күреп кабул ителә торган образларны файдаланып, кирәкле психик сыйфатларны (хыяллану, игътибар, фикерләү), башкару күнекмәләрен (рольгә керү, хыялдагы планда эш итү сәләте), тоемлауларны (мускуллар, хисләр белән) үстерү өчен этюдлар әзерләү.

Балаларны таныш әдәби әсәрләр буенча кечерәк тамашалар уйнарга; образны гәүдәләндерү өчен мәгълүм тәэсир итү чаралары (интонация, мимика, ишарә) кулланырга өйрәтү.

Балаларны роль, сюжет, образны гәүдәләндерү чаралары сайлауда инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәтүгә этәрү; бер үк образ тудыруда эксперимент ясау өчен мөмкинлекләр бирү.

Геройның эмоциональ халәтен кичерергә һәм аңларга, башка персонажлар белән рольләрдә үзара эшчәнлеккә өйрәтү.

Һәр баланың башкарган рольләре исәбен һәм характерын күзәтеп бару юлы белән балаларның театральләштерелгән эшчәнлектә төрле яклап үсешенә булышлык итү.

Тамаша өчен урын, уен материаллары тәкъдим итеп һәм озак вакытлы уенда берничә баланы берләштерү мөмкинлеге тудырып, режиссерлык уены үсешенә ярдәм итү.

Театральләштерелгән уеннарда образлы уенчыклар һәм бибабо, мөстәкыйль рәвештә балчыктан, пластик массадан, пластилиннан әвәләп ясалган фигуралар, киндер-сюрприздан эшләнгән уенчыклар файдаланырга гадәтләндерү.

Эмоциональ-хисси тәҗрибә туплау, балаларның спектакльдә кулланылучы тәэсир итү чаралары комплексын аңлавы өчен педагогик театр (өлкәннәр) мөмкинлекләрен файдалануны дәвам итү.

**Дидактик уеннар.** Предметларны тышкы билгеләре буенча чагыштыру, төркемләү, өлешләрдән (шакмаклар, мозаика, пазллар) бербөтен төзү сәләтен камилләштереп, предметларның үзлекләре турындагы күзаллауларны ныгытуга юнәлтелгән дидактик уеннар уйнарга өйрәтү.

Сизелүче (тактиль) тойгыларны, ишетүне, тәм тоюны камилләштерү («Капшап (тәм буенча, яңгыраш буенча) ачыкла»). Күзәтүчәнлек һәм игътибарны үстерү («Нәрсә үзгәрде?», «Балдак кемдә?»).

Иң гади өстәл-басма уеннары («Домино», «Лото») кагыйдәләрен үзләштерү омтылышын хуплау.

## Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

**Сюжетлы-рольле уеннар.** Балаларның уен ниятләрен һәм сәләтләрен камилләштерү һәм киңәйтү. Сюжетлы-рольле уеннар оештыру теләген формалаштыру.

Уен өчен тема сайлауны хуплау; тирәлекне аңга кабул итүдән, әдәби әсәрләрдән һәм телевизион тапшырулардан, экскурсияләрдән, күргәзмәләрдән, сәяхәтләрдән, походлардан алынган белемнәр нигезендә сюжетны үстерүгә өйрәтү.

Балаларны уен темасын килештерергә; рольләр бүлешергә, кирәкле шартлар тудырырга, уртак гамәлләрнең эзлеклелеге турында сүз куешырга, уртак уенда элемтәләрне җайга салырга һәм көйләргә: сүз куешырга, татулашырга, юл куярга, ышандырырга өйрәтү һ.б. Уен барышында туган низагларны мөстәкыйль хәл итәргә өйрәтү. Балаларның тотрыклы уен берләшмәләрен ныгытуга булышлык итү.

Үз гамәлләреңне партнерлар гамәлләре белән килештерү, уенда рольләрдәге үзара эшчәнлекне һәм үзара мөнәсәбәтләрне саклау сәләтен формалаштыруны дәвам итү. Персонажлар белән рольле һәм сюжетлы уен гамәлләре барышында туган эмоцияләрне үстерү.

Рольләр составын киңәйтү, уен сюжетына тәңгәл рәвештә рольләрнең гамәлләрен һәм үз-үзеңне тотышны килештерү һәм алдагы гамәлләрне фаразлау юлы белән уенны катлауландырырга өйрәтү.

Таныш уенны яңалыклар белән баетуга (өлкән кешенең катнашуы, атрибутиканың үзгәрүе, алмаш предметлар өстәү, яңа роль кертү) булышлык итү.

Үз-үзеңне иҗади яктан күрсәтү; яңа уеннар барлыкка килү һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру.

Балаларны коллектив рәвештә уен өчен кирәкле корылмаларны төзергә, алдагы эшне планлаштырырга, ниятләнгән эшне бергәләп башкарырга өйрәтү. Дәресләрдә үзләштерелгән конструктив сәләтләрне кулланырга өйрәтү.

Уенчыкларны пөхтә итеп, алар өчен билгеләнгән урынга җыештырып кую гадәтен формалаштыру.

**Хәрәкәтле уеннар.** Балаларны мөстәкыйль рәвештә таныш уеннарны оештырырга; ярыш элементлары булган уеннарда катнашырга гадәтләндерүне дәвам итү. Халык уеннары белән таныштыру.

Яшьтәшләр белән мөстәкыйль уеннарда намуслылык, гаделлек тәрбияләү.

**Театральләштерелгән уеннар.** Балаларны актив рәвештә уен гамәлләренә җәлеп итү юлы белән театральләшкән уенга карата кызыксыну үстерүне дәвам итү. Үзеңне төрле рольләрдә сынап карау теләге тудыру.

Балалар алдында перспективалырак (драматургия күзлегеннән) сәнгати бурычлар кую («Син ярлы Көлбикә идең, ә хәзер син гүзәл принцесса», «Бу роль әле беркем тарафыннан да ачылмады»), уен, спектакль өстендә эшләү тактикасын үзгәртү хисабына уен материалын катлауландыру.

Һәр балага чыгыш ясарга әзерләнү, уен процессы уңаеннан үз фикерен белдерү мөмкинлеге биреп, иҗат һәм ышаныч атмосферасы тудыру.

Балаларны, булган барлык мөмкинлекләрне файдаланып, спектакльләр, концертлар әзерләү һәм уздыру өчен иҗат төркемнәре төзергә өйрәтү.

Үз кулларың белән ясалган атрибутларны, костюм детальләрен файдаланып, рольдә үз-үзеңне тоту сызыгын төзергә өйрәтү.

Импровизацияне, рольдә үзеңне иркен хис итү сәләтен хуплау.

Балаларны төрле театральләштерелгән тамашаларга (концерт, цирк уеннары, спектакльләрдән күренешләр күрсәтү) җәлеп итеп, аларның артистлык сыйфатлары тәрбияләү, иҗат потенциалын ачу. Балаларга яшьтәшләре, ата-аналары һәм башка кунаклар алдында чыгышлар ясау мөмкинлеге тудыру.

**Дидактик уеннар.** Балаларны 2–4 кешелек төркемчәләргә берләштереп, дидактик уеннар оештыру; уен кагыйдәләрен үтәргә өйрәтү.

Балаларның хәтерен, игътибарын, хыялын, фикерләвен, сөйләмен, сиземләү сәләтләрен үстерү. Предметларны чагыштырырга, аларның билгеләрендә (төс, форма, зурлык, материал) булган кечкенә аерымлыкларны күреп алырга, предметларны гомуми билгеләре буенча берләштерергә, өлештән бербөтен төзергә (җыелма шакмаклар, мозаика, пазллар), предметларның урнашуындагы үзгәрешләрне билгеләргә (алда, артта, уңда, сулда, астында, өстендә, уртада, янда) өйрәтү.

Төрле дидактик уеннар һәм уенчыклар (халык уенчыклары, электрон, компьютер уеннары) белән эш итү теләге формалаштыру.

Балаларда уен гамәленә карата эмоциональ-уңай мөнәсәбәт тудыру.

Төркемле уеннарда кагыйдәләргә буйсынырга өйрәтү. Иҗади мөстәкыйльлек тәрбияләү. Дустанә мөнәсәбәт, дисциплиналылык кебек сыйфатлар формалаштыру. Уен-ярышларда намуслы көндәшлек культурасы тәрбияләү.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

Балаларда уенның барлык төрләрен оештыруда, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен һәм нормаларын үтәүдә мөстәкыйльлек үстерүне дәвам итү.

Инициатива, оештыру сәләтләрен үстерү.

Коллективизм хисе тәрбияләү.

**Сюжетлы-рольле уеннар.** Уен сюжетына тәңгәл рәвештә балаларны үзләренә төрле рольләр алырга; атрибутлар, конструкторлар, төзелеш материалы кулланырга өйрәтүне дәвам итү.

Балаларда үз уеннарын үзләренчә көйләү, мөстәкыйль рәвештә уен өчен җитенкерәмәгән предметларны (театр уены өчен билетлар, сатып алу өчен акча) сайларга һәм булдырырга өйрәтү.

Уеннарда әйләнә-тирә турындагы күзаллауларны, әдәбият әсәрләре, мультфильмнар турындагы тәэсирләрне иҗади куллануга булышлык итү.

Иҗади хыялны, үзеңнең уен ниятләреңне яшьтәшләрең ниятләре белән килештереп, бергәләп уенны үстерү сәләтен үстерү; сүз куешу, барлык уйнаучыларның гамәлләрен планлаштыру һәм тикшерү сәләтен формалаштыруны дәвам итү.

Хезмәттәшлеккә һәм үзара ярдәмләшүгә нигезләнгән мөнәсәбәтләр формалаштыру. Яхшылык теләү, яшьтәшеңә ярдәм итәргә әзер булу, уен буенча иптәшләреңнең мәнфәгатьләре һәм фикерләре белән исәпләшү, бәхәсләрне гадел хәл итү сәләте тәрбияләү.

**Хәрәкәтле уеннар.** Театральләштерелгән уеннар оештыруда балаларның мөстәкыйльлеген үстерү.

Сәхнәләштерү өчен мөстәкыйль рәвештә әкият, шигырь, җыр сайлау; булачак спектакль өчен кирәкле атрибутлар һәм декорацияләр әзерләү; үзара вазифаларны һәм рольләрне бүлешү сәләтен камилләштерү.

Образны гәүдәләндерүдә иҗади мөстәкыйльлек, эстетик зәвык; артистлык күнекмәләрен үстерү. Тәэсир итү чараларын (поза, ишарәләр, мимика, интонация, хәрәкәтләр) кулланырга өйрәтү.

**Театрга карата мәхәббәт тәрбияләү.** Балаларның театральләштерелгән эшчәнлегендә театрның төрле төрләрен (бибабо, бармак, банка, картинкалар, перчатка, курчак театрлары һ.б.) киң куллану.

Театраль куелышлар, видеоматериаллар карау аша театр культурасы күнекмәләрен тәрбияләү, театр сәнгатенә тарту. Балаларга театр, театр һөнәрләре турында сөйләү.

Театраль тәэсир итү чаралары (яктылык, грим, музыка, сүз, хореография, декорацияләр һ.б.) белән тудырылган сәнгать образларын аңлауга ирешергә өйрәтү.

**Дидактик уеннар.** Балаларны төрле дидактик уеннар уйнарга өйрәтүне дәвам итү (лото, мозаика һ.б.). Уеннар оештыру, алып баручы ролен башкару сәләтен үстерү.

Үз гамәлләрен алып баручы һәм уенның башка катнашучылары гамәлләре белән яраштырырга өйрәтү. Уенда тапкырлыкны, куелган бурычны мөстәкыйль хәл итү сәләтен үстерү.

Балаларны кайбер дидактик уеннар («Шаулавычлар», «Кыштырдавыклар» һ.б.) булдыруга җәлеп итү. Сиземләү сәләтләрен үстерү һәм ныгыту.

Уенда мәктәпкә әзерлек өчен кирәкле сыйфатлар: ирекле тәртип, ассоциатив-образлы һәм логик фикерләү, күзаллау, танып белү активлыгы чагылуга һәм үсүгә булышлык итү.

# 2—7 яшьлек балалар белән эшне комплекслы-тематик планлаштыру үрнәге

## Икенче кече яшьтәгеләр төркеме (2 яшьтән 3 яшькә кадәр)

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| *Балалар бакчасы* (августның 4 нче атнасы — сентябрьнең 1 нче атнасы) | Балаларны балалар бакчасы шартларына җайлаштыру. Балалар бакчасы белән якын-тирәлек буларак таныштыру (төркем бүлмәсе һәм җиһазлары: шәхси шкаф, карават, уенчыклар һ.б). Балалар һәм тәрбияче белән таныштыру. Бакчага, тәрбиячегә, балаларга карата уңай эмоцияләр формалашуга булышлык итү. | |
| *Көз* (сентябрьнең 2–4 нче атналары) | Көз турында элементар күзаллаулар формалаштыру (табигатьтә, кешеләрнең киемнәрендә, балалар бакчасы участогында сезонлы үзгәрешләр). Уңыш җыю, кайбер яшелчәләр, җимешләр, җиләкләр, гөмбәләр турында беренчел күзаллаулар булдыру. Һавада йөргән вакытта балалар белән төрле төстәге яфраклар җыю, аларны карау, формалары һәм зурлыклары буенча чагыштыру. Йорт хайваннары һәм кошлары турында белемнәрен киңәйтү. Урман җәнлекләренең һәм кошларының тәртибендәге көзге үзенчәлекләр белән таныштыру. | «Көз» бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе.<br>Көзге яфракларны җыю һәм коллектив эш әзерләү — җыелган иң матур яфраклардан плакат әзерләү. |
| *Мин дөньяның бер кешесе* (октябрьнең 1–2 нче атналары) | Кеше буларак үзе, кеше гәүдәсенең төп өлешләре, аларның вазифалары турында күзаллаулар формалаштыру. Үз исемен, гаилә әгъзалары исемнәрен белүне ныгыту.Тәрбиячегә исеме һәм атасының исеме белән эндәшү күнекмәсе формалаштыру. Нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар булуы турында беренчел төшенү; сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллаулар формалаштыру. | Ата-аналар белән бергә чәй эчү өстәле әзерләп уздыру. Балаларның фоторәсемнәре белән коллектив плакат әзерләү. «Бездә кем яхшы?» уены. |

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| *Минем өем* (октябрьнең 3нче атнасы — ноябрьнең 2 нче атнасы) | Балаларны туган шәһәре (авылы), аның исеме, объектлары (урам, йорт, кибет, поликлиника); «шәһәр» һөнәрләре (табиб, сатучы, полиция хезмәткәре) белән таныштыру. | «Минем яраткан уенчыкларым» тематик тамаша. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Яңа ел бәйрәме* (ноябрьнең 3 нче атнасы — декабрьнең 4 нче атнасы) | Яңа ел һәм Яңа ел бәйрәме тирәсендә балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив, музыкаль-сәнгати, укулар) оештыру. | Яңа елга багышланган балалар бәйрәме (утренник). |
| *Кыш* (гыйнварның 1 – 4 нче атналары) | Кыш турында элементар күзаллаулар (табигатьтә, кешеләрнең киемнәрендә, балалар бакчасы участогында сезонлы үзгәрешләр) формалаштыру. Йорт хайваннары һәм кошлары турында белемнәрен киңәйтү. Урман җәнлекләренең һәм кошларының тәртибендәге кышкы үзенчәлекләр белән таныштыру. | «Кыш» бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Әниләр көне* (февральнең 1 нче атнасы — мартның 1 нче атнасы) | Гаилә һәм әниләргә, әбиләргә мәхәббәт темасы тирәсендә балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив, музыкаль-сәнгати, укулар) оештыру. | Әниләр бәйрәме |
| *Халык уенчыклары* (мартның 2–4 нче атналары) | Халык уенчыклары мисалында халык иҗаты белән таныштыру. Халык авыз иҗаты (җырлар, такмаклар һ.б.) белән таныштыру. Фольклорны балалар эшчәнлегенең барлык төрләрендә файдалану. | Күңелле уеннар. Халык уенчыгы бәйрәме. |
| *Яз* (апрельнең 1–4 нче атналары) | Яз турында элементар күзаллаулар (табигатьтә, кешеләрнең киемнәрендә, балалар бакчасы участогында сезонлы үзгәрешләр) формалаштыру. Йорт хайваннары һәм кошлары турында белемнәрен киңәйтү. Урман җәнлекләренең һәм кошларының тәртибендәге кышкы үзенчәлекләр белән таныштыру. | «Яз» бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Җәй* (майның 1–4 нче атналары | Җәй турында элементар күзаллаулар (табигатьтә, кешеләрнең киемнәрендә, балалар бакчасы участогында сезонлы үзгәрешләр) формалаштыру. Йорт хайваннары һәм кошлары яшелчәләр, җимешләр, җиләкләр турында белемнәрен киңәйтү. Урман җәнлекләренең һәм кошларының тәртибендәге кышкы үзенчәлекләр белән таныштыру. | «Җәй» бәйрәме. |
| Җәйге чорда балалар бакчасы каникул режимында эшли (июньнең 1 нче атнасы — августның 3 нче атнасы). | | |

# Кечкенәләр төркеме
# (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

| **Чорның интеграцияләүче темасы** | **Педагогик бурычлар** | **Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары** |
|---|---|---|
| *Сау бул, җәй, исәнме, бакча!* (августның 4 нче атнасы — сентябрьнең 1 нче атнасы) | Балаларда балалар бакчасына кайтуга карата шатлык уяту. Балалар бакчасы белән якын-тирәлек буларак таныштыруны дәвам итү: бакча хезмәткәрләренең профессияләре (тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, музыка җитәкчесе, табиб, ишегалды себерүче), предметлы тирәлек, бакчада үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләр. Төркемнең әйләнә-тирә мохите белән, бакча бүлмәләре белән танышуны дәвам итү. Уенчыкларны карарга, аларның формасын, төсен, төзелешен әйтергә тәкъдим итү. Уен вакытында балаларны бер-берсе белән таныштыру (әгәр инде таныш булсалар, бер-берләрен искә төшерергә булышу). Балалар арасында дустанә мөнәсәбәт формалаштыру (коллектив белән сәнгати эш, дуслык турында җыр, уртак уеннар). | Балалар бакчасы хезмәткәрләре ата-аналар белән берлектә оештырган «Балалар бәйрәме». |
| *Көз* (сентябрьнең 2 – 4 нче атналары) | Балаларның көз турында (табигатьтә, кешеләрнең киемнәрендә, балалар бакчасы участогында ), уңыш җыю, кайбер яшелчәләр, җимешләр, җиләкләр, гөмбәләр турында күзаллауларын киңәйтү. Авыл хуҗалыгы һөнәрләре белән (тракторчы, сыер савучы һ.б.) таныштыру.Табигатьтә үз-үзеңне тоту куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән таныштыру. Табигатькә сак караш тәрбияләү. Һавада йөргәндә балаларга көзге яфраклар җыярга һәм аларны карарга тәкъдим итү. Көз турында шигырьләр өйрәнү. Көзге табигатьнең матурлыгын күрә белү сәләтен үстерү, һава торышын күзәтүләр алып барырга өйрәтү. Йорт хайваннары һәм кошлары турында белемнәрен киңәйтү. Урман җәнлекләренең һәм кошларының тәртибендәге көзге үзенчәлекләр белән таныштыру. Көз темасына рәсемнәр, аппликацияләр ясарга һәм әвәләп ясарга теләк уяту. | «Көз» бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |

| Чорның интеграциялəүче темасы | Педагогик бурычлар | Йомгаклау чараларының үрнəк вариантлары |
|---|---|---|
| *Мин һəм минем гаилəм* (октябрьнең 1–2 нче атналары) | Сəламəтлек һəм сəламəт яшəү рəвеше турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру. «Мин» образын формалаштыру. Үзеңнең йөзең һəм тəнең турында кайгырту буенча элементар күнекмəлəр формалаштыру. Үзенең тышкы кыяфəте турында күзаллау тудыру. Гендер күзаллауларын үстерү. Үзенең исемен, фамилиясен, гаилə əгъзаларының исемнəрен атарга телəк уяту, үзе турында беренче затта сөйлəргə өйрəтү. Үз гаилəсе турында күзаллауларын баету. | Сəламəтлек көне.<br>Спорт күңел ачулары. |
| *Минем өем, минем шəһəрем* (октябрьнең 3 нче атнасы — ноябрьнең 2 нче атнасы) | Йорт белəн, йорт кирəк-яраклары, җиһазлар, көнкүреш приборлары белəн таныштыру. Туган шəһəр (авыл), аның атамасы, төп истəлекле урыннары белəн таныштыру. Транспорт төрлəре, шул исəптəн шəһəр транспорты, шəһəрдə үзеңне тоту кагыйдəлəре, элементар юл хəрəкəте кагыйдəлəре, светофор, җир өсте һəм җир асты кичүлəре (ата-аналар белəн үзара бəйлəнеш) белəн таныштыру. «Шəһəр» профессиялəре (милиционер, сатучы, чəч кисүче, табиб, машина йөртүче, автобус шоферы) һөнəрлəре белəн таныштыру. | Юл хəрəкəте кагыйдəлəре буенча сюжетлы-рольле уен. |
| *Яңа ел бəйрəме* (ноябрьнең 3 нче атнасы — декабрьнең 4 нче атнасы) | Балаларның турыдан-туры укыту өлкəсендə дə, мөстəкыйль эшчəнлегендə дə Яңа ел һəм Яңа ел бəйрəме тирəсендə балалар эшчəнлегенең барлык төрлəрен (уен, коммуникатив, хезмəт, танып белү-тикшеренү, продуктив, музыкаль-сəнгати, укулар) оештыру. | Яңа елга багышланган балалар бəйрəме (утренник). |
| *Кыш* (гыйнварның 1–4 нче атналары) | Кыш турында күзаллауларны киңəйтү. Кышкы спорт төрлəре белəн таныштыру. Кышын үз-үзеңне тоту иминлеге турында күзаллау формалаштыру. Су һəм боз белəн экспериментлар ясау барышында тикшеренү һəм танып белү кызыксынуы формалаштыру. Табигатькə сак караш, кышкы табигатьнең матурлыгын күрə белү сəлəтен тəрбиялəү. Табигатьтəге сезонлы үзгəрешлəр турында (һава үзгəрешлəре, кыш көне үсемлеклəр, җəнлеклəр һəм кошларның үз-үзен тотуы) күзаллауларны киңəйтү. Һəрвакыт кыш була торган урыннар турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Балаларның индивидуаль һəм яшь үзенчəлеклəренə туры китереп, турыдан-туры укыту һəм мөстəкыйль эшчəнлекнең төрле төрлəре вакытында алган тəэсирлəре белəн уртаклашу телəге тудыру. | Балалар иҗаты күргəзмəсе.<br>«Кыш» бəйрəме. |

| Чорның интеграциялəүче темасы | Педагогик бурычлар | Йомгаклау чараларының үрнəк вариантлары |
|---|---|---|
| *Ватанны саклаучылар көне* (февральнең 1–3 нче атналары) | Патриотик тəрбияне гамəлгə ашыру. «Хəрби» һөнəрлəр белəн таныштыру. Ватанга мəхəббəт тəрбиялəү. Беренчел гендер күзаллаулары формалаштыру (малайларда көчле, кыю булу, Ватанны саклаучылар булырга омтылу хислəре тəрбиялəү). | Ватанны саклаучылар көненə багышланган бəйрəм. |
| *8 Март* (февральнең 4 нче атнасы — мартның 1 нче атнасы) | Гаилə һəм əнилəргə, əбилəргə мəхəббəт темасы тирəсендə балалар эшчəнлегенең барлык төрлəрен (уен, коммуникатив, хезмəт, танып белү-тикшеренү, продуктив, музыкаль-сəнгати, укулар) оештыру. Тəрбиячелəргə карата хөрмəт тəрбиялəү. | 8 Март бəйрəме. Балалар иҗаты күргəзмəсе, күңел ачулар, коллектив иҗат, балалар уены. |
| *Халык мəдəнияте һəм традициялəре белəн танышу* (мартның 2–4 нче атналары) | Халык уенчыклары турында күзаллауларны киңəйтү (Дымково уенчыгы, матрешка һ.б.). Халык кəсеплəре белəн таныштыру. Халык авыз иҗаты белəн таныштыруны дəвам итү. Фольклорны балалар эшчəнлегенең барлык төрлəрендə файдалану. | Фольклор бəйрəме. Балалар иҗаты күргəзмəсе. |
| *Яз* (апрельнең 1–4 нче атналары) | Яз турында күзаллауларны киңəйтү. Табигатькə сак караш, язгы табигатьнең матурлыгын күрə белү сəлəтен тəрбиялəү. Табигатьтəге сезонлы үзгəрешлəр турында (һава үзгəрешлəре, яз көне үсемлеклəр, җəнлеклəр һəм кошларның үз-үзен тотуы) күзаллауларын киңəйтү. Табигатьтəге иң гади бəйлəнешлəр турында күзаллауларны киңəйтү (җылытты — үлəннəр үсеп чыкты һ.б.). Балаларның яз турында тəэсирлəрен сəнгати эшчəнлекнең төрле төрлəрендə чагылдыру телəге уяту. | «Яз» бəйрəме. Балалар иҗаты күргəзмəсе. |
| *Җəй* (майның 1–4 нче атналары) | Балаларның җəй турында, сезонлы үзгəрешлəр турында (табигатьтəге үзгəрешлəр, кешелəр киемендə, балалар бакчасы участогында) күзаллауларын киңəйтү. Җимеш һəм яшелчə бакчасы үсемлеклəре турында элементар күзаллаулар булдыру. Су һəм ком белəн эксперимент барышында тикшеренү һəм танып белү кызыксынуын формалаштыру. Табигатькə сак караш, җəйге табигатьнең матурлыгын күрə белү сəлəтен тəрбиялəү. | «Җəй» бəйрəме. |
| Җəйге чорда балалар бакчасы каникул режимында эшли (июньнең 1 нче атнасы — августның 3 нче атнасы). | | |

## Уртанчылар төркеме
## (4 яшьтән 5 яшькә кадәр)

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| *Белем көне* (августның 4 нче атнасы — сентябрьнең 1 нче атнасы) | Балаларда танып белү омтылышын, мәктәпкә, китапка кызыксыну үстерү. Балалар арасында дустанә, ягымлы мөгамәлә формалаштыру. Баланы балалар бакчасы белән якын социаль тирәлек буларак таныштыруны дәвам итү (булып узган үзгәрешләргә игътибар юнәлтү: коймa буялган, яңа өстәлләр алынган һ.б.), бакча хезмәткәрләренең һөнәрләре турында күзаллауларны киңәйтү (тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, музыка җитәкчесе, табиб, ишегалды себерүче, аш пешерүче һ.б.). | Балалар бакчасы хезмәткәрләренең ата-аналар белән берлектә оештырылган «Белем көне» бәйрәме. Балалар бәйрәмне әзерләмиләр, әмма конкурсларда, викториналарда актив катнашалар, үзләренең сәләтләрен күрсәтәләр. |
| *Көз* (сентябрьнең 2–4 нче атналары) | Балаларның көз турында күзаллауларын киңәйтү. Терек һәм терек булмаган табигать күренешләре арасында иң гади бәйләнешләр булдыру сәләтен үстерү (суытты — күбәләкләр юкка чыкты, чәчәкләр коелды һ.б.), сезонлы күзәтүләр алып бару. Авыл хуҗалыгы һөнәрләре, урманчы һөнәре турында күзаллауларны киңәйтү. Яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр турында (җирле, экзотик) белемнәрне киңәйтү. | «Көз» бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Халык мәдәнияте һәм традицияләре белән танышу* (мартның 2–4 нче атналары) | Халык уенчыклары турында күзаллауларны киңәйтү (Дымково уенчыгы, матрешка һ.б.). Халык кәсепләре белән таныштыру. Халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Фольклорны балалар эшчәнлегенең барлык төрләрендә файдалану. Табигатьтә үз-үзеңне тоту куркынычсызлыгы кагыйдәләре турында күзаллауларны киңәйтү. Табигатькә сак караш тәрбияләү. Элементар экологик күзаллаулар формалаштыру. | Фольклор бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Мин дөньяның бер кешесе* (октябрьнең 1–3 нче атналары) | Сәламәтлек һәм сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллауларны киңәйтү. Балаларның үз гаиләсе турында күзаллауларын киңәйтү. Гаиләдә туганлык мөнәсәбәтләре турында (ул, кыз, әти, әни һ.б) беренче күзаллаулар формалаштыру. Үзенең исемен, фамилиясен, яшен; әти-әнисенең исемен белүен ныгыту. Баланың әти-әнисенең һөнәрләре белән таныштыру. Якын өлкәннәр хезмәтенә карата хөрмәт тәрбияләү. | Сәламәтлек көне. |

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| | Үз-үзенә уңай бәя, «Мин» образын формалаштыру (һәр балада мөмкин булган кадәр еш аның яхшы булуы, аны яратулары хакында ышаныч формалаштыруга ярдәм итү). Үзенең тышкы кыяфәте турында күзаллауларны үстерү.<br>Якын кешеләренең хәленә керә белү тәрбияләү, олы туганнарына карата ихтирамлы, кайгыртучан мөнәсәбәт формалаштыру. | |
| *Минем шәһәр, минем ил*<br>(октябрьнең 4 нче атнасы — ноябрьнең 2 нче атнасы) | Туган шәһәр (авыл) белән таныштыру. Туган як, аның тарихы һәм мәдәнияте турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру. Туган якка мәхәббәт тәрбияләү.<br>Транспорт төрләре һәм аларның үзенчәлекләре турында күзаллауларны киңәйтү. Шәһәрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, элементар юл хәрәкәте кагыйдәләре турында күзаллауларны киңәйтү. Һөнәрләр хакында күзаллауларны киңәйтү. Россияне данга күмгән кайбер күренекле кешеләр белән таныштыру. | Спорт бәйрәме. |
| *Яңа ел бәйрәме*<br>(ноябрьнең 3 нче атнасы — декабрьнең 4 нче атнасы) | Яңа ел һәм Яңа ел бәйрәме тирәсендә балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив, музыкаль-сәнгати, укулар) оештыру. | «Яңа ел» бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Кыш*<br>(гыйнварның 1–4 нче атналары) | Балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү. Терек һәм терек булмаган табигать күренешләре арасында иң гади бәйләнешләр булдыру күнекмәләрен үстерү. Сезонлы күзәтүләр алып бару сәләтен, кышкы табигатьнең матурлыгын күрә белү, аны рәсемнәрдә, әвәләп ясауда чагылдыру күнекмәләрен үстерү. Кышкы спорт төрләре белән таныштыру. Кышын кешеләрнең үз-үзләрен куркынычсыз тоту кагыйдәләре турында күзаллау формалаштыру. Су һәм боз белән экспериментлар ясау барышында тикшеренү һәм танып белү кызыксынуы формалаштыру. Кар һәм бозның үзлекләре турында белемнәрне ныгыту.<br>Һәрвакыт кыш була торган урыннар турында, Арктика һәм Антарктикада яшәүче хайваннар турында күзаллауларны киңәйтү. | «Кыш» бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
| --- | --- | --- |
| *Ватанны саклаучылар көне* (февральнең 1–3 нче атналары) | Балаларны «хәрби» һөнәрләр (солдат, танкист, очучы, диңгезче, чик сакчысы); хәрби техника (танк, самолет, хәрби крейсер); Россия флагы белән таныштыру. Ватанга мәхәббәт тәрбияләү. Гендер тәрбиясен гамәлгә ашыру (малайларда көчле, кыю булу, Ватанны саклаучылар булырга омтылу хисләре тәрбияләү; кызларда малайларга карата, киләчәктә Ватанны саклаучылар буларак, хөрмәт тәрбияләү). Баһадирлар турында риваятьләр аша тарихка тарту. | Ватанны саклаучылар көненә багышланган бәйрәм.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *8 Март* (февральнең 4 нче атнасы — мартның 1 нче атнасы) | Гаилә һәм әниләргә, әбиләргә мәхәббәт темасы тирәсендә балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив, музыкаль-сәнгати, укулар) оештыру. Тәрбиячеләргә, балалар бакчасының башка хезмәткәрләренә карата хөрмәт тәрбияләү.<br>Гендер күзаллауларын киңәйтү. Балаларны әниләренә, әбиләренә, тәрбиячеләргә бүләкләр әзерләүгә җәлеп итү. | 8 Март бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Халык мәдәнияте һәм традицияләре белән танышу (мартның 2–4 нче атналары) | Халык уенчыклары турында күзаллауларны киңәйтү (Дымково уенчыгы, матрешка һ.б.). Халык кәсепләре белән таныштыру. Балаларны Дымково һәм Филимоново бизәген өйрәнүгә җәлеп итү. Халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Фольклорны балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен оештырганда файдалану. | Фольклор бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Яз* (апрельнең 1–4 нче атналары) | Балаларның яз турында күзаллауларын киңәйтү. Терек һәм терек булмаган табигать күренешләре арасында иң гади бәйләнешләр булдыру күнекмәләрен үстерү, сезонлы күзәтүләр алып бару.<br>Табигатьтә үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләре турында күзаллауларын киңәйтү. Табигатькә сак караш тәрбияләү. Элементар экология күзаллауларын формалаштыру.Язын җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчасында башкарыла торган эшләр турында күзаллаулар формалаштыру. Балаларны балалар бакчасындагы участокта, чәчәклектә көчләреннән килердәй эшләргә җәлеп итү. | «Яз» бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| *Җиңү көне* (апрельнең 4 нче атнасы — майның 1 нче атнасы) | Патриотик тәрбияне гамәлгә ашыру. Туган илгә мәхәббәт тәрбияләү. Җиңү көненә багышланган бәйрәм турында күзаллаулар формалаштыру. Сугыш ветераннарына карата хөрмәт тәрбияләү. | Җиңү көненә багышланган бәйрәм. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Җәй* (майның 1–4 нче атналары) | Балаларның җәй турында күзаллауларын киңәйтү. Терек һәм терек булмаган табигать күренешләре арасында иң гади бәйләнешләр булдыру күнекмәләрен үстерү, сезонлы күзәтүләр алып бару. Җәйге спорт төрләре белән таныштыру. Урманда куркынычсызлык иминлек тәртибе турында күзаллаулар формалаштыру. | «Җәй» бәйрәме.<br>Спорт бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Җәйге чорда балалар бакчасы каникул режимында эшли (июньнең 1 нче атнасы — августның 3 нче атнасы). | | |

## Зурлар төркеме (5 яшьтән 6 яшькә кадәр)

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| *Белем көне* (августның 3–4 нче атналары) | Балаларда танып белү омтылышларын, мәктәпкә, китапка карата кызыксыну үстерү. Балалар арасында дустанә, ягымлы мөгамәлә формалаштыру. Баланы балалар бакчасы белән якын социаль тирәлек буларак таныштыруны дәвам итү (булып узган үзгәрешләргә игътибар юнәлтү: койма буялган, яңа өстәлләр алынган), бакча хезмәткәрләренең һөнәрләре турында күзаллауларны киңәйтү (тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, музыка җитәкчесе, табиб, ишегалды себерүче, һ.б.). | «Белем көне» бәйрәме. |
| *Көз* (сентябрьнең 1–4 нче атналары) | Көз турында күзаллауларны киңәйтү. Авыл хуҗалыгы һөнәрләре белән таныштыруны дәвам итү. Табигатьтә үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләре турында белемнәрне ныгыту. Көз турында ел фасылы буларак, үсемлекләр һәм хайваннарның табигатьтәге үзгәрешләргә җайлашуы, табигать күренешләре турында гомумиләштерелгән күзаллаулар формалаштыру. Экосистемалар, табигать зоналары турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Терек булмаган табигать турында күзаллауларны киңәйтү. | «Көз» бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| *Мин сәламәт булып үсәм* (октябрьнең 1–2 нче атналары) | Сәламәтлек һәм сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллауларны киңәйтү. Сәламәт яшәү рәвеше алып баруга омтылыш тәрбияләү. Үз-үзенә уңай бәя формалаштыру. Өй адресын һәм телефонын, әти-әнисенең исемен, һөнәрен белүне ныгыту. Балаларның үз-үзләре, үз гаиләләре турында, әти-әниләренең кайда эшләве, аларның хезмәтенең җәмгыятькә кирәклеге турында белемнәрне киңәйтү. | Сәламәтлек көне. |
| *Халык бердәмлеге көне* (октябрьнең 3 нче атнасы — ноябрьнең 2 нче атнасы) | Туган ил, дәүләт бәйрәмнәре турында күзаллауларны киңәйтү; туган иле тарихы белән кызыксынуны үстерү; Ватан өчен горурлык, аңа мәхәббәт хисләре тәрбияләү. Россия тарихы, гербы һәм флагы, гимн көе белән таныштыру. Россияне данлаган кешеләр, Россиянең күпмилләтле ил булуы, Мәскәүнең илебез башкаласы булуы турында сөйләү. | Халык бердәмлеге көне бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Яңа ел* (ноябрьнең 3 нче атнасы — декабрьнең 4 нче атнасы) | Балаларны бәйрәмне әзерләүдә һәм аны уздыруда актив катнашырга җәлеп итү. Коллектив белән бәйрәм алды эшчәнлегенә катнашудан канәгатьләнү хисе барлыкка килүгә булышу. Бәйрәм культурасы нигезләрен салу. Бәйрәмгә карата уңай эмоциональ мөнәсәбәтне, аны әзерләүдә актив катнашу теләген үстерү. Якыннарын бәйрәм белән котлау, үз кулы белән ясаган бүләкләр бирү омтылышын хуплау. Төрле илләрдә Яңа ел бәйрәме традицияләре белән таныштыру. | Яңа ел бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Кыш* (гыйнварның 1–4 нче атналары) | Кыш белән кышкы спорт төрләре булган ел фасылы буларак таныштыруны дәвам итү. Су һәм боз белән экспериментлар ясау аша беренчел тикшеренү һәм танып белү кызыксынуы формалаштыру. Кышкы табигать үзенчәлекләре (салкыннар, бәс, кар явулар, көчле җилләр), шәһәрдә, авылда кешеләр эшчәнлеге үзенчәлекләре; кышын куркынычсызлык тәртибе турында белемнәрен киңәйтү һәм баету. | «Кыш» бәйрәме.<br>Кышкы олимпиада.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Ватанны саклаучылар көне* (февральнең 1–3 нче атналары) | Балаларның Россия армиясе турында күзаллауларын киңәйтү. Ватанны саклауның авыр, ләкин мактаулы бурыч булуын, аның тынычлыгын һәм иминлеген саклау турында сөйләү; сугыш елларында бабаларыбызның ничек сугышуы һәм илебезне дошманнардан саклап калуы турында сөйләү. | Бәйрәм.<br>23 февраль — Ватанны саклаучылар көне.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| | Балаларны патриотизм, Ватанга мәхәббәт рухында тәрбияләү. Гаскәрләрнең төрләре (җир өсте, диңгез, һава, танк гаскәрләре), хәрби техника белән таныштыру. Гендер күзаллауларын киңәйтү, малайларда көчле, кыю булу, Ватанны саклаучылар булырга омтылу хисләре тәрбияләү; кызларда малайларга карата, киләчәктә Ватанны саклаучылар буларак, хөрмәт тәрбияләү). | |
| *Халыкара хатын-кызлар көне* (февральнең 4 нче атнасы — мартның 1 нче атнасы) | Гаилә, әниләргә, әбиләргә мәхәббәт темасы тирәсендә балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив, музыкаль-сәнгати, укулар) оештыру. Тәрбиячеләргә карата хөрмәт тәрбияләү. Гендер күзаллауларын киңәйтү, малайларда ир-атларның хатын-кызларга карата игътибарлы һәм ихтирамлы булырга тиешлеге турында күзаллаулар формалаштыру. Балаларны әниләренә, әбиләренә, тәрбиячеләргә бүләкләр ясарга җәлеп итү. Иң якын кешеләргә карата сак һәм игътибарлы мөнәсәбәт, аларны яхшы гамәлләр белән сөендерү хисе тәрбияләү. | 8 Март бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Халык мәдәнияте һәм традицияләре* (мартның 3–4 нче атналары) | Балаларны халык традицияләре һәм йолалары, халык гамәли бизәлеш сәнгате (Городец, Полхов-Майдан, Гжель) белән таныштыруны дәвам итү. Халык уенчыклары турында күзаллауларны киңәйтү (Городец, Богородское матрешкалары). Милли гамәли бизәлеш сәнгате белән таныштыру. Балаларга йорт һәм башка корылмалар, аларның эчке бизәлеше, көнкүреш предметлары, киемнәр турында сөйләү. | Фольклор бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Яз* (апрельнең 1–2 нче атналары) | Яз турында ел фасылы буларак, үсемлекләр һәм хайваннарның табигатьтәге үзгәрешләргә җайлашуы турында гомумиләшкән күзаллаулар булдыру. Язга хас билгеләр; кошлар килү; терек һәм терек булмаган табигатьтәге күренешләр һәм сезонлы хезмәт төрләре арасындагы бәйләнеш; табигатьтәге язгы үзгәрешләр (кар эри, елгалар ташый, кошлар кайта, үләннәр һәм чәчәкләр кояшлы якта күләгәле якка караганда тизрәк үсеп чыга) турында белемнәрне киңәйтү. | «Яз-матур» бәйрәме. Җир көне — 22 апрель. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| *Җиңү көне* (апрельнең 3 нче атнасы — майның 1 нче атнасы) | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны патриотизм, Туган илгә мәхәббәт рухында тәрбияләү. Бөек Ватан сугышы геройлары, илебезнең сугышта җиңүе турында күзаллауларны киңәйтү. Бөек Ватан сугышы батырларына куелган һәйкәлләр белән таныштыру. | Җиңү көненә багышланган бәйрәм. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| *Җәй* (майның 2–4 нче атналары) | Балаларда җәй турында ел фасылы буларак, җәйгә хас билгеләр турында гомумиләшкән күзаллаулар булдыру. Кешеләр, хайваннар һәм үсемлекләр тормышына җылылык, кояш нурлары тәэсире (табигать «чәчәк ата», бик күп җиләк-җимешләр, яшелчәләр өлгерә; җәнлекләр, кошлар һәм аларның балаларына ашарга җитәрлек); ашарга яраклы һәм агулы гөмбәләр турында күзаллауларны киңәйтү һәм баету. | «Җәй» бәйрәме. Әйләнә-тирә мохитне саклау көне — 5 июнь. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Җәйге чорда балалар бакчасы каникул режимында эшли (июньнең 1 нче атнасы — августның 3 нче атнасы). | | |

## Мәктәпкә әзерлек төркеме (6 яшьтән 7 яшькә кадәр)

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| *Белем көне* (августның 4 нче — сентябрьнең 1 нче атнасы) | Балаларда танып белү кызыксынуын, мәктәпкә, китапка кызыксынуны үстерү. Мәктәп турында, ни өчен укырга кирәклек, мәктәптә кем һәм нәрсәгә өйрәтүе, уку кирәк-яраклары һ.б турында белемнәрне ныгыту. Укытучы һәм «укучы» һөнәрләре турында күзаллаулар, бу эшчәнлек төрләренә карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру. | «Белем көне» бәйрәме. |
| *Көз* (сентябрьнең 2–4 нче атналары) | Көз турында күзаллауларны киңәйтү. Авыл хуҗалыгы һөнәрләре белән таныштыруны дәвам итү. Табигатьтә үз-үзеңне тоту куркынычсызлыгы кагыйдәләре; ел фасыллары, елда айларның эзлеклелеге турында белемнәрне ныгыту. Табигатькә сак караш тәрбияләү. Балаларда көзнең сәнгать әсәрләрендә чагылышы үзенчәлекләре турында күзаллауларны киңәйтү. Көзге күренешләрне рәсемнәрдә, аппликациядә гәүдәләндерүгә кызыксынуны үстерү. Иҗади һөнәрләр турында белемнәрне киңәйтү. | «Көз» бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| *Минем шәһәр, минем ил, минем планета* (октябрьнең 1–2 нче атналары) | Туган як турында күзаллауларны киңәйтү. Балалар яшәгән төбәкнең истәлекле урыннары белән таныштыруны дәвам итү. Туган җиргә мәхәббәт, үз иленең казанышлары белән горурлану хисләре тәрбияләү. Җирнең уртак йортыбыз булуы, андагы бик күп илләр, аларда яшәүче төрле халыклар белән тыныч яшәү, аларның мәдәниятен, йола һәм традицияләрен хөрмәт итү мөһимлеге турында сөйләү. | Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
